# КАЗАН УТЛАРЫ

11
НОЯБРЬ
1978

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**11**
НОЯБРЬ
1978

## Бу санда

ОКТЯБРЬНЫҢ БӨЕК БАЙРАКЧЫСЫ

Л. ХЬЮЗ. Җир шары буйлап. Шигырь . . . . 3
Л. КОНДРАШЕНКО. Ленин. Шигырь . . . . . 3
Я. ДИМОВ. Яз бәйрәме. Шигырь . . . . . . 5
М. ХӨСӘЕН. Бүген дә ул түргә уза. Шигырь . . 6
М. МӘҺДИЕВ. Кеше китә — җыры кала. Повесть 7
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Сузган ике кулым. Шигырь. 70
С. БАТТАЛ. Кышкы урманда төн. Шигырьләр . . 75
Ф. ЯРУЛЛИН. Курку. Хикәя . . . . . . . . . 76
Ш. АНАК. Көн белән саубуллашу. Шигырьләр . 80
М. ГАЛИЕВ. Еллар чалымы. Шигырьләр . . . . 83

«ЗАМАНДАШ» КОНКУРСЫНА

Р. ФӘИЗОВ. Мәдинә. Хикәя . . . . . . . . . 86

ДУСЛАР ИҖАТЫ

БЕРДАХ. Диңгез балыгын бирмәде. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 97

ОЧЕРКЛАР

М. РАФИКОВ. Иделкәйнең ак ташы . . . . . 101
М. МАЛИКОВА. Камчатка ерак та, якын да . . 111

ПУБЛИЦИСТИКА

Р. БӘДЫЙГОВ. Бердәм сафта . . . . . . . . . 120

ИСТӘЛЕКЛӘР

Ә. ЕНИКИ. Хәтердәге төеннәр . . . . . . . 124

ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВКӘ 50 ЯШЬ

Р. КУКУШКИН. Витаминлы шигырьләр . . . . 142

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. МИҢНУЛЛИН. Киләчәк буын хакына . . . . 150

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

**Э. НИГЪМӘТУЛЛИН.** Прозабыз турында уйлану-
лар . . . . . . . . . . . . . . . 161

КИТАП КҮЗӘТҮ

**В. ХАКОВ.** Катлаулы мәсьәләләрне хәл итү
юлында . . . . . . . . . . . . . . . 169

СӘНГАТЬ

**Л. ДОМРАЧЕВА.** Актер шәхесе . . . . . . . 175

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**З. НУРИ.** Нәниләр һәм зурлар. Шигырьләр . . 180
**Ә. ШАМИН.** Эх, Гата, Гата. Парча . . . . . . 183
**Г. ЛУЧ.** Авыл склерозы. Юмореска . . . . . 184
**М. ӘПКӘЛИ.** Балык тотканда. Парчалар . . . . 186

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Тынгысыз әдәбиятчы . . . . . . . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-69, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шәүкәт Галиев**, **Аяз Гыйләҗев**, **Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур**, **Туфан Миңнуллин**, **Рәфыйк Нәфиков**, **Атилла Расих**, **Гали Халит**, **Сибгат Хәким**, **Нил Юзиев**, **Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 17/VII-1978 ел. Басарга кул куелды 18/IX-1978 ел. ПФ 09012. Кәгазь форматы $70 \times 108^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91 000 экз. Заказ В-238. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1978 ел.

## Лэнгстон Хьюз,

Американың негр язучысы

### Җир шары буйлап

Җир шары буйлап юл уза Ленин.
Ул барган якка чик юк, киртә юк —
Дөньяда чөнки Ленин исемле
Кояш чыкмаган якты иртә юк.

Каршылый аны барча кешеләр —
Кара тәнле дә, сары тәнле дә...
Ул салган сукмак — миллионнар юлы,
Ул юл кыен да, ул юл ямьле дә.

Планета буйлап юл уза Ленин.
Дуслар куана, дошман калтырый:
Күгендә җирнең кызыл йолдызның
Нурлары әнә ничек ялтырый!

## Леонард Кондрашенко,

рус шагыйре

### Ленин

*Триптих*

I

**ЛЕНИНГРАДТА ФИНЛЯНДИЯ ВОКЗАЛЫ ЯНЫНДАГЫ ҺӘЙКӘЛ**

Броневикка менеп баскан.
Сөйли.
Ишарәсен
бронза моңы саклый:
Кулын сузган алга юнәлтеп ул.
Ә учында
сүнмәс кояш балкый.

Ул кояшта
мең-мең җир көче бар.
Көйрәт аны, заман,
мәңге көйрәт.

Шул мәңгелек уттан
балкып торсын,
Суынмасын мәңге
бронза сурәт.

Броневикка менеп баскан.
Сөйли —
Үлемсезлегенең гүя
сызып юлын.
Чорлар аша
курыкмый уз син, броня! —
Ди юлбашчы
алга сузып кулын.

2

**ЛЕНИН ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ
ТУЛЫ БАСМАСЫ**

Фикер — диңгез.
Аны давыл айкый,
Дулкын арты
хәтәр дулкын бәреп!
Шулай аңлыйм
Ленин язганны мин,
Укыйм аны
шулай дулкынланып.

Хәрби түгел,
гади пинжәктән ул.
Гасырларны узып атлый күптән.
Җир шарының даһи остазы ул,
Гадилеге аны бөек иткән.

Аның сыйнфы —
илләр, материклар.
Кыю сафка бик-бик күпләр килә.
Ул язган сүз, ул күрсәткән юлны
Планетаның һәр почмагы белә.

Атлаганда
гел яктыны яклап,
Менгән чакта
тормыш үрләренә
Без һәммәбез
шуннан өйрәнәбез
Көрәшү һәм җиңү
һөнәренә.

3

**ҖИР ШАРЫ МӘЙДАННАРЫНДА
ОКТЯБРЬ ДЕМОНСТРАЦИЯСЕ**

Бөтен нәрсә — Ленин.
Ул — һәр төштә.
Барча юлда әйди, өнди Ленин.
Безгә маяк,
безнең байрак булып
Киң галәмгә инде
менде Ленин.

Яктысында аның
        без яктырак,
Һәр офыкта аны күрә күңел.
Аннан башка хәзер планетаның
Яшәве дә
        инде мөмкин түгел.

Бөтен нәрсә — Ленин.
        Ул — һәр төштә.
Барча юлда әйди, өнди Ленин.
Безгә маяк,
        безнең байрак булып
Киң галәмгә инде
        менде Ленин.

Ленин — безнең
        фикер кыйблабыз ул,
Очкыннары кабына
        һәр йөрәктә.
Безнең белән
        мәңге бергә булыр
Һәм хыялда Ленин,
        һәм көрәштә.

**Янко Димов,**
болгар шагыйре

## Яз бәйрәме

Владимир Ильич Ленин,
Туган көнең белән!

Ил өстендә инде
Яз очканын беләм.
Ә күккә бит аны
Син юнәлттең үзең.
Блокнотка шуны
Кичә язган сүзең
Шул йолдызның зурлый
Мәңге сүнмәс көчен —
Бар халыклар җирдә
Ышансыннар өчен.

Владимир Ильич Ленин,
Каплый алмас болыт —
Кояш балкыр күктә
Яз бәйрәме булып.
Канат җәеп күккә
Карый хыял күзе.
Синең туган көнең —
Яз бәйрәме үзе,
Юк, бу очрак түгел,

Бу — иң гадел закон.
Халыклар һәм илләр
Азатлыгы хакын
Яклауларың син,
Мәңгелеккә илтә.
Йөрәкләргә — көч ул!
Ул үлемсез итә!

Зәки Нури тәрҗемәләре.

## Мәхмүт Хөсәен

### Бүген дә ул түргә уза

Урамнарга яуган энҗе карлар
Йолдызларга охшап җемелди.
Соклandырып ак кар йолдызларын,
Кызыл байрак җилдә җилферди.
Кызыл байрак...
Зурлый аны бар як —
Алтмыш ел ул балкый иректә!..
Таң илтте ул —
Октябрьның таңын
Лайнерларда космик киңлеккә.
Безнең байрак Айны алсулата,
Чулпаннарда сибә нурларын.
Ленин үзе космонавтлар белән
Урый гүя галәм кырларын.
Юк, искерми мәңге аның фәне —
Гел җимешле ул Фән, гел яңа.
Ленинизм — безнең байрагыбыз,
Компасыбыз барыр юлларда.
Бүген дә ул түргә уза гүя
Кремльдәге якты зал аша...
Әйтерсең лә безнең белән бергә
Тантанада үзе катнаша.

Мөхәммәт Мәһдиев

# КЕШЕ КИТӘ— ҖЫРЫ КАЛА

ПОВЕСТЬ

## Хисмәт кода судлашып йөрмәде...

Бәхетеңне сыер сөзсә — көтү көткән акчаңны да җыеп ала алмассың, диләр... Өйләнүнең бәла-казасы Шәяхмәт агайның нигезеннән килә. Аларның өй бурасында әйләнмәле бер бүрәнә бар. Хәбирә карчыкның әйтүенчә, бөтен бәхетсезлекнең башы шунда. Шәяхмәтнең беренче кат өйләнүе ундүртенче елда булды. Ләкин империалистик сугышның бу мәсьәләгә зыяны тимәде диярлек. Хикмәт анда булмады. Никахтан соң нәкъ кияү булып керәсе көнне генә кыздан хәбәр җибәрделәр: үлсәм үләм, Шәяхмәтне куеныма кертмим дип әтисенә елап тавыш чыгарган. Кызның әтисе кияү төшерәсе көнне кара кайгысына батып карт хәзрәт янына килде.

— Хәзрәт, кыз чыгымлап тора, нишлибез? — диде.

Карт хәзрәт сирәк сакалын сыпырып аптырап калды. Соңгы елларда кызның ризалыгыннан башка никах укыган өчен бер-ике мулланың указы ычкынган иде. Бу мәсьәләне «Йолдыз» гәзитәсе бик күзәтеп бара, аның һәр санында муллаларның кыңгыр эшләрен чеметкәләп торалар. Өйлә намазына дип тәһарәт яңарткан хәзрәт үзенең фамилиясен шул секундта «Йолдыз» битендә итеп күз алдына китерде. Алла сакласын, алла сакласын...

Шәяхмәт урынына келәткә карт хәзрәт үзе керде. Келәт ишегенең аратасын тыкты да, идәндәге ак җәймәле түшәктә тәгәрәп елап яткан буй җиткән кыз янына утырды.

— Асыгыз, кисегез, мулла абзый, яратмыйм шул егетне,— дип, кыз калтыранып елады. Хәзрәт ике ут арасында калды. Кыз, чыннан да, кызганыч иде. Икенче яктан караганда — ак келәт, ап-ак җәймә җәелгән йомшак урын, Шәяхмәт үзе төскә-биткә ярыйсы гына егет. Я, нәрсә була инде киреләнмәсә? Тагын ни кирәк инде?

— Минем хакка гына, — диде хәзрәт, кызның кул аркасын сыйпап.— Әйе, минем хакка гына. Әгәр син хәзер киреләнсәң — мине харап итәсең. Никах укыган өчен мине указсыз калдырырлар. Балаларым күп, үзем карт. Минем хакка гына... Бер дә булмаса ике-өч атнадан аерылырсың.

Зинһар дип әйтәм... Бер дә булмаса, аерым йоклап торырсыз. Алай да ярый...

Хәзрәт әйткәнчә, ике атнадан Шәяхмәтнең хатыны аерылып китте. Йортка килен кирәк иде, аннан соң чын җылы түшәкнең дә нәрсә икәнен беләсе килә иде, егет икенче хатын алу турында исәп йөртә башлады. Сугышка китәр алдыннан Шәяхмәт күрше авылдан ире хәбәрсез югалган солдатканы иярттe дә кайтты. Бу юлы инде кияүләп йөрисе түгел иде — хәзрәтне чәйгә алып киләсе дә, күз алдында никах кына укытасы.

Хәзрәт бик кәефләнеп, көйли-көйли, тәһарәткә әзерләнеп йөри иде.

> Даре дөнья
> Хуптыр, әмма
> Ахры — мәүте улмаса.
> Даре гокъба
> Хуштыр, әмма
> Шиддәте нар
> улмаса...[1]

Шул вакыт аны никах мәҗлесенә чакырдылар.

Итле аш исе чыккан тәбәнәк өйгә килеп кергәч, хәзрәтнең күзе чыбылдык артындарак посынып бәлеш майлап яткан яшь киленгә төште. Һай, бу Шәяхмәт! Нинди сылу, яшь солдатканы эләктергән бит! Яшь киленнең тәнендәге куәт, дәрт ике-өч адымнан сизелеп тора иде. Менә бәхетле кеше бу Шәяхмәт... Ләкин авызыңа кирәргә язмаган ризык булса, юк инде. Аркан белән тартсаң да керми.

— Иреннең үлгәнлегенә белешмәң бармы? — диде хәзрәт, кулларын кызыл башлы сөлгегә сөртеп.

Моны башта әһәмиятсез сорау дип белделәр. Үлгәнлеккә хәбәр юк иде... Хәзрәт чөйдәге бишмәтенә үрелде.

— Һичничек булдыра алмыйм, җәмәгать, — диде ул, авызын ачып катып калган Шәяхмәткә һәм карт-карчыкка карап. — Әйе, булдыра алмыйм. Аның өчен мөфти хәзрәтләренең фәтвасы бар: ире сугышта үлгәнлеккә белешмәсе булмаган хатыннарга никах укымаска. Әнә бүген генә газиттә күрдем: шуның аркасында Бөре өязендә бер мулланың указы ычкынган. Мине дә кызганыгыз: үзем карт, алты кызым бар. Указсыз мин нишлим? Ә? Ире исән-сау кайтып минем өстән мәхкәмәгә бирсә, мин нишлим? Алла берүк үзе сакласын...

Чыбылдык артыннан мышык-мышык елаган тавыш ишетелде. Яшь хатын да, Шәяхмәт тә кызганыч булып тоелдылар. Ләкин ни хәл итмәк кирәк?

Еллар үтеп, заманалар үзгәреп, инде башкага өйләнеп, хатынынан бер-бер артлы ике бала тугач та Шәяхмәт:

— Ну, хәзрәт, шул кадәр күңелем кергән иде теге солдаткага, бер генә кич булса да рөхсәт итмәдең, — дип, берничә тапкыр карт муллага чын-чыннан үпкә сүзен белдерде.

Өйләнү хикмәтләре нәсел буенча шулай дәвам итәр дип кем уйлаган? Шәяхмәтнең олы улы Хәкимулла тыныч вакытта, яңа заманда өйләнде, мулланың инде кирәге юк иде, шулай да шау-шулы булды. Борчулы булды.

Әтисе кебек йомык кына егет иде өйләнгәнче, уйламаганда бер-ике әкәмәт ясап ташлады. Кыш иде — ел авыр килде. Районда игеннәр начар булды, халык иписез калды. Хезмәт көне аз булган Ташлытаудагы крахмал заводыннан бәрәңге бардасы ташыдылар. Район оешканнан бирле райбашкарма комитеты рәисе булып эшләгән Габитов шул елны гына озак авырудан соң дөнья куйды. Яман телле кулаклар колхозның

---

[1] Дөнья йорты, әгәр аның ахыры — үләме булмаса, бик әйбәт; көчле уты булмаса, ахирәт йорты да әйбәт.

икмәксез калуын шуңа бәйләп, теш ыржайтып көлделәр. Имеш, Габитов үләр алдыннан аның урынбасары больницага кереп:

— Синнән башка нишләрбез, иптәш Габитов? — дип борчылып кинәш сораган.

Тегесе:

— Бу елга түзегез, бар да булыр, — дигән, имеш. Аның урынына калган урынбасар, янәсе, шунда «барда булыр» дип аңлаган...

Бераздан атлар кырыла башлады. Яшьләр икмәкле җирләргә эшкә таралдылар. Егетләр лесхоздагы ЧТЗ тракторларына шакмак турарга киттеләр. Шәяхмәт исә малайларын читкә чыгармады, Хәкимулланы ат карарга урнаштырды, аның артыннан буй үсеп килгән Нургалине, Ташлытау ТБУМ[1] ына йөртеп, ничек кенә булмасын укымышлы кеше итәргә теләде. Нәкъ шул авыр көннәрдә Хәкимулла ат җигеп, кичләрен берике тапкыр Атҗабарга барып кайтты. Малайның исәбе йомры иде — әтисе каршы килмәде. Актык күәс ипине салган көнне Хәкимулла төн уртасында кар шыгырдатып ат белән ишегалдына килеп керде. Ишек пары белән өйгә мамык шәл бөркәнгән, кыска жикет кигән, битенә мул итеп вазелин сөрткән кыйгач кашлы кыз килеп керде. Йортка кершән исе, салкын һава исе таралды. Зәйнәп җиңги самаварын өстәлгә китереп утыртты да, хәл-әхвәл сорашып чәй эчкәч, ак мунчага кунарга кереп киттеләр.

Урын үзгәләпме, нидәндер йокысыз төн кичерделәр. Бигрәк тә Шәяхмәт агайның эче пошты. Бу авылда өйләнүнең нәрсә икәнен аның кадәр кем белә соң? Зәйнәп җиңгинең өзлексез уң кашы тартты...

Каһәр суккан нигез! Тагын нинди борчулар күрсәтәсең бар икән? Иртән алар йортка кайтканда яшь киленнән җиллэр искән иде. Моның хикмәтен Хәкимулла белән кыз алып кайткан нәселдәш егет Минлегали сөйләде. Хәкимулла, имеш, алданган.

— Күземә күренмә, син мине хур иттең, — дип, төнлә җәнҗал чыгарган, имеш.

Я алла! Моны күрше-күлән белсә, ни хәл итәрсең? Идарәгә ишетелсә — ни хурлык!

Ләкин монысы әле башы гына булган икән. Кояш чыгып көянтә буе күтәрелүгә, Атҗабардан кода белән кодагый килеп җиттеләр. Биек якалы толып кигән кода дигәне өйгә кереп коры гына сәлам бирде. Кодагый сәкегә утырып дога кылды.

— Хәерле бәрәкәт бирсен йортка, исән-сау торамсыз? — диде. Кода да, кодагый да як-якка каранып, кыз белән кияүне эзләделәр. Шәяхмәт абзый белән Зәйнәп җиңгигә шул вакытта җир тишеге генә кирәк иде! Ләкин аңлашмыйча булмый. Авыр тынлыкны коры кода бозды.

— Я, безнең кыз сездәме? Кеше төсле эшләргә ярамаганмыни? Сорап алып китәргә ярамаганмыни? Аның, шөкер, ата-анасы бар! Зинадан тумаган бит ул!

Шәяхмәт дер-дер килде. Кода таза, кырык яшьләр чамасындагы мәһабәт ир иде.

Шул минутта йортка Хәкимулла килеп керде. Түбән карап кына эшне аңлатты.

— Миңниса үзе тавыш чыгарды... Таң алдыннан чыгып китте... Үзе гаепле. Кая киткәнен әйтмәде. Эрәгә пырдымсызланды...

Көтелмәгән хәбәр коры коданы бөтенләй чыгырдан чыгарды. Ул таза йодрыгын әле Шәяхмәт, әле Хәкимулланың авыз тирәсендә уйната башлады.

— Әле сез шулай иттегезмени! Алай икән... Тәк-тәк... Моның өчен, беләсезме, нәрсә?

---

[1] ТБУМ — тулы булмаган урта мәктәп.

Хатыннар елап җибәрделәр. Коры кода калтырана башлады.

— Не смей сез кеше баласын алай страм итәргә! Менә мин сезне хөкемгә тарттырам! Имейте виду, әгәр сезне падсуд торгызмасам! Сез минем кем икәнне белмисездер әле! Атҗабарның витсанитары Хисмәт булырмын мин! Сезне судья алдына бастырмасам, я буду сабака!

Алар кызу-кызу җыенып чыгып киттеләр. Капкадан атны борганда, Хисмәт кода зур йодрыгын тагын бер селкетте.

— Әгәренки кыз өйгә кайтып кермәгән булса, аталы-уллы авылдан сөрдерәм мин сезне!

... Көн уртасына таба буран котырды. Хәкимулла ат җигеп Хисмәтләрнең күрше авылдагы туганнарына китте. Кыз аларга кермәгән иде. Кайтышлый адашты. Маяктан-маякка ат җитәкләп йөрде, яшь ат юл катысын таба белмәде. Озак җәфалангач, кияү егете маяк төбенә утырды да, йөгән сабагын тоткан килеш, үкереп-үкереп елады. Бераздан маяклар арасыннан толып киеп атка утырган бер адәм килеп чыкты. Бу — Миңлегали иде.

— Әйдә, Хәкимулла абый, борчылма, тегенең эзенә төштем мин, — диде. — Ташлытауга апаларына барып кергән. Әйдә, буран басыла, авылга таба барып карыйк...

Хисмәт кода судлашып йөрмәде. Күп тә үтмәде, аның кершәнле кызы Ташлытаудагы мануфактура кибетендә эшләүче бер егеткә ябышып чыкты. Авыл халкы бу вакыйганы артык куертмады. Тик Хисмәтнең туйда бөтен кешедән артык эчеп тә теле дә бәйләнмәгәнен шаккатып сөйләп йөрделәр. Имеш, кодалар ат туарган арада кызыннан бер кадак май белән ярты каз сорап алган да, лапас астына кереп, шуларны сыпыртып чыккан. Ахырдан никадәр генә сыйласалар да, Хисмәт коданы берәү дә исертә алмаган.

Шулай да Хисмәт, туйдан кайтышлый, Шәяхмәтләр капкасы янынннан чанада җырлап узды.

Уралып-уралып ага
Урал буе елгалар.
Урал буена тезелгән
Колхозлар, коммуналар.

Сәнәк күтәреп ат абзарыннан кайтып килгән Хәкимулла туй чанасына юл биреп читкә карап калды. Хисмәтнең елтырап торган үткен карашы белән очрашасы килми иде аның...

## Син миңа ачуланмыйсыңмы?

Яз мул сулары, җылы яңгырлары белән бик кинәт килде. Болгаушинья[1] яңгырларыннан соң ике көн эчендә елгалар бүртте, юллар бозылды. Шәяхмәтнең абзасы Шәйхи хәлфә календарь битен карады. Көннең озынлыгы унөч сәгатьтән узып бара иде.

— Сигездә сикертә, тугызда туктата, — диде ул идарә янында яңгырга хозурланып торган ирләргә. — Унда уйната, унбердә — күк табан, уникедә б.. табан, унөчтә — җик сабан. Димәк ки, сигез сәгать вакытта адәм чыдамаслык салкыннар була — сикергәләмә хәлең юк. Тугызга киткәндә — чана табаны ябыша. Атыңны туктата. Унда — басу өстендә буран уйный. Унбердә — чана эзе күкселләнә башлый. Уникедә юлдагы ат тизәге күренә башлый.

Ташлытаудан ипи ташу бик кыенлашты. Шәяхмәтнең кече улы Нургали ТБУМнан язгы каникулга кайтты. Нургали семьяда шук малай

---

[1] Благовещение — христианнарның дини бәйрәме, 25 мартка туры килә. Татар халкы игенчелеккә бәйле күзәтүләрен рус бәйрәмнәре буенча хәтерләгән.

иде — кайткан көнне үк хикмәт ясады. Хәбирә карчыкка кереп: «Кызың утыз ике кирпеч ипие белән Ташлытау үзәнендә чыга алмыйча калды, каршысына килергә кушты», — дип сөйләде. Хәбирә карчык кулына озын таяк алып, күтәрмәле чабаталарын киеп, Ташлытау юлына чыгып китте. Төн уртасында муеннан батып зәргә күпме җирне әйләнеп кайткач кына исенә төште: бүген искечә беренче апрель икән... Ач карынга чын күңелдән рәнҗеп, ул Нургалине каргады. Карт кешене рәнҗеткән өчен бугазы өзелсен дип теләк теләде...

Барысына да түзеп була, әмма шушы яз җитсә, хайван каһәрли башлыйлар. Каян башларына килә шул? Апрель кояшының җылысына рәхәтләнеп кенә утарда сикерешеп йөргән кырыкмышларны печә башлыйлар. Нигә тияргә? Айгыр көенчә үссәләр җигеп булмыймыни? Нигә җан каһәрләргә? Бичаралар, әле кайчан гына кояшка калыгып бер-берсенең муеннарын саргылт эре тешләре белән кырт-кырт кашыйлар, уйнашып иркәләнәләр иде. Бүген әле берсен, әле икенчесен канга батырып аерым бүлмәләргә алып кереп биклиләр. Абзарлар янында йөрәк өзгеч ат кешнәгән тавыш. Юк, бу кешнәү түгел, бу — атлар елавы. Пычак астына барып кергән яшь атның өзгәләнеп кешнәвенә карт атлар кушылып ярсыйлар, дәһшәтле кешниләр. Әйтерсең сугыш башланган да, атлар күз алдында балаларын кыралар. Инде элекке елларда ук печелеп дөньядан күңеле кайткан, тәртә арасына кергәндә дә, яшь бия яныннан узганда да бер үк төрле төссез караш белән уза торган алашаларга да бу тавыш әллә ничек тәэсир итә. Алаша миенең әллә кайдагы томанлы бер почмагыннан ниндидер дәртле тормыш чаткысының бер нуры чагылып үткәндәй була. Бу тавышлар хәтәр... Бу тавышлар яман бер хәлне искә төшерә... Әнә шул яман тавышларның теге ягында ниндидер икенче бер төрле дәртле тормыш бар иде бугай...

Бүген бөтен колхоз ирләре ат абзарлары янында ду-чат килде. Тимерчелектә эш кайнады. Юл өзеге бетүгә РККАга дигән атлар комиссия торырга тиешләр иде. Районнан килгән ветврачлар атларны шул комиссиягә хәзерләделәр. Монда да кансыз булмады. Кара турының арт аякларын дагалау аерата авыр булды. Таза ат, гадәт буенча, ал аякларын тыныч кына тотты, монысы инде ел саен эшләнә торган эш иде. Әмма арткы аякларга рашпель тотып әле берәүнең дә үрелгәне юк иде. Кара туры монда бер хәвеф сизде. Болар бүген көне буе аның ак кашкалы нәкъ үзе төсле малайларын акыртып каһәрләгәннәр иде, мөгаен, шуны эшлиләрдер дигән шик керде. Нәкъ шул секундта дага кадагы кыек китеп тояк астындагы иткә кагылды. Кара туры җан ачысы белән алга ыргылды, корсак астындагы бияләй яссылыгы брезент түшлек шартлап өзелде, шуннан бөтен гәүдәгә коточкыч куәт килде: тагын нәрсәләрнедер шытырдатып өзеп, ул өстәге аратага сырты тигәнче арт санын күтәрде дә, бөтен куәте дөньяга таралырлык итеп тибеп җибәрде. Дагалау станогының астагы каен аратасы ике җиреннән шартлап сынып, ярты җир буе ераклыкка очты. Станокның баганалары дер селкенеп алдылар. Кеше өстенә кеше егылды, кара туры исә актык тавышы белән җир селкетеп кешнәп җибәрде...

Ат абзары янында исә бу тавышны ишетмәделәр. Анда икенче бер яшь айгырны комиссиягә әзерлиләр иде. Анысының урт тешләре өстенә бер артык теш үсеп чыккан да, авыз эчен бозган. Шул тешне алырга кирәк иде.

Бу атны бөтен күрше-тирә колхозларда таныйлар. Чөнки төсе бик кызык: бер ягы ак, икенче ягы кызыл ямаулы. Мондый төс табигатьтә бик сирәк очраганлыктан, бу яшь айгыр кайда гына күренмәсен, моны Кара Чыршы авылыныкы дип белеп торалар иде. Инде бу таза, куәтле яшь айгырны абзар янында саламга егып салганнар. Өстенә алты-җиде кеше атланып утырган, сүс дилбегә белән аякларын боргычлаганнар. Авызын зур итеп каерып ачып шакмак тыкканнар. Районнан килгән

фельдшерларның берсе терсәк буе имән чөйне атның теге артык тешенә терәп куя да, җан көченә чөйнең башына агач чүкеч белән суга. Яшь айгыр ыңгыраша, бөтен гәүдәсе белән дерелдәп тартышып куя. Фельдшер, кансыз бәндә, аның саен кизәнеп суга. Ат авызыннан «доңкъ» иткән тонык тавыш чыга, ургылып кара кан бәрә, җир селкенә... Ул кычкырмый да, кешнәми дә, ул инде ыңгыраша гына. Бераздан кара канга аралашып теш ватыклары чыкты, ямаулы айгырны чиштеләр, торгыздылар. Башын салындырган килеш, ул берөзлексез дерелдәде. Аннан кайсыдыр, идарә чутына яздырып, кибеттән бер шешә аракы алып килде, ямаулы айгырның башын югары күтәрттеләр дә борын тишегәннән аракы койдылар. Атның авыз кырыеннан саламга аккан аракыга фельдшер кызганулы караш ташлады.

— Чурт та булмый аңа, ике сәгатьтән башак бирерсез, — дип, инструментларын җыештыра башлады. Янннан кешеләр киткәндә ямаулы айгыр, чыннан да, башын җиргә иеп, үз астында уылган саламнарны иснәштерә калды.

Апрель ахырларына җир кипте, җылы көннәр башланды. Бөтен сынамышлар буенча уңыш мул булырга тиеш иде — халык җиң сызганып кыр эшенә тотынды. Шәяхмәтне куян фермасына куйдылар: авылда куян асрауның рәтен белгән кеше бары тик ул гына иде. Бераздан Нургали дә каникулга кайткач, атлы эшкә тотынды. Председатель Тимерхан көзгә хезмәт көненә уңыш өч килодан да ким булмаячак дип күңелләргә дәрт өстәде.

Бушап калган бураларны тутыру өчен бик нык эшләргә, бик күп хезмәт көне җыярга кирәк иде. Хезмәт көне, хезмәт көне... Әнә шул күп булганда гына Ташлытау юлыннан ипи ташудан котылып булачак. Әнә шул булганда гына Хәкимулланы башлы-күзле итеп булачак, шул булганда гына Нургалигә җиде класс белем алдырып булачак...

Арыш серкәләнгән көннәр иде...

Шәяхмәт кичке аштан соң баскыч төбенә чыгып утырды. Катык каткан, яшел суган тураган арыш умачы ашаганнан соң һавада утыру аеруча ләззәтле була. Аның янына бераздан Хәкимулла да чыкты. Җылы, сөремле кич. Кайдадыр яңгыр ява булса кирәк, йомшак кына гөрелдәү ишетелеп ала. Мондый вакытта киләчәккә план кору уңай. Ата җай белән генә сүз башлады.

— Я, син күпмегә кәтле болай галахлыкта йөрергә уйлыйсың? Ни ултара, ни пултара дигәндәй...

Хәкимулла сүзнең төбен тиз аңлады.

— Авыр ел бит, әти. Кешедән оят. Ә тегесендә минем гаеп булмады, әти. Аны әнигә генә сөйләп булмый...

— Я, ярар, булган эш булган, буявы сеңгән. Мин өйләнү мәшәкатен күрмәдем түгел. Әмма быел уракка төшкәнче берәр чара кылып карарга кирәк. Акыллы кеше яз өйләнә. Хезмәт көне дә бер ояга җыелыр. Күзең төшкән берәрсе бармы?

Хәкимулла дәшмәде.

— Менә шул: борынынны салындырып йөрисе юк. Бүген мин келәтне чистарттым. Бер капчык чамасы арыш чыкты. Яңага житәр. Кара җиргә аяк бастык, шәт иншалла, яңага барып җитәрбез инде. Җитмәсә тагын, аптырама, илдә чыпчык үлми... Тик бу юлы уйлабрак инде. Җитте. Безнең нигез өйләнү мәсьәләсендә болай да кыңгыраулы булып чыкты...

Хәкимулла икенче көнне Миңлегали белән Ташлытау базарына китте. Исәпләре — Ташлытау ашханәсендә җыештыручы булып эшләгән Миңлебикәне күреп сөйләшү иде. Бу юантык кына көләч кыз, ничектер, бер көнне Ташлытау урамында очрап, Хәкимулла белән шаяртып сөйләшеп торган иде. Аннан соң Ташлытау кызлары элек-электән Кара Чыршы авылына убылып кына кияүгә чыгып баралар иде.

Базар көнне ничек кенә булса да Миңлебикәне очратырга кирәк иде. Ләкин тик торганда бер кызга: «Әйдә, минем хатын буласыңмы?» — дип ничек әйтәсең? Монда бит бик зур кыюлык кирәк. Нишләргә?

Андый чакта Миңлегали мең кешегә бергесез егет.

— Икебезгә бер ярты, — диде ул, чыбыркысын сиртмәдәге вика астына яшереп. — Аннан син күр дә, мин күр. Синнән булмаса, үзем сөйләшәм.

Ләкин базарда аракы табуы бик җиңел булып чыкмады. Базар кайный, дегет чиләгеннән башлап тимерле сандыкка кадәр алып килгәннәр — әмма аракы юк. Коры законны гамәлгә керткәннәр икән. Базарның урта бер җирендә зур фанерга ач яңаклы, таза беләкле кеше рәсемен ясап куйганнар. Ул күзләрен киң итеп ачкан да, базардагы кешеләргә нәрсәдер әйтә сыман. Әһә, рәсемнең астында аракы шешәсе. Теге кеше бармагы белән шуңа төрткән. Шунда ук зур хәрефләр белән язып куелган:

«Аракы — летуннар, рвачлар дусы.

Аракы — пролетариатның дошманы.

Аракыга каршы көрәш — һәр кәсептәшләр союзы әгъзасының бурычы».

Базар тулы спекулянтлар. Шәһәр кешесенә охшаган берәү, жырлый-жырлый, алма сата.

Есть яблоки — алма бар,<br>Кому надо яблоки?<br>Таких яблок не найдете,<br>Весь город обойдете.

Икенче бер чөгендер борынлы кеше кызыл башлы шырпы сата. Анысы да көйли:

Спички есть — кому надо?<br>Шырпы бар — кемгә кирәк?

Бер почмакта билле толстовка, ак киез эшләпә кигән таза бер адәмне ике милиционер тоткан. Аларны халык чорнаган. Тегеннән-моннан ишетелгән сүзләрдән шул аңлашылды: бу — Ташлытауның иң эре спекулянтларыннан берсе икән.

Ташлытауның ат карагы, кызыл муенлы Заһри кем беләндер бәхәскә кергән. Ул кызып-кызып сөйли.

— Менә безнең мөселман диненә чыкмый ул, мин сиңайтим... Бер көнне ат дуктыры керәшен Чтапанов белән бәхәсләштек. Менә, мин әйтәм, бәхәскә китсә дим, мин әчке киемемне чайкыйм да эчәм... Птамушто безнең мөселман тәһарәтсез йөрми дим...

Заһри — Кара Чыршылыларга мәгълүм кеше, авыз күтәреп йөргән Хәкимулла белән Миңлегалине тиз таныды.

— Зәмзәм суымы? — диде ул шыпырт тавыш белән. — Соң бит аны моннан эзләсе түгел. Ә-әнә кайда була ул...

Заһри теге плакат янын күрсәтте. Чыннан да, егетләрнең шунда килүе булды, ике-өч кеше күз кыскалап куен кесәсеннән сургучлы шешә башларын күрсәттеләр.

Миңлегали сүзе дөрес булып чыкты. Кешене яшь димә, атасыз димә. Башы гына эшләсен. Миңлегали эшне, гомумән, жиңел кулдан эшли. Аның белән эчүе дә күңелле. Аның кулы жиңел.

Миңлебикәләр Ташлытауның ындыр арты урамында, тар тыкрыкта торалар икән. Кызның беркөн сөйләшүе, чыннан да, әрәгә булмаган, спекулянтлар оясыннан туйган, авылда яшисе килә икән. Тик әти-әнисе ялгыз калырга риза булырлармы? Аннан соң, алар тыкрыгында егетләр бик елдым, күрә торып тыныч кына кыз биреп жибәрмәсләр... Урлый алсагыз гына инде... Әйе, әти-әнидән дә, күрше егетләреннән дә.

... Вәгъдә буенча, алдагы базар көнне төнге сәгать уникеләрдә тар-каранғы тыкрыкка акрын гына атлап сиртмә җигелгән ат килеп керде. Миңлегали Ташлытауга кергәнче арыш арасында калды. Ул андый-мондый тавыш чыга калса, бакча яктан гына ярдәмгә килергә тиеш иде.

Тик... тик, берәүнең дә ярдәме кирәк булмады. Бер генә секундка болыт астыннан ай калыкты. Шул чакта тыкрыктан кулына ак төенчек тоткан, жикет кигән, шәльяулыкка төренгән бер кыз бала килеп чыкты да, йомылып йөгереп, Хәкимулланың сиртмәсенә килеп ауды. Хәкимулла үз йөрәгенең дөп-дөп типкәнен ишетте. Сыртына кинәт кенә чыбыркы төшкән ат кисәк алдырып чабып китте. Арыш басуыннан йөгереп килеп чыккан Миңлегали дә чак кына сиртмә астына эләкмәде. Ә колхозның кара туры нәсел айгыры җир селкетеп арыш арасындагы юлдан Кара Чыршыга таба чапты.

Таң атканда гына Шәяхмәтнең тар ишегалдына килеп керделәр. Атның эче селкенә, борын тишекләре киңәеп, анда кызыл кан тамырлары калыккан иде. Сиртмәдән төшеп тузаннарны кагынганда, урланган кыз да шәльяулыгын салып какты. Шул вакыт Хәкимулланың күзеннән җиргә ниндидер кыршаулар коелган сыман булды. Кызый — Миңлебикә түгел иде...

... Болар — нәселләре белән үткен кешеләр исәпләнәләр иде. Заманында якын-тирәнең атларын кырыштырып йөргән Заһри, эшләр чуала башлагач, Ташлытауга күчеп утырды. Ташлытау базары калын була, Заһри шикелле үткен кешегә анда да маклер булып көн итәрлек җай чыга торды. Заһри бик хәтәр юлларда йөрде, ГПУ кешеләренең борын төбеннән дә качкалады. Берсендә, кышкы кичтә, Заһриның артыннан чыктылар. Егерме чакрым җан-фәрманга чапкач, аның аты арды. Уйлап торырга вакыт юк, җиңел чаналы ГПУ кешеләре инде арттан җитәләр иде. Заһри авылга житкәндә генә атын кире якка борып, зират капкасына бәйләде дә, үзе, койма буена тезләнеп, кычкырып корьән укый башлады. Аның тавышы бик көчле иде һәм мондый чын тавыш белән корьән укып утыручының ат карагы булу мөмкинлеге берәүнең дә башына кермәде.

Заһриның аты турында да әйләнә-тирәдә әкиятләр йөрде. Имеш, куучылар артыннан җитеп атына «тпру» дип дәшеп караганнар, ат аның саен элдереп чаба икән. Ахырдан гына белгәннәр: Заһриның аты «тпру» дигәндә чабарга, «на» дигәндә туктарга өйрәтелгән булган. Икенче бер вакыт Заһриның артыннан куган яшь милиционер аның атын эләктергән. Имеш, Заһри үзе арыш арасына кереп элдерткән, ә яшь егет аның чабып барган атына менеп утырган. «Тпру» диюгә ат йомылып чаба башлаган, егет, ни чарә кылырга белмичә, шулай кырык чакрым җәһәннәм арбасында барган. Бер таудан төшкәндә башым бетә дип үкереп елый башлаган.

— Ай-яй, үлемем шушы икән, — дигән.

Нәкъ шул секундта ат дүрт аягын терәп катып кала, камыты күзләренә килә. Монысының да хикмәтен соңыннан беләләр: Заһриның аты «ай-яй» дигәндә дә туктарга өйрәтелгән икән.

Заһри һәм аның дус-ишләре турында Кара Чыршы тирәсендә коточкыч әкиятләр йөрде. Атжабарда аның икенче хатыны да бар дип сөйлиләр иде. Аның туктый торган фатирларыннан берсе шул авылда иде. Имеш, Заһри үзенең дус-ишләре белән кәеф-сафа корып утырганда Ташлытау юлыннан милиционер килгәне күренсә, авылның мәзине манарага менеп азан әйтә икән. Милициядә эшләүче егетләр арасында керәшен егетләре байтак кына иде — азанның кайчан әйтеләсендә аларның ни эше бар? Азан тавышын ишетүгә Заһриның мөритләреннән берсе тиз генә басу капкасын яба, аннан озак кына торып ат каршына чыга, капканы ача, исәнләшә, сораштыра, ә ул арада Заһри инде элдерткән була.

Заһри капкынына эләгеп волостьның, кантонның күпме начальнигы алданды. Җае гына чыккан саен, туры килгән саен ул аларга якты чырай күрсәтә һәм чиреге белән көмешкә, табагы белән ат ите утыртырга күп сорамый иде. Егерме дүртенче елны Заһри судка да эләкте.

Шәкүр карак эләккән елны Заһри русский гармунын колак янына күтәреп, мехларын өзәрдәй итеп мәҗлесләрдә җырлады.

Шәк-күр кар-рак замманындай
Бик күп атлар урлаган шул,
Төрмә тәр-рәз-зәләрен-нәй
Ут-тырган дай ел-лаг-ган...

Моның махсус көе дә бар иде һәм мәҗлестәге агай-эне арасында бу җырдан соң яшь сыккан кеше аз булмады.

Үз хатынына Заһри каты булды.

— Хатын-кызга, — дип сөйли иде ул, — бер вакытта да уч төбеңне күрсәтмә... — Шуны әйткәндә аның йөнтәс аркалы куллары йодрыклана иде. Хатынының тормыш вак-төякләре белән борчыганын да ул бер дә яратмады. Һәр вакыт өстәл янында мыекларын сыпырып уйланып утыра иде ул. Һәм хатыны берәр сүз әйтеп, аның уйларын бүлдергәндә, үткен карашларын аңа чәнчеп:

— Миндә атаң кайгысы, синдә... кайгысы, — дип әшәке сүз белән кырт кисә иде.

Атҗабар тегермәнчесенең сеңлесе Заһридан бала табып, яр буена чыгарып күмгән дип тә сөйлиләр иде. Һәрхәлдә, Атҗабарның яшьләре көзге төннәрдә яр астында яшь бала тавышын ишеткәннәр дип ышанучы аз түгел иде.

Шулай да Заһри бер тапкыр нык кына эләкте. Эшләр бик начар иде — җиденче август карары буенча хөкем ителсә, ким дигәндә алты ел бирәчәкләр иде. Ташлытауның агач КПЗсында утырганда Заһри ишекне ачтырып йомышын үтәргә чыкты. Хатыны кыздырган ит китергән иде — шуны ашагач, эче авырта башлавын җае белән дежур милиционерга кичтән үк әйтеп куйды. Шуңа күрә аның озаклап йомыш юлында йөрүенә тегесе игътибар итмәде — җәйнең җылы таңында йокы аеруча татлы була — яшь милиционер йокымсырап китте. Уянгач кына кобурасының җиңеләйгәнен сизде...

Илләт якларыннан, Апаз базары тирәсеннән урап Заһри эшен төгәлләде. Тиешле шаһитлар белән сөйләшенде. Өч көн узып таң беленгәндә, ул револьвер тотып КПЗга килеп керде. Дежур милиционер — олы яшьтәге мыеклы керәшен — урыныннан сикереп торды. Заһри исә револьверны аның өстәленә китереп куйды.

— Санап ал, нәкъ алты патрон, — диде. — Берсенә дә тимәдем. Ялгышымны аңладым, инде камерама кертеп утыртыгыз.

Төп эш буенча шаһитлар булмады, ә качкан өчен Заһрига нибары бер ел колониядә көтүче булып йөрергә генә туры килде.

Заһриның бердәнбер кызы Васфикамал да үткен булып чыкты. Ташлытау артындагы кечкенә урамда бөтен малайларны кыйнап үсте, күрше-тирәнең көнбагыш башларын, кыярларын авыз иткәләде. Тик уналты яшенә җиткәндә генә, Ташлытау егетләре аңа күз сала башлагач кына, бу гадәтләрен ташлады. Кап-кара ике толымлы, кыйгач кашлы бу кыз бер җәй эчендә үсте дә китте. Карасалар — үткен күзле, коңгырт битле бу кыз Ташлытауның иң чибәр кызларыннан берсе икән. Ашханәгә аш пешерүче булып урнашкач та аны ГПУда оперуполномоченный булып эшләүче Нәбиуллин күреп алды. Бернична тапкыр алар Заһриның бакча башында яшерен генә очраштылар, кайнар тәнле бу кызый аны беренче кичне үк үбеп алгач, Нәбиуллин аяк астындагы җирнең кинәт чайкалганын сизде. Шул көннән башлап ул төш күргән кебек кенә яшәде. Бер-ике җинаятьчене ычкындырды, өстеннән аноним хат та килде.

Опер булсаң, опер бул, ат карагы кызына кызыгып йөрмә, диделәр... Егет ике ут арасында калды. Ә беркөнне ашханәнең кухнясында эшләүче хатыннар Нәбиуллинның шәһәрдән өйләнеп кайтуы турында сөйләделәр. Васфикамал сыек май кыздырган табасын ялгыш әйләндереп чуен плита өстенә аударды. Кухняны зәңгәр май исе басты... Васфикамалның кайнар мәхәббәте, башка беркемгә карата да, беркайчан да уянмаячак кайнар хисләре плита өстендәге сыек май белән бергә чыжылдап яндылар. Күз яшьләрен барысыннан да яшерде, тик кичен эштән кайтканда күршесе Миңлебикә алдында гына чишелде.

— Малай, җаным, нишлим, киңәш бир, — диде. — Мин, — диде, — шуны ишеткәннән соң әллә нинди томан эчендә яшим. Мин утлы күмер өстенә ялан аяк басып йөрим. Көндәш белән торган шикелле бит. Бер урамда бит, бер урамда... Аның хатын белән урамнан узганын мин ничек карап калыйм? Поезд асларына керимме, нишлим? Башларымны кайларга алып качыйм?

Ләкин Миңлебикәнең дә үз хәсрәте хәсрәт икән. Ул да серне чиште. Кара Чыршының Хәкимуллага вәгъдә биргәнен дә, карт әти-әнисенең ялгыз калабыз дип, авылга кыз бирүгә бик нык каршы килгәннәрен дә, Хәкимулланың бер мәртәбә хатын аерган даны булуын да сөйләде.

— Вәгъдә көне иртәгә бит, мин нишлим? Егетне алдадым бит, ничек итеп аны рәнҗетмәскә? Аш хакы бар бит, — дип, ул да яшь түкте. Ике кыз капка төбендә озак-озак серләштеләр...

Икенче көнне Васфикамал су буенда кер чайкады. Аның күзләре кызарган, карашлары моңлы иде. Юылган керне каты-каты кысып сыкты. Бу — хәсрәтне оныттыра икән. Үзе берөзлексез җырлады. Бер җырны хәтта ике-өч тапкыр җырлады.

Уйлый күңлем, уйлый күңлем,
Уйлый күңлем шашарга,
Уйлый күңлем Татарстаннардан чыгып качарга.

Һай, бу кыз баланың хәлләре! Чыннан да, бу — беркем дә җиңеләйтә алмаслык йөрәк хәсрәте иде...

Ярый инде, җае чыкты. Югыйсә Нәбиуллинның шәһәр хатыны белән Ташлытау урамыннан узганын ни хәлләр итеп карап калыр иде...

Васфикамалның күзендә Хәкимулла кызгандыргыч моңсу караш күрде. Кызарып кояш чыгып килә иде — авыл тып-тын. Бары тик Миңлегалинең генә ат абзарлары тирәсендә шыгырдатып ишек ачканы, ат кертеп йөргәне ишетелә.

Сүзне Васфикамал башлады.

— Син миңа ачуланмыйсыңмы? Син миңа ачуланма, яме? Мин сине бервакытта да кеше алдында кызартмам. Мин колхоз эшеннән курыкмыйм. Ачуланма, әйдә гөрләшеп бер тормыш корыйк. Тик ачуланма гына. Мин сине бер дә читен хәлгә калдырмам...

Хәкимулла телгә килде. Хәер, ул нәрсә сөйләгәнен белмәде. Кызның кайнар кулларын үзенең бирчәйгән уч төпләренә кысты да пышылдап нидер сөйләде.

— Мин сине күптән күреп йөри идем. Ташлытауга барган саен... Тик бервакытта да сине миңа карарсың дип уйламадым. Син бит чибәр... Син бит яшь. Синең бит нинди чибәр егетең бар иде. Начальник кеше. Син китмә, яме. Кал. Әйдә, өйгә кер. Рәхмәт, Васфикамал, билләһи, рәхмәт. Гомерем буе бу яхшылыгыңны онытмам.

Васфикамал бу сүзләрне ишетмәде.

Чолан баганасына сөялгән килеш, ул елый иде. Хәкимулла аның җилкәсенә кулын куйган да, тагын да ни әйтергә белмәгән килеш, бер кулындагы чыбыркы сабын әйләндерә дә әйләндерә.

Ела, Васфикамал, ела! Кояш чыкканда елаган күз яше — изге яшь. Кеше нигезенә килеп төшкән кыз баланың беренче тапкыр түккән күз яше — изге яшь...

Барысы да җайланды. Иртәнге көтүне куганда Шәяхмәтләр моржасыннан май исе катыш сыек төтен чыкты. Яшь килен көтү куып кайтучы бөтен хатыннарны телсез калдырып, көянтә-чиләк белән су буеннан Шәяхмәтләр капкасына кайтып керде.

Тик сәгать иртәнге тугызлар тирәсендә генә Шәяхмәтләрнең өенә итәкләрен бөрмәсенә кыстырып күтәргән бер хатын җәһәт-җәһәт кенә килеп керде. Туп-туры түргә узып, сәкегә утырды. Бу — кодагый иде. Моны Кара Чыршыда бик яхшы беләләр иде. Такта чәй, ситсы, галош кебек әйберләрне Кара Чыршыга шыпырт кына шушы хатын ташый иде. Бермәлгә өйдә тынлык урнашты. Кемдер сүз башларга тиеш иде. Моны Ташлытау кодагый башлады. Хәер, сүз дип сүз түгел, әллә нәрсә. Ул күзләрен ямьсез итеп Васфикамалга текәде дә, кинәт кенә дерелди, калтырана башлады.

— Уф-фу-фу-фу-фу...

Иреннәрен ялап алды да тагын калтыранды.

— Уф-фу-фу-фу-фу...

Шулай диде дә, кинәт башын чырык итеп бәреп, сәкегә ауды. Өй эчендәгеләр каушап калдылар. Тик Васфикамал гына моңа борчылмады. Күзен алартып яткан анасы янына килеп, ул аның башын мендәргә салды.

— Бер дә исегез китмәсен, безнең әнинең шундый гадәте бар аның, утә дә китә ул, — диде. Зәйнәп җиңги, куркудан нишләргә белмичә, Шәйхи хәлфәне алып чыкты. Шәйхи хәлфә тегеләй дә, болай да баш тартып карады, әмма, өшкерергә бик нык кыстагач, баш тартмады.

— Мин өшкерүен өшкерәм, әмма духтырга күрсәтергә кирәк, — диде.

Бераздан Ташлытау кодагый торып утырды, йорт эченә күз салды. Дөбердәтеп эшләп йөргән кызын, кенәгәләрен тотып колхоз исәп-хисабы белән утырган коданы һәм телсез-тешсезгә охшаган кодагыйны күргәч, бераз тынычлангандай итте. Кызыл шәльяулыгына битен каплап елады-елады да урыныннан кузгалды.

— Ярар, алды-арты хәерле булсын, сандыгыңны әтиең кичкә китерер, — дип, ничек тиз керсә, шулай тиз чыгып та китте.

Шәяхмәтләр өендә икенче тормыш башланды...

## Мондый авыруга сүз ярамый

Ташлытау станциясе булмаса, тормышны ничек алып барыр идең?

Ташлытау станциясе — җирнең үзәге икән. Аннан башка тормыш, яшәеш мөмкин түгел икән. Авылдан берәү чыгып китсә — Ташлытауга. Авылга берәү кайтып керсә — Ташлытаудан. Көзге пычракта бәрәңге заданиесен шундагы крахмал заводына илтеп тапшырасы. Бәрәңге тапшыру — зур эш. Челтәрле үлчәүдә тавык йомыркасыннан кечерәк булган бәрәңге аска коела — анысы исәпләнми. Ат йөге белән килеп кергән күпер — үзе үлчәү. Имеш, карандаш салып караганнар, үлчәү сизгән. Язын ипиең бетсә, Ташлытауга барып, я заготзернода, я типографиядә төнге сменада эшләргә мөмкин. Гәзит баса торган машинаны кулдан бер төн әйләндерсәң — бер бөтен түгәрәк ипи. Агитбригада килсә — Ташлытаудан. Әле көз башында гына килеп, мәктәптә сәхнә ясап, пыр туздырып тәнкыйтьләп киттеләр. Куян фермасын урман буена салдыру планына каршы килеп, су буена салдырган ферма мөдире Шәяхмәткә барыннан да катырак эләкте. Тигез итеп киселгән кыска чәчле ике кыз сәхнәдә чәт-чәт килеп җырладылар.

Кәлимуллин Шәяхмәт —
Вредитель калдыгы.
Ул куяннарның фермасын
Су буена салдырды.

Болар — Ташлытау кызлары иде...

Шәяхмәт колхозда абруйлы кеше булып исәпләнә иде — иң алгы рәттә утырган җиреннән торып клубтан чыгып китте дә, өенә кайткач, җиделе лампасын яндырып, төне буе Ташлытаудагы зур кешеләр исеменә гариза язып утырды. Язды — сызды. «Мин түбәндә кул куючы...» «Мин югарыда имзамны куюсатүче, үтенәмен сездән шул хакта...» Нәрсә хакында? Моны ул үзе дә белми иде. Тик күңел нахак сүзгә бик нык рәнҗегән иде, гарәп хәрефләре белән тулган кәгазь күңел ярасына шифа була алмады.

Ике көн үтмәде, Ташлытауга бәрәңге заданиесе илтергә киткән улы Хәкимулланың юлда аты үлеп калды. Колхоз аты юлда үлгән... Шәяхмәтнең тәбәнәк өен кара кайгы басты. Аның өе мәктәпкә әйләндерелгән мәчет янында гына иде, уразаның соңгы көнендә егетләр, элекке гадәт буенча, манарага әлвидагъ[1] әйтергә менделәр. Хәер, бу инде уразаны озатудан бигрәк клуб юклык хикмәте иде. Егетләр манара башына фонарьлар, тальян гармун алып менгәннәр, авызларында тәмәке. Әлвидагъның элек мондый бер җыры бар иде:

Хәсәнатлар тәбдил улып
Җөмләдерлү сәйеат...[2]

Телләренә шайтан төкергән яшьләр! Хәкимулланың Ташлытау юлында үтергән аты күрше Хәсәннең утызынчы елда колхозга тапшырган аты иде. Манара башыннан әлвидагъ көенә бөтен авылга җыр таралды.

Хәкимулла Хәсән атын
Заданиедә үтергә-ә-ә-н...
Әлвидагъ! Әлвидагъ!
Хәкимулла Хәсән атын...

Бу җыр Шәяхмәтнең йөрәк бәгырьләрен телгәләде. Шул уңай белән семьяда рәт китте.

— Колхоз идарәсендә син юаш торасың, үзеңне вредитель дип җырлыйлар, малаеңны манарадан торып мыскыл итәләр, — дип, килене Васфикамал ярага тоз салды.

Дөньяда ике явыз булса шуның берсе Васфикамалдыр. Ни әйтсә — зәһәр чыга, ни сөйләсә — ярага нашатырь сибә. Йортка Васфикамал килгәннән бирле күрше-күлән белән алыш-биреш бетте. Гомер буе ипи, он, тоз, керосин алышып яшәгән күршеләр белән Васфикамал бер ел эчендә исәп-хисапны өзде. Шәяхмәтнең «Наданнар өчен уку китабы» дигән каты тыш эченә салган бурыч кенәгәсен күз алдында учакка атты. «Шәйхиләрдән алачак ипи: өч кадак ике чирек, бер әчмуха, бер кайчы, бер йозак авырлыгы... Хәдичәгә бирәсе солы оны: сигез кадак бер чирек, бер богау йозагы» дип чуарланган дәфтәр бөгәрләнеп янды. Васфикамал вәгъдәсендә торды, колхоз эшен сытып эшләде. Уракта — беренче. Кеше киленнәре изелеп-елап ун-унике сотый урганда, Васфикамал арышның иң куе җиреннән егерме өч, егерме биш сотый урып килде. Иллә мәгәр, бригадир да, башкалар да Ташлытау килененең теленнән куркып качалар иде. Шәяхмәтнең абыйсы—гомер буе авылда киңәш-

---

[1] Әлвидагъ — саубуллашу, хушлашу. Бу урында ураза ае белән хушлашу. Егетләр өчен бу — бәйрәм булган. Күңелсез, ризыксыз ай белән алар шатланып хушлашканнар. Әлвидагъ — ниндидер бер суфи шагыйрь әсәре булырга тиеш.

[2] (Гарәпчә.) Бу көнне эшәкелекләрнең барысы да яхшылык белән алышынган, дигән мәгънәдә.

табыш биреп йөргән Шәйхи хәлфә дә, Васфикамалның ачы теленә бер эләгеп карагач, капкасыннан чыкмас булды. Васфикамал урман буена утауга киткәч кенә, бәрәңге бакчасының киртәсенә сөялеп бер көнне энесе Шәяхмәткә мәзәк сөйләде.

— Ходаның язганы, сәхабәләрнең берсе теленә шайтан төкергән шундый бер хатынга өйләнгән. Теге сәхабәнең иманын суырган бу явыз. Сәхабә кипкән, ябыккан, саргайган. Әйе... Ходаның хикмәте, бер кичне ачуы чыгып, йөрәкләнеп китеп, теге мәлгунәнең аяк-кулын бәйләгән дә авыл читендәге ташландык коега алып барган. Әйе... «Мин синең белән ун ел җәфа чиктем, моннан ары түзәр чамам юк», — дигән дә коега ыргыткан. Кайтып тәһарәт яңартып, ясигъ намазын укыган бу. Әйе... Шуннан корьәннең ясин сүрәсен укып, сабый баладай йокыга тала бу. Тынычлап йоклый. Анадан яңа тугандай була бу. Бервакыт, ходаның язганы, тәрәзәсен бик каты кагалар моның. Шәмен кабызып тәрәзәсенә килсә, әстәгъфирулла, тәүбә, җиде башлы дию пәрие моның тәрәзә астында җир селкетә ди. «Теге явызыңны тизрәк алып кит, кырык ел яшәгән коемнан куып чыгарды», — дип, җиде пар күзеннән яшь коя ди... Әйе...

Мәзәкнең дәвамы булгандырмы, юктырмы, нәкъ шул вакытта бакча артында баш түбәсенә чүмәлә кадәр печән утырткан Васфикамал күренде. Аның, җир бетереп, иртәрәк кайтуы икән. Шәйхи хәлфә җәһәт кенә мунча артына сызды, Шәяхмәт әле генә кайткан булса да, куян фермасына тайды.

Кычкырышның иң зурысы шул көнне чыкты. Хәер, аның кайсын иң зурысы дип әйтергә дә белмисең. Инде шактый күрелде. Дөньяның нәрсә икәнен беләсең килсә, я тар аяк киеме ки, я өйлән, диләр бит. Васфикамал явызлыкка явыз, әмма акылы — хикмәт. Хәкимулла ничә тапкыр кичен өеннән чыгып китеп карады. Кайтмыйм, көтмә, дип китеп карады.

Юк бит, акыллы хатынны аның белән җиңеп булмый икән. Берсендә кичен елый-елый капка янында аерылышты.

— Я, ярар, Васфикамал, — диде ул, күз яшенә тыгылып, — бәхил бул. Төрле вакыт булгандыр. Бәхил бул, яме? Мин тегермән суына төшәм... Бәхил бул...

Караңгы булып килә иде. Васфикамал, иңенә шәлен салган килеш, баганага сөялеп калды.

— Ярый, ярый, бәхил, бик бәхил.— Үзе шунда ук өстәп куйды — Бар, бар, озак йөрмә, иртәгә эшкә киткәнче печәннәрне печәнлеккә мендерәсе булыр.

Тегесе һаман киреләнде.

— Ярый, көтмә мине, бәхил бул.

Ә бераздан Миңлегалиләр капка төбендә ике тәмәке уты күренде. Кичке тынлыкта Хәкимулланың мыдыр-мыдыр сөйләшкәне ишетелә иде.

— Без инде иртәгә эшкә киткәнче печәнне мендерик. Васфикамалга авырга туры килә. Чүтки хатын-кызга авыр күтәрергә ярамый... Иртүк кер инде син, — диде Хәкимулла.

... Кич көтү кайткан вакыт иде, Хәкимулла сәнәк күтәреп эштән кайтып керде. Сүзне Васфикамал башлады.

— Кешенең ирләре ир төсле, ат җигәләр, ә син хатын-кыз арасында печән җыеп йөрисең! Хурлыгы ни тора!

Шуннан барысы да буталды. Шәяхмәт, кеше-кара кермәсен дип, капкага арата салды. Васфикамал моны күреп тагы да ярсыды.

— Әле сез малаегыз белән бергә капка бикләп мине кыйнамакчы буласызмы? Менә кыйнатырмын мин сезгә! Колхозның беренче ударницасы мин, белдегезме шуны? Сез әле капка биклисезме?

Шәяхмәт тә, Хәкимулла да ык-мык иттеләр. Кая инде Васфикамалга кагылу, үзе тимәсә... Шәяхмәт тәмле тел белән тынычлык урнаштырмакчы булды.

— Килен, сабыр, зинһар, сабыр. Нишләп без сиңа кул тидерик ди? Аннан башка да борчулы вакытыбыз. Менә ат түләтәбез дип торалар. Бүген генә идарә утырышы булды. Сабыр дим...

Ат түләтү турындагы хәбәр Васфикамалны чыгырыннан чыгарды.

— Әһә-ә-ә, алаймени әле? Әле сез минем бер караңгыдан икенче караңгыга эшләгән белән ат түләмәкчемени! Тотмый торыгыз әле, яме! Тәгәрәп үлсәм үләрмен, сез ужым бозауларын рәткә салырмын! Биетәм әле мин сезне исән булсам, биетәм... Әдәм көлкесе бит, әдәм көлкесе. Ташлытаудан доктор спрафкысын да көтүче юк бит, түләргә әзер торалар...

Шәйхи хәлфә, больницага киткән карчыгының озак торуына эче пошып, Ташлытау юлын күзәтергә манарага менгән иде. Шәяхмәтләр ишегалдындагы ыбыр-чыбырны беткәнче карап, тыңлап торды.

Бераздан карчыгы белән чәй эчеп утырганда, аның чоланын Шәяхмәт какты. Шәйхи хәлфә катасын киеп чоланга чыкты, энесенең сәламен алды.

— Хәкимулланың хәле начарланып китте, авызыннан ак күбек килә, — диде Шәяхмәт читкә карап кына. — Кереп, карап чыксана... Үземнең фермага барасым бар.

Шәйхи хәлфә хәйләкәр елмайды.

— Берәр ярамаган ризык капмагандыр бит, ходай бәндәсе?

— Юк, бер дә аны-моны ашамады. Эштән кайтты да сәкегә сузылып ятты. Шуннан — телсез-авызсыз. Син кереп чыга күр инде. Әллә нәрсә булуы бар, — дип, Шәяхмәт эшнең асылын яшерде.

Шәйхи килеп кергәндә, чоланда зәһәрләнеп килен елый, Хәкимулла күзләрен йомып йортта чалкан ята иде. Аның маңгаена юешләп сөлге япканнар, әни карчык умач уганда онга буялган куллары белән Хәкимулланың аяк киемнәрен салдырып маташа. Васфикамал, күзләрен тутырып, зур өметләр белән Шәйхи хәлфәгә карады.

Шәйхи шул вакытта бу йортта тынычлык мәсьәләсенең кинәт кенә үз кулына килеп кергәнлеген сизде.

— Барыгыз да чыгып торыгыз,— диде ул вәкарь белән генә. Хатыннар теләр-теләмәс кенә чоланга таба атладылар.

Шәйхи хәлфә ишекне эчтән элде. Сәкегә килеп утырды.

— Я, ач күзеңне, энем Хәкимулла. Курыкма, бу мин, бер үзем.

Хәкимулла шикләнеп кенә күзен ачты. Башын күтәреп йорт эчен күзәтте — берәү дә юклыгына ышангач:

— Уф-ф-ф, — дип авыр сулап куйды.

— Я, энем, ни хәл соң, нәрсә булды?

Хәкимулла иреннәрен ялап алды.

— Үләм, дәү абый, үләм. Нишлим, киңәш бир! Кычыткан белән бер бит Васфикамал.

— Соң, энем, ниме?.. Ниме дип инде, син аны яратасыңмы соң?

Хәкимулла тагын бер уфылдады, кипкән иреннәрен тагын ялады.

— Сүзнең дөресе кирәк, дәү абый, яратам шул мин аны. Миңа дөньяда бүтән бер кеше дә кирәк түгел. Ну, теле бит, теле...

Шәйхи хәлфә урыныннан сикереп торды.

— Йом күзеңне, энем. Менә шулай. Инде телеңне дә бераз чыгарып тешләп куй. Менә шулай. Бер ярты сәгатьтән айнырсың.

Ул барып ишек келәсен ычкындырды. Ишектән атылып Васфикамал килеп керде. Аның артыннан кайнана... Килен зур күзләрен Шәйхигә текәде.

— Я, ничек, Шәйхи абый җаным, ни булган?

Шәйхи ашыкмады. Вәкарь белән генә тамагын кырды.

— Менә нәрсә, җәмәгать, — диде ул. — Мондый авыруны беләм мин. Без Кышкар мәдрәсәсендә укыганда, — дип, бер тарих та сөйләп алды. — Инде килеп дару мәсьәләсен әйтсәгез, моңа дару бер генә: өйдә тынычлык кирәк. Мондый авыруга сүз ярамый. Келт итеп өйдә бер җайсыз сүз чыктымы — бу егыла. Икенчесендә бөтенләй борып куюыгыз ихтимал. Өйдә тавыш чыгара күрмәгез, тавыш...

Шул минутта, чыннан да, өйдә җылы тынлык урнашты. Васфикамал, күләч елмаеп, күзләрен сөртә-сөртә, Шәйхи хәлфәне ишек ачып озатты. Шәйхи артыннан кайнана һәм килен чоланга чыгып баскычка утырдылар. Ташлытау ягыннан дымлы җил исә, күктә гөрелдәгән тавышлар ишетелгәләп куя. Карачкыл күк йөзен телгәләп-телгәләп еракта яшен ялтырап ала, һавага өлгереп килгән арыш исе таралган. Арыш басуы иртәгә кияү куенына керергә тиешле җиткән кыз кебек дулкынлана, тигезсез сулый, үзенең яшьлеге белән саубуллаша.

Бу — арыш камчылаган кич иде.

## Кешегә кул күтәрү —
## хатын алыштыру түгел

Урамда адәм аякланмаслык пычрак.

Менә өч көн инде сыек пычрак өстенә җепшек кар ява. Каз-үрдәкләрне суярга да көн юк, туңдырмаган көе мал-туарны ужымга чыгарып булмый. Кичләрен куе томан төшә, авеслек тирәсенә урманнан бүреләр килә. Шуны сизеп, авылда төн буе этләр елый. Һәрберсе оясына кереп, баскыч астына кереп, моңлы итеп елый. Әвеслек тирәсендә кайтырга соңга калган казлардан иртәгесен юеш мамык кына калган була.

Никадәр генә пычрак булмасын — Октябрь бәйрәмендә урам йөрергә чыкмыйча булмый. Муенга юеш кар ява, аяктагы галошны пычрак суыра, ә урам демонстрациясенә катнашасы килә. Узган ел күргән ачлыктан соң бу — беренче туклык бәйрәме. Келәтләрдә ашлык, өй астында бәрәңге. Колхозчының күнеле көр.

Урам буйлап халык төркеме килә. Иң алдагы рәттә гармун тоткан Миңлегали. Ике таякка кызыл ситсы тарттырганнар, аңа акбур белән лозунг язганнар. Гармун көенә алдагы рәттә җырлыйлар. Җырны бөтен халык күтәреп ала:

Кызыл байракның уртасы
Урак белән чүкеч.
«Берләшегез, бөтен дөнья
Эшчеләре!» диелгән.
Ленинград-Москва,
Урамнары таш кына,
Яшь йөрәгем капиталны
Бетерергә ашкына.

Җиңенә кызыл бәйләгән кеше — колхоз председателе Тимерхан — берәүнең капка төбендәге эскәмиягә басып лозунг әйтә:

— Яшәсен бөек Октябрь бәйрәме!
Бөтен халык «ура» кычкыра...

Аннан кызыл ситсылар белән бизәлгән мәктәп йорты янына җыелдылар. Җиңенә кызыл бәйләгән колхоз председателе караватшикелле бер нәрсәгә менде. Аның ике ягына ике яшүсмер килеп бастылар. Икесенең дә муенында кызыл галстук. Берсе авызына җиз труба капкан, икенчесе барабан аскан. Халык гөрләде, ябалак-ябалак юеш кар яуды. Председательнең өзек-төтек тавышлары ишетелде.

— Ханова Маһруйбикә, корсаклы булуына карамастан, йөз сиксән биш хезмәт көне эшләде. Колхоз идарәсе аны бүләкләргә карар бирде...

Трубаны кычкырттылар, барабан суктылар.

— Кәлимуллин Шәяхмәт, өлкән яшьтә булуына карамастан, өч йөз хезмәт көне эшләде...

— Кәлимуллина Васфикамал, колхозда туып-үсмәгән булуына карамастан, җәйге урак өстендә искиткеч күрсәткечләргә иреште. Колхоз идарәсе аны... Халык кул чапты.

Берничә көннән салкыннар китте, җир туңды. Каз өмәләре башланды, авыр елда өйләнми калган егетләр дә кыймылдый башладылар. Келәтләргә мул итеп ашлык салынды, бераздан авыл кар астында калды. Кыска көннәре белән тыныч, тук кыш башланды.

Рәхәт гомер тиз үтә. Нужалы көннәр генә озакка сузылып башыңны гаҗиз итә. Декабрьның соңгы көннәрендә колхозда ревизия комиссиясе эшли башлады. Шәяхмәт ревкомиссиянең председателе иде—ул көн-төн кәнсәләрдә ятты. Төн уртасында гына киемнәренә тәмәке көсе сеңдереп кайта торган булды, анда да кенәгәсен ачып, күзлеген тегәрҗеп белән борынына элеп, кенәгәләр актарып төн уздыра башлады. Ревкомиссиянең эше тәмамланугa, колхозда уңыш бүлү башланды. Бу — «тигезләү» дип атала иде. Ягъни җәй буе аванс алып ашаганнан соң «тигезләп» алу. Хәкимулла, күрше Миңлегали һәм башка яшьләр, атлар җигеп, флаглар элеп, уңыш таратып йөрделәр. Һәр йортта аларны аш-су белән каршыладылар, ара-тирә почмак яктан гына чынаяк чокырына салып әче бал бирүчеләр дә булгалады. Буралар, капчыклар тулды. Лодырь исемен алган Борһанга да хезмәт көненә тиешле ярты пот бодайны егетләр юри кызыл олау белән илттеләр. Әмма ялгыштылар: Борһан эшнең ничек булачагын белгән иде булса кирәк, капка төпләрен көрәгән, капканың аратасын алган иде.

Ишегалдына шөлдерләр, таңкәле йөгәннәр белән бизәнгән өч ат килеп керде. Миңлегали тальян гармунын үкертеп алды. Хәкимулла белән күкрәгенә КИМ значогы таккан яшь егет җырлап җибәрделәр.

Атлар төз лапас астына кереп буталдылар. Чоланга киез итектән, күлмәк изүләрен ачып җибәргән кызгылт йөзле Борһан килеп чыкты. Аның теле-телгә йокмый иде.

— Һу-у, күршеләр килгән икән, түрдән рәхим итәсез,— дип, ярты пот бодайны кадерләп кенә кулына алды. Пар чыгып торган ярым ачык ишектән өйдәге мәҗлеснең тавышы ишетелде.

Егетләр бераз каушап калдылар. Ул арада Борһан, этеп-төртеп дигәндәй, аларны эссе өйгә кертеп тә җибәрде. Түрдәге сәкедә таныш түгел ике кеше чокыр белән әче бал чөмереп утыралар иде. Йөзләре чөгендердәй кып-кызыл, күзләре майланган, таза беләкле куәт иясе кешеләр. Миңлегали читенсенеп ишеккә таба чигенде. Хәкимулла, бераз гына төшереп алса, үгез кебек куәтләнә һәм йөрәкләнә иде — ул түргә узды. Кызыл йөзле адәмнәрнең берсе карлыккан тавыш белән җыр башлады. Авызы ерылган икенчесе тамак төбе белән генә кыска көйгә такмаклый иде.

Хатын-кызлар уртак,
Маңгайларга пичәт...

Бу җырны егетләрнең моннан дүрт-биш ел элек ишеткәннәре бар иде. Бу — яңа нәрсә түгел. Нишләргә? Идарәдә расланган исемлектә Борһан юк иде, аларга кирәсе түгел иде бит... Нишләргә? Шулай уйланып торган арада Борһан почмак яктагы аралыктан ашъяулык япкан зур яшел табак күтәреп чыкты. Чаршау ачылып киткән арада мичкә ышыкланып качып торган кешене күреп Хәкимулла телсез калды. Почмак якта шыкаеп торган кеше — кайнатай Заһри иде. Алай икән...

— Әйдә, сыйдан рәхим итәсез,— дип, Борһан егетләрне сәке кырыена утыртты. Табак өстендәге ашъяулыкны ачып, егетләргә мыскыллы караш ташлады. Табакта... әле генә абзардан алып кергән туң сыер тизәге иде. Иң башта Хәкимулла сикереп торды.

— Син,— диде ул, йодрыгын Борһанның борын төбенә терәп,— син! Мин сине нишләтергә белермен! Мин сине жиде бабаңның кабер тактасын... — Ул яман сүгенеп җибәрде.

Борһан көчле кулы белән борын төбендәге йодрыкны сабыр гына урынына төшерде.

Мыскыллы елмайды.

— Я, күрше, син нәрсә, Борһан абыең сине сыйлый, ә син кул күтәрәсең. Кешегә кул күтәрү хатын алыштыру түгел ул. Шту син...

Кызыл йөзлеләрнең берсе, авыз тутырып елмаеп, Хәкимуллага дәште.

— Я, син, калай этәч, әйтеп бирче: сезнең колхозыгыз атамы ул, анамы?

Хәкимулланың күзләре урыныннан купкан иде.

— Ата, — диде ул, җиңеннән өстерәп маташкан Миңлегалине читкә этәреп. — Ата. Ну, ул синең ише ырвачларны, беләсеңме, нишләтә? — Хәкимулла тагын сүгенде. — Әнә шуңа күрә ата ул, белдеңме шуны, җиде бабаңның кабер тактасын сүтеп ыргытыйм... Колхозга тел тидерсәң, мин сине нишләтәсен белермен...

Ишекне «дык» итеп ябып, егетләр чыгып киттеләр. Атларның сыртына берәрне чиртеп, амбарга таба юырттылар.

Ул кичне эштән кайткач, Хәкимулла Васфикамал белән сөйләшмәде.

•

## Йомры башлы, кәкре аяклы ир бала

Инде ул көннәр артта калдылар.

Инде бөтен авылга «кысыр» дип даны таралган Васфикамал күрше урыс авылыннан тозлы кыяр алып кайтты. Ташлытауда иртәгә сабан туй буласы иде. Әче балның үкереп утырган, яңа тарттырган бодай оныннан келәт эчләре ап-ак булган, суелган тәкәләрнең тиресен киереп чормага элгән көннәр иде.

Васфикамал келәткә он иләргә кергән җиреннән, авыз суын йота-йота, эче бушаган кыярны суырды. Моны әле беркем дә белми иде. Хәерлегә булсын... Көтү кайткан вакыт иде, Ташлытау сабан туена чакырырга дип этисе килеп керде. Пөчмак яктагы мичкәнең бөкесен дыңдың китереп бәреп ачтылар. Өйгә эче бал исе тулды. Колхоз эшләреннән бераз бушаган вакыт иде, бер уңайдан күрше-күләннең ир-атын да дәшеп алдылар. Мондый мәҗлесләрдә бик сирәк була торган Шәйхи хәлфә бүген кыстатып тормады. Бер чокырны җибәрүгә, аның теле ачылды, үзенең яшь вакытларын тәмләп сөйли башлады.

...Шәйхи солдат пленнан кайткан елны ике көн эчендә бөтен авылны шаккатырырлык ике эш эшләде. Атлары үлгән вакыт иде — этисенең акчасын урлап, Теләче базарыннан чем-кара бия алып кайтты. Солдат ике көн югалып торгач, картлар борчылдылар — Шәйхи солдат төн уртасында гына шыпырт кайтып кереп, кара бияне лапас астына бәйләде. Өйгә керде.

— Кайда йөрдең, дуңгыз? — диде этисе.

— Мин,— диде Шәйхи,— нәкъ син эзләгән бияне таптым, түшәк эчендәге акчаңны табып, Теләчедән кара бия алып кайттым.

— Борчактыр инде синең,— диде әтисе мәрхүм.

— Борчакмы, горохмы,— диде Шәйхи,— чыгып кара әле.

Әтисе чыгып караса, лапаста колакларын шомартып кара бия басып тора.

— Ну, задур егет икәнсең,— дип, карт нишләргә белми сөенә. Әикенче көнне егет кара бияне җигеп күрше авылга китте. Анда пленда бергә булган дус егет бар иде — Әхмәдулла. Төн уртасында Әхмәдулланың капкасына атны бәйләде. Аларга шул көннәрдә генә ике кунак кызы килгән иде — Әхмәдулла Теләче базарында шунын берсен Шәйхигә димләмәкче булды. Келәтләренә барып керделәр, шырпы сыздылар. Чәчәкле ястык өстендә ике кунак кыз белән Әхмәдулланың сеңелесе чайрап йоклап яталар.

— Кайсы синеке? — диде Әхмәдулла, шыпырт кына. Түшәк кырыенда, ике озын толымына чорналып, калку күкрәкле, кыйгач кашлы берсе ята иде...— Менә,— диде Шәйхи,— шушысы. Солдат ялгышмады. Әйе. Керәсе ризык теш сындырып керә, диләр.

Яшь чакта Шәйхи хәлфә күп мәзәкләр эшләде. Бервакыт шулай, авылга килгән кунак кызны озатып куйды. Төз лапас астында тордылар. Тышта салкын, бозгак, каз суйган вакыт. Төз лапас ышыгына сөяләп кенә торганда хуҗа хатын комганын күтәреп чыкты. Нәкъ егет белән кыз янына килеп утырды. Кунак кыз дер-дер килде. Шәйхи дә эчкәрәк шыкаймакчы иде — салам кыштырдады. Шуннан — син күр дә, мин күр. Теге явыз сикереп тә торды:

— Бу кемнәр була тагын, оятсызлар, — дип тавыш чыгарды. Шәйхи бишмәтен башына бөркәде дә чыгып йөгерде. Арттан шалтырап комган очты...

Шулай да пленнан кайткан елны бер карчыкны кызык итте. Германнан электрик фонаре алып кайткан иде. Ул вакытта андый фонарь юк — кешегә күрсәтсән, аны җен дип беләләр. Чоланда качып торды — исәбе тегенең кызы янына керергә. Кызы өйалдындагы бүлмәдә йоклый иде. Ни хикмәттер, монда да шул ук хәл чыкты. Кызнын әнисе кич ятар алдыннан бисмилласын укый-укый комганын алып чоланга чыгуы булды, Шәйхинең аягына сөртенде.

— Каравыл!! — дип кычкырып та җибәрде. Шәйхи дә куркуыннан тегенең күзенә электрик фонарен гына төбәде... Мәрхүмә, ничә көннәр түшәк өстендә ятты, куркылыклар койдырды.

Әче балдан авыз иткәләп, Шәйхи карт шуларны сөйләде.

— Ә минем яшь чакта андый хәлләр аз булмады, — диде ул, кызып. — Уникенче елны җәй көне укудан кайттым, карт хәзрәт авырып ята — әле берсенең ире еракка китә, әле берсенең баласы туа. Хәзрәтнең дога кылып сәдака алырлык та чамасы юк. Менә бервакыт хәбәр тарала: Кәлимулла малае — зур укыган кеше, дип сөйли башлыйлар. Менә бер карчык бер тәлинкә ясмык оны күтәреп килә — сыеры чирләгән. Икенче берсе тегүгә чыга — юл сәдакасына тагын бер тәлинкә ясмык оны. Мин авырсынып кына дога күндерәм — анысы була, әмма, шәкерт булсам да, егет кеше бит, миңа ясмык оны ни чуртыма. Атна-ун көн узмый, бер базарда төшереп алган яшьтәшләр сүз ыргыталар.

— Без, — диләр, — сине туйдырабыз, соры корт син, — диләр. Миңа шул җитә калды. Кызган баштан авылга чатыр чабып, атны күбеккә батырып, кайтып кердем дә, урам уртасында тавыш чыгардым. «Кемгә бер тәлинкә ясмык оны бирәсем бар, килеп алыгыз, фәләнегезне фәлән итим»,— дип, базарда бодай саткан акчаны урамга бич чәчеп кайттым. Дөрес, урамда кызмача баштан күренүем шул бер генә булды. Әти дә бик тәртипле крәстиян иде, аннан соң мин авылда — бердәнбер укымышлы кеше. Унөченче елда Кара Чыршыда балалар укытып йөрдем. Безнең халык бик кара иде, мин балаларны бер ел эчендә әдрис язарга, хат

язарга өйрәтмәкче булдым. Картлардан бер-ике куштан каршы килә генә бит. Берсе — Гайфулла куштан иде — Ташлытау базарыннан кайтышлый мәптек ишеген кагып мине чакырып чыгара. Толып якасын торгызган, авызыннан котырган сыер сөте исе бәрелеп тора.

— Синме, — ди, — минем малайга хәрендәш алып килергә куштың?

— Әйе, — дим, — мин куштым.

— Ә ана хәрендәш нәрсәгә?

— Мин аны язарга өйрәтәм. Хәрендәш шуңа.

— Ана нишләп акча әрәм итим мин? Яза белми ул, яза белмәгән кешегә хәрендәш нәрсәгә?

— Соң бит, — дим, — әнә шул яза белмәгәнгә күрә хәрендәш кирәк. Теге һаман үзенекен тукый. «Яза белмәгән кешегә хәрендәш алырга мине кем дип белдең син? Әллә миндә әндри казнасы бар дип белдеңме?» — дип бәйләнә үк башлады. Мин дә кыздым. Мин әйтәм, әле син исерек баштан килеп монда мәктәпне мыскыл итмәкче буласыңмы? Толып якасыннан учлап тотып үземә таба суырып алдым да, ярабби, берне аяк астына җибәрдем... Теге бөтерелеп баскычтан очып төште. Икенче вакыт авыл җыенында миңа бәйләнеп ята:

— Беләм мин сезне, — ди. — Укыган кеше — чукынган кеше ул, — ди. — Сез, — ди, — үзегез өйдә чәйнек борыныннан гына эчеп ятасыз, безнең кара халык шикелле түгел, — ди.

— Менә, — мин әйтәм, — ту-ты шул-шул, — дим, — сез дә менә тегенди-мондый кирәге, җае булганда шулай чәйнек борыныннан гына җибәрә торган булыгыз, — дип сүгәм тегене.

Чокырдан бер йотым авыз иткәч, Шәйхи хәлфә мактана үк башлады.

— Ә миңа кешедән куркырга ничу! Гомер буе крәстиян хезмәтендә булдым, Кара Чыршы колхозында лабогрейканы миннән башка берегез дә көйли алмый. Миннән башка яшәп карагыз, ничек булыр икән... Ә мин күпне күргән кеше... Әйе, Германнан кайтышлый, мин сиңа әйтим, Мәскәүнең Саломанский циркында Ярославскийның үзен тыңлаганым бар минем. Пленныйларны җыеп митинг ясадылар. Ә сезнең әле аның үзен күрү түгел, ишеткәнегез дә юктыр. Ту-ты. Ә менә Галимҗан Ибраһимов дигән язучы бар иде шундый, мин бит аны да күрдем шул җыелышта. Ул Мәскәүдә зур эштә иде. Ул да сөйләде: «Сезнең, — диде ул, — теге якта гомерегез әрәм үтте. Инде уйлап карагыз, хөкүмәт үзебезнеке, — хезмәт иясләренеке, — диде. — Менә, — диде, — шул үзебезнең хөкүмәтне, үзебезнең влачны дошманнардан сакларга кирәк...» Менә кемнәрне күргән кеше ул абзагыз.

Бераздан тальянын күтәреп Миңлегали килеп керде. Миңлегали — Шәяхмәтнең апасы Фәхерниса малае, яшьли әтисез калып, һәр вакытта да нәселдә ирләр мәҗлесе булганда олылар чутыннан йөрде. Кызыл чәчәкле сатин белән эшләнгән тальянын тез башына гына утыртып, ул карт-корыны җыр дөньясына алып кереп китте. Мәҗлес хуҗасы Шәяхмәт, кулына чынаяк чокырын тоткан килеш, үзе җыр башлады. Зәйнәп җиңги ике тәлинкә белән майга чыжылдаган коймак чыгарып утыртты. Шәйхи хәлфәнең күзләре нурланып китте һәм тамагын кырып, әкрен генә ул да җырлап җибәрде.

Заһри кода да ярыйсы гына кызып алган иде, чират үзенә җиткәч, кыстатып тормады. Шәйхи хәлфәнең җыры тәмам булуга, ул «әйт шуны, кода» дип күтәреп алды да, елтыр күзләрен бит җыерчыкларына яшереп елмайды һәм егетләрчә куәтле тавыш белән башлап җибәрде.

Васфикамал зур самаварны өченче мәртәбә күтәреп чыкканда инде төн уртасы авышкан, мәҗлес кызган, асылмалы лампаның керосины бетеп, филтәсе күмерләнә башлаган иде. Миңлегали һаман әле тез ба-

шына утырткан тальянын теркелдәтә, ирләр исә бөтенесе бер булып «Кубәләгем-түгәрәгем» көенә сиптеләләр иде.

Кояш чыгышы ягы алсу нурга төренгәндә унлы лампа «гөлт-гөлт» килде дә сүнде. Баксаң, аның инде күптән кирәге дә юк, июньнең кыска төне әллә кайчан таңга авышкан икән. Кунаклар таралыштылар. Аягын ышкый-ышкый, Шәйхи хәлфә койма буйлап кына кайтып китте. Миңлегали өенә кайтып тормады — Нургали белән икесе печәнлеккә менеп киттеләр. Заһри кодага сәкедә зур чәчәкле ястык салдылар. Хәкимулла белән Васфикамал төз лапас астындагы тимер хутлы арбага чыгып яттылар. Арбага кичтән чабып салынган солылы вика, клевер түшәлгән иде. Сабан туйга барырга әзерләнгән тәртә арасына куйган яхшы сбруйдан күн исе чыккан, ул яңа чапкан печән, ат, сыер абзары исе белән аралашып, ниндидер, башны әйләндерә торган җәйге жылы төн исе хасил иткән иде.

Кызарып кояш чыкканда барлык кеше тирән йокыда иде. Өйдәге сәкедә, иске тубал теккәндәй гырылдап, Заһри кода йоклый, аның авызыннан әллә ниткән авазлар ишетелә. Печәнлектә бөтен фани дөньяның мәшәкатен онытып сабый балалар йокысы белән ике яшь егет мышный. Арба кырыена башын асылындырып, Хәкимулла ыңгыраша-ыңгыраша йоклый. Ул төш күреп елмая, төшендә ниндидер, йомры башлы, кәкре аяклы матур гына бер ир баланы алдында тотып утыра, имеш. Васфикамал аңа үзенең күрше урыс авылына барып килгәнлеген йокы алдыннан гына сөйләгән иде — шул минуттан башлап Хәкимулла өчен бөтен дөнья, аның кануннары үзгәрде. Аның өчен хәзер дөньяда бер нәрсә дә куркыныч түгел, ул җиңә алмаган авырлык дөньяда бөтенләй юк сыман иде...

Я, борынгызга чирттеме хәзер Хәкимулла абыегыз? Югыйсә кеше арасында сөйләшерлек хут калмаган иде. Әле узган көз генә Шәйхиләрдә сыер суйган көнне ирләр мәҗлесендә сүз чыгарып алганнар иде. Ни чыкмаса, шул Борһаннан чыга инде. Мәҗлестән таралганда, аралыкта, мич башы кырыена эленгән, өелгән киемнәр арасыннан Борһан үзенең бүреген эзләде. Караңгыда ялгыш Хәкимулла бүреген алып кия язды.

— Ах-ха-ха, — дип кешнәде шул чакта Борһан, — ах-ха-ха! Харап кына булыр икән кеше! Хәкимулла бүреген кисәң — беттем диген инде. Әле минем хатынның бер малай үстерәсе килә. Юк, энем, үзенә булсын, мә, мә... Ах-ха-ха!

Барысы да рәхәтләнеп көлделәр дә, бер минуттан оныттылар һәм караңгы чоланда тәмәке кабыздылар. Тик Хәкимулла гына юк булды. Аны бераздан Шәйхи абзасы лапас астыннан алып чыкты. Хәкимулла гарьләнеп үксеп-үксеп елый иде.

...Шулар исенә төшкәч, Хәкимулла анадан яңа тугандай булып китте. Менә бетте, үзды ул вакытлар... Не смей сез хәзер теш ыржайтырга!

Акрын гына иртәнге җил исеп куйды. Ул тәмле йокыдагы кешеләрнең өй түбәләрен сыйпап узды. «Йоклагыз, адәм балалары,— диде ул гүя,— йоклагыз! Бу — сезнең тыныч иртәләрегезнең соңгысы. Татлырак итеп төш күреп калыгыз — бу татлы төш шулай ук соңгысы. Йоклап калыгыз, сезне зур сынаулар, кара хәсрәт көтә. Нык булыгыз, адәм балалары!»

Бу җил, күп юллар узып, көнбатыштан килә иде. Кара Чыршы авылы өстеннән ул үткәндә канатларына кара тәре ясалган самолетлар үлем төяп көнбатыштан көнчыгышка юл алганнар иде. Төз гәүдәле, озын сыйраклы, пөхтә киемле фашист генераллары танкларын, тупларын тыныч йокыда җәелеп яткан Россия кырларына кертә башлаган минутта Кара Чыршы авылы, чыннан да, татлы йокыда иде әле.

Кырда иген чайкала, иген чайкала...

Бу — елына бер генә тапкыр килә торган атна. Ул атнада көннәр эссе дә, болытлы да булмый: кырда нинди дер зәңгәр дулкын йөгерә, арыш басуы яшелле-күкле булып сөрем эчендә кайный. Көр басуның шулай дулкынлануына карап торуы рәхәт тә, моңсу да. Менә җәйнең иң кыска төннәре житте, моннан соң инде көн кыскара башлар. Арыш басуы саргаер, ул инде дулкынланмас. Аны урып алырлар, борчак җиреннән кайтышлый ял итәргә чүмәләләр арасына торналар төшәр. Көз житәр... Һай, бу гомернең бәрәкәтсезлеге. Әле генә бит, сабан тургайлары яшел уҗым өстендә ук булып атылып сайрыйлар иде. Ә хәзер — арыш басуы өстеннән җил йөгерә — сагыш арта...

Арыш басуы уртасындагы тузанлы юлдан кара туры атында чатыр чабып Ташлытауга таба Тимерхан чыгып китте. Аның сиртмәсенең тавышы үзе күмелгәч тә басу түреннән ишетелеп торды.

— Запас пирвый категори, — диде Шәйхи хәлфә аның турында. — Аларның законы буенча егерме дүрт сәгать эчендә воянкум янында булырга тиешләр.

Сугыш, сугыш...

Сугышның нәрсә икәнен авылда Шәйхи хәлфәдән башка кем белсен? Шәяхмәт сугышта нибары ярты ел йөрде. Ә менә аның өлкән абыйсы Шәйхигә кирәгенчә эләкте. Гумбинен янындагы каты сугышта әсирлеккә төшкән Шәйхине Германиягә озаттылар.

Шәйхи солдат шул вакытта һоһенцоллерннарның[1] көньяк Германиядәге язгы сарайларын күреп телсез калды. Дөньяда һоһенцоллерннар да яшәгән, Кара Чыршының Кәлимулла малае дә яшәгән! Бу сарайның һич тә тарантас лапасы, мүкле абзар, Кәлимулла карттан калган иске келәт белән уртаклыгы юк иде. Тау башына таба сузылган мәрмәр баскычлар. Мәрмәр баскычлар кырына асылынып үскән әллә ниткән җимешләр... Салават күперенең бөтен төсен чагылдырган түшәмнәр, күтәрелеп карасаң, бүрегең төшәрлек манаралар. Аяк астында им өчен бер шырпы кисәген тапмассың... Бераздан ул Вюнсдорфка килеп чыкты.

Сугыш бетте, ләкин Вюнсдорфтагы татар әсирләрен өйләренә кайтару мөмкинлеге күренмәде. Шәйхи хәлфәнең мәдрәсәдә алган белеме монда кирәк булып чыкты. Алар әсир шәкертләр, мөгаллимнәр белән баракларда концертлар куеп йөрделәр.

Герман профессоры Вайль әсирләр арасында татар җырларын язып йөрде. Шәйхи солдат монда да кирәкле кеше булып чыкты. Ул мәдрәсәдә ятлаган шигырьләрен профессорга сөйләп күрсәтте. Профессор тылмач аркылы боларны җыеп китап чыгарачагын сөйләде. Апрель аенда Вюнсдорф кырында алар сабан туй да ясадылар. Шәйхи солдат шул вакытта Кара Чыршы авылында беркем дә күрмәгән һәм күрмәячәк хәлләрнең шаһите булды. Сабан туйда алар татарча көрәш, капчык сугыш кебек милли уеннарны күрсәттеләр. Аннан герман атларын җигеп җир сөрделәр, ат житмәгән сукаларга үзләре җигелеп йөрделәр, тубал белән иген чәчеп күрсәттеләр. Шәйхи солдат җир буенча беренче булып барды, тубалындагы бодайны «бисмилла» әйтеп герман җиренә чәчте... Германның кара-көлсу туфрагына бодай бөртекләре белән тавык йомыркасы ыргытты. Әйләнә-тирәдә шакмаклы чалбар, цилиндрлар кигән Берлин байлары, муеннарына ак челтәр чорнаган озын күлмәкле көяз хатыннар шау-гөр килеп кул чаптылар, «гут, гут, татариш зольдатен, гут» дип шауладылар. Әсирләр акчасына ялланган герман солдатлары җиз трубаларда «Каз канатын» уйнадылар. Аннан җилкәсенә нинди дер

[1] Прусс корольләре һәм герман империалистларының династиясе.

аппаратлар асып, авызына юан сигара капкан берәү нәрсәгәдер кычкырынгалап йөгереп йөрде. Моны Америкадан килгән гәзит мөхбире диделәр. Гәзитнең исеме «Чикаго трибюн» икән. Кара Чыршы авылының крестьян Шәйхи Америка корреспонденты алдында тубал тотып рәсемгә төште.

Герман армиясенең нәрсә икәнен, Пруссия алпавытларының Рәсәй халкына карашын авылда Шәйхи карттан да тирәнрәк аңлаган кеше кем булды икән? Вюнсдорфка эләккәнче Шәйхи солдат немец алпавытларында эшләде. Яшь алпавыт Лейпциг университетының философия факультетын тәмамлаган культуралы кеше иде. Хатыны — рус князьләре нәселеннән диләр иде. Алпавыт Шәйхиләргә яхшы мөнәсәбәттә булды, ормады-сукмады, хәтта бер тапкыр бәйрәмдә кечкенә генә бүләкләр дә бирде. Әмма крестьян Шәйхи бер нәрсәне бик нык төшенде: алпавыт һич тә бу әсирләрне кешегә исәпләми, аларны эшче хайван дәрәҗәсендә күрә иде. Аның өч ел буе, бер көн дә ялгыштырмыйча, боларны нәкъ сәгать биштә уятуы, бер минутка да ялгыштырмыйча, нәкъ төнге унберләрдә утларын сүндерүе, өч ел буена ашау-эчү тәртибенә бер генә төрле дә үзгәреш кертмәве Шәйхине җәберсетте. Аның иртән кырга килеп әсирләр белән елмаеп исәнләшүе, нәкъ бер үк сәгатьтә, бер үк минутта һәркөнне болар торган йортка кереп тикшереп йөрүләре егетләрнең күңелен җәрәхәтләде. Бу — салкын исәпкә корылган герман төгәллеге кешене изүнең аерым бер ысулы иде. Шул ук вакытта Шәйхи солдат немец алпавытларының сугыш тәмен бик нык яратуын, башка бер халыкта да булмаганча, боларда чит илләрне басып алу дәртенең көчле һәм нык икәнлеген күрде. Шуңа күрә сугыш башланган көнне беренче тапкыр урамга чыгу белән ул бер генә сүзне кабатлады:

— Ярманда машина күп, җәмәгать,— диде ул,— аллага тапшырдык. Батырлыкка безнең халыкка чыкмый чыгуын, иллә мәгәр, тегеләрдә корал таза. Аларның карчыклары да базарга барганда бисәпилкегә генә утырып чабалар. Уйнама син алар белән...

Ул көнне беркем бернәрсә аңламады. Ирләр эштән иртәрәк кайттылар, чат саен җыелышып тәмәке көйрәттеләр. Чыннан да, нәрсә икән ул сугыш? Ни өчен бу вакытта? Сабан туй итеп булмады бит. Аннан печәнгә төшәсе, игеннәрне урып-җыясы бар иде. Ни өчен шулай вакытсыз башланды? Хәкимулла шушы көннәрдә башка чыгарга тиеш иде— морҗачы гына килеп җитмәгән иде. Ничек инде ул шундый кызу эш вакытында сугыш башлыйлар? Башында мие бармы ул германнарның? Ичмаса, морҗа чыгарганны гына көткән булсалар...

Авылда иң беренче повестка Тимерханга килде. Тимерхан моннан берничә ел элек яшел фуражка киеп кайткан егет иде, аны беренче категорияле запастагы пограничник дип йөртәләр иде. Шуңа күрә аңа повестка килүне берәүне дә гаҗәпләндермәде. Беренче категория икән беренче инде, ни хәл итмәк кирәк? Барсын, күрсен, бәлки ул арада германны әле бәреп тә чыгарырлар. Инде бит соңгы ун ел эчендә никадәр көчәйдек. Клуб сәхнәсендә үз җиребезне саклау турында күпме матур җырлар җырланмады! Аннан, күпме егетләрнең күкрәгендә БГТО, ГТО, МОПР значоклары бар! Ә осавиахимчылар? Добрахимчылар дип йөрткәннәр иде үзләрен башта. Алар сөйлиләр иде, имеш, иптәш Ворошилов бер чакрымнан атып инә күзенә тидерә дип. Әгәр ворошиловча төз атучылар чик буена барып бассалар, германың түгел чуртым да чыдамас! Бер карыш та бирмибез дип әйттек бит моңарчы.

Шулай тагын ике көн узды.

Менә беркөнне кичен көтү кайтканда авыл дөрт итте. Колхоз кәнсәләренә бер пачка повестка килгән иде. Моңарчы күз авыруы белән солдаттан калып килгән Хәкимулла да, машинкада басылган кош теледәй кәгазьне кулына тоткач, әле аның чын мәгънәсенә төшенмәде. «Кружка, кашык, җылы кием, өч көнлек ризык, паспортны алырга. Чабата кими-

чә, күн аяк киеме белән килергә тырышырга». Башка бер сүз дә юк. Авылга шундый утыз кәгазь. Кеп-кечкенә авылга утыз кәгазь.

Ул кичне утлар озак янды, кемнәрдер төн буе гармун белән йөрделәр. Капкалар шыгырдады, келәтләрдә он тузгыды, моржадан төтеннәр урләде. Кыз-кыркын ашыгыч рәвештә ак оекбашлар бәйләде, һавада майлы күмәч исе аңкыды.

Сугыш шулай башланды.

Кешеләрнең әле бүгенгә кадәр өйләнешү, туй ясау, кунак жыю мөмкинлекләре бар иде — бүген ул бетте. Моңарчы әле ир белән хатын, килен белән кайнана талашалар, бер-берсенә җәбер сүзләре әйтәләр иде — хәзер алар бетте. Үпкәләп сөйләшми йөрүче егетләр-кызлар була иде — үпкәләүләр бетте. Сугыш дөньяның вак-төяген оныттырды. Бүгенгә кадәрге бөтен тормыш — бер төш күрү генә булган икән.

Хәкимулла кичен үзенең яңа йортында Миңлегали белән сөйләшеп утырды.

— Шушы йортта Васфикамал белән бер генә кич куна алмадым бит, энем җаным, — дип өзгәләнде. — Васфикамалга ярдәм ит, туганым, яме. Моржаны коелы итеп чыгарсын. Әтиләр белән аларның бик борчагы пешеп җитми, син күз-колак бул. Их, туганым! Син әле монда каласың. Нургали белән синең яшь кергәнче сугыш бетәр. Нургали бик наян булды. Әти белән әни аны бераз боздылар. Аннан соң, беләсеңме, туганым, нәрсә? Мин инде сиңа гына әйтим, — бер кеше дә белми торган серем бар бит. Хәтерлисеңме Атжабар Хисмәт кызы Миңниса белән ниләр күргәнне? Монда бит мин сине алдадым. Кызның яман исеме бармыюкмы, мин бөтенләй белмәдем. Мин ул төнне аның белән сөйләшеп тик яттым. Ә ул елап дулады. «Синең ирлегең кайда, сөйләшеп ятар өчен генә алдыңмени мине», — дип елады. Шуннан калганын син беләсең. Матур кыз иде бит ул. Ә Васфикамалны яратам. Теле зәһәр зәһәрен, әтиләрне дә бик җәберләде баштарак. Ну, яратам... Эшкә бик булган бит.

Миңлегали исә үз кайгысын сөйләде. Ул ике елдан бирле Зөләйха исемле бер кыз белән йөри иде, сугыш башланган көнне төшендә Зөләйханы күргән.

— Яңа салган өй бурасы янында йомычка җыеп йөри, җанашым, — дип, Миңлегали башын тотып яшь түкте. — Бура керсә — бетте диген инде. Я мин үлеп калам, я мин кайтканчы Зөләйхага бер хәл була. Төштә бура күрү — тәгаен генә үлем инде ул...

Төн уртасы авышкач кына юрган-мендәрләр күтәреп Васфикамал белән Хәкимулла моржасыз өйгә йокларга килделәр. Моңа өндәүчеләр Шәяхмәт белән карчыгы Зәйнәп булды.

— Барыгыз, бар, — диде Зәйнәп җиңги аларны озатканда, — барыгыз. Бер кич булса да үз нигезегездә кунып калыгыз. Бисмилла әйтеп ятыгыз. Барыгыз, балаларым. Йа алла, хәер-рәхмәтеңнән үзең ташлама... Үзеңә тапшырдык.

Ләкин сагыз исе килеп торган яңа өйдә күзгә йокы кермәде. Хәкимулла белән Васфикамал таң атканчы серләштеләр. Аларның тора башлаганнан бирле мондый итеп сөйләшкәннәре булмады. Васфикамал Хәкимулланың кытыршы сөякле кулларын үзенең яңагына куеп яшь сыкты, берөзлексез сөйләнде.

— Без яши белмәдек, әй, дим, синең белән. Тормышның кадерен белмәдек. Күбрәк мин узындым. Юкка-барга сүз чыгарып, синең җаныңны каһәрләдем. Шуның көялеге бу. Сугыштан исән кайтсаң, яши белер идек. Юк-бар сүз белән иң матур вакытларыбызның кадерен җибәрдек. Без яши белмәдек...

— Малай туса, ни исемле кушарсың? — диде Хәкимулла, авыр сулап. — Мин, нишләптер, малай булыр дип уйлыйм.

Васфикамал аңа тагы да ныграк елышты.

— Малай булса Нәриман, кыз булса Сәрия куябыз. Тик син генә тизрәк кайт.

Хәкимулла авыр сулады.

— Их, шушы төнне зур күсәк белән терәтеп торырга,— диде ул, ачынып...

...Таң атты, кояш чыкты. Ат абзарлары тирәсендә тимер ходлы арбаларны көйли башладылар, дугаларга кыңгыраулар тактылар. Авыл ыгы-зыгы килде. Әле берәү дә еламый, берәү дә шауламый. Бары тик йөгерешәләр генә. Мунча кергән, кырынган кызмача ирләр бер-берсенә йөгерешеп керәләр, кызу-кызу тәмәке суыралар. Каядандыр гармун тарткан тавыш ишетелә. Бу мәшәкать сәгать уннарга кадәр шулай барды. Повесткада «сәгать сигезгә Ташлытауда булырга» диелгән иде. Сәгать ун тулды, кемнеңдер әмере булгандай, капка төпләрендәге әсәрешкән атлар башларын селки-селки урамга борылдылар. Халык Ташлытауга чыгып китә торган юл чатына агылды. Күперне чыккач, бер арба ирләр җыр башлады.

Ал кисәргә, гөл кисәргә
Үтмәс кайчыларыбыз,
Киләсе ел бу вакытта
Булмас кайсыларыбыз?

Капка асларында койрыкларын кәкрәйтеп йөргән этләр күккә карап елаштылар. Тальян, шөлдер тавышына эт заты чыдый алмый... Койрыкларын җиргә терәп утыралар да, капка төбеннән китмичә генә күккә карап елыйлар. Бу тавыш күңелләргә шом сала. Нәрсәдер бар, дөньяның кай төшендәдер гаделсезлек бар... Эт күңеле сизгер, ул зрәгә генә алай шыңшымый. Хәер, этләр генә түгел. Шөлдер, гармун тавышына атлар да борчыла. Әсәренгән атлар борын тишекләрен киңәйтеп, башларын чайкый-чайкый, басу капкасына таба атладылар. Түбән очтан да шундый бер йөк ирләр күренде. Басу капкасы төбендә чуптарларын түбән иеп ялгыз каен тора. Юлга чыгасы атлар шул каен төбенә жыелдылар. Ике-өч гармун тавышы бергә кушылды. Болар өчесе дә төрле көйгә уйныйлар иде. Мондый буталган көйләр күңелләргә тагын шом салды. Чыннан да, бу сугыш дигәннәре әллә нинди куркыныч нәрсә икән! Хатын-кыз елаша башлады, атлар тыпырчынды. Күпер аркылы тагын ике арба ирләр күренде. Болар — эре сөякле, озын гәүдәле Атҗабарлар иде. Атҗабарлар элек-электән гайяр халык, базар, станция тирәләрендә эшне ялт та йолт әйләндереп килделәр, базар көннәрендә шактый кызып, төрле хикмәтләр дә ясыйлар иде. Аларның атлары да каен төбенә килеп туктады, ирләр арбаларыннан коелдылар. Тавыш-елаш көчәйде. Атҗабарларның печән салган арбасына кылыч борынлы, үткен күзле, муены-бите кара янган, ак күлмәкле берәү менеп басты.

— Җәмәгать, — диде ул тимер тавыш белән, — җәмәгать! — Гармуннарны шул минутта ук туктаттылар. — Җәмәгать! Мин сезгә менә нәрсә әйтмәкче булам. — Ул ап-ак кулъяулыгын чыгарып авыз кырыйларын сөртте. Шул вакыт Хәкимулла бу кешене танып алды. Сөйләүче кеше Атҗабарның Хисмәт иде. Халык аңа таба борылып катып калды.

— Бәхил булыгыз, туганнар, дуслар... Атҗабардан бүген чыгып китүчеләр арасында мин иң өлкәне. Беренче категория. Без кая барганыбызны беләбез. Безгә кайтулар булмас инде. Әйе, кайтулар — едвали. Сугышның нәрсә икәнен мин беләм. Фин сугышын күрдем. Бусы фин сугышы гына түгел. Фашист армиясе бик кабахәт армия ул. Безгә кайтулар — едвали. Бәхил булыгыз. Тату яшәгез. Кара Чыршылар! Миңа үпкәләүчеләр бардыр арагызда. Заманында җир селкетеп йөрдек. Үпкә-сапкагыз булса — онытыгыз. Безгә кайтулар булмас инде. Әйе, едвали... Дөньяда фашист дигән эт чылбырдан ычкынган. Ә ул — бик хәтәр эт. Едвали кайтырбыз.

Хисмәт шактый исерек иде. Арбага баскан килеш ак кульяулыгын болгый-болгый, ул җырлап җибәрде.

Агыйдел сулары кебек
Зур сулар булмас инде шул,
Зур сулар булмас инде.
Минем йөрәккәем кадәр
Ярсулар булмас инде.

Хисмәт арбадан төште. Басу капкасы төбендәге халык төркеме бер секунд эчендә бердәм авыр уфылдап кинәт кенә елый башлады. Моңа балалар чырылдаганы өстәлде. Шул вакыт Кара Чыршылар арбасы өстенә Тимерхан менеп басты. Аның тамагы карлыккан иде — халыкны чак тынычландырды. Ул кыскача гына речь сөйләде.

— Иптәшләр, — диде ул, — бу сугыш канлы, корбанлы булыр. Ә сез җебеп төшмәгез. Колхозны үзебез төзедек, шуны саклагыз. Бер-берегезгә ярдәмле булыгыз. Дөрес, безнең барыбыз да кайта алмас. Ләкин кайткан кешеләр алдында кызарырлык булмагыз. Сау булыгыз, әгәр председатель буларак ачуыгызны китергән чакларым булган икән — гафу итегез. Колхозны аяктан екмагыз, иптәшләр, сау булыгыз.

Кешеләр күз яшьләрен сөрттеләр. Атларны бора башларга кирәк иде, ләкин берәү дә үзе башлап басу капкасына атын бормады. Арбаларның күчәр башлары эләгеп матавыклаганда, Шәйхи картның койма буеннан сәер генә тавыш ишетелде. Шашкан халык төркеме шунда таба борылды. Монда — картлар икән. Күбесе киез итектән, каеры тун кигәннәре дә бар. Инде сиксәнне узып, соңгы ун елда капка төбеннән узмаган картлар да җыелганнар. Тип-тигез өч рәт булып сафка басканнар, кулларын колак янына күтәргәннәр, күзләрендә — ялварулы аяныч караш. Картлыктан нурлары беткән күзләрен яшьләндереп, тешсез авызларын ачып, Ташлытау юлына карап торалар. Бер карт яшелләнеп муртайган, казыклары авышкан киртәгә сөялгән. Әрекмән арасыннан аның маңгаи иске киез итеге күренә. Өстендә кызгылт-сары иске тун. Башында беләүләнгән түбәтәй. Аның күптән дөньяга чыкканы булмагандыр, ахры, чепи күзләре кояшка чагыла, үзенең авызында сүз чынлыгы өчен бер теше юк. Ул кипкән иреннәрен шапылдатып, авызын киң ачып, корышкан кулларын колакларына күтәреп азан әйтә.

Әшһәде әнлә илаһә иллялла-а-аһ!
Вә әшһәде әнлә мөхәммәде рәсүлулла-а-аһ!

Аның тавышы кабердән чыккан кебек тонык иде, ул калтырый-калтырый көйләде. Бу тавыш үлемне хәтерләтте. Картларның өметсез аяныч карашлары, дога тавышы халыкка яшен төсле тәэсир итте. Тагын елаш башланды. Нәрсә бу? Ни өчен? Моны берәү дә уйламады. Басу юлына тәялеп чыгып киткән ирләр шул ук юлдан исән-сау кайтырга тиешләр иде. Боларның берсе дә үләргә тиеш түгел, үләргә хаклары юк иде. Әнә шуңа күрә моңа ирешү өчен эшләнгән барлык чаралар да бүген урынлы тоела иде.

Инде атлар кузгалды...

Авыл, мәет чыккан йорттай, тын калды.

Бары тик карчык-коры гына ул көнне Хәбирә карчыкка йомырка илтте. «Шушы йомырка кебек бөтен көе кайтсыннар»,— дип, Хәбирә карчыкның ян сәкесендә ул көнне бик күп дога укылды.

Кичен күк йөзен болыт басты. Күптән яумаган яңгыр Ташлытау юлындагы тузанда тимер арба эзләрен тигезләде. Икенче, өченче көнне дә тоташ яңгыр булды.

— Бәндәләр күз яше бу, — дип, юеш тәрәзә пыялаларына битләрен терәп, киленнәр, аналар, карт-коры яшь койды. Яңгырга кушылып Васфикамал да өч көн рәттән елады. Бары тик Шәяхмәт кенә еламады.

— Көненең дә... ачуым килмәгәе, чисти... канады,— дип, ул унайсыз сүз әйтеп сукранды. Чөнки, идарә члены буларак, колхоз председателе вазифасын гомуми җыелышта аңа тапшырганнар иде.

Яңгыр тоташтан койды...

Урамнар йомшарды, кырда арыш башаклары сыгылып төште. Яңгыр Хәкимулланың морҗасы чыгарылмаган өенең түбәсенә койды — аннан яңа такта исе таралды. Басудагы игеннәргә койды — аннан баллы ис, юеш салам исе таралды. Ташлытау военкоматының түбәсенә койды, залының түшәменә үтте дә стенасын чылатты. Сугышка киткән егетләрнең штукатуркага карандаш белән язган-сызгалап калдырган соңгы эзләре җебеде. Атна буе яуган янгыр Шәйхи картның өйалдына үтте, яңгыр үткән урыннарга ул табаклар, ләгәннәр тезде.

Бетмәс-төкәнмәс мәшәкате белән авылда сугыш чоры тормышы башланды...

## Ат җиккәндә үзең җик...

Кара Чыршылар гомер буе җыр белән көн иттеләр. Кичләрен урамда да, кечкенә генә мәҗлестә дә, клубта да җырлап рәхәтләнәләр иде. Якын-тирәдә Кара Чыршыларның җырчы халык икәнлеге мәгълүм иде.

Инде җыр туктады. Күңелләрдә бары тик киткән кешеләрнең генә җырлары калды. Кешеләр үз эчләренә яшеренделәр. Тоз, кервчин, шырпы, сабын... Гасырлар буенча килгән саклану рефлексы кешеләрне шуңа этәрде. Мөмкин кадәр сак булырга, мөмкин кадәр экономияле тотарга. Табарга, тупларга кирәк. Тоз, керосин, шырпы, сабын... Әйтерсең герман солдатлары сабын белән тоз ашап, керәчин эчеп яшиләр.

Кешеләр үзгәрделәр. Көн саен көтелмәгән бер хәл була башлады. Сугыш башланып ике атна үтүгә, Ташлытаудан семьясы белән Заһри күчеп килде. Хуҗасы читтә яшәгән бердәнбер йортны сатып алган икән. Заһриның планы йомры иде, илдә чыпчык үлми. Кара Чыршы — ил ул. Егерме биш сотый бәрәңге бакчаң булганда исән калырга мөмкин.

Шул көннәрдә Васфикамал да башка чыкты. Картлар, авыр чорда бергә торыйк, дип ялынып карадылар, файдасы тимәде.

Васфикамал әдәп саклап кына сөйләште.

— Бер-беребезгә ярдәм итәрбез, бәрәңге бакчасы әрәм була,— диде.— Сезнең белән торсам, бакча бирмәсләр. Кайгырмагыз, сез мине ташламасагыз, мин ташламам...

Нургали районда гы зоотехниклар курсын ташлап, күрше-тирә авылларга кино куеп йөри башлаган иде. Дулкын-дулкын кара чәчле, кылыч борынлы, калын җилкәле бу чибәр егеткә күзләре төшеп, төн йокысыз калган кызлар аз булмады. Якын-тирә авыллардан бер Нургалидә генә велосипед бар иде. Кара Чыршы кибетеннән теш порошогы белән вакса, ислемай һәм «Пушки» папиросы кебек әйберләрне Нургали генә ала иде. Ләкин сугыш башлангач, бу рәхәтлек юкка чыкты: Нургалине паровозларга утын хәзерләү өчен мобилизация белән урман эшенә җибәрделәр.

Сугыш барысын да үзгәртте.

Моңарчы басудан келт-мелт каз куып йөргән Шәйхи хәлфә янгын сараена каравылга килде. Элек тегенди-мондый мәзәк хәлләр сөйләнеп йөрергә яраткан карт кинәт кенә бик җитдиләнде. Германияне үз күзе белән күргән булуы халык арасында аның абруен күтәрде. Хәзер аны Шәйхи хәлфә дип түгел, Шәйхи карт, Шәйхи солдат дип йөртә башладылар.

Шәяхмәт берәр атнадан председательлекне кешегә тапшырырмын дип йөргән иде — барып чыкмады. Райкомга чакырдылар да, кыска гына сөйләштеләр.

— Ничә яшендә?
— Алтынчыны вакладым.
— Грамотаң бармы?
— Гарәпчә, латинча бераз сукалыйм. Теге узган ел керткән хәрефләре белән әлегә кыен.
— Менә нәрсә, иптәш Кәлимуллин. Колхозның иң җаваплы постларында эшләгәнең безгә мәгълүм. Билгеле, ялгышларың да булгандыр. Ләкин сезнеке шикелле кечкенә колхозга без әллә каян председатель эзли алмыйбыз. Вакыты шундый — эшли тор. Алдагы бюрода расларбыз. Үзенне фронтта дип бел. Синең өчен фронт — иген басуы.
«Ялгышлар» дигәннән, Шәяхмәт бер нәрсәне хәтеренә төшерде. Мөгаен, яшь чырайлы бу егетнең элегрәк булган бер хәлне ишеткәне бардыр. Коммуна төзелгән еллар иде. Шәяхмәт аны оештыручы булды. Кыр станына чыктылар. Шунда яшәделәр, шунда эшләделәр. Дөрес, һәркем үз семьясы белән аерым бер почмакта йоклады. Дошманнар әйткәнчә, тоташ юрган булмады. Менә беркөнне корбан гаете килеп житте. Нишләргә? Коммуна әгъзалары арасында ураза тотучылар, Хәбирә карчыкка фытыр сәдакасы бирүчеләр байтак иде. Гаеткә бер көн кала болар быжгый башлады. Авылга кайтабызмы? Гает укырга ярыймы? Бәйрәм ризыгын кем пешерә? Боларны авылга кайтару — коммунаның абруен төшерү дигән сүз иде. Шәяхмәт төн буе кыр станындагы салам түшәгендә йокысыз ятты да, иртәгесен коммуна ашханәсендә гомуми чуттан кабартма пешертте. Гает кабартмасы тәмле булды. — Шәяхмәтнең шул көннән соң халык арасында дәрәҗәсе күтәрелеп китте. Ләкин бу хәл югарыга ишетелеп, өч көн үткәндә, аны кыр станыннан авылга кайтардылар. Бераздан коммуна да таралды.
Райком ишегеннән чыкканда ул шул көннәрне хәтерләде.
Шәяхмәт Ташлытаудан икенче кеше булды да кайтты. Кешенең эчендә ни барын кем белсен?
Ул тегәрҗеп белән эләктергән күзлеген хәзер борынынннан бер дә салмас булды. Сөйләгәндә русча сүзләр кыстыра башлады. Кырысланды. Ләкин эчтән сызды, көйде. Чыннан да, колхоз белән идарә итәрлек сәләт чамалырак иде. Моны ул үзе бик яхшы аңлый иде.
Ләкин иң катлаулысы — бюрога хәзерләнү булды. Шәяхмәт колхоз турында да, өйдән чыгып киткән малайлары турында да түгел, әнә шул раслану турында уйлап йокысыз калды. Сакал бөртекләре агарды. Я инде, Шәяхмәткәме соң шундый зур йөкне өстерәү? Аның уйлавынча, колхоз председателе ул яшь кеше булырга тиеш. Председатель кеше бервакытта да башын ватмый. Аның өчен дөньяда аңлашылмаган бер генә мәсьәлә дә юк. Житәкче кеше ул Шәяхмәт шикелле төннәрен йокысыз кичерми. Ул көне буе оештыру эшләрен алып бара да, төнлә тәмле итеп йоклый. Ә Шәяхмәт нәрсә? Олы малае ике тапкыр өйләнде. Бертуган абыйсы Шәйхи герман пленында булган кеше. Житмәсә, империалистик сугышка киткәндә авылда бер ел балалар укытып йөргән, мәдрәсәдә укыган. Хәлфә дигән исеме калган...
Шәяхмәт аштан язды. Саргайды, кипте. Юк, яңа кеше тапканчы колхоз белән бәлки ул житәкчелек итә дә алыр...
Саргайган кәгазьле кечкенә форматтагы колхоз уставын Шәяхмәт көн ятлады, төн ятлады. Хатыны белән сөйләшмәс булды. Уракчылар янына кырга барганда да уйлап барды. Эчтән сөйләнде. «Авыл хужалыгы артеленең төп нигезе... артельнең төп фондлары...»
Иртәгә бюро дигән көнне Шәяхмәтнең сабыр канаты сынды. Юк, болай булмый бит инде... Адәм баласының да сабыр итүенең бер чиге бар.
— Йа алла! Ничә еллар буе сине телгә дә алганым юк иде... — Шәяхмәт, ирексездән, шулай уйлый башлады. — Инде ярдәмеңне салып, иртәгә бюрода мине коткарсаң — актык сулышыма кадәр кеше-

ләргә яхшылык эшләр идем, үзем турында уйламас иде. Иа хода! Гафур рәхим...

Кич белән ул, карчыгыннан яшереп, келәт иднәненә җәймә җәйде.

Ләкин намаз укымаганга егерме биш еллар чамасы икән шул. Бөтенесе бергә буталды.

— Әгузы билләһи минәш-шәйтан ирражим. Бисмиллаһи рахман иррәхим. Илаһи ният кылдым кичке намазга... Үзеңнең төп бурычыңны нидә күрәсең? Фронтны икмәк белән тәэмин итүдә. Авыл хуҗалыгы артеленең нинди фондлары була? Иөземне юнәлдердем кыйбла тарафына... Колхоз милке дип нәрсәгә әйтәбез?

Шул кичтә крестьян Шәяхмәт ак җәймә өстенә утырып гомере буе халык мәнфәгате өчен көрәшергә, бу юлда актык тамчы канын кызганмаска ант итте. Актык тамчы кан... Кашыклы кан... Бу — кайдадыр ишетелгән сүз. Кайда икән? Әһә, утызынчы елларда, Ташлытаудан агитбригада килгәч, кыска чәчле ике кыз сәхнәдә җырлаганнар иде.

Комсомоллар кемнәр алар?
Алар безнең братлар.
Кашыклы канга калганчы
Көрәшергә ырадлар.

Алай икән... Юк, әгәр иртәгә аңа шундый зур эш йөкләсәләр, Шәяхмәт кашыклы канга түгел, ә актык тамчы канга калганчы халык өчен эшләр, көрәшер...

Ләкин иң гаҗәпләнерлеге бюро утырышында булды. Шәяхмәт белгән бөтен нәрсәне күңеленнән барлап бетергән иде инде — аны чакырып алдылар. Билен шөпшәдәй кысып буган сары чәчле бер хатын, Шәяхмәт килеп керүгә, папкасын ачып укый башлады:

— Кәлимуллин Шәяхмәт, чыгышы крестьян, фәлән елгы, фәлән елда коммуна оештырган, партиясез, чит партияләрдә тормаган, чит илдә туганнары юк... — Беткәнче шуның эше. Колхоз турында ләм-мим. Ник кенә бер сорау бирелсен. Ул арада тавышка да куйдылар.

— Расларга дигән тәкъдим бар, — диде кемдер.

— Кем дә кем... Бертавыштан.

Картның гаҗәпләнүенә чик-чама булмады. Ул шулай аптырап калган көе кайтып китәсе иде, ярый әле, райкомның беренче секретаре — Искәндәрев фамилияле шәһәр егете — Шәяхмәтне бюро утырышыннан соң озата чыкты. Тәмәкесен кабызып, тар коридорда картның җилкәсенә кулын куйды.

— Син, иптәш Кәлимуллин, зур йөкне өстеңә алдың. Менә яшь кешенең киңәшен тыңла. Халык алдында бервакытта да үзеңнең көчсез икәнеңне күрсәтмә. Халык алдында җебеп төшмә. Сөйләгәндә ышаныч белән генә сөйлә. Аерым кешеләрне масса алдында ачуланма. Масса алдында күбрәк мактарга тырыш. Ачуланасы кешең булса — аерым сөйләш. Ат җиккәндә үзең җик — кешедән җиктермә. Халык кара куллы, үз арасыннан чыккан җитәкчене ярата. Көчең җитмәс лодырь белән бервакытта да кеше алдында бәхәсләшмә. Без ярдәм итәрбез, ләкин үз башың үзеңдә. Ну, бывай... — Карт шунда гына аңына килде.

... Председатель булып расланып кайткан көнне Шәяхмәт колхозның гомуми җыелышын җыйды. Үз гомерендә беренче мәртәбә җыелыш ачты. Мөмкин хәтле русча сүзләр кыстырырга тырышты.

— Давайте, иптәшләр, алгарак узыгыз. Бик сурьезный әйберләр турында сөйләшәсе бар, — диде клубка җыелган хатын-кыз, карт-корыга дәшеп. — Менә икенче атна сугыш бара. Колхозчылар җанын фида кылып тырышалар, иптәшләр. Әмма ликин безнең колхоз членнары арасында эшкә салкын караучылар бар. Кайбер эштән турыдан-туры баш тартучылар — отказчиклар бар. Эштән отказ бирү — бүгенгесе көндә җинаять эше. Отказчикларга рәхим-шәфкать булмаячак. Эшкә чыгып та

адәм рәтле эшләмәгән иптәшләр юк түгел. Алар белән мин аерым сөйләшермен. Кайберәүләр уйлыйлар, шту мин үз кеше, малограмотный дип. Юк, җәмәгать, алты сукканга бер атлаган ала бия кебек йөрүчеләргә миннән пощады булмаячак. Птамушто фронтка икмәк кирәк... Иптәшләр, белеп торыгыз, — дип тәмамлады ул сүзен, — безнең Кызыл Әрмия герман әрмиясен барыбер җиңәячәк, сугыш бетәячәк. Колхоз яңадан элеккечә булаячак...

Бу — беренче тапкыр чиркәнчек алу иде.

Шулай да элеккеге Шәяхмәттән котылып председатель Шәяхмәткә әйләнү бик авыр барды. Менә, мәсәлән, телефоннан сөйләшүне генә ал. Тимерхан стенадагы телефонны бора иде дә, бугаз тамырларын бүртереп, районлагы әллә кемнәр белән кычкырып сөйләшә иде. Шәяхмәттән анысы булмый. Ләкин районга көн саен кич бер чылтыратырга кирәк. Телефон бик начар эшли, шуның өстенә бер линиядә биш авыл. Тегеннән дә, моннан да тыгылалар. Һәр авыл кичке алтыда районга мәгълүмат бирә. Бу — бик авыр эш. Шуңа күрә табельщица кыз моны үз өстенә алмый. Аннан соң, районнан кушылганча, председатель үзе дә көн саен бер тапкыр үзәк белән бәйләнешкә керергә тиеш.

— Ташлытау! Ташлытау дим! Әлү, әлү, Ташлытау! — Шәяхмәтнең кичләре әнә шулай газаплы уза. — Чү, кайсыгыз өрә анда? Өрмә, өрмә, алланың ачы каһәре суккыры! Ташлытау! Ташлытау! Өрмә дим анда, кайсы авылныкы син! Өрмә, чукынчык, барыбер кем икәнеңне беләм. Атҗабар бит син. Кем малае икәнеңне беләм мин синең. Хисмәт чукынчыгы бит син. Ташлытау... Әлү. Әлү. Өрмә дим, башың беткере... Бусы кайсы авыл килмешәге тагын? Барыбер кем икәнеңне белермен. Сводка соңга кала бит. Ташлытау, Ташлытау, өф-өфф...

Председатель булуның әнә кай яклары да бар икән. Болары инде кырдагы эшне оештыруга караганда да авыррак иде.

Көзге якта караңгы төннәр башланды.

Һәр көн үзе белән бер яңа мәшәкать, һәр төн бер куркыныч алып килә. Кайдадыр, кемнәрдер сугыштан качып дезертирлыкта йөриләр ди. Кайдандыр, кемнәрдер Кара Чыршы басуына чыгалар да, бодай уып, ашап, урманга кереп китәләр ди. Ташлытаудан Нәбиуллин килеп, әллә ничә мәртәбә урам каравылчыларын тикшереп китте. Элеккеге тыныч тормыш бетте: элек, каравылга чыккач, урамны бер-ике әйләнә идең дә, каравыл өенә кайтып әкият сата идең... Хәзер төне буе урамда йөрергә кирәк, тәрәзәләрдән ут күренсә, барып шакырга, кисәтергә кирәк. Күпердән узучыларны тикшермичә җибәрмәскә. Кем ул, кая бара, ни эзли? Боларның барысына да председатель җаваплы.

— Син монда, — диде аңа участковый Нәбиуллин, — гарнизон начальнигы. Смотри, бөтенесе өчен башың белән җавап бирәсең...

Нәбиуллин еш кына төн уртасында килеп каравылчыларны тикшерә иде — бер төнне үзен дә тоттылар. Каравылда Борһан икән. Борһан сугышка менә китәм, менә китәм дип, гел военкоматтан борылып кайта иде. Колхозда да рәтләп эшләмәде, бүген-иртәгә сугышка китәсе булгач, аңа эш кушучы да булмады. Соңгы тапкыр ул урам каравылына шактый салып чыккан иде, тәмәкесен учына яшерде дә күпер кырыендагы тал төбенә утырды. Авыл тып-тын. Эт тә өрми. Тик Ташлытау юлыннан гына тарантас тавышы ишетелә. Борһан колакларын сагайтты. Тарантас авылга таба килә иде. Менә бервакытт җан-фәрманга чабып күпергә яхшы ат килеп керде. Борһан мәче тизлеге белән тал төбенн[illegible] сикереп чыкты да атның башына асылынды. Ат өркеп ал санын күтәрде һәм ачы тавыш белән кешнәп җибәрде. Тарантас эчендәге кеше очып ат артына — тәртә арасына барып төште. Авылда этләр өрә башлады, атның дилбегәсе чорналды, ал арба борылып, тарантас ауды. Тәртә астыннан, ат аяклары арасыннан сузылып килеп чыккан кеше Нәбиуллин икән. Ул караңгыда Борһанны чамалап алды.

— Борһан, син нишлисең?
— Ә мин каграз дезертирларны тотам.
— Җибәр атны, син нәрсә, мине танымыйсыңмы әллә?
— Тануын таныйм, но җибәрә алмыйм. Мин бүген каграз дежур.
— Соң дежур булсаң бул, мин бит — Нәбиуллин. Син бит исерек, җибәр атны!
— Ие, мин исерек, но мин каграз дежурыем.
— Борһан, мать честная! Җибәр, дим, атны, син бит ләх исерек...
— Ие, мин исерек, но мин каграз дежур бүген. Каграз мин дезертирлар тотам. Пчаму син фронтта түгел? Ә? Менә мин дежур бүген...
Нәбиуллин чак-чак кына бу бәладән котылды. Урамда тавыш ишетеп күпер янына Шәяхмәт төшкән иде, ат башыннан Борһанны шул гына аерып алды.
Ике-өч көннән соң Борһан сугышка чыгып китте.

## Салкын сугыш

Сугыш башлангач та Заһри, беренче тапкыр, үзен кайгыртты. Улының әле сугышка яше керми иде. Райондагы таныш-белешләренә берничә түшкә сарык озатып карады, аннан шыпырт кына районга ике йөк каен утыны илтеп кайтты. Ләкин комиссиягә чакырудан туктамадылар. Тән, теш, күз таза — нәрсә дип сугыштан калырга кирәк? Тукта, исәп кирәк, хисап кирәк, диләрме әле? Берничә сарык һәм ике йөк утын эшли алмаган эшне ике такта чәй әйләндереп чыгарды. Дөресрәге, Хәбирә карчыкның дәвасы коткарды.
— Менә, күрше, синең үзеңә генә өйрәтәм,— диде карчык,— шушы гөмбә череген кич ятканда колагыңа өрдер. Бер көн өрдер, өч көн өрдер, җиде көн өрдер. Колагың саңгырауланыр. Мичкә тәгәрәткән бәрәңгедән башка ризык ашама — йөзең саргаер. Иртән йокыдан торгач, бер чокыр тәмәке суы эч — йөрәгең кагар. Комиссиягә барасы көнне ике чокыр эч. Инде бик тә каласың килә икән — үз тизәгеңне аша. Сугыш беткәч, боерган булса, өемне сипләп бирерсең.
Ул көннәрдә Хәбирә карчык Заһрилар белән ике арада күп чабулады. Кара Чыршының МТСта шофер булып эшләүче бер егет әйткән, имеш:
— Ну, шушы Хәбирә карчыкның ботына счетчик куяр идем, көненә күпме җыяр иде микән? — дип. Чыннан да, аның эше авыр иде: өрлек кадәр Заһрины чирлегә чыгарырга кирәк иде.
Атна-ун көн үтүгә Заһри саргаеп кипте, күрше-күлән белән сөйләшкәндә колагына кулын куеп тыңлый башлады. Халык арасында төрле хәбәр таралды. Имеш, комиссия вакытында военком үзе килеп кергән дә, Заһри чыгып барганда аның янында гына идәнгә чылтыратып акча төшергән. Заһри ялт итеп борылып караган ди. Ләкин врачлар, йөрәген тыңлап, әлегә калдырып торганнар ди. Шулай да кодасы Шәяхмәт аны кызык итте. Бернәрсә ишетмәгәнгә салышып йөргән көннәрендә ул Заһрига хәл белергә керде. Хәл-әхвәл сөйләшеп утырган уңайдан ул кодасының кече кызы Гөлфияне янына чакырды да әкрен генә сораша башлады. Төнлә белән кемдер эскерттән бер ат йөге салам урлаган иде. Шулай, шулай, диде. Шәяхмәт, әтиең узган төн салам алып кайттымы, аны кая куйдыгыз, диде. Заһри күзләрен елтыратып сәке буенда утыра, Гөлфиягә нәрсәдер әйтмәкче була, ләкин сабый узган төнне булган хәлне сөйли башлый. Шуннан Заһри түзми:
— Гөлфия, бар, дуңгыз, сабагыңны кара, — дип әйтергә мәҗбүр була.
Ахырдан Гөлфиягә эләгә эләгүен, ләкин бу хәбәр халыкка фаш була. Шул көннән башлап халык белән Заһри арасында ниндидер салкын

сугыш башлана, мөмкин кадәр аның белән очрашмаска, сөйләшмәскә тырышалар. Ләкин төп мәсьәлә инде хәл ителгән иде, Заһри сугыштан калып торды. Ул арада кече улы Әхмәтзарифның да срогы житте. Монысын инде икенче төрлерәк юллар белән коткарырга кирәк бит, каһәресе!

Яшьтәшләре беренче мәртәбә каралырга киткән көнне Әхмәтзариф ат җигеп көлтә кертергә чыкты: аның метрикасында нибары бер сан үзгәргән иде.

... Бер көнне кич Заһри идарәдән кайтканда Шәяхмәтне сагалап торды да:

— Әйдә, кем, кода, кодагыең бик әйбәт сарык итеннән аш пешереп калды, колхоз-район хәлләрен сөйләрсең, кешесенә күрә генә бирәр төрек малае да табылыр, — дип кыстый башлады. Шәяхмәт риза булды. Өрмәгән җиргә утыртмадылар председатель коданы. Өстәл астыннан гына чирege белән аракы да чыгарылды. Бераздан Заһри шунда утырган җиреннән түнде; Шәяхмәт ашын гына ашап, бик рәхмәт, дип кайтып китте. Икенче көнне кич, нәрәт биргәндә, Заһри кода икмәк тапшырасы атларны төнгә бүрәнә өмәсенә сорый килде. Ләкин шул минутта Шәяхмәтнең пружинасы ычкынды. Ул ачуланып өстәлгә сукканда, Заһриның бите шәмәхә кара белән тулды.

— Күземә күренәсе булма, син мине кода гына дип белдеңмени? — дип, ул аны бөтенләй куып чыгарды.

Гомер буенча авылда дошмансыз яшәгән Шәяхмәт өчен бу хәл бик авыр тоелды. Ләкин нишләмәк кирәк? Шуның өчен дә сугыш вакыты бит ул.

## Миңа бит нибары кырык дүрт яшь

Ташлытау ягы егетләре бер батальонда сугышка керделәр. Батальон беренче бәрелештә үк каты кырылды. Алар лагерьдан килгәннәр иде. Лагерьда бер ай агач кистеләр, землянка казыдылар да, бер төнне кинәт кенә товар поездына төялеп фронтка чыгып киттеләр. Лагерь кешеләрне бик йончытты. Кухня төзеп, ашау-эчүне, мунчалар салып, аларны рәтләгәнче керләнеп беттеләр. Хәрби кием алганчы шактый гомер узды. Аяк киемнәре тетелеп бетте. Болай да йөрәге селкенеп кенә торган Хисмәт бу хәлләргә түзмәде, бер көнне политинформация вакытында үзен фронтка җибәрүләрен сорап, тавыш чыгарды.

Бар иде дөньяның йөрәкле, таза, чибәр бер егете. Аны Атҗабарның Камали Хисмәте дип йөрттәләр иде... Инде ул җан бирә алмыйча ята.

Кан тама, нарат ылыслары белән аралашкан дымлы комга Хисмәтнең каны саркый. Менә ул, кырык дүрт ел буе аңа куәт биргән нәрсә, тамчылап әрәм була. Атҗабар басуындагы ипидән, шундагы һавадан, шундагы судан ясалган кан Фин култыгы буенда тама. Кешенең бөтен матурлыгы — канда. Кешенең бөтен яхшылыгы — канда. Җан дигәннәре шул кандыр ул. Тукта, җаным, тукта, акма. Тамма, җаным, мине сакла. Аһ, бу кыйпылчыкны! Каян килеп эләкте соң бу! Ичмасам бер генә фашистны да тәрәп атып булмады бит. Сугышка килеп йөрүеңнән ни файда?

...Чолганышта калган яралы Хисмәт Фин култыгы буендагы нарат урманы эченнән озак шуышты. Ничә сәгать? Ничә көн? Моны ул белмәде. Беренче көнне шуышканда кая таба барганын белмәде. Беренче бомба, беренче курку барысын да онытырган иде. Аларның батальонына каршы диңгез буеннан танклар һөҗүм итте. Снаряд кыйпылчыгы Хисмәтнең тез башын чәлпәрәмә китерде, бер иптәше белән танкка кар-

шы шуышкан Хисмәтне һава дулкыны нарат астындагы чокырга атып бәрде. Иптәше яр буендагы зур валун артына йөгерде. Хисмәт чокырда аерылып калды һәм бераздан аңын югалтты. Аңына килгәч, шуышты да шуышты. Сугыш тавышы инде бөтенләй ераклашкан иде. Кара тәреле самолетлар нарат башларына тияр-тимәс кенә очып йөрделәр. Аларга атучы булмады. Димәк, фронт сызыгы чигенгән.

Төн узды. Икенче көнне Хисмәт зур чуер ташлар арасыннан шуышып диңгез буена килде. Диңгез тыныч кына чупылдап ята. Ләкин бу ни хәл? Хисмәт үз күзләренә ышанмады. Дулкын белән чыгарылган иске камыш чүпләре арасында йөзләгән фуражкалар, бескозыркалар чайпала иде. Йа алла! Күз күреме җирдә шулай баш киемнәре чайпала. Ә диңгез акчарлаклары берни дә булмагандай чиелдыйлар, уйныйлар...

Хисмәт тешләрен кысты. Сүгенде. Флягасыннан бер йотым су эчте. Бүгенгә җитәрлек су бар. Ничек тә алга, үзебезнекеләргә таба шуышырга кирәк. Кояш чыккан як үзебезнеке.

Ул көнне кич кояш бик кызарып батты. Диңгез буенча алтын күпер сузылды. Биек наратларның эре ылыслары алтын төсенә керделәр. Тукта, бу кайсы ай? Августмы? Сентябрьме? Урман эче салкыная башлады. Тәнне дерелдәү басты. Бераздан эссе булып китте. Аннан төн житте. Урманда ниндидер бер кош төне буе борчылып кычкырды. Ул гел Хисмәт өстендә генә кычкырды. Бу кошның тавышы бик таныш иде. Бу кош... Бу — козгын. Хисмәтләрнең авылында ул мәчет аена кунып кычкыра иде. Камали карт шул козгын кычкырса, бөтен тынычлыгын югалта, «мәет өмет итә ул, каһәр», дип мәчет ишегалдына кереп, козгынны куркытып йөри иде. Тукта... Бу — Фин култыгы түгел, Атҗабар икән бу... Менә хикмәт. Менә мин сезгә сөйлим әле беренче бомбаның ничек төшкәнен...

Хисмәттә гангрена башланган иде.

Шул төнне ул аңын җуйды. Иртәгесен аны чолганышта калган ике сугышчы табып алдылар. Хисмәт аңына килеп күзен ачты. Саташам дип уйлады — күзен йомды. Тагын ачты. Ләкин саташмый икән. Аның авызына су тиереп торган сугышчыларның берсе Кара Чыршының Хәкимулла иде. Хисмәт ут кебек кызган куллары белән аның кулын кысты. Аннан зур пилотка кигән ябык кына рус егетенең кулын озак тотып ятты. Мондый вакытта сугышчылар берсен-берсе ташламыйлар, димәк, хәзер үлмәскә генә кирәк. Болай булгач — булды.

Көндез кыймылдарга ярамый иде. Чокырга урнаштылар да, кичне көттеләр. Хәкимулла белән рус егете ботаклар җыеп носилка ясадылар. Бил каешларын носилкага бәйләделәр. Хисмәттә яшәүгә өмет чаткысы кабынды. Рус егетенең әйтүенә караганда, фронт сызыгы ун чакрым чамасы ераклыкта иде. Бу сүз күңелләрне җылытты. Көн озын булды, өч сугышчы комлы чокырда, нарат башларына карап, үткән тормышны искә алдылар. Хисмәт төштән соң кызыша башлады. Күзен йомгалап ятты. Иртәнге дәрте сүрелгәндәй булды. Берничә тапкыр үлем турында сөйләнеп алды.

— Минем, — диде ул, — Миңнисамның ике айлык кызы бар. Зөлфия исемле. Син исән-сау кайтсаң, безнекеләрне күр. Безнең авылга бар. Ташлытауга да бар. Минем ничек үлгәнемне сөйлә... Ә син теге вакытлар өчен бер дә оялма. Минем олы кыз Миңниса үзе чая булды. Мин сиңа ачу тотмадым. Теге көнне генә әтиең белән сүзгә килеп алдык та... Минем кыз чая булды. Үземә охшаган. Аннан, бик яшь тә иде бит ул вакытта. Унҗидедә генә...

Хисмәт бөтен гәүдәсендә ниндидер бер рәхәт талгынлык сизде. Менә ул үзләренең киртәсенә сөялеп тора. Егет вакыты. Җәйге кич. Кызлар уенга төшәргә җыеналар. Хисмәт шәһәрдән кайткан курсант. Ак күлмәктән, галифе чалбардан, хром итектән. Менә әтисе кичке намаздан кайтып килә...

...Әтисе, мәрхүм, юаш кеше иде. Авыл халкы аны Табак Камали дип йөртте. Уникенче елда Атҗабарны кызыл әтәч ялап чыкты. Бөтен кешенең диярлек йорт-җире янды, әмма Камали картныкына, читтәрәк булгач, зыян тимәде. Халык күрше-тирә авылларга чыгып китте. Халык ярдәм итә — Атҗабарлар урамга килеп керү белән кайсы он, бәрәнге, кайсы балта, пычкы, киез итек чыгарып бирә. Камали картның эче пошып ята. Беркөнне ул да тәртә башларын күмерләндерә дә Кара Чыршыга китә.

— Кайсы авылдан? — дип сорыйлар.

— Атҗабар, — ди бу, күзләрен сөртеп. Шуннан тегенә бер табак биреп кайтаралар. Шул көннән башлап аны Табак Камали дип йөртә башлыйлар. Картның үлүе дә бераз мәзәгрәк булды. Атҗабарга колхоз оештырырга килгән бер шәһәр егете аларда фатирда торды. Егет көн саен иртән бәкегә төшеп су коена. Карт тегеннән сорый:

— Нәрсәгә кирәк бу хикмәт? — ди. Егет әйтә, минем, ди, озак яшисем килә, ди, коммунизмны күрәсем килә, ди. Карт үлүдән бик курка иде, гомерен озынайтырга теләп, чатнама суык бер көнне бәкегә төшеп чума. Йөгереп кайта да, мич башына менеп тә ята. Шул ятудан тора алмый...

Хисмәт исә бай күңелле булды. Теләгәнчә яшәде. Сабан туй саен батыр калды. Әтисе юаш, фәкыйрь күңелле кеше иде. Ләкин әнисе үткен хатын — Хисмәт шуңа охшаган. Усал булды. Атҗабарга кунакка килгән җыен чибәр кыз Хисмәткә эләгә иде. Бер кунак кыз янына кем барасына бәхәс чыккач та, Хисмәт җиңде. Атҗабар урамын чатнама суык көнне көпә-көндез кем ялан аяк әйләнеп чыкса, кичен кунак кызны шул озата, диделәр. Хисмәт урамны ялан аяк әйләнде. Кунак кыз моны ишетеп хурланып елады. Ә кичен Хисмәтне күргәч өнсез калды. Хисмәт чибәр иде. Кунак кыз шул кичне үк үзе башлап чоланда аны суырып үпте. Егет булса шундый булсын, диде. Икенче вакыт тагын шулай бәхәсләштеләр. Атҗабарда егетләр шундый, йорт саен бер ташбаш. Анысында шәһәрдән килгән алтын тешле бер укымышлы кыз иде. Бу юлы да Хисмәт җиңде. Кем бер сарык бәрәнен ашап бетерсә, кичен кызны шул озата, диделәр. Камали картның бер бәрәне шул бәхәснең корбаны булды. Алтын тешле кыз, кич очрашкач, рәхәтләнеп көлде. Син, егет, миңа бик ошыйсың, ну сиңа укырга кирәк, диде. Женотделда эшли икән. Шуның сүзе белән Хисмәт курсларда йөреп кайтты. Ветеринар булды. Ул вакытта байтар дип йөртәләр иде.

...Хисмәт уянгандай итте. Әле генә күз алдыннан кичергәннәрен дәвам иткәндәй сөйләнә башлады.

— Юк, мин шәп яшәдем. Колхозда минем кадәр хезмәт көне эшләгән кеше булмады. Бәйрәмдә кунак җыймыйча калмадым. Минем әрдәнәгә өйгән ике еллык каен утыным гына калды. Ә син безнекеләрне күр. Минем карт әнине күр. Мин аның яраткан улы идем. Син чыгарсың... Чыгарсың...

Кояш батар алдыннан Хисмәт саташа башлады. Яман сүгенде.

— Ну, бу алла да нәрсә карый икән, ә? Миңа бит нибары кырык дүрт яшь. Әнә безнең авылның Габделхәер карт әле дә яши — мин малай вакытта ук карт кеше иде инде. Беркеме юк. Үлем көтеп яши. Ник мине үтерә бу алла, ә? Миндә ни үче бар аның? Ну, теге дөньяга баргач, тәгәрәп үлсәм дә, Гитлерны эзләп табам. Сукыр тәре! Әле минем җырлап яшәр вакытым бит! Едвали ул исән калыр, миңа эләксә... Едвали... Едвали...

... Сапер көрәкләре белән юеш комны казып, Хисмәтне күмделәр. Кабер өстенә нәкъ тегермән ташы төсле түгәрәк бер чуер ташны шудырып бастырдылар. Караңгы төшкән, көнчыгышка таба барырга вакыт иде.

Ә теге кош нарат башында һаман кычкырып калды...

## Миңлегалинең Гарәбстанда йөргәне күренә

Кырык беренче елның көзендә кар бик иртә яуды да, бөтен ашлык чүмәләләрен күмеп калдырды. Шомлы көз иде ул. Каз-үрдәкләрнең яшь карда тәпиләре алсуланып, гомерләре беткәнне сизеп, адашыпаңгыраеп йөри башлаган көннәрендә кисәк кенә жылытты да куйды. Бер көн эчендә басу ала-тилә булып калды. Хәбирә карчыкның нәкъ шундый ала төстәге карт сыерын шул көнне кич әвеслек янында бүре харап итте. Иртәгесен куе авыр томан таралгач, аны карарга халык жыелды. Карт иде инде. Җәйге кичләрдә мөгрәп кайта иде. Хәбирә карчыкның жил капкасы ачык булмаса, «өйдәләрме?» дигән сыман зур күзләрен тәгәрәтеп, селәгәйле танавын капкага төртеп ыңгырашып тора иде. Ә хәзер... Комсыз бүре аның арт санын талаган, бугазын чәйнәгән, хәтта сырт сөяген урталай өзәргә маташкан. Никадәр газаплангандыр сыер...

— Сугыш хикмәте инде бу, ярман жиреннән әллә ниткән яллы бүреләр килгән, безнең бу тирәдә туп шартламагач, аларга тыныч инде, фәлән инде, төгән инде... — дип, бу хәбәрне ул көннәрдә авыл буенча Хәбирә карчык таратып йөрде. Имеш, узган атнада таң белән базарга баручылар елга буенда әллә нинди зур, бозау кадәр өч бүре күргәннәр, үзләре яллы, үзләре аксыл-соры ди...

Бу хәбәр житә калды. Тагын әллә кемнәр андый бүреләрне урман аланында чүннек янында да, басуда да күргәннәр. Язгы ябагасы коелып бетмәгән ач бүренең эшләгән бу җинаяте бик күп имеш-мимешләр белән, жепшек көндә әвәләгән кар шикелле, тәгәрәткән саен үсте дә үсте. Ул ел әллә нинди тынгысыз, шомлы булды. Бер куркыныч хәбәрне икенчесе бастырып кына барды.

Ул елгы кадәр зәһәр салкын кыш булганы юктыр. Иртә көн тудымы, хатын-кыз хәл белешергә керешә.

— Сугыштагы бәндәләрне кыру өчен инде бу суыклар, йа хода! — дип авыр сулыйлар. Шуннан китә хәбәрләр... Германнар, имеш, Мәскәүдә икән инде. Аларны яклап төрек патшасы сугышасы, ди. Алдагы рамазан гаетендә Казан каласында чәй эчмәсәм, иманым кяфер булсын дип әйткән, ди анысы. Мин сугышсам, дин өчен сугышам дип әйтә, ди. Сугыш башларга түбәтәем селкенеп кенә тора дип әйтә, ди. Хәбәр артыннан хәбәр — берсе икенчесеннән куркынычрак. Калада төнлә кисәк кенә трибүгә ясыйлар, күктә әллә ниткән утлы көлтәләр йөриләр, ди. Калада картларны да сугышка жибәрәләр, ди. Тагын әллә ниләр әллә нәрсәләр бар, ди. Аргы як Хәлиулланың да хаты килгән, ди. Кайда сугышканыбызны әйтергә ярамый, хатны пулевой почтага гына язасы, дигән. Ходаем, бөтен дөньясын пуле баскандыр инде. Мичкә киптерергә куелган кура жиләге ничек кимеп чыкса, сугыштан без дә шулай чыгабыз дип әйткән, ди.

... Заманына күрә тәртибе, гореф-гадәте, жыры үзгәрде. Кышның зәмһәрир суыкларында кызлар һәр кичне клубка жыелалар. Клуб эче бәсләнеп йолдызланып тора. Рәтләп ягучы юк. Утын китерүче юк. Салкын, салкын. Җанны жылытырлык берни юк. Сугышка кадәр атнасына ике генә көн ачылган клуб хәзер һәр көн ачык. Сугышка кадәр авызыннан сүз тартып ала алмаслык кызлар ачы тавыш белән жырлыйлар. Ачы, зәһәр тавыш белән... Җыры да салкын.

Көтмә, кызый, сөйгәненне,
Кайтмый туган иленә,
Озын-озын окопларда
Атып яткан вакытларда
Пуля тигән иңенә...

Агитбригадалар килә башлады. Салкын клубта калтыранган артистлар бер кат күлмәктән сәхнәгә чыгып коточкыч нәрсәләр сөйлиләр. Гитлер, Геббельс, Риббентроп... Ничек җир йөртә аларны. Менә бер чандыр хатын кыска чигүле күлмәктән чыгып, туңа-туңа шигырь сөйли. Бала төнлә уянган икән. Әнисе янына килгән, Кызчык әйткән:

«Әнкәй! Мин Гитлерны күрдем төшемдә...»

Салкын төндә, стеналары йолдызланган клубта салкын күзле бу ябык хатынның куркыныч шигыре җанны өшетте. Гитлер дигән сүз белән салкынлык, ничектер, бергә генә йөри алалар кебек тоелды.

... Төннәрен урам тын була, утлар сүндерелә. Соңгы төннәрдә Шәяхмәтнең апасы Фәхерниса карчыкның гына тонык ут яктысы күренә. Кышның шул зәһәр көннәрендә аның карап торган бер улы Миңлегалинең үлгән хәбәре килде. Күрше авыл егете: «Миңлегалине үз кулым белән җирләдем, немец минасына шартлап харап булды, әнисенә әйтегез», дип язган иде. Ләкин ул хат килгән көнне Фәхерниса карчыкка биш-алты юллык кына кара пичәтле кәгазь килеп төште. Атларга кичке башак биреп кайтканда — ул Миңлегали урынына ат караучы булып калган иде — хат ташучы ана шул кәгазьне тоттырып чыгып китте. Язу танымаса да, ана йөрәге аның нәрсә турында икәнен сизде, тез буыннарының җегәре китте, ләкин күзенә яшь килмәде. Ул икенче көнне, Миңлегалинең яратып җигә торган бурлы атына башак биргәндә, атның башын кочаклап озак елады, ул көнне бурлыга онны бер соскыч күбрәк сипте. Шуннан соң аның йокысы качты, гел төнлә белән Миңлегали кайтып кергән кебек була: капка-койма шыгырдап алса да, салкыннан өй бүрәнәсе шартласа да, ул күзен ача, ишеккә озак карап тора, кысып куелган бишле лампаның филтәсен күтәрә төшә, ләкин Миңлегали юк, ишек кырыенда, кәтүктән эшләнгән чөйдә аның пальтосы гына эленеп тора.

Фәхерниса карчык гомер буена эш яратты, колхозга беренче булып язылды, малаем кешедән ким булмасын дип, тол көенчә тырышып карап үстерде. Дин тотмады, юк-барга ышанмады, ләкин әйтеп бетермәслек кайгы аны какшата язды, ул бер көн эштән кайтышлый Хәбирә карчыкның карындык тәрәзәсен какты. Тышын таракан кимергән корьәнне карчык озак актарды, бер аятен гарәпчә мыгырданып, корышкан бармагы белән йөртеп чыкты да, тамак кырып, тезеп китте:

— Вау[1] килсә бәхетле булыр, халык арасында кадерле булыр, капкадан кергәндә зәхмәт җиле кагылган булган, сул ягында бер авыруы булган, анысы бер усал хатынның күзе төшкәннән. Үлмәсә әле дә исән буласы икән, исән булса, Гарәбстанда җимешлектә йөрүе күренә,— дип, эшлекле кыяфәт белән корьәнне киштәгә алып куйды.

... Таң атканчы Фәхерниса карчыкның уты шулай яна, ә салкын төн сорылана башлагач, зирәк йокыга тала, ләкин нәкъ шул вакыт, әкрен генә ишек ачылып, Миңлегали килеп керә-дә, йомшак тавыш белән:

— Әни, әни, мин атларга башак бирергә соңга калганмын бит,— дип, әнисенең баш очына килеп юрганына кагыла. Фәхерниса карчык ниндидер бер йөрәк рәхәте белән җылынып сискәнеп уянып китә, күзен ача — аһ, ул Миңлегали түгел, юрган өстенә аның бердәнбер иптәше — әдрәс мәчесе сикереп менгән икән. Стена сәгате авыр герен идәнгә таба өстерәп тек-тек килә, тын өйдә аның тавышы «юк-юк» дигән кебек булып ишетелә. Фәхерниса карчык урыныннан тора, «юк шул, бәбкәм, юк», дип авыр сулый, кемдер йөрәккә салкын су коя, йөрәк туктагандай итә, баш шаулый... Ул акрын гына ат абзарларына таба атлый, эш вакытында ачы хәсрәт онытылып тора. Менә ул ат абзары янындагы инешкә аркылы салынган күпер өстенә кергәч туктый, күпер канатына сөялеп хәл ала, тагын үйга кала... Миңлегали сугышка чыгып кит-

[1] Вау — гарәп алфавитындагы «у» хәрефенә якын авазның исеме.

кәндә ул баш өянәге килеп авырып ята иде. Улының әйберләрен төн йокламыйча әзерләде, иртәнге чәйдән соң, баш чатнавына чыдый алмыйча, ян сәкегә менеп ауды. Иптәшләрен белешергә дип чыгып киткән Миңлегали бераздан кызмача кыяфәттә кайтып керде. Ана белән ул икәүләп җылый-җылый капчык тутырдылар, ул әнисен урынына яткырды да, ике кулын биреп күрештe һәм читкә карап кына:

— Әни... күрешә алмасак, ни... яме... бәхил булышыйк... — дип нәрсәдер сөйләнде, капчыгын җитез генә күтәреп, кульяулыгы белән күзләрен сөртә-сөртә, чыгып китте. Капка төбендә шөлдерле атлар ярсып тыпырдаша, Миңлегалинең кызыл чәчәкле сатин белән тышланган тальянын аргыяк егете өзелердәй итеп тарта иде. Тимер ходлы арба менә шул күпергә килеп кергәч, Миңлегали дилбегәне үз кулына алып, атларны кисәк кенә туктатты да, кепкасын салып арбага ыргытты һәм туп-туры тау башына, әнисе янына йортка таба йөгерде. Килеп керүгә, әнисе яткан сәке янына тезләнде һәм карт ананы күкрәгенә кысып кочаклады да, күз яшенә тыгыла-тыгыла йөгереп үк чыгып китте, өйдә коточкыч шомлы тынлык урнашты, тик мәче генә ишек янагына үреләүреләү тырмаша иде. Яңгыр булыр, ахрысы, яңгыр. И, бала, бала... Арбада утырган иптәш егете алты айдан соң аның аяк-кулларын җыеп күмәчәген ул чакта кем уйлаган... Юньле бала иде Миңлегали. Үләренә бер атна кала гына командирларыннан Фәхерниса карчыкның үз исеменә хат килгән иде. «Әби, — дигән иде командир, — бик батыр ул үстергәнсең, хөкүмәт, партия сиңа кат-кат рәхмәт укый, андый егетләр белән бу сугышта без, һичшиксез, юлбасарларны дөмектерербез».

Ул көнне Фәхерниса карчык мичкә мул якты, сандык төбеннән күптән салып куйган меңенче чәйнең почмагын китеп алды да лепердәп кенә самавар кайнагач, күрше-күләнне чәйгә дәште. Күңелле иде ул көн! Әй, гөнаһ шомлыгы, Гитлер, муйның сынсачы, актык минутларында авызыңа су тидерүчедән мәхрүм булсаңчы! Ярабби, дөньядан имансыз үтсәңче! Шул вакыт әче таң җиле исеп китә, еракта карның таң кызыллыгы белән тоташкан җирендә нindидер шөбһәле тавыш ишетелеп куя:

— Та-та-та, та-та-та, — дип көйли. Ул тавыш, әллә ничек шунда, сугыш кырыннан килгәндәй тоела, бәлки, чыннан да, тын куыра торган җил ул тавышларны монда сугыш кырыннан ук алып киләдер.

— Та-та-та, так-так-так...

Бәлки ул сугыш тавышы да түгелдер, күрше колхозның төнге сменадагы молотилкасы тавышыдыр, ләкин нигәдер ул тавыш бик шомлы, бик куркыныч булып ишетелә... Шул тавыш колакка килеп кергән саен кар өстенә бер кеше егыладыр, кар өстенә кып-кызыл булып кан саркыйдыр кебек тоела...

Тишек чиләгенең суы агып беткәч җиңеләйгән кое сиртмәсе авыр шыгырдап икенче якка авыша, коры агач тавышы, салкын төн тынлыгын кистереп-кистереп, еракка яңгырый:

— Шулайдыр, шулайдыр, — дигән кебек ишетелә.

Чорма тәрәзәләрен аллландырып таң сызылганда Фәхерниса карчык ат абзарларына барып җитә.

## Игеннәрне кем җыяр?

Бер әвеннән утыз пот чамасы арыш чыга...

Әвен киптерәләр, чабагач белән сугалар, аннан, суырып, Ташлытау элеваторына озаталар. Халыкның күңел күрәя — теше таза булган кеше арыш башагын уып ашый, эштән кайтышлый янгын сарае янындагы агач мичкәгә ятып су эчәләр. Карт-коры гына хәлсез.

Яраланып госпитальдә ятканнан соң гвардия өлкән сержанты Тимерхан авылга кайтып төште. Титак-титак атлап, бөтен авылны йөреп чыкты, басуларны әйләнде, амбарга, ат абзарларына сугылды. Көннәр бик кызу тора, игеннәр дә ярыйсы гына. Тик халык ач — бөтенесенең күзендә нур беткән, уен-көлке, җыр ишетелми. Эссе көнне ачлык аеруча яман хәл. Ачлыкның шундый бер вакыты җитә, инде ашыйсы килми, ә берөзлексез сусата. Янгын сараенда каравыл торган Шәйхи карт Тимерханга үзләренең хәлен аңлатты: карчыгы бүген он капчыгын кайчы белән турап аш салырга калган...

Партия райкомына, военкоматка учетка баскан көнне үк Тимерханга әйтеп кайтардылар: кайтуга колхозыңны кабул ит, теге карт бик тырышып эшләде, дәүләткә икмәк тапшыру буенча Кара Чыршы колхозы районда беренче булды, ләкин яшьрәк кеше кирәк иде, диделәр. Идарә утырышында Шәяхмәт колхозның эшләрен тапшырды. Амбарда бер бөртек ашлык юк; базда бер бөртек бәрәңге юк; җигү атлары бөтен колхозына тугыз баш; эш үгезләре — таналары белән — унике баш һәм башкалар.

Икенче көнне үк Тимерхан, әвеннән чыккан арышны тарттырып, халыкка аванс бирде. Хезмәт көне мул булган кешеләрдән алтышар кило он алучылар булды. Өченче көнне иртән сәгать бишкә Тимерханны райком бюросына чакырдылар. Тимерхан гимнастеркасын үтүкләде, орденнарын, медальләрен кадады. Яңа председатель буларак, беренче мәртәбә бөтен формасын туры китереп күренергә уйлады. Сугыш башланганда беренче секретарь булып эшләгән яшь кеше әле дә монда икән. Ләкин аны өлкә комитеты пленумына чакырганнар. Бюроны икенче секретарь алып бара.

Бу кеше Тимерханга таныш. Зур башлы, зур борынлы. Фамилиясе Хәйруллин. Утызынчы елларда Атҗабарда, Кара Чыршыда избач булып эшләп йөргән иде. Аның исемен дә, фамилиясен дә белүче булмады, «ызбач» дип кенә йөртәләр иде. Фамилиясен белгән кешеләр дә һәр вакыт башка Хәйруллиннар белән бутамас өчен «баш» Хәйруллин дип йөртәләр иде. Сугыш башлангач үк Хәйруллинга бронь бирганнәр дип сөйләделәр. Токтымал зур борынлы кешенең «бронь» алуы халык арасында мәзәгрәк яңгырады, «ызбачка борын бирганнәр» дип, исләре дә китмичә сөйләп йөрделәр ул вакытта...

Хәйруллин зур борынына күзлек элеп куйган да, кешеләргә күзлек өстеннән карый. Алдында ике-өч пачка «Беломор». Өстендә китель. Полковник дип белерсең!

— Я, — диде ул, Тимерханның эше турында бюро членнарыннан бер хатын-кыз сөйләп биргәч, — я, аклану өчен нәрсә әйтә аласын?

Тимерханның үпкәсе тамак төбенә күтәрелде.

Мөмкин кадәр тыныч булырга кирәк иде.

— Беренчедән, — диде ул, — мин суд каршында тормыйм, ә үземнең партиядәшләрем янында басып торам.

Хәйруллин аңа мыскыллы караш ташлады.

— Нәрсә, икенче сүзең дә бармыни?

— Әйе, бар, иптәш секретарь. Мин ике ел ут астында йөрдем, минем белән Жуков һәм Рокоссовский сөйләшкәне бар, ләкин алар да миңа «сез» дип дәштеләр.

Хәйруллин нервыланып папироска ябышты.

— Я, я, син... Сез... бик остармагыз монда. Сез нәрсә, әллә фронттан кайттым дигәч тә, теләсә нәрсә эшләп йөреп булыр дип уйлыйсызмы? Җинаятегез турында сөйләгез! Сезгә кем рөхсәт бирде аванс өләшергә? Безнең указаниены ни өчен көтмәдегез? Шулмы сезнең фронттагы иптәшләрегезгә ярдәм итүегез? — Хәйруллин, калтырап, пышылдауга күчте. — Коммунист, понимаете ли...

Ул берөзлексез папиросын чәйнәде.

— Кара Чыршы колхозы председателенә бюро членнарының сораулары бармы?

Тимерханның эше турында сөйләп биргән хатын тамагын кырды. Бу — районның прокуроры Улибаева икән.

— Сораулар юк, — диде ул, карандашын өстәлгә бәрә-бәрә, — мәсьәлә ачык. Вәлетдинов Тимерхан партиядә кала алмый. Йомшак күңелле булуны партия безгә гафу итмәс. Карарбыз, алдарак ничек эшләр.

Урындыклар шыгырдап куйды.

Ачык тәрәзәдән тышта коеп яңгыр ява башлаганы ишетелде. Барысы да тышка таба борылдылар.

— Да-а, кызыл олау киләсе көн иде бит бүген, — диде Хәйруллин, папиросын чәйнәп, — болай булса, эш харап.

Улибаева кулындагы карандашын өстәлгә бәрде.

— Алласын да тотып... фәлән итәргә... — Ул яман сүгенде.

Тимерхан тетрәнеп китте. Алай икән... Болар сугыш вакытында шулайрак өйрәнгәннәр икән... Хәзер хатын-кызлар да сүгенә икән. Ләкин яңгыр бик кирәк иде бит әле. Бәрәңге чәчәкләре көеп ята иде. Аңысын ник уйламыйлар?

Хәйруллин сәгатенә карады.

— Ярар, иптәшләр, башка фикерләр юкмы? Кем дә кем... Бертавыштан. Иптәш Вәлетдинов, партбилетыгызны куегыз.

Тимерханның күз аллары караңгыланды. Тукта, бу бик таныш картина бит. Кайда булды соң әле мондый хәл? Әһә, госпитальдә ятканда ул «Күтәрелгән чирәм» дигән романны укыган иде. Анда да партбилетны чыгарып салырга әйтәләр. Әһә, әһә...

— Иптәш Вәлетдинов...

Тимерханның күзен кан басты, калтырана башлады. Менә бер секундка хәтер тау кадәр әйберне актарып алды. Менә кырык өченче елның июль киче. Рота командиры траншеяда коммунистлар белән сөйләшә. Һөҗүм сәгате якынлаша, иптәш коммунистлар, ди. Коммунистлар исеменнән рота парторгы Вәлетдинов сөйли. Тырышып, дулкынланып сөйли...

— Өйдә калган карт аналарыбыз, сабый балаларыбыз хакына актык сулышыбызга кадәр көрәшербез...

Ә аннан таң атканда тревога булды. Тимерхан күзен ачканда күк йөзе үкерә, көнчыгышны горизонт артындагы кояшның нурлары кыпкызыл төскә керткән, җир гүли иде. Бу — бөтен дөньяга мәшһүр Курск һөҗүме башланган минут иде.

Каяндыр салкын, җансыз тавыш ишетелде.

— Партбилетыгызны куегыз, иптәш Вәлетдинов...

Тимерхан кинәт кенә озын өстәлне этеп җибәрде. Өстәл кырыендагылар сискәнеп киттеләр.

— Партбилетнымы? Партбилетмы сезгә, иптәш Хәйруллин? — Ул үзенең тавышын үзе танымады. — Минем партбилетым кирәкмени сезгә, тыл батыры? Менә сиңа, Хәйруллин, менә... кулыңны башта гөлҗиһан сабыны белән ю!.. Менә сиңа, күрдеңме?..

Тимерхан Ташлытауны ничек чыгып киткәнен белмәде. Җылы яңгырдан соң ялт итеп кояш чыккан, урамда пычрак, җан-фәрманга чапкан ат тоягыннан чәчрәгән сыек балчык әллә кайларга оча иде.

Ул көнне идарәдә әвенне тәүлегенә ике тапкыр куярга дип карар кабул ителде. Шәяхмәт әвен киптерүче итеп билгеләнде. Элеккеге председатель өчен яңа тормыш башланып китте. Ул төнлә мич яга, әвен ташы өстеннән башакларны җыеп ала, мичкә ут җибәрә.

Әвен өеп бетергәч, кай вакытта аның янына янгын сараенда торучы абзыйсы Шәйхи карт та килеп утыра.

— Пожар-фәләннән берүк үзе сакласын, чамалап эшлә, — дип, башта кырыс кына сөйләшә. Әвенне бер кат әйләнеп чыга, мич алларын тикшерә. Мич каршына утырып, гадәт буенча сугыш хәлләре турында сүз куерта башлыйлар.

Шәйхи карт сугыш башланганнан бирле Германия турында гына сөйли.

— Ярманда, түлке, машина күп инде анда, — ди. — Батырлыкка безнең солдатка чыкмый инде чыгуын, әмма ликин тегеләр машина күп булу белән алдыралар. Аларның бит тегендә-монда барганда карты-карчыгы да бисәпилкегә генә утырып чаба.

Мичтә ак чыршы утыны шартлап яна, ике туган берсен-берсе бүлдермичә генә сугышка кадәрге тормышны, мул ризыкны, рәхәт көнне, тыныч төнне искә алалар. Шәйхи карт матур сөйли. Аның бик кызык бер гадәте бар: ул чиктән тыш арпа коймагын ярата, хәзер шуны сагына. Сүзгә керешсә, шуны телгә алмый калмый.

— Һәй, алла, эштән кайтышыңа һәйбәт такта чәй пешеп, табада арпа коймагы чыжылдап утырсын иде,— ди. Әйтүен дә ул үзенчә арпы коймагы дигән төслерәк итеп әйтә. — Менә бу тормыш нәрсә инде? Ашарга утырсаң, мин сиңа әйтим, алдыңда кычыткан ашы. Ә бүтән нәрсә юк. Иллә мәгәр, күзе чыккыры Гитлерны әйтәм, җимерде тормышны, дәргяһтан сөрелгән. Ниткән көйле иде бит. Колхозны ничек күтәргән идек бит. Сугыш беткәч, менә әйткән иде диярсең, иртәнге чәйне кайнар арпы коймагыннан башка эчмәм.

Ут янында утырып Шәйхи картның буыннары йомшый, җитмешне узган картка каланча башына менеп сәгать сугуы көч җитмәслек эш булып тоела.

— Бар, улым, вакыт җиткән булса, берәрне бәреп төш әле, — дип, ул бу эшне җае килгәндә янындагы малай-шалайга куша. Төннәрен ул зирәк була, әмма иртәнге якта аны йончыта, вата башлый. Кайчакларда аны сәгать исәбен дә буташтыргалый дип сөйлиләр. Имеш, унберунике тирәсенә китсә, астагы кешеләргә санап торырга әйтеп менеп китә икән. Шулай бер чак «җитте!» дип кычкырырга онытканнар да, ул берне артык суккан.

— Җитте, артык булды, — дип кычкырулары булган, Шәйхи карт чигереп алам дип, тагын берне суккан. Барлыгы әллә ундүрт, әллә унбиш булган. Ләкин коры, җилле көннәрдә каланча башыннан аны чакырып та төшерә алмыйсың. Әле бер якка, әле икенче якка борылгалап, ул акрын гына көйләп утыра.

Утырдым атның биленә,
Киттем ярман җиренә.
Ярман җире яшел үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм.

Таң алдыннан мич янып бетә, Шәяхмәт кисәү тәяргә түбән төшеп китә. Шәйхи карт сәгать сугарга каланчага таба атлый. Карт-коры бүген аеруча борчулы: колхозның иң таза егетләре иртән торуга сугышка китәргә тиешләр. Моның кадәр игеннәрне кемнәр җыяр? Кемнәр эш итәр?

... Приемда каралып кайткан егетләр авылда ни бары ике көн ял иттеләр. Хәл кадәренчә кунакка йөрештеләр, кибеттән һәрберсенә исемлек белән өчәр литр аракы сатып бирелде. Яңа гына мыек тибә башлаган яшь чырайлы бу малайларның бүген-иртәгә ут эченә барып керәчәгенә ышану бик кыен иде. Хәер, алар үзләре дә егет булып әллә ни кыланып йөри алмадылар, бар ятканнары ат абзарлары тирәсе булды. Үзләренең атларын яшь малайларга тапшырдылар, атларның холыкгадәтләре турында тәмләп сөйләделәр, сбруйларын караштылар. Бары тик иртәгә фронтка китәсе кичне генә түбән очта Заһриның Әхмәтза-

рифын туры китереп, кайсыларыдыр дөмбәсләгән. Нәрсә өчен булган ул, тегенең туган елын үзгәртеп сугыштан калганы өченме, әллә башка сәбәп беләнме, моны берәү дә белә алмады.

Иртәгесен бөтен халык кырда вакытта рекрутлар атка төялеп бер тапкыр урам әйләнделәр. Аларның күбесе әле урамнан гармун белән үз гомерендә беренче тапкыр җырлап узгандыр. Һәрхәлдә, урамнан егетләр түгел, малайлар җырлап узган сыман тоелды.

Аларның ак кульяулыклары арыш басуы эченнән шактый вакыт күренеп барды. Әвен янында Шәяхмәт, кулын каш өстенә куеп:

— Хәерле юл, балакайлар, сугышны бетереп кайтыгыз, — дип, озак карап торды. Каланча башында Шәйхи карт, яшьләр киткән юлга карап, шактый моңаеп утырды. Ат дугасы кумелерлек арыш эченнән яшьләрнең соңгы җырлары ишетелде.

## Мәйсүфә карчыкның башы шаулады

Курәчәгең булса күркә талап үтерер, дигәннәр.

Тимерхан бөтен күрәчәкне инде Сталинград белән Курск дугасында күреп бетердем дип уйлаган иде. Менә монда икән ул тормышның чыны... Фронтта ичмасам ашау кайгысы булмады — армия тук иде. Өс-баш Сталинград сугышы алдыннан бик шәбәйде. Бөтен куркыныч шунда — үлем синең күзенә текәлеп карап тора. Үлем куркынычы сиңа һәр минут кайнар сулышын өреп тора.

Ә монда... Монда үлем үзе читтәрәк. Ул каядыр басу артыннан салкын гына карап тора. Ул акрын килә. Фронттагы үлемне бер минут эчендә читкә куып була, самолетлар эскадрильясы күтәрелеп, танклар алга барганда яки бик көчле артподготовка вакытында, син җиңгәндә, үлем чигенеп тора. Ә монда үлем салкын сулышын өрә...

Госпитальдән Хәкимулла кайтып төште. Ике култык таягына арык гәүдәсен салган, бер аяксыз, күзе бәйләүдә. Пуля колак яныннан кереп бер күзне, яңак сөяген, борынны, теш казнасын җимереп чыккан. Юлда очраса танырлык түгел. Яраланып яткан урынга якын гына бомба төшеп ярылган. Кеше җаны — эт җаны икән. Контузия алган — шулай да исән калган. Арык, эре сөякләр. Үгез җигеп элеваторга ашлык илтә барган малайлар аны Васфикамал капкасына кадәр утыртып алып кайттылар. Беренче көнне сүз күп булды, Хәкимулла кисәк кенә начарланып китте. Күрешергә кергән Тимерханны танымады. Дер-дер калтырап:

— Менә мин шушылай булдым инде, старшой, — дип, сыңар күзеннән яшь коя башлады.

Васфикамал аңа өс-баш хәзерләде, юк ризыкны бар итеп, нәрсәдер пешерде, мунча якты. Кайнатай Заһри кичен бер ярты күтәреп килде. Бер стакан салгач, Хәкимулла бөтенләй саташты. Аракының калганын җыеп куйдылар.

— Я, улым,ниләр күрдең, кайда яраландың? — дип, Зәйнәп түти белән Шәяхмәт гарип улларының ике ягына утырдылар. Хәкимулла калтырый башлады.

— Менә мин шушылай булдым инде, братцы, — дип, елап җибәрде. Өйдәгеләр тешләрен кысып читкә борылдылар, яшь сыктылар.

— Мин Харьковны беренче алганда иң беренче звут белән кердем, — диде Хәкимулла, бераз аңы кайткач.

— Я, я, шуннан?..

— Шуннан... — Ул тагын башын дерелдәтте... — Шуннан черный туча килде...— И на фиг... Мин шуннан соң без памяч...

Васфикамал анын тезендәге улы Нәриманны саклык өчен үз алдына алды.

— Куркыныч булдымы? — диде ул, күз яшьләрен алъяпкыч итәге белән сөртеп.

— Куркыныч. Башта куркыныч. Беренче көнне бернәрсә белмичә ятабыз. Тып-тын. Анысы Фин култыгында. Кисәк кенә самолет — и бах... Мин шуннан Харьков участогына эләктем. Гитлерның җанын фәлән итим...

... Иортта ашарга юк иде, Хәкимулланы көн саен арбага утыртып, Васфикамал борчак җиренә алып йөрде. Үзе борчак чаба, Хәкимулла борчак чүмәләсе янында кузак ярып ашый. Янына килгән кешеләргә сугыш хәлләрен сөйли.

— Мин Харьковны беренче азат иткәндә беренче звут белән кердем,— ди.— Шуннан черный туча килде дә мин шуннан без памяч...

Кырда эшләгән берничә карчык ураза тотып маташалар. Сәхәргә алабута кушылган арыш оныннан талкан болгаталар да, көне буе кырда ачка кибегәләр. Шәйхи карт боларны бик кызгана.

— Арыш белән бодай башы уып ашаганнан ураза ачылмый, — ди ул, халык янына килгәч. — Иллә мәгәр, инде тоз белән таракан җимешен авызга да алырга ярамый. Алар инде уразаны чәнчелдереп кенә куялар...

Бу мәсьәләдә борчылырлык урын юк — тоз да, җимеш тә сугыш башланганнан бирле күренмиләр иде.

Август урталарында Тимерханны өлкә комитетына чакырдылар. Юлда барганда Тимерхан борчылмады. Чөнки беренче секретарьның бу эш өчен Хәйруллинны кыздырганын, гомумән, бу эшне ашыгыч рәвештә әвәләп ташлаган өчен бюро члennарына ризасызлык белдергәнен ишеткән иде. Тик озак тотмасалар гына ярар иде. Шушы атнада арыш эскертләүне хәл итәргә кирәк. Эскертләгән арыш — яртылаш амбарга кергән арыш. Бер көндә эшне бетерсәләр ярар иде... Бюро башланырга ике сәгать кала Тимерханны ак чәчле бер хатын-кыз чакырып алды. Буфетта ашарга талон бирде. Комиссиядә өчесе дә өлкән яшьтәге кешеләр, берсе кителенә өч рәт орден шакмаклары таккан, сыңар куллы иде.

— Я инде, иптәш Вәлетдинов, нигә алай житәкче работникны мәсхәрә итәсез?— дип сүз башлады сыңар куллы.— Сезнең белән безгәме соң инде алай кыланырга? Кайсы участокта булдыгыз? Алтмыш икенчедәмени? Ну, ну, генерал Родимцевның штабында булгаладым. Менә бит кайда йөргәнбез. Аванс мәсьәләсендә сез нәкъ менә коммунистларча эшләгәнсез. Шулай. Һәр нәрсәнең чамасы бар. Без өлкә комитетында ул турыда сөйләштек. Армияне икмәк белән тәэмин итү, әлбәттә, шактый чикләүләргә баруны сорый. Ә Хәйруллинны оскорбить иткәнсез. Теге действиегез — мальчишество. Без бит — фронтовиклар. Марканы төшермәскә иде...

Өлкә комитеты бюросында эшне шушы сыңар куллы аңлатты. Тимерхан озын өстәлгә якын гына күзлеген ялтыратып пуфылдап утырган кешене танып алды: Хәйруллин икән. Өлкә комитеты секретаре түрдә үк иде, Тимерхан аның йөзен ныклап күрмәде. Бюро членнарыннан ул бер-ике генералны гына күреп алды. Калганнары күз алдында бөтенесе бергә кушылдылар. Барлыгы өч минут вакыт үтте.

— Аңлашылды,— диде өлкә комитеты секретаре.— Аңлашылды. Иптәш Хәйруллин! Без сезне күпме өйрәттек — бер файдасы да тимәгән, күрәсең. Сез нәрсә, Людовик ундүртенче шикелле, «государство — это я»,— димәкче буласызмы әллә? Үзегезнең коммунистыгызны шул поступокка кадәр җиткерү — бу нәрсә, кадрлар белән эш итә белүме? Бу — тәрбияме? Кайтыгыз, иптәш Вәлетдинов, эшләгез. Икмәкне дәүләткә күбрәк бирегез. Ләкин колхозчының да ашказаны барын онытмагыз.

магыз. Әйе, әйе. Колхозчының да нәкъ райком секретарыныкы кебек ашказаны бар. Ләкин нервыларны авызлыклый белергә дә өйрәнегез...

Суга төшкән тавык кебек калтыранган, агарынган Хәйруллин кием элгечләре янында Тимерханның җиңеннән тартты.

— Слушай,— диде ул,— слушай, Вәлетдинов. Син ир кеше, мин ир кеше, давай ба́ба булмыйк. Онытыйк без моны. Безгә киләчәктә дә бергә эшлисе бар. Әйдә, поездга кадәр берәр җиргә кереп утырыйк. Ирләр булыйк. Бергә яшисе бар...

Тимерхан каршы килмәде. Ләкин ресторанга кереп утырып, тәмәке кабызгач та сүз ябышмады. Тимерхан элек-электәннән бу кешене яратмый иде. Әле кырыгынчы елларда ук бу кеше Кара Чыршыга килеп лекцияләр укып йөргән иде. Бер килгәндә ул «Ислам дине һәм хатын-кыз» дигән темага лекция укыса, икенчесендә «Дуңгыз — ит фабрикасы» яки «Ворошиловча төз ату — оборона куәтенең нигезе» дигән темага укый иде.

Калын муенлы таза ир, җилкәсенә ак сөлге салып, өстәл янына килеп басты. Колак артына карандаш кыстырган, кызыл битле, оятсыз карашлы. Ул ашыга-ашыга язды.

— Тәк. Бер литр коньягың — ике йөз илле тәңкә. Ике тавыгың — йөз егермешәр тәңкәдән — ике йөз кырык тәңкә. Бер кило алмаң...

...Хәйруллин кызды. Ни район бюросы турында, ни өлкә бюросы турында ләм-мим сүз әйтмәде. Ул сугыш вакытында курортка бару мәсьәләсенең бөтенләй кыеңлашканын сөйләп утырды. Күп чөмерде, исерде. «Без тегеләй иттек, болай иттек» дип, үзенең тылдагы хезмәтен мактады. Иң авыры бездә булды, диде. Сездә нәрсә ул, орден тагып кайтучыларның складта сабын биреп торып сугышны уздырганнары да бар дип, Тимерханның йөрәгенә тоз салды.

Тимерхан сәгатенә карады. Шунда гына ике сәгать буена авызыннан бер сүз дә чыкмаганын уйлап алды. Ул урыныннан торды. Тиешле акчасын өстәлгә куйды да, саубуллашмыйча ук чыгып китте. Өлкә комитетының бюросыннан соң бер атна үттеме-юкмы, район партконференциясендә Хәйруллинны секретарьлык эшеннән азат иттеләр. Бераздан, тишекле бер тиен кебек, ул Кара Чыршыга лекция белән килде. Ике көн рәттән кичен лекция укыды. Беренче көнне «Башка планеталарда тереклек бармы?» дигән темага лекция укыды. Көндез уракчылар янына барып, «Төшкә ышанырга ярыймы?» дигән темага сөйләп кайтты.

Китәсе көнне командировочный кәгазенә кул куйдырырга Тимерхан янына керде. Берни дә хәтерләмәгәндәй, зур авызын ерып елмайды, киң каеш белән буып куйган гимнастеркасын артка таба җыя-җыя күреште.

— Менә мин монда да килеп чыктым әле,— диде.

Тимерхан дәүләткә ашлык тапшыруның барышын өйрәнеп, төтенгә чумып утыра иде, аңа күтәрелеп карады, кашларын җыерды.

— Әйе, иптәш Хәйруллин,— диде ул,— сез нәкъ ачлык афәте кебек: теләсә кайда очрыйсыз...

Әйе, башка планеталарда тереклек мәсьәләсенә кадәр Кара Чыршыдагы тереклекне сакларга кирәк иде. Бер көн элек ферма көтүчеләре шешенделәр. Бүген аларга аванс он бирмичә ярамый. Хәкимулла авыр хәлдә ята. Аңа каяндыр бодай оны юнәтергә кирәк. Бал суырткач, бер кило бал җибәрмичә булмас. Әйе, үз планетаңны рәтләргә кирәк. Ипи мәсьәләсе — уен түгел...

...Шәйхи карт бүген ач. Беркөн алган авансның соңгы бөртек оны кичә кичке ашка тугланды. Бүген иртән карт келәт буеннан кычыткан җыеп алып керде. Карчыгы аны кайнар суда пешекләде, аннан соң аны чапкыга салып балта белән турадылар. Сугышка кадәр бу чапкыда сарык ите турала иде... Я, язмыш, тагын ниләр күрсәтәсең бар икән?

Бүген бөтен колхоз клевер җыя, яңгырга киткәнче эш итәргә кирәк, югыйсә Тимерхан оланга бик авырга киләчәк. Юк, Шәйхи карт мондый вакытта өйдә утыра алмас! Каравыл торып көч чыкмый, ни битең белән шундый көндә ял итәргә кирәк?

Ул, арык җилкәсенә сәнәген салып, ындыр артыннан гына ат абзарларына таба атлады. Бригадирның кереп аерым рәвештә үзенә эшкә әйтмәвенә бераз гына гарьләнде. Я, ярый, тегендә баргач күрсәтер әле ул куәтне, бригадир үзе дә үкенер әйтмәгәненә, нибуч... Менә тик ипи ашасаң иде. Тик бер генә телем арыш ипие булса иде хәзер. Тик бер генә телем...

Басу юлыннан клевер төягән бер ат килә. Йөк өстендә Заһриның олы улы Әхмәтзариф. Ул аякларын салындырып утырган да, бернинди хәсрәтсез кыяфәт белән җырлап кайта. Тукта, бу нәрсә әле? Ничек? Көн уртасында шундый таза егет колхоз аты белән үз хуҗалыгына клевер ташыймы? Бүгенге көнне моннан да оятсыз эш булырмы? Нәрсә, болар әллә өй эчләре белән безне мыскыл итмәкчеләрме?

Шәйхи карт ат башына ничек килеп ябышканын үзе дә сизми калды. Ул сәнәген ташлады, аның күзен кинәт кенә ниндидер элпә каплады. Шул элпә аркылы ул үзенең каршында ниндидер дошман, ерткыч дошманны күрде. Бу дошман — саргылт мыек типкән, сары кашлы, шома битле Әхмәтзариф. Моны бетерергә кирәк, һич югында, рәхәтләнеп бер дөмбәсләргә кирәк, шунсыз күздәге пәрдә ачылмаячак...

— Төш, имансыз!— Карт үз тавышын танымады.— Төш диләр сиңа, сасы көзән! — Ул Әхмәтзарифның чалбар балагына сөякле бармаклары белән чытырдап ябышты да, бөтен көче белән аны аска өстерәде. Менә йөк янында алар икәүдән-икәү кара-каршы бастылар. Җитмештән узган карт үз каршындагы егетнең итләч битенә карап алды һәм шүрләде: бу бер этеп җибәрсә, карт мәңге аякка басмаячак. Шулай да ул Әхмәтзарифның халат чабуын кулына чорнап тотты.— Хәзер үк пожарныйга илтеп бушат йөгеңне, алланың нәгъләте төшкере!

Тагын нәрсәдер әйтмәкче иде карт, ләкин нәкъ шул вакыт аның борынына ипи исе килеп керде. Әйе, әйе, җылы арыш ипие исе. Ул, мөгаен, кәрәз кебек күзәнәкледер, аның аскы ягы бераз гына көлледер... Менә ул ипи кисәге картның авызыннан бер вершок кына ераклыкта, ул менә шушы шома битле, йомшак сары мыеклы егетнең халат кесәсендә, гәзиткә төргән... бир син аны картка, ярты телемен генә бир, шуны ашаса, ул бер үзе бер бригада өчен эшләр бүген. Картның тамагы кибеп китте, юк, юк, менә тамак төбен җыерып әллә каян гына авызга су тулды, борын тишекләре киңәйде. Ләкин бер-ике секундтан карт айныды. Тап-таза егетнең бер сүз әйтмичә, куркынып үзенә карап торуын күргәч, ул ипи исен онытты. Каршындагы егет аңа үзенең шомалыгы һәм елтыр күзләре белән нигәдер бурсык сыман тоелды. Карт халат чабуын ычкындырды һәм тын ала алмыйча газапланып:

— Хәзер үк... илтеп... бушат йөгеңне, алланың ачы каһәре суккыры!— дип гыжылдады. Ул егәрсез аяклары белән үз юлына таба атлады, Әхмәтзариф исә атын кирегә таба бора калды.

Бу — карт белән Әхмәтзарифның соңгы очрашулары иде. Озак та үтмичә, Әхмәтзариф сугышка китте.

Җәйнең эссе көннәрендә авылга тагын бер афәт килде. Инде арыш башагы уып ашап тернәкләнеп килгән генә көннәр иде. Инде аяк йөзләрендәге, күз төпләрендәге шешмәкләр бетеп бара иде. Ләкин нәфес — шайтан диләр бит. Арыш башын уып табада кыздырсаң — ашап туйгысыз бер ризык була. Моны бернәрсә белән алыштырып булмый. Арыш урагына төшкәнче төрлечә кыланып карадылар. Көн саен бер яңа ризык табыла торды. Имеш, ак чәчәкле дару үләненең башын кыркып ашка салсаң, нәкъ тә ак оннан җәйгән токмач була

икән. Бу хәбәр таралгач, бакча башларындагы ак чәчәкле үлән бер көн эчендә ялап алынды, ләкин ярты авылны эч киту аяктан екты.

Әмма иң ышанычлысы арыш башагы булды. Дөньяда нәрсә булса да булыр — арыш бөртеге кадәр туклыклы бүтән ризык булмас. Андагы көч, андагы егәр, андагы куәт... Аны уып ашагач, көненә 25 сотыйны кул белән урып чыгу — ике тиен бер акча. Әгәр инде өеңә алып кайтып табага берәр кашык сөт өсте тамызып та куырып җибәрсәң — башка ризыкларың бер якта торсын. Шәйхи картның Мәйсүфәсе нәкъ шуның белән харап булды. Исәбе — кичкә учак ягып, таба өстенә сөт өсте тамызып, арыш куыру иде. Аннан соң бәлки кеше төсле сусап бер утырып чәй эчәр иде.

...Иске күлмәгенең тирән кесәсен әйләндереп амбар янында бушатырганда Мәйсүфә карчык нәрсәләр күрәсен башына да китермәде. Я, тотылды, тентеделәр, уган арыш дүрт йөз грамм килде. Алып калдылар. Тик менә картына нәрсә ашатырга бүген? Бу районнан килгән хатын да явыз булып чыкты. Шул төсле капшап кеше тентиләрме соң инде? Шуны күрмәмешкә салынса нәрсә була, бер-береңә шулай торырга ярыймы соң инде?

Улибаева таләбе белән Тимерхан кичен колхозчыларның гомуми җыелышы булачагын игълан иттерде. Көндезге смена тәмамланып төнге сменага чыкканчы, халыкны клубка җыйдылар. Улибаева җыелышта дилбегәне үз кулына алды.

Шуннан китте, шуннан китте. Озак сөйләде. Мәйсүфә карчык иң алгы рәттә кара хәсрәткә батып утырды: чолан баганасына ул җәймә белән эремчек асып киткән иде. Эремчек инде саркып беткәндер, житмәсә, карты да монда утыра, күршеләрнең эте кереп җәймәгә үрелсә, нихәл итәрсең... Тизрәк бетерсен иде инде. Ләкин Улибаева кызды. Моңарчы сөйләгәне ярый иде. Әйе, фронтка икмәк кирәк, йөз грамм ипи белән бер сугышчының гомерен саклап була. Улибаева дөрес сөйли. Әгәр, ди ул, көн саен һәр колхозчы дүртәр йөз грамм арыш урласа, безнең илдә илле-алтмыш миллион колхозчының һәрберсе көн саен шулай урласа... Бу урланган арышны бер эшелонга төясәң... Моның белән бөтен бер армияне унбиш-егерме көн туйдырып булыр иде. Чыннан да, нигә соң бу ягын уйламаган Мәйсүфә карчык? Менә бит укыган кешедә зиһен... Әмма Улибаева болар белән генә калмады.

— Син җүнсез,— диде ул, ак значок кадалган кара береткасын арткарак шудырып.— Әйе, җүнсез син. Иманың юк синең. Динең юк синең. Динсез син. Син җүнле булсаң, бүгенге көндә безнең сугышчыларыбыз үлмәсеннәр, сугыш тизрәк бетсен дип, кичен эштән кайткач намаз укыр идең. Ә сиңа алтмыш бер яшь. Динсез син. Синнән бүген Кара Чыршы колхозының бөтен халкы йөз чөерә, алар синнән баш тарталар, безгә мондый кеше кирәк түгел дип әйтәләр. Беләсеңме, син нинди кеше?

Мәйсүфә карчыкның башы шаулады. Я, нәрсә сөйли инде бу мишәр хатыны, ә? Моның авызы әйткәнне колагы ишетәме, юкмы? Мәйсүфәме соң инде динсез? Ичмасам аның карты Шәйхине әйтсен иде ул. Ни белеме бар, үз гомерендә намаз укымады. Улмы имансыз? Колхоз төзелгәннән бирле анда талкы талкыган, тары утаган, ясле балаларына аш пешергән, амбарда капчык ямаган Мәйсүфә ничек имансыз булсын? Шулай ук бүген халык аннан баш тартамыни? Бу ни хәл бу? Арыш башын югыйсә шыпырт кына бөтен кеше аз-маз уып өенә алып кайткалый иде.

Мәйсүфә карчык өзек-төтек кенә җөмләләрне мие белән тотып карады, ләкин күбесенең мәгънәсен аңламады.

Җыелыштан соң гына таралдылар. Эремчек белән чәй эчтеләр. Күңелне әллә ниткән авыр тойгы баскан иде...

## Чоры шундый, бабай, аңла...

Улибаева агач мәчет өстендә таш манара сыман булды. Кеп-кечкенә колхозга бу усалны ничек турылап җибәргәннәр диярсең. Я ул Тимерхан белән кара-каршы утырып сөйләшми, я ул киңәш кормый, я сүзгә колак салмый. Төп эшне эшләсе урында гел җинаять эзли. Менә колхозда эшче көчләр җитми. Атлар җитми. Парга сөрү буенча Тимерхан чак-чак кына каты шелтә алмый калды. Ярый әле җае чыкты. Әллә каян әллә кая узучы ике ташбаш солдат Кара Чыршы урамына гөрелдәп танк белән килеп туктадылар. Авылда исән-имин булган бөтен кеше бу могҗиза янына җыелды. Солдатлар, күсәбәсе белән ипи чыгарып, шуны аракыга алыштырмакчы булдылар. Шул вакыт алар янына Тимерхан килеп чыкты. Алар өчәүләп басу капкасы янындагы каен төбенә утырып тәмәке көйрәттеләр дә, бераздан кул сугыштылар...

Авылдагы бердәнбер МТС тракторының подшипникларын эреткәннәр иде. Башнясын артка таба борган танк трактор плугы белән йөз илле гектарлы җирнең астын өскә китерде. Районга шул көнне мәгълүмат китте, Тимерхан да Ташлытаудан бюродан чыккач чәч артларын алдырып кәефләнеп кайтты. Тик Улибаева гына теге ике солдатка бәйләнеп, алар авылдан чыгып киткәнче телефоннан военкомны эзләп, хәрби округ начальнигына телеграмма бирәм дип, Тимерханның үзәгенә үтте...

Ул арада чәчү башланды. Чәчү машинасына атлар юк иде. Булган атларның барысы да задание тапшыралар. Нишләргә? Кул белән чәчәргә ярамый. Хәер, кул белән чәчәрлек ирләре дә юк бит әле аның... Ә чәчәргә кирәк. Чәчәргә бик кирәк. Киләсе җәй, әгәр сугыш дәвам итсә, иң авыры булыр. Сугыш бетсә дә, алдагы җәй бик авыр булыр. Кешеләрнең элеккеге запаслары бетте. Күзен бирелә торган уңыш елдан-ел кими. Кешеләр ябыктылар, хәлсезләнделәр. Йөрәкләрдә май бетте. Сугыш алҗытты. Ничек тә чәчәргә кирәк. Я, рота парторгы, тагын бер тапкыр ут эченә кереп чык...

Улибаеваны ниндидер ашыгыч эшләр белән районга чакырганнар иде — Тимерхан кичен идарәгә картларны, өлкәннәрне җыйды. Алар килгәнче Шәяхмәт белән икесе киңәш корып алдылар. Карар ителде: колхозны киләсе елгы ачлыктан ничек тә коткарырга. Шушы атна эчендә арыш чәчүне төгәлләргә.

Киез-катасын ышкый-ышкый атлап, янгын сараеннан Шәйхи карт килде. Чирек литрлы шешәдәге сода суын куен кесәсенә салып, корык-корык йөткеренгәләп, Зәһри килде. Сул кулын кендек турысыннан салындырып Борһан килде. Ул яраланып кайтканнан бирле җинел эшләрдә генә йөри иде. Исемлектән әллә кайчан төшерелгән тагын ике карт килде.

Идарәнең алгы бүлмәсенә тәмәке исе сеңгән. Стеналары сары, мүкләр сары. И дөнья! И бу дөньяның колхоз идарәләре, аларның стеналары, аларның мүкләре! Сезнең телегез булса, сез ниләр сөйләмәс идегез! Элек бу бүлмәгә сыймаслык булып ирләр җыела иде. Кырын ятып тәмәке көйрәтәләр иде. Монда төннәрен тегенди-мондый мутлык эшләп кайтучы егетләр туктала иде. Кайсы тирәдә ниләр эшләп, ниләр күреп кайтуын кешегә сөйләү-сөйләмәү хокукы үзендә булуына горурланып, бүлмә уртасындагы озын агач өстәлдә кырын яталар иде. Иренмәсәң, пәкеңне чыгар да, бер җирено чокып яз. Истәлек булып калыр. Бәлки син бүген үз гомереңдә беренче тапкыр үбешкәнсеңдер. Бәлки син үз гомереңдә беренче тапкыр салкын капка төбендә торганда яшь кызның пальто төймәсен чишеп, кайнар кочагына чумып басып торгансыңдыр? Нигә ул көнне пәке очы белән шушы өстәлгә билгеләмәскә?

Бәлки син үз гомереңдә беренче тапкыр бүген... Хәер, өстәл өсте болай да тулы. Кайда сез, монда эзләрегез калган егетләр? Сезнең кайсыларыгыз исән? Кайсыларыгыз бүген дошман өстенә ут яудыра? Кайсыларыгыз бүген тоткынлыкта, кайсыларыгызның сөякләре инде туфракка әйләнә? Ә идарә бүлмәсе өчен әйтерсең тарих туктаган, сугыш башланмаган. Аның стенасында сугышка кадәрге үк картина. «Бүреләр — авыл хуҗалыгы дошманнары. Аларны бетерегез»,— дип язганнар да, үлгән бүре өстерәп кайтучы бер аучы рәсемен ясаганнар. Ах, авыл хуҗалыгына зарар китерүчеләр әгәр дә шул дүрт аяклы мәхлуклар гына булса! Әгәр дөньяның явызлыгы шул дүрт аяклы соры койрыкларда гына булса! Билләһи, барысын да җыеп, Тукай әкиятендәгечә, итле бутка гына ашатып асрар идең! Менә сугыш алдыннан төшерелгән карта. Колхозның туфрак картасы. Тыныч вакытны хәтерләтеп, әле дә эленеп тора. «Туфрак төрләре» дип язылган. Аннары процентлар белән шул төрләр күрсәтелгән.

Типик көчле һәм уртача көчле кара туфрак.
Көлсу уртача көчле һәм көчле кара туфрак.
Көлсу һәм аз көчле кара туфрак.
Кара-кучкыл соры урман туфрагы.
Кәзле-карбонатлы көрән-соры туфрак.

Ах, бу фән кешеләре! Кара син аларны, халык өчен бары тик «җир», «басу» дигән сүзләр генә бар иде, болар нишләтеп ваклап бетергәннәр. Кәзле-карбонатлы, имеш! Менә алай бүлгәләп өйрәнеп торырга вакыт юк хәзер! Чәчәргә кирәк, вәссәлам! Шулай да, бу картадан тыныч заман исе килә. Әйе, бар иде шундый заманнар. Бар иде, туфрагын да, чишмә суының составын да өйрәнә башлаган тыныч еллар бар иде...

Түр стенада гына кешене айнытырлык, бүгенге көнгә кайтарырлык бер кәгазь бар: бу — татар халкының фронтовик сугышчыларга язган хаты. Шул кәгазь ябыштырылмаган булса, бүлмәдә басып торганда дөньяда сугыш барганын беләсе дә түгелсең.

Тиешле кешеләр җыелып беткән иде. Тимерхан уйларыннан айнып киткәндәй булды.

Борһан дуңгыз башта шактый аяк чалып маташты.

— Шту син, иптәш Вәлетдинов, кул белән чәчү упшым да тыелган эш бит...

— Анысы синең эш түгел,— дип бүлдерде аны Тимерхан.— Җаваплылыкны мин үз өстемә алам. Киләсе ел уңышы турында сүз бара, аңлыйсыңмы, юкмы?

Борһан бирешмәде.

— Анысы,— диде ул,— хөкүмәтнең амбары киң. Безгә инде уңыш булса да өч йөз грамм, булмаса да өч йөз грамм. Менә мин үзем ранный кеше...

Тимерхан аны туктатты.

— Синең ничә балаң бар? Дүртәүме? Әнә шуларны киләсе елга хәер сорашырга чыгарырга ризамы син, юкмы? Шулар алдында нәрсә дип җавап бирербез, әгәр бер сеялкага ышанып ятсак? Син беләсеңме районнан телефонограмма килгәнен? Бер атнадан яңгырга китәчәк.— Тимерхан тавышын үзгәртте.— Борһан абый, сүземне тыңла. Минем хәлне дә аңла. Мин хөкүмәт алдында, партия алдында җаваплы кеше. Минем шушы колхозның сугыштан кайтачак ирләре алдында җавап бирәсем бар. Мин шушы колхоздагы бүген ач утыра торган карт-коры, хатын-кыз, бала-чага алдында җаваплы. Их, әгәр дә минем кулымнан килсә...

Борһан бирешт-е.

— Ну, ярар,— диде ул,— мин әле тегеннән-моннан түгел, әтвит-

ственность ягыннан гына әйтәм. Миңа нәрсә — мин партийный түгел, гулый баш — сам знаш...

Иртәгесен ак тула оек өстеннән чабата киеп, алты арык ир йомшак кара җир өстенә бастылар. Болар нәкъ торналар төсле күренәләр иде. Иң беренче учны Шәйхи карт сибеп, көйгә генә атлап җир өстенә кереп китте. Аннан Шәяхмәт. Аннан Заһри кода. Анысының үз гомерендә муенына тубал кигәне булдымы икән. Аннан карсак буйлы Борһан. Тагын — хәлсез генә ике карт. Тырыс-тырыс... Учтан сибелгән ашлык, тубалга бәрелеп, шундый тавыш чыгара. Арттан каргалар йөри. Тырыс-тырыс.

...Улибаева дүрт көннән соң гына әйләнеп кайтты. Шәһәрдә семинарда булган икән. Тимерханнан көзге чәчүнең барышы турында мәгълүмат сорады. Чәчү тәмам иде. Уполномоченный нинди дер хәл булганын сизенде булса кирәк, ак значоклы кара башлыгын арткарак шудырып, тәмәке кабызды. Берәр кискен сүз әйтер алдыннан ул һәр вакыт шулай башлыгын арткарак шудыра.

— Нәрсә, Вәлетдинов, монда да танк коткардымы?

Тимерхан да тәмәке кабызды.

— Юк, иптәш Улибаева, көн чәчтек, төн чәчтек, танктан башка гына. Ә теге солдатлар басу капкасыннан чыгып киткәндә Шәйхи абзыйның киртәсен әләктереп җимереп киткәннәр... Анда борылырга бик җайсыз шул.

— Я, дөресен әйт, кул беләнме?

— Ну, шту сез...

— Дөресен әйт, кул беләнме?

— Юк дим, юк. Сез нәрсә ул хәтле, минем башыма тай типкән дип белдегезме?

— Ну, хәзер кырга барып тикшереп тотсам, мин сине трепакагә бастырам. Дөресен әйт, үзеңә җиңел булыр ахырдан.

Улибаева кырда озак йөрде. Басуга буеннан-буена юл-юл булып чәчкеч эзе сузылган иде. Бу Вәлетдинов женде р... Ничек эшли алган ул уполномоченныйдан башка моның кадәр эшне? Гаҗәп. Нигәдер халык ярата үзен. Тамаклары ач, ә сүзен тыңлыйлар. Райком секретаре да ярата. Үзенә инде ике кисәтү бирделәр, ә барыбер секретарь шуның белән дус. Белмәссең...

Улибаева юлдан эчкәрәк керде. Кинәт кенә аның үпкәсе бугазына күтәрелде. Юлдан ун-унбиш адым кергәч, чәчкеч эзләре юк иде. Әһә... Аңлашылды. Барысы да ачык. Димәк, юл буйларын гына тырмачлап алганнар. Тизрәк районга хәбәр итәргә. Яраткан председателегез хөкүмәтне алдый, дияргә. Тизрәк комиссия җибәрсеннәр... Зур җинаять. Кара Чыршы колхозында зур җинаять ачылды. Җинаять эшләре кодексында әйтелгәнчә...

Идарәдә тын гына, тәмле генә әңгәмә бара иде. Колхоз хисапчысы, авыз кырыена сүнгән тәмәкесен кыстырган килеш чут төймәсен шалт-шолт салып, үзенең кичә ниләр күргәнен Борһанга сөйли, алар янында йомыш белән килгән тагын бер-ике карт таякларын кочаклап утыралар иде.

— Юк,— ди хисапчы Борһанга,— синең белән аерылышкач, әле мин Абрарга кердем. Ул, ызначит, чыгарып куйды бер чити, аны сындырдык — чут төймәсе «шалт» итте.— Аннары кайтышлый Сәүбән очрады. Бу әйтә, минем, ди, слушай, ди, җыеп куйган бер чити бар, ди. Бераздан аны да салганбыз без — менә булдымы өч.— Ул чут төймәсен тагын «шалт» итеп китереп салды, канәгатьләнү белән елмайды.— Инде кайтыйм дип кенә тора идем, бер вакыт — Абрар йәнәдән килеп...

Шул вакыт идарәгә, баласын югалткан юлбарыстай ыжгырып, Улибаева килеп керде. Ул ачу белән портфелен өстәлгә ыргытты. Хисапчының өченче читигә салынган соңгы төймәсе әле әйләнеп тора иде.

— Бу картлар катып бетмичә, кул белән чәчүдән котыла алмыйбыз инде без,— дип, яман сүгенү сүзе әйтте. Картлар чәчрәп киттеләр дә, шыпырт кына таю ягын карадылар, хисапчы да шкафтан кәгазьләр эзләргә кереште.

Уполномоченный председатель булмасенә узды. Сүзне Улибаева башлады.

— Я, нәрсә, тотылдыңмы, бессовестный?

— Юк, иптәш Улибаева, тотылмадым, котылдым. Әнә күк йөзен карагыз. Әле генә телефонограмма алдык: бүген төнлә явым башланачак. Августның ахырына кадәр аязуы икеле.

— Райком алдында ни дип җавап бирерсең?

— Халык алдында ни дип җавап бирсәм, райком алдында да шуны әйтермен. Булмаган атны, булмаган тракторны көтеп ятсам, җирне кысыр калдырсам — менә ул вакытта җавап бирүе кыен булыр иде. Ә җавапны, кирәк булса, бәлки сезгә дә бирергә туры килер. Сез дә күктән төшкән кеше түгел.

Тимерханның зур кара күзләре елтырап китте. Аның соңгы сүзләре Улибаеваны телсез калдырдылар. Чыннан да: «Үзең ни карадың?» — диярләр. «Шәһәрдә идем, белмәдем». «Ә алдан нинди чаралар күрдең?» «Берни дә... Бернинди...» «Ә партбилетың барын онытмадыңмы? Колхозга без сине ни өчен җибәрдек?»

Беренче тапкыр Тимерхан аның йомшак тавышын ишетте.

— Менә нәрсә, иптәш Вәлетдинов. Ничек дип әйтергә? Син инде тегеннән-моннан тикшерү килсә, үз сүзеңнән кайтма. Чәчкеч белән икән, чәчкеч белән, чорт с тобой. Ләкин чигенмә. Сүзеңне үзгәртмә.

Тимерхан елмаеп тик утырды...

Шул секунд эчендә Улибаева кара битле, зур кара күзле бу авыл егетеннән үзенең җиңелгәнен сизде. Тавышы калынайды.

— Ә вообще, Вәлетдинов, ужасный кеше син. Сине берни белән дә не прошибешь... Синең үз кирелегең кире. Терпеть не могу...

Тимерхан белән ызгышып алгач, ул кызу-кызу атлап янгын сараена таба китте. Күк йөзе болытлап тора, урман ягыннан дымлы, җылы җил исә иде. Шәйхи карт, буыннары сызлаганга, үзен кая куярга белмичә, сарай әйләнәсендә каз-үрдәкләрне куыштыргалап йөри иде. Соңгы вакытта ул, гомумән, өенә бик сирәк — тамак ялгап алырга гына кайта торган булды. Теге ямьсез җыелыш аның күңеленнән китми иде. Менә бүген буыннар бик тә сызлый, кул аркаларындагы тамыр юллары бүрткән. Бер явып җибәрсә кана...

Улибаева белән ул авырдан гына исәнләште. Тегесе исә, берни дә булмагандай, «Тәмәке тарту урыны» дип язылган почмакка килеп, эскәмиягә утырды һәм папирос кабызды. Аннан читкә караган килеш акрын гына сүз башлады.

— Ә син, бабай, миңа алай кара янып йөрмә.

Шәйхи карт дерелдәп китте, читкә карап, борынын бушатты. Берни дә әйтмәде.

Картның күзләре яшьләнде.

— Соң бит, кызым... Ни бит...— Аның борыны йомшады.— Кеше алдына чыгарлыгыбыз калмады бит.— Ул Улибаева янына килеп утырды, кулындагы себеркесен кочаклады.— Без дә адәм балалары бит...

Прокурор авыр сулады.

— Син,— диде ул картка,— үзең турында, үз өеңнең җылысы турында гына уйлыйсың. Менә син минем өемдәге җылы белән кызыксынганың бармы? Ә? Менә шул шул. Беләсең килсә, минем ирем сугышның беренче аенда ук үлде. Ташлытау военкоматына иң беренче үлем хәбәре минем ирем турында килде. Ә мин дүрт бала белән тол

калдым. Аларны хәзер җитмештән узган анам карый. Ә син, беләсеңме, ул балаларга көненә күпме икмәк бирелә? Ике йөз грамм! Бер сыныкк ипи ул! Олы кызым быел унынчыга керә. Унсигезенче яшенә китә. Әнә шул балага — ике йөз грамм! Ләкин мин бераүгә дә үпкәләмим. Ике йөз грамм ипи — ипи ул. Әгәр минем балаларым бүген ачлы-туклы утыралар икән, мин моңа бары тик фашизмны гына гаеплим. Ә син миңа үпкәлисең...

Кичке эңгер-меңгер вакыты җитә иде — әңгәмә сузылды. Шәйхи карт бу аяусыз хатыннан ишеткән сүзләренә шаккатып утырды, һич кенә дә ышанасы килмәде.

— Менә мин,— дип дәвам итте прокурор хатын,— шушы колхоз амбарына кереп: «Ягез әле, миңа семьяма алып кайтырга бер-ике кило борчак бирегез», дисәм, һичшиксез, бирәчәкләр. Шуны алып кайтсам, минем анам һәм балаларым көне буе тук булачаклар. Ишетәсеңме, бабай, бер көн буе! Ләкин мин аны эшли алмыйм. Әгәр мин сезнең амбарыгызга кереп бер кило он алып чыксам, мин ни битем белән сезнең каршыга килермен?

Караңгы төшеп, кешеләр кырдан кайта башлагач кына Улибаева урыныннан торды. Портфелен кулына алды. Береткасын салып, чәчләрен рәтләде. Шәйхи карт шул вакытта прокурорның да нәкъ үзе кебек авыр хәлдә, ялгызлыкта газап чигүче гап-гади бер хатын икәнлегенә ышанды. Аның күңелендә бу хатынга карата әнә очы кадәр дә үпкә калмаган иде.

Улибаева аерылып китәр алдыннан картны бөтенләй телсез калдырды.

— Мин, әгәр шул җыелышта үз әнием утырса, — диде ул,— нәкъ шундый ук чыгыш ясар идем. Һәм, бер дә икеләнмичә, шулай каты сөйләр идем. Вакыты шундый, бабай, аңла... Ну, ярый, озак сөйләштек.

Икенче көнне иртән яңгыр ява башлады. Вак яңгыр, тоташ яңгыр. Көнбатыштан җылы җил исә торды, куе соры болытларны ишепишеп, авыл өстенә куа торды. Кырдагы арыш чүмәләләре инде кибәнгә куелган, чәчү тәмамланган иде. Тик сабан ашлыгын гына җыеп аласы бар. Бүген колхозчыларга аванс бирергә кирәк. Бер хәл алсыннар. Аннан соң Тимерханның үзенә дә бер мунча кереп чыгарга, киемнәрен алыштырырга һәм бер төн кеше төсле йоклап карарга кирәк... Яу, яңгыр, яу. Тик озакка гына сузма. Менә берничә көннән арыш шытып чыгар. Башта ул кызгылт юка элпә генә булып тишелер. Арыш уҗымы тишелгән вакытта шәмәхә-кызгылт була. Моны крестьян гына белә. Ә кайбер кешеләр аны яшел дип уйлыйлар. Юк, син, арышны чәчкәч, өч көннән соң килеп җиргә иелеп кара. Әгәр аны чәчкәннең соңында менә бүгенгедәй җылы яңгыр да явып узса. Бөгел дә туфракка кара. Черки канаты кебек кенә юка, шәмәхә-кызгылт кыяк күрсән — шул арыш уҗымы була. Тормышның бөтен тереге әнә шул кызгылт элпәләрдә. Аны күрергә нибары ике-өч көн калды... Ә җавапка тарту... Анысы инде арышның тишелгән көнендәге төсен белмәүчеләр эше. Ни булса да булыр...

Солдат итеге белән басу балчыгын изеп, Тимерхан кырны иңләпбуйлап гизде. Вак яңгыр аңың киемнәрен, чәчләрен чылатты, җирдән җылы һава күтәрелде. Ничава, ничава... Болай булса, исән-имин җиңеп чыгабыз. Инде фашистларны үз җирләрендә бөтенләй бетерү турында сүз киткәч, җиңү турында ышанып сөйләргә була...

Председательнең нервлары ял иткән сыман булды. Авыр уйлардан бушанып, ниндидер бер эчке рәхәтлеккә талып, акрын гына авылга таба атлады. Иртәгә көнгә наряд бирергә дә, чыннан да, бер кич ял итеп карарга кирәк.

Бер атнадан бәрәңге җирен бүлеп бирәсе бар. Кеше саен икешәр гектар туры килә. Ничек кенә җыеп аласы? Дәүләт каршындагы йөкләмәне ничек үтәсе? Салкыннарга кадәр башкарып чыгып булырмы?

## Контузиясе булмаса ни әйтер идең?..

Кара Чыршыдан сугышка киткән кешеләрнең иң соңгысы Әхмәтзариф та инде Германия җиренә кадәр барып җиткән. Хәер, Әхмәтзариф булмаса, Германиянең нинди икәнен Кара Чыршылар каян белерләр иде! Менә ничә ай инде Зәһриларга герман җиреннән бер-бер артлы посылка ява. Германның кара ипие дә чытырдавыклы кәгазьгә төрелгән, исле майларының да исе бер җир буе ераклыктан килә икән. Әберкөнне Зәһри бөтен авылны сыйлады: Әхмәтзариф нәкъ мең ярым юан сигара җибәргән. Берсе-берсен ике көн тарт, өч көн тарт, чәч араларың зәңгәрләнгәнче тарт! Һәрберсен бишәр сумнан ике көн эчендә сыпырып алдылар. Кичләрен Кара Чыршыда гел хуш исле төтен генә торды. Шәйхи карт та сигараны бер суырып карады һәм ютәленә буылып:

— Бу ярманнарның үз тәмәкесе түгел, аларның үзләрендә үсми ул, төрекләрдән алган тәмәке бу,— дип, кешеләрне ышандырды. Шәйхи картның соңгы вакытларда кәефе гомумән әйбәт иде: ел буе эшләгән хезмәт көненә көзлектә азмы-күпме уңыш тиде. Умачтан өзелмәслек булды. Инде сугыш та бетүгә таба бара...

Язның җылы, парлы көннәреннән берсе иде. Авылга Берлин шәһәрен алу турында телефонограмма китерделәр. Райком кәгазе кырдагы колхозчыларга бу шатлыклы хәбәрне җиткерергә тәкъдим итә иде. Кәгазьнең эчтәлеген иң беренче булып каланча янында кояшта җылынып утырган Шәйхи карт белде. «Берлин» сүзе картны сискәндереп җибәрде. Аның күзләре яшьләнде, тез буыннарына каяндыр көч килде, беләкләренә нииндидер могҗиз куәт тулды. Тиз генә каланча башына үрмәләде. Аның үз гомерендә бер тапкыр да каланчага болай тиз менә алганы булмагандыр. Карт басу түрендәге халыкка күз ташлады... Менә чәчүлек басуында бригадир, карт-коры, хатын-кызлар... Алар әле берни дә белмиләр. Түзегез, җаннарым, түзегез, тагын бер генә тын алсын Шәйхи бабагыз. Менә-менә калтыраган кул түбә астына кыстырып куйган арба кендеген эләктерде, тыны буылган карт уч төпләренә төкерде дә, аякларын киң җәеп басты.

— Йа хода, мәдәт бир!

Авыл өстендә кинәт кенә чаң тавышы ишетелде, капкалар ачылды, урамда ыгы-зыгы башланды.

— Кайда яна?

— Безнең авылдамы? Күренәме? — дип халык йөгереште.

Ул арада чәчүчеләр янына ат атланып Тимерхан чыгып чапты. Басу түрендә бер мәлгә эш тукталды. Чаңны Кара Чыршыда бары тик янгын булганда гына сугалар иде. Карт үз гомерендә беренче мәртәбә бүген аңсыздан тәртип бозды. Ләкин бу тәвәккәллек аңа искиткеч зур рәхәтлек бирде һәм аның шатлыктан тонган күзләре инде бернәрсә дә күрмиләр иде. Карт, үзен-үзе белмичә, түбә астына эленгән вагон буферын арба кендеге белән кыйнады. Буфер елады да елады, аның саен карт селтәбрәк суга бирде.

Берничә минут эчендә шатлыклы хәбәрне авылның бөтен кешесе белеп өлгерде. Ә төшкә таба Шәйхи картны каланча башында үзенең әйләнмәле тирәкле урындыгына сеңеп күзләрен йомган килеш таптылар. Аның җансыз битендә ниндидер канәгатьләнү хисе бар сыман иде.

...Кабер тирәсен яшел кәсләр белән рәтләп, кирәкләрне өстерәп зираттан чыкканда ук Заһри кода тәкелдәп кайтты.

— Карт кода кемгә генә әйтеп калдырды икән инде? Кайсыбызга әйтте икән карт кода?

Заһрига җавап бирүче булмады — авыл башына кергәч, кирәкләрен җилкәгә алдылар.

Ә Шәйхи карт бер дә әллә кемгә түгел, үз нәселләренә әйтеп калдырган икән. Сигезенче май көнне иртән Хәкимулла начарланды. Инде авызына бер ризык та капмый иде. Көне буе саташты, ниндидер командалар бирде, сүгенде, җырлады. Кечкенә малайны бабасы Шәяхмәт йортына алып киттеләр. Кояш батар алдыннан гына авыру аңына килде һәм әтисен, әнисен, хатынын янына чакырды.

— Әти, әни,— диде ул буыла-буыла,— Васфикамал! Малайны үстерегез. Миңа рәнҗемәгез. Васфикамал! Әтиләрдән аерылма. Яхшы. Шулай әйбәт. Шулай...

Кем чакыруы беләндер килгән Хәбирә карчыкның сәке буенда искергән, карлыккан тавышы ишетелде.

— Ясин... вәл корьәнил хәким. Иннәкә ля минәл морсалинә галә сиратил мөстаким...

...Кояш батканда Хәкимулла өзелде.

Иртәгесен миллионнар көткән җиңү хәбәре килде.

Ул көнне Тимерханның язгы җилдә ярылып кубалакланган, күптәннән елмаю белмәгән бите көләчләнгән, яктырган иде. Ул идарә алдына өелгән бүрәнәләр өстенә менеп баскан да сөйли, аның тамагы карлыккан, ул кыска җөмләләр белән өзек-өзек сөйли. Май. кояшында аның күкрәгендә «Дан» ордены ялтырап ала.

Аның сүзләре кул чабулар, әллә каян китереп житкерелгән тальян тавышына, шатлык дулкынына күмелә, ул тотлыга. Кышын-язын кыр эшендә йөреп битләре каралган киленнәр, җиңгиләрнең күзләрендә яшь бөртекләре ялтырый, кулларын артка куеп бөкрәеп йөргән бабайлар турырак басып торырга тырышалар. Бөтен кешенең йөзендә шатлык, карт-корының җыерчыклары ачылган һәм ул җыерчыклар коңгырт битләргә ак сызыклар булып сузылганнар. Бары тик Заһри гына халык төркеме артында саргылт йөзен җиргә текәп басып тора. Ул бөгелгән, һәм юл-юл күлмәкләр, сырган телогрейкалар арасында аның немецтән килгән кара ефәк жилеты сөлек сырты кебек ялтырый иде.

Тимерханның сүзләрен ул көнне күпереп яткан кара җир дә, клуб бакчасындагы купшы каеннар да, койма өсләреннән башларын салындырган көяз шомыртлар да тыңлаган кебек иде.

Җиңү бәйрәме көнне төштән соң Хәкимулланы җирләделәр. Үлем шулай Кәлимуллиннарныкылар тирәсендә уйнады. Өйдән мәетне озатканда хатын-кыз капка төбендә җыелып калды. Васфикамал эченнән генә бөтен дөньяны каргады. Юк, мәкаләләрдә язганча ук булмады. Ярты үлек ире кайтып кергәч, ул теге мәкаләләрдә язылганча шатланмады. Андый кеше идемени аның ире! Болай газапланганчы, әлбәттә, үлгәне артык иде. Контузиясе булмаса ни әйтерием! Булмады, бәхет булмады. Яңа өйдә малай үстереп, колхозда парлап эшләп, гөр килеп яшәп булмады. Каһәр суксын дөньясын, Гитлерның муены астына килсен! Тотылгандыр тотылуын үзе дә...

Мәетне кабергә төшергәндә, кечкенә Нәриман чыркылдап көлеп, кызыл балчык өстендә уйнады. Тик ак марлягә төрелгән кинчә гәүдәне ләхеткә индергәндә генә кычкырып җылый башлады:

— Әттә! Әттә! Монда мен! Монда мен!

Хәкимулла үлеп бер-ике көн торгач, аны Хәбирә карчык төшендә күргән.

— Ләхетемне тар алдылар, әйләнеп ята алмыйм,— дип зарланган, имеш .Бу хәбәр карчыклар арасында козгын кебек шом салып йөрде...

Шуның белән Атҗабар Хисмәтнең соңгы минуты турындагы сер мәңгегә җиргә күмелде. Бичара Хәкимулла аңы ачыкланган саен Хисмәтне күмүе турында сөйләмәкче була һәм һәрберсендә, припадкасы кабатланып, бу вакыйга таман эчендә кала иде.

«Хәбәрсез югалган» Хисмәттән исә Атҗабарда карт анасы, хатыны һәм балалары һаман да хат өмет итәләр иде...

## Син кем, атаң малаемы, солдатмы?

Ташлытау станциясенә товар поезды килеп керде. Урта вагоннарның берсеннән ак керфекле, җыйнак гәүдәле бер солдат сикереп төште, перрондагы эскәмиягә менеп басты да, кулындагы җиз быргыны иреннәренә терәп, башын горур рәвештә артка ташлады.

Станция артындагы куе имән урманы ят тавышны тәгәрәтә-тәгәрәтә еракка озатты.

— Ту-ту-ту-туву!

Бу сихерле тавыш товар вагоннарын хәрәкәткә китерде. Эшермәле зур авыр ишекләрдән җиргә шыбырдашып берьюлы йөзләгән, меңләгән солдат коелды. Бер минут эчендә урман янындагы тын станция танымаслык булып үзгәрде. Берәүләр котелокларын тотып кайнар суга йөгерделәр, икенчеләр су алып яткан паровоз янында билдән чишенеп юынырга, төртешеп су чәчрәтергә тотындылар. Бөтерелеп килгән мыеклы, киң җилкәле мәһабәт бер сержант сыра сатучы кыз янында сүз куерта башлады, күз ачып йомганчы яңа мичкәнең бөкесен этеп төшереп, насос киертеп бирде. Икенче берәүләре ларек эчендәге кызлар тирәсендә кайнаштылар, аларны үзләренең вагоннарына чакырдылар... Уен-көлке, җыр-бию, этеш-төртештән станция мәш килде.

Бары тик бер генә солдат уен-көлкегә катышмады. Кайшалып дулкынланган кара чәчле, кылыч борынлы, гимнастерка якаларын чишеп җибәргән бу егет перрон буйлап ары-бире йөренде дә, борчулы кыяфәт белән үз вагоны янына килеп туктады. Кулындагы кечкенә төенчекне вагон эченә ыргытты, бераздан яңадан алып чыкты. Ул кемнедер көтә, эзли иде. Сөт сатучы кызлар да, яшел суган белән төеп пешерелгән кайнар бәрәңге сатучы марҗалар да бу егетнең Кара Чыршы Шәяхмәт улы Нургали икәнен танымадылар.

...Июль ахырлары иде. Нургали хезмәт иткән гвардияче дивизияне кинәт кенә көнчыгышка күчерергә дигән әмер булды. Җиденче көн үткәндә товар поезды дивизияне, Идел күпереннән уздырып, Уралга таба ашыкты. Эшелон Ташлытау станциясеннән узачак булганга, Нургали телеграмма бирде. Ләкин ни өчендер Мәскәү бик ашыктырды, эшелон Нургали чамалаганнан ярты көн алда килде. Әле поезд станциягә кергәнче үк Нургали ишек янына килеп басты. Менә ул үз авылларын күрде. Авыл нindидер зәңгәр рәшә эчендә утыра. Менә бу җирләрдә кырык беренче елның җәендә борчак чәчелгән иде, быел да борчак икән. Әнә басу уртасындагы юлдан бер атлы чаба. Арбасына яшел клевер салган, ак күлмәктән, киез эшләпә кигән татар карты.

Хыялга чумган Нургали станциядәге тавыш, уен-көлкене ишетмәде. Эх, бер генә минутка әтисен-әнисен күрә алса иде ул! Аның хыялын тегe, чандыр гәүдәле, ак керфекле солдат бүлдерде. Ул яңадан мәгърур бер кыяфәт белән башын артка ташлап җиз быргысын кычкыртты. Нургалине туган туфрагыннан аерып алып китү әйтерсең лә аңа бер канәгатьләнү бирә иде. Команда тавышы станцияне яңгыратты.

— По ва-һо-на-а-м!

Соңгы минут җитте. Өмет киселде. Нургали соңгы солдат булып җирдән аягын алды, тормоз баскычына менеп басты. Перрон белән

ике арага каршы яктан брезент белән капланган платформалар таккан хәрби эшелон килеп керде. Һәр вагонның баскычында кызыл кырыйлы фуражка кигән, карабин аскан солдатлар тора иде.

Дивизия төялгән эшелон чыгып китүгә, аның артыннан ук бастырып, станциягә танклар төялгән авыр состав шуышып керде. Дәһшәтле танкларның көпшәләренә авыр чехоллар киертелгән, бөтен платформаларда ниндидер бер шомлы тынлык хөкем сөрә иде. Кайдадыр, Япония чикләрендәме, ниндидер зур вакыйгалар булырга тора, җир шарының кайсыдыр почмагы кан сорый. Җир шарында әле тынычлык урнашып бетмәгән, җир үзенең улларын әнә шунда җыя. Станция аркылы көнчыгышка таба узган авыр вагоннар тыкылдавы көенә җир үзенең улларын көрәшкә чакыра иде.

— Нык булыгыз, балаларым, нык булыгыз... Сезнең кайберләрегез бу көрәштә шәһит булыр. Шәһитләр каны — изге кан,— ди. Җир-ана, вокзал турысыннан бер вагон узган саен, бу сүзне кабатлый:

— Изге кан,
изге кан,— ди.

## Әхмәтзариф кызыл утызлык чыгарып бирде

Сугыш беткән елны Заһриның фани дөньяга дәрте сүнә башлады. Сугыш кырыннан кайткан агайлар белән ничектер сөйләшергә сүз тапмады. Кичен капка төбендә тәмәке тартып, фронт хәлләрен сөйләшеп утырган ир-ат арасында ул үзен чит итеп сизә иде. Сугыш вакытындагы доходлар да кимеп китте: инде бәрәңге сатып, кием алыштырып баеп булмый. Шәйхи кода әйтә иде: дөнья куласа ул, әйләнә дә бер баса, дип. Дөрестер, ахры. Герман маллары да тиз туздылар. Аларның кайсы ясалма ефәк булып, бер юуга сыпылып чыкты, икенче бер төрлесе иләктәй сидрәде. Шулай да бер-ике әйберне Заһри үз кулында саклап калды. Аның берсе ялангач хатын гәүдәсенә эшләнгән зажигалка иде. Бу бик уңай әйбер булып чыкты: күкрәгендәге бер төймәгә бармак башыңны тидерүгә, оятсыз хатын бер аягын күтәреп җибәрә дә, әллә каян гына ялт итеп ут кабына. Дөрес, соңга таба Заһри моны кешегә күрсәтмәс булды. Чөнки бик тәкъваләнеп китте: йорт эшеннән ваз кичеп, намаз-нияз дигән булып йөри башлады. Әллә каян гына колак аппараты эшләтеп алды. Ул хәзер таякка таянып йөри, һавада козгын-фәлән кычкырып узса да, туктап, кулын каш өстенә куя һәм:

— Әссәләмөгаләйкем, хәерле хәбәр!— дип кала. Зират тирәсенә бозау арканларга барганда да кемнәргәдер дәшә. Зират киртәсенә килеп таяна да:

— Әссәләмөгаләйкем, дарәлкаумен мөэминин! — дип сәлам бирә.

Тәкъва Заһри шулай итеп фани дөнья белән мәшәкатьне әкренләп өзә барды. Соңгы елларда йөрәге бик начарланды. Ахрысы, кырык беренче елда тәмәке суын күбрәк эчеп ташлагандыр. Тәмәке суы, тәмәке суы... Моны искә алырга бераз гына уңайсызрак иде. Заһри дигән даның була торып, бер карчыкның кулына үзеңнең сәламәтлегенне тапшырдың. Син бит инде яңа шартларда да Заһрича яшәргә җай тапкан идең. Я, ярар, егерме бишенче елда Шәкүр эләккәч, эшләрең чуалды ди. Ә маклерлык? Маклер кешегә кайсы власть булса да начар түгел бит! Я, ярар, сугыш башланып, эшне бозды ди. Сугышта да бит бөтен кеше үлеп калмады. Ат җиктереп берәр складка киемсалым, сабын ташырга куйган булсалар? Менә бер-ике медаль тагып, бүгенге көндә «фронттан» дип авылга кайтып төшсәң? Мондый сәламәтлек белән аяк өстерәп җир йөзендә йөрүеңнән ни файда? Казан ар-

ты базарларында җир селкетеп йөргән Заһри бер надан карчыкның сүзе белән шушы хәлгә төшсен әле! Булмады, тормыш ул дигәнчә булмады. Кырык беренче елның июненнән соң барысы да кирегә китте. Булмасын иде аның бер аягы, булмасын иде аның бер кулы... Бер күзе булмасын иде. Ләкин иң кирәге — Заһрилыкның бөтен сыйфатларын үзенә җыйган бер генә нәрсәсе — йөрәге сәламәт булсын иде. Юк бит, шул иң кирәге аксый.

...Шәйхи кода, герман җирендә молотилкада эшләгәнлектән, машинаның көен тавышыннан белә иде. Тузан болыты эчендә ду-чат килеп гөрелдәтеп ындыр сукканда, Шәйхи карт читтән тыңлап тора да:

— Туктагыз әле,— дип, барабанщикка ишарә ясый иде. Һәм беркем дә сизмәгән бер көйсезлекне эзләп табып, рәтли иде. Заһриның да йөрәге хәзер әнә шундый хәлдә. Әгәр чит кеше аның күкрәгенә кулын куйса, һичшиксез, йөрәкнең ватык молотилка шикелле тигезсез, ритмсыз эшләгәнен сизәр иде. Дөп-дөп-дөп! Дөп... дөп... Дөп-дөп-дөп! Дөп... дөп... Ләкин бу — молотилка түгел. Моны инде берәү дә рәтли алмаячак иде. Болай ук дип кистереп әйтүче юк, әмма Ташлытау докторы бүген аның йөрәген тикшереп карап, шаккатты.

— Ерак юлга чыкма, үзеңне тыныч тот, моңа дәва шул гына,— диде. Заһри бүген генә бөтен фаҗигане аңлады...

Ләкин чыкмаган җанда өмет бар, ди. Заһри яшь вакытта авыруның нәрсә икәнен белмәде. Тегенди-мондый чир эләгә башласа, аның дәвасы билгеле иде: бер стакан аракы. Шайтанны күптән авызга алган юк. Нишләргә? Бәлки бу ватык арбаны бераз рәтләп җибәрер ул?

...Вакыт соң иде инде, капка-ишекләр ябылган, кояш батыш ягы нигәдер кызарып тора. Я давыл чыгарга, я яңгыр килергә тиеш иде. Менә салкын җил исеп китте, кибетче Борһан керле халатын салып, кибет тәрәзәсен ябарга дип чыкты. Ишек төбендә арык, сары йөзле Заһри тора иде. Борһанга бу кеше ничектер кызганыч булып тоелды.

— Кәеф-хәтерләр ничек, күрше? Әйдә, кереп чык эчкә таба, аннан бергә кайтырбыз,— дип, Заһрины кибеткә алып керде. Чүлмәкләр, сүсбаулар арасыннан бер шешә тартып чыгарды да, кырлы стаканга мөлдерәтеп аракы салды. Заһри башта бик нык каршы торган булды.

— Кирәкми, энем Борһанетдин, гөнаһ була, безнең ише авыру кешегә килешми ул,— диде.— Теге вакытларда ярады.— Ул авыр сулап куйды.— Һәй, алла, бар иде заманалар. Гомер үтте дә китте. Теге чак исеңдәме? Уңышка ярты пот бодай алганыңны әйтәм... Ну, кызык иттең син ул чакта. Ә гомер узды. Әйе, әйе, узды...

Борһан, гадәт буенча, эш бетәр алдыннан шактый ук төшереп алган иде, сөйләшерлек кеше очравына гомумән шатланды. Кызып, тормышта яшәүнең мәгънәсе турындагы фәлсәфәгә кереп китте.

— Менә, пример, бүген эштән кайтышлый миңа кереп бер шофер салып чыкты,— диде ул.— Күреп торам, кызмача бу. Тагын йөз иллене сорый. Тәк. Менә мин нишлим? Тагын йөз иллене салса исерә бу, аннан көт тә тор бер хәлне. Я ул урамдагы каз-үрдәкне сытып уза, я үзен харап итә. Или өенә кайтып хатынын җәберли бу. Йөз иллене салган кеше азрак җәбер күрсәтәме хатынына, йөзнеме? Әлбәттә, йөзне. Менә шунда инде Борһанетдин энең йөз илле урынына йөз тирәсен бирә тегеңә. Кәнишне, акчаны йөз илледән ала. Нәкъ ул дигәнчә. Я, нәрсә, начарлык эшлимме мин, әллә яхшылыкмы? Безнең инде синең белән алган медальләр юк, нихәл итәсең. Ә шулай да яши белергә кирәк. Менә мин үзем кырык беренчедә яраланып кайттым. Анысы — минем эш. Синең кияү — кайтып үлде. Анысы — аның эше. Әйе... Менә пич башыннан егылып төшүнең шулай рәте бар аның...

...Төн урталары иде инде. Заһри ишектән килеп керде дә, гөрселдәп, агач караватына барып егылды.

Иртәгесен йокыдан торгач, Фагыйлә җиңги бер хәрәкәтсез яткан Заһрины күреп, имәнеп китте: аның күзләре пыялаланган, авызы ачылган, ияге төшеп киткән, иреннәре сап-сары булып каткан иде.

Заһриның гәүдәсен докторлар районнан ике көннән соң гына биреп кайтардылар. Кәгазендә: «Йөрәк параличыннан үлгән», дип язылган иде.

Заһрины бөтен күршеләре җыелышып җирләделәр. Күмеп кайтканда нигәдер бер кеше бер авыз сүз әйтмәде. Һәркайсы сүзсез генә үз капкасына кереп китте. Һәркемне әллә нинди тойгы, кайгыга охшамаган авыр тойгы баскан иде.

...Бер елдан соң Әхмәтзариф та кайтып төште. Ул өс-баш, ул кыяфәт — генералмени! Әхмәтзарифны Ташлытау автоколоннасының шоферы «Студебеккер» белән станциядән Кара Чыршыга китерде. Җәйнең матур көннәреннән берсе иде — Заһрилар капка төбенә машина килеп туктауга, халык җыелды. Авыр чемоданнарны, саргылт күн сумкаларны, фонарьлы велосипедны шофер кузовтан аска биреп торды. Мундир кигән, ак ефәк перчаткалы таза сержант Әхмәтзариф аларны саклык белән генә чирәмгә куеп торды. Урамнан узып баручы берничә кыз машина янына җыелды. Болар Ташлытаудан концерт белән килгән агитбригада кызлары иде. Әхмәтзариф шоферга кызыл утызлыкны чыгарып бирде дә саубуллашты, аннан кызлар белән сүзгә кереште. Авызына сигара капты да, божралы, хуш исле төтен сибеп, сөйләнә башлады.

— Ә мин узган ел отпроситься итә алмадым. Ишеттем, что папа үлгән. Без Потсдам янында гына тордык — особое положение. Авыл юлын онытканмын. Через Атҗабар кайттык...

Кибеттә чират торган Фагыйлә җиңги йөгерә-йөгерә кайтып килде. Бер сүз әйтә алмыйча тынына буылып, Әхмәтзарифның киң каешлы биленә сарылды да, калтырап елый башлады.

Күпне күргән Фагыйлә җиңгинең битләре җыерчыкланган, таушалган иде. Әхмәтзариф затлы кызлар барында бу хәлдән бераз гына кыенсынды һәм үзенең ялтыравыклы каешыннан әнисенең кытыршы, ярылган кулларын аерып читкә этәрде.

— Ладно, әни, өйгә кергәч поговорим,— диде.

Әхмәтзариф кайткан атнада авылга тагын җиде-сигез егет кайтты.

## Атлар атламас инде...

Шәйхи карт сөйли торган иде: имеш, Агыйделнең бер ягында берәү чиләк ясый, икенче ягында икенче кеше шул чиләккә капкач ясый, дип. Кара Чыршыда бу хәл бик күп семьяга туры килә иде. Әмма туры килмәгәннәргә дә Шәйхи картта халык сынамышы бар иде. Аллаһы тәгалә, дип сөйли иде Шәйхи карт, кешеләрне парлаганда көйли-көйли, борын эченнән генә мырлап парлаган.

— Бер явызга — бер яхшы!

— Бер яхшыга — бер явыз!— дип көйли дә утыра икән. Ихтимал, монысына туры килүчеләр дә Кара Чыршыда аз түгелдер...

Хәер, Шәйхи картның сөйләгән әкиятләреннән тагын берсен халык хәтер түрендә саклап калган иде. Борын-борын заманда, кешеләр әле агачка, ташка табынган чорда, бер адәм аудан кайтышлый тимердән ясалган бер хикмәтле әйбер табып ала. Бу әйберне хатынына алып кайтып бирә. Хатыны бу тимерне әйләндереп-әйләндереп карый да, бер дә рәтенә төшенмәгәч, авызына каба. Калтырап торган тел сыман бер нәрсәсенә чиртә дә, өрә башлый. Шуннан көй чыга. Баксаң — бу кубыз икән. Шуны уйнап җибәрүе була — ире шатлыгыннан бии башлый. Әнә шул заманнан бирле ирләр хатыннарының кубызларына биилэр ди...

Шәйхи картның үлгәненә инде егерме биш елдан артык вакыт үткән, инде аның кабере өстендәге чардуган череп җимерелгән, ләкин сөйләгән сүзләре әле дә Кара Чыршыда яши бирә.

Алар нәселенең каберләре бер аумакта. Каберлек тирәсендә күе булып чәчәкле үлән үскән, кич белән анда чикерткәләр чурлый, чәчәкләрдән бал исе тарала... Зират янында гына клевер басуы. Кайшалып үскән клевер басуы офыктагы урман полосасына кадәр тоташ диңгез булып җәелеп яткан.

Кояш батып килә иде...

Кара Чыршы урамыннан тузан туздырып эсселектән әлсерәгән сыерлар узды, борыннарыннан селәгәй агызып, башларын салындырып сарыклар узды — көтү кайтты. Чык төште, авылга сыер исе, сөт исе таралды, келәтләрдә сепараторлар гүэлди башлады. Зират буендагы юлдан чатыр чабып килгән бер ат йөге халык күренде. Яшьләр икән. Клевер басуына таба атларын бордылар да, арбадан коелып чырылдаштылар, көлделәр, тәмәке кабыздылар — ду килделәр. Егетләр — ак күлмәкнең җиңен сызганып, итәген кара чалбар эченә тыгып киенгәннәр. Кызлар — кыска җиңле күлмәктән, барысының да беләгендә сәгать. Егетләрдән берсе арба астыннан чалгы алып клевер чаба башлады, икенчесе җәһәт кенә зират коймасын сикереп керде дә, бер көлтә чәчәк җыеп чыкты. Зират тирәсе яшьләрнең шат тавышына күмелде — көянтәдәй бөгелеп, очларын җиргә тидергән озын нәзек каеннар дәшмәделәр. Тып-тын калган карт наратлар... Зират үзенең бөтен тынлыгы белән әйтерсең лә бу чыркылдык яшьләрдән сорый иде:

— Юлчылар, сез кайдан киләсез?

— Без Атҗабардан киләбез!

— Юлчылар, сез кая барасыз?

— Без туйга барабыз!

Өенә кайтырга соңга калган бер козгын коңгылдап очты. Зират өстеннән кичке соңгы җилнең дулкыны узды.

— Кем өйләнде соң, балакайлар?

— Кара Чыршыда бүген туй була! Васфикамал Нәриманы туй ясый! Без ашыгабыз! Безнең бүген төндә туйны уздырып, иртәгә Ташлытау сабан туена барасыбыз бар! Без ашыгабыз! Син инде үзеннең карт наратларың, көянтәдәй кәкре каеннарың белән гомер буе шулай тик торасың... Безнең яшисебез бар! Безнең бүген җырлап биисебез бар! Безнең иртәгә сабан туйга барасыбыз бар! Ә син, картлач, гел бер урында. Син яшәүнең кызыгын белмисең, синдә тынлык... Син бүген безне тыңла...

...Туй бара. Чәчләре, сакал-мыеклары ап-ак булган Шәяхмәт почмак якта Васфикамал белән каз түшкәсе турый. Ике-өч көн инде аның ял күргәне юк. Васфикамал өйдә туй вакытында хуҗа булырсың дип, ялгыз картны үзенә китертте. Карт, тегәрҗеп белән беркеткән күзлеген борынына элгән дә, тозлы каз ите турый... Бер кисәк, ике кисәк, өч кисәк. Бер ел, ике ел, өч ел... Юк, ун ел, егерме ел, утыз ел... Менә шулай дөрес. Унарлап санасаң гына гомерне дөрес исәпләп була. Менә бу өйне салганга ике дистәдән артык. Әйе, кырык беренчедә иде. Нәриман туганга — ике дистәдән артык. Карчыгы Зәйнәпне җирләгәнгә — бер дистә чамасы. Елларны шулай дистәләп исәпләргә кирәк. Гомер — ит кисәге түгел. Үзенең пенсиягә чыкканына да киләсе елга ун ел була икән. Персональный диделәр. Кая барсаң почет — бөтенесе хәлеңне сорый. Картаеп буламы? Сызланмыйсыңмы? Кәефләр ничек? Мәктәп балалары пионер сборына чакырмый калмыйлар. Сайлау вакытында һәр елны аны урналар янына утырталар. Бер сайлаучы —бер нокта, ике сайлаучы — ике нокта. Биш нокта — биш кеше тавыш биргән. Сайлау саен Шәяхмәт шуны эшли. Хәзер ревкомиссиягә чакырмыйлар. Анда, управлениедә, әллә ниткән тар юбкалы, югары белемле

мут кызлар исәпләү машинасын гына борып утыралар... Шәяхмәттән башка да була хәзер. Хәер, ул гына түгел. Тимерханнан башка да авыл хуҗалыгы бара икән. Ләкин ул партшкола тәмамлады. Тимерхан хәзер шәһәрнең кайсыдыр районында партия райкомының икенче секретаре. Аның да чәчләре агара башлаган. Димәк, тормышның законнары шундый, яшьлек, эш, куәт — барысы да бер вакытлык кына. Бер төрле кешеләр — бигрәк тә яшьләр — Шәяхмәттән туп-туры:

— Ничәдә инде син?— дип сорыйлар. Кайберләре, ике дә уйламыйча, ул барында «фәлән кеше үлгән, картаеп үлгән» диләр. Баксаң — ул кеше әле Шәяхмәт карттан яшь булган икән. Картлык, картлык...

Олы яктагы яшьләр кыздылар. Тәрәзәләр ачылды. Хромка гөрләде. Килен ягыннан килгән яшьләрнең берничәсе шәһәр егетләре иде. Алар чыбык тарттырып магнитофон, фотоаппарат, пластинкалар белән матавыкландылар. Җылы кичке һавага ачык тәрәзәләрдән җыр таралды.

Нигә яшьлек — янмагач та, көймәгәч тә,
Яшьлек уты йөрәгемне өзмәгәч тә,
Нигә яшәү, нигә гомер, нигә хисләр,
Яшьлек гомерен сөя-сөя кичмәгәч тә.

Бүлмә ишегеннән Шәяхмәт олы якка күз салды. Бер якта — Нәриманның дуслары — барысы да диярлек шоферлар, тракторчылар. Кара бәләкле, таза егетләр. Әнә берсе көрәшче. Иртәгә ул Ташлытауда көрәшергә тиеш. Кызып алган — унлап кеше өчен өстәлгә әзерләп куйган балыкны тәлинкәсе белән тартып китерде дә, җимереп ашап бетерде. Яшь килен өстәл шәһәрчә булсын дип бик тырышкан иде... Шәһәрчә булсын дип сөйли-сөйли тост күтәрәләр. Тракторчылар телгә әллә ни оста түгел икән. Барысының да сүзләре чама белән бер тирәдә әйләнә.

— Ике яшь матурның тигез мәхәббәте өчен шушыны эчеп җибәрик...

— Өстәлгә килгән иткә керешкәнче, берәрне астына салып куйыйк...

— Тигез мәхәббәтле ике яшь матурның...

— Яшь матурлы ике тигез мәхәббәтнең...

Стенада, зурайтып эшләнгән рәсемдә — Хәкимулла белән Васфикамал. Хәкимулла үз гомерендә кимәгән яхшы пиджактан. Танысаң таны — танымасаң юк.

Ул зур күзләрен өстәл янындагы кунакларга текәгән дә әйтерсең лә аларга дәшә:

— Әй, сез безне хәтерлисезме? Дөньяда без дә бар идек. Сез — безне дәвам итүчеләр. Кайвакытта безне дә искә алыгыз,— дип әйтә кебек.

Васфикамалның гына карточкадагы киеме тормышта булганча. Чәчәкле маркизет күлмәге ияк астыннан ук түгәрәкләнеп, муенын каплаган. Муенында ике рәт эре гәрәбә. Чәч юлы кыл уртадан ярылган. Киерелгән кыйгач кашлар. Яшь, чибәр. Утыз алтынчы елның җәендә яшькелт ящик күтәргән бер кеше Кара Чыршыда йөргән иде. Шул вакытта төшелгән рәсем. Теге кеше капкага корылган ак җәймәгә сөяп утырта иде дә, ящиктан чыккан бер чыбыкның башын тотып, иреннәрен кыймылдата иде. Кара Чыршы халкы моны сихер укый дип белә иде. Әнә шул кеше төшергән рәсемне Нәриман быел зурайтып эшләтте. Ә чибәр Васфикамал менә мич алдында паштет турый. Кайнатасы гына түгел, ул да картайган. Ирсез үткән тормыш аның канын киптергән. Арык иңбашлары, кара янган арык яңаклар. Ярылган куллар. Дәрт чаткысы сүнгән күзләр. Борчу, борчу. Нәриман авыр чорда туды. Кырык өченче елда, Васфикамал кырда бәрәңге алган вакытта, тәрәзә төбендә ятып йоклап, чирләде.

Васфикамал эштән кайтканда бала телсез калган иде. Тәрәзә суыгы... Шуннан озак вакыт теле булмады. Кышлар, язлар узгач кына

җәйнең матур бер көнендә телгә килде. Һич тә көтмәгәндә. Урамнан йөгереп керде дә ашка кычыткан турап яткан әнисенең тезен кочаклап чырык-чырык көлә-көлә бер сүз әйтте. Ахрысы, урамдагы олырак малайлар өйрәткәндер. Васфикамал шатлыгыннан ни эшләргә белмичә, аны күтәреп төп йортка йөгерде.

— Әткәй, әткәй!— дип кычкырды ул, капкадан йөгереп кергәндә,— Нәриман... дип әйтте!

Әйтергә ярамаган сүз ул көнне бөтен нәселне шатландырды.

— Нәриманның теле ачылган!

— Нәриман сөйләшә башлаган!

— Нәриман фәлән дип әйткән!

Бу хәбәр Шәяхмәтләрнең бөтен нәселе буенча йөрде.

Аннан сугыштан соңгы авыр еллар. Васфикамал ферма мөдире. Көн-төн эштә. Кичен соң гына кайтканда капка төбендә малае утыра. Зур солдат фуражкасы күзенә үк төшкән, борын аслары юеш, балчыкка каткан тез башлары, чебиләгән тәпиләр. Үзенең күлмәгендә һәр вакыт әнисенең сугыш вакытындагы хезмәте өчен алган медале булыр. Нәриман ул медальне укырга кергәнче бер дә күкрәгеннән төшермәде.

...Ә хәзер Нәриман киң җилкәле бер ир булып өстәл башында басып тора. Кулында стакан. Ул эчәргә яратмый — Шәяхмәтләр нәселендә андый кеше, гомумән, булмады. Ләкин бүген ул кызган. Шатлыктан. Кыз авырлык белән эләкте. Ничә тапкыр Ташлытауга мотоцикл белән төнлә барып карады — кызның күрше егете аяк чалды. Узган ел сабан туйда бер авыз сүз сөйләшеп булмады — шул күрше егете күзәтте. Кыз белән сөйләшү өчен мөмкинлекне тормыш үзе ясады. Ә галимнәр могҗиза юк дип сөйлиләр, ышан син аларга. Пычагымны беләләр. Бәхетле дуңгызның борын очында азык булыр, диләр. Бәхетең генә булсын.

Узган ел совхозга бер путевка килде — Ленинградтан чыгып китеп, Балтик диңгезе буенча йөрисе иде. Рабочкомда моны Нәриманга бирергә дигән карар чыгарылды. Еллык күрсәткечләр буенча ул узган ел совхозда беренче урынны алган иде. Нәриман Ленинград турбазасында Зөлфияне күреп шаккатты. Болар Татарстаннан икәү генә иде. Шәһәрләрдә йөргәндә Нәриман экскурсоводларны җүнләп тыңлый алмады — күңелендә гел Зөлфия булды. Тик Фин култыгының бер урынында гына ул экскурсоводны йотлыгып тыңлады — сары чәчле, зәңгәр күзле, озын буйлы эстон кызы бик матур акцент белән кырык беренче елда бу тирәдә барган канлы сугышлар турында сөйләде. Нәкъ тегермән ташы төсле бер чуерташ өстенә басып экскурсоводны тыңлаганда Нәриман үзенең учына Ташлытау кызының кулын алды. Тегесе моңа кулын кысып җавап бирде. Шуннан соң бу куллар берсе-берсен ычкындырмадылар. Эстон кызы бу җирләрдә барган авыр сугышлар турында сөйләгәндә нарат башында берөзлексез козгын очынгалады. Оча-куна коңгылдады. Бәлки аның шул тирәдә генә оясы бардыр. Козгын бәлки эстон кызы сөйләгән канлы сугышларны үз күзе белән күргәндер. Козгынны өч йөз ел яши диләр...

Зөлфияне Ташлытаудан алып кайтуы җиңел булмады. Моңа сәбәпләр шактый иде. Иң беренчесе — булачак киявнең әнисен кызга яманладылар. Бөтен Кара Чыршыны дер селкетеп торган Васфикамал, диделәр. Кыз Нәриманны Ташлытауга чакырды.

— Күч тә кил, ике көн эчендә СМУга урнашырсың,— диде. Бу хәбәр нииндидер юллар белән Васфикамалга ишетелде. Тол хатынның йөрәге телгәләнде. Ярсыды.

— Минем кешегә бирергә дип үстергән малаем юк,— диде ул, тынына буылып. Бу хәбәр дә Кара Чыршы белән Ташлытау арасын икеөч көн эчендә әйләнеп чыкты.

— Минем кешегә бирергә дип үстергән малаем юк!

Аннан — эш мәсьәләсе. Зөлфия китапханәче иде — Кара Чыршыда китапханәче урыны юк. Бөтен булган китап, бильярд, волейбол тубы, клуб, уку йорты — барысы да егерме биш тәңкәлек ниндидер чирек штат белән бер апа кулында. Ә Зөлфиянең китапханәче дигән дипломы бар. Эшсез калсаң, нихәл итәрсең?

...Васфикамал бәлеш майлый.

Васфикамал кайнатасы белән кичә якта стаканнарга компот тутыра. Бер стакан, ике стакан, өч... Узган гомер... Бер ел, ике ел, өч ел. Аның гомерен еллап санарга кирәк. Бу нигезгә чыкканына егерме җиде ел. Бу авылга килгәненә утыз елдан артты. Хәкимулла эшчән, намуслы егет иде. Аның белән узган алты ел хәзер алты көн дә күк тоелмый. Теге якта яшьләр гөж киләләр. Ник кенә берсе Хәкимулланы искә алсын. Хәер, аларның берсе дә Хәкимулланы белми. Ә кодагый туйга килмәде. Йөрәк ярасы.

— Хисмәт Миңнисасы туйга килмәгән!

— Теге вакытта Хәкимуллага килеп киткән икән ул!

Авылда шундый хәбәр йөрде.

— Хисмәт Миңнисасы кызын Нәриманга бирми икән! Аларның нәселдән килгән дошманлыклары бар икән! — Монысы кыз алып кайтыр алдыннан таралды. Йа алла, нинди дошманлык булсын соң! Сугыш барысын да җимерде. Хәкимулла, шулай итеп, берәүгә дә калмады: Васфикамалга да, Миңнисага да. Миңниса да бәхетсез булып чыкты. Мануфактура кибетендә эшләгән егет шулай ук сугышта үлде. Бөтен булганы — Миңниса бер кыз баласы белән Ташлытауда ипи карточкасы алып яшәп калды. Гомер үтте дә китте. Инде шулардан соң дошманлашып торыргамы?

Нәриман кызны алырга бер барды — булмады. Кыз әнисен рәнҗетүдән курыкты. Икенче барды — кинодан чыкканын күтәп торды да, урлап диярлек алып кайтты. Беренче төнне сөйләшеп тамаклары карлыкты.

— Ичмасам, теге килүеңдә авызымны томалап урлый да белмәдең, — дип, кыз елап алды. Аннары кайнар беләкләре белән Нәриманның муенына чорналды. Шуннан дөнья әйләнеп китте... Иртән ишегалдында көлә-көлә бер-берсенә су сибешеп уйнаган яшьләрне күреп, Васфикамалның йөрәге әрнеде. Малай шулай ук кешегә ычкындымени? Әни кайда? Аңа дигән җылы сүз хәзер Ташлытау кызынамени? Кем үстерде соң бу горнадир күк егетне? — Тол хатын карасына катты.

Беренче чәйдә үк ачу тышка бәреп чыкты.

— Менә мине кыстагыз, — диде ул ярсып, малай белән киленнең берсен-берсе кыстап утыруларына чыдый алмыйча. — Менә мине кыстап ашатыгыз! Мин шушы егетне үстергән ана булырмын!

Килен чоланга чыгып, шунда ук елап керде. Кайнана явыз дигәннәр иде — рас сүз икән...

— Улым, — диде Васфикамал, күзләрен яшьләндереп, — улым. — Килен суга киткән иде. — Менә әйтер сүзем бар: үз урыныңда тора бел: хатыныңны узындырма. Мунчала булма. Баланы яшьтән, хатынны баштан, дигәннәр борынгылар. Катырак тор. Бозау булма.

Ләкин... Ах, бу баланы! Нәриман мунчада Зөлфиягә моның бөтенесен дә сөйләп ташлаган...

— Шулай, шулай дигән, әни каты торырга куша, дигән...

Яшь килен дә мунча чыгуга җае белән кайнанасына ырпыланып алды.

— Нәрсәгә дип безнең араны бозасың? — диде.

Аннан... Бер атна узуга, килен аерылып китте. Нәриман аны барып алды. Ике атнадан тагын китеп барды.

— Барып йөрмә, — диде Васфикамал улына. — Алай узындырма. Үзе килсен. Икенче китмәс. Алай иләндермә.

Лəкин ялгыз калгач малай бозылды. Әнисе белән сөйләшмәс булды. Юк кына җирдән тавыш чыгарып, әнисенә каты сүз әйтте.

— Безнең эти,— диде ул,— бик начар кеше булгандыр.

Васфикамалның йөрәге селкенеп алды.

— Ник алай дисең, улым?

— Шәп кеше булса, ул сине алмаган булыр иде...— Ана телсез калды.

Икенче бер вакыт салган баштан Ташлытауга барырга дип мотоциклын кабызды. Васфикамал ишек бусагасында юлына аркылы төште.

— Улым, йөрмә, егылып харап булырсың, тыңла сүземне,— дип ялынды. Лəкин хатыны киткән кешенең холкыннан алла үзе сакласын.

— Әни, мине төрмәгә кертәсең килмәсә, юл өстеннән кит,— диде малай. Ничек сөйләшә бит!

Яшь килен машина белән үзе килде. Әнисен дә иярте килгән иде. Хисмәт Миңнисасы дигән үткен хатын шул икән... Бер мәлгә ике кодагый дәшмичә бер-берсенә карап тордылар. Әйтәсе сүзләр күп иде — һәр икесенең бугазына төер утырды. Ташлытау кодагые кулындагы җәймәсен идәнгә салды да, ду күчереп шкафтагы савыт-сабаны төйи башлады. Килен караватт өстендәге урын-җирне бик әкренлек белән генә сүтәргә кереште. Шул вакыт комбинезон кигән Нәриман өйгә кайтып керде. Керде дә, майлы киеме белән түргә узды һәм Зөлфияне кочаклап алды. Зөлфиянең өстендә җиңсез ак күлмәк иде. Кодагыйлар телсез калдылар.

— Минем җибәрергә дип алган хатыным юк!— диде Нәриман, Зөлфияне кочаклаган килеш. Ташлытау кодагые аптырап калды: Зөлфия дә Нәриманның күкрәгенә сыенып, аны кочаклап тора иде.

— Мин дурак! Мин тиле! Канчак! Синең сүзең белән йөргән мин җүләр!— дип, Хисмәт Миңнисасы кызын тиргәде.

Килен торып калды. Ә Нәриман, имеш, кибетче хатынга елый-елый сөйләгән.

— Хатынсыз тору күңелләме?— дип сораган тегесе Нәриманнан.

— Юк,— дигән Нәриман,— сиңа гына әйтәм, апай җаным, эти үлеп этине дә болай юксынмаган идем...

Килен торып калгач, кибетче хатын Нәриманны туры китереп, тагын сораган, имеш.

— Хатыныңны яратасыңмы?— дигән.

Нәриман ике дә уйламыйча җавап биргән.

— Көннән-көн катырак яратам, апай җаным. Көннән-көн катырак яратам...

Килен шулай торып калды. Кайнана белән ике арада артык сүз чыкмады, тик бер генә тапкыр килен үзе сүз башлады.

— Мине килеп алмаска малаеңны котырткан булгансың икән,— диде. Васфикамал авыр сулады, бер сүз дә дәшмәде. Менә шулардан соң кодагый туйга килмәде. Лəкин Зөлфия утырып калгач, Нәриман әнисе өчен өзелеп тора башлады.

...Ә мәҗлестәге яшьләр җырлыйлар да җырлыйлар. Инде тышта яктырып килә, инде килен чоланга чыгып ике тапкыр елап керде. Нигәдер күңел китек. Кайнана белән берсе-берсен яратыша алмасалар, нихәл итәрсең? Эш урыны табылмаса, нихәл итәрсең? Болар нигә бик каты җырлыйлар соң? Ә, әйе... Болар моның яшьлеген җырлыйҗырлый озаталар. Аларның бер кайгысы да юк. Сау бул, яшьлек! Хушыгыз, гөнаһсыз, борчусыз вакытлар!

Гармунчы инде тиргә баткан.

Яшь килен почмак яктан ризык ташый. Ризыкны үз вакытында, тәртибе белән генә бирергә кирәк. Башта кем алдына куясы, аннары кем алдына... Монысын олылар әйтеп тора. Кунак сыйлау уен эш түгел. Туй алдыннан Васфикамал унбиш көн йокламады. Унбиш көн

салкын түшәктә йокысыз аунады. Хәер, түшәкнең суынганына тиздән утыз ел була... Ә яшьләр бу турыда белмиләр. Аларга җыр булсын.

Ах, шул назны мин дә сөеп кочар идем,
Сөяр идем, канатланып очар идем.
Әгәр яшьлек ике тапкыр килә икән,
Икесен дә сөя-сөя кичәр идем...

Васфикамал баскычка чыгып басты. Ишегалдында — коляскалы мотоциклләр, капка төбендә — йөк машиналары, лапас астында — печәнле арба.

Кызарып таң ата. Әнә Ташлытауга таба бара торган олы юл. Ташлытау юлы өстендә быел да арыш басуы. Шул юлдан чатыр чабып таң атканда Васфикамалны алып кайтканнар иде. Ул кара туры атны Васфикамал хәтерләп калды. Ул ат очраган саен Васфикамал яшь вакытындагы шул бәхетле таңын хәтерләп авыр сулап сагыш эченә чума иде. Кара туры сугыш вакытында ачлыктан егылып кутәрәмгә калды. Аннан аны суеп фермадагы төлкеләргә бирделәр... Бу юлдан кырык беренче елда Хәкимулла чыгып китте. Аның киң җилкәсе арыш басуында шактый озак күренеп барды. Аннан аны үгез арбасына утыртып кайтарып куйдылар. Бу юлдан Васфикамалның «урлашкан» кайнесе Миңлегали чыгып китте. Миңлегалине дә теге кара туры белән озатканнар иде... Инде бу юлда арба тәгәрмәченең эзен дә күрмәссең. Аннан инде машиналар гына чаба. Бу юлдан атлар беркайчан да атламас инде.

Яшьләр түр башына Шәяхмәт картны да чыгарып утырткannar икән. Нәриман исә һаман басып сыйлый. Инде бераз исерә дә төшкән. Җае чыккан саен Зөлфиянең әле аркасыннан, әле беләгеннән сөеп ала. Шатлыгы эченә сыймый. Зөлфиянең ялангач беләкләре кара янган, үзе ак күлмәктән. Мәҗлестә аннан чибәр берәү дә юк.

— Дәү әти, тәбриклә мине,— дип, Нәриман бабасына кулын бирә.

— Әни, тәбрик ит мине,— дип, Васфикамалга кулын бирә. Васфикамалның сагышлы йөзенә елмаю чыга.

— Зөлфия! Тәбрик ит мине! Минем бүген иң шатлыклы көнем. Бу, беләсезме? Бу — гомергә бер килә. Зөлфия, син дошман сүзенә карама. Дошманнар бервакытта да мактамаслар. Әйбәт яшәрбез. Минем узган елдан калган уналты капчык бодаем гына бар. Дошман сүзенә карама. Безнең әнинең теле үткен булса да, гадел кеше ул. Син аны әле белмисең. Ул сугыш вакытында районында беренче уракчы булды. Әни, кил әле монда, тәбрик ит мине...

Яшьләр Шәяхмәтнең сөйләвен үтенделәр. Стаканнар хәрәкәткә килде. Шаулаштылар.

— Шәяхмәт кода сөйләсен!

— Бабай нәрсә әйтер икән...

— Сорыйбыз, үтенәбез. Тост әйтсен!

Шәяхмәтнең күптән инде сөйләгәне юк иде. Стаканына шыпырт кына ижевский су салып кулына алды. Бөтен гомере күз алдыннан узгандай булды. Аның бөтен гомере шушы Кара Чыршы колхозына бағышланды. Колхозга иң беренче радиоалгычны ул алып кайтты. Халык ышанмады, ящик эчендә кеше бар дип хыялландылар. Бераздан аны шәһәр радиокомитетына чакыртып сөйләттеләр. Ул көнне Кара Чыршы халкы, идарә янына җыелып, Шәяхмәтне тыңлады. Тамагын кыра-кыра, Шәяхмәт радио аркылы авылдашларына эндәште.

— Фәхерниса, Гыйльметдин, мине ишетәсезме? Мин — Шәяхмәт, шәһәрдән сөйлим. Әйе, мин радио кәмитетендә утырам. Мине ишетәсезме?

Анда да ышанмаучылар булды. Борһан, идарәгә кереп, шкаф эчләреннән Шәяхмәтне эзләп йөрде.

— Шушында гына ул, шәһәрдә түгел,— дип, теш ыржайтты. Ә туйдагы яшьләрнең ничәсендә генә транзистор бар. Чөй саен элеп куйганнар.

Сугыштан соң колхозда беренче электр станциясен салдырганда да Шәяхмәт карт зур эш эшләде. Идарә, станцияне эзләп-эзләп тә таба алмагач, Мәскәүгә кеше җибәрергә булды. Бер центнер бодай сатып, шуның акчасына Шәяхмәтне Мәскәүгә җибәрделәр. Колхоздан алган бер кәгазь белән йөри-йөри, ул Верховный Советка килеп җитте. Шверник янына керде. Шверник белән алар кордаш булып чыктылар. Шуна күрәдерме, Шәяхмәт каушамады. Иркенләп сөйләште. Мәскәүдән ул кайтып, ун көн уздымы-юкмы, Ташлытау станциясенә йөк килеп туктады. Контейнерга «Кара Чыршы авылы, Кәлимуллинга» дип язылган иде. Шверникнең өстәлендәге календарьга Шәяхмәтнең исеме, авылы язылды ул вакытта. Кара Чыршы авылын Шверник белә иде ул чакта. Ә хәзер... Кара Чыршы дигән сүз инде бетеп бара. Хәзер инде ул «Дружба» совхозының өченче этдилиниясе дип кенә йөртелә. Хәзер инде директорның исемен белүче дә аз. Кечкенә «этдилиниедә» ул бөтенләй булмый. Утызынчы елларда салынган яхшы амбарларны сүттереп, үзәк усадьбага ташытты. Тегермәнне сүттереп алып китте. Хәзер совхоз үзәгендә электр тегермәне. Бу бик уңай, ләкин шуларны сүтеп алып киткән саен Шәяхмәтнең йөрәге әрни. Ә яшьләр моны аңламыйлар. Нәрсә, әллә шул турыда бер-ике сүз әйтергәме? Кеше рухы белән сак эш итегез, дияргәме? Юк, аңламаслар... Болар әле бик яшь...

Шәяхмәтнең фикерен стенадагы репродуктор бүлдерде. Анда «өченче отделение»нең бригадиры сөйли иде.

— Иптәшләр, сабан туйга киткәнче сыерларны туйдыру мәсьәләсен хәл итәргә кирәк булыр. Әгәр шуны эшләмәсәк, яхшы булмас, иптәшләр. Галимулла, син арба тагып аръяк басуга клеверга чыгарсың. Нәриман, сиңа да тракторыңа арба тагып фермага вика илтеп кайтырга кирәк булыр. Мөмкинлек бирмәдек түгел, бирдек, инде өч көн кунак җыясың, туй итү ул, кәнишне, яхшы эш, но үзеңнең төп эшеңне дә онытырга ярамас. Иптәшләр, һава хәлләре бу арада әйбәт тора, шуннан файдаланып, безнең өченче отделениедә эшлисе эшләрне төгәлләргә кирәк... Шуларны эшләмәсәк, яхшы булмас, иптәшләр...

Шәяхмәт карт торып басты.

— Оланнар,— диде ул, тамагын кырып,— балалар! Мин бик озак яшәдем. Әйе, озак. Инде мин, олы кеше буларак, үземнең гомеремдә алган тәҗрибәдән чыгып, бер нәрсә әйтмәкче булам: дөньяның төрле вакыты була. Әйбәт чагы әлегә, менә бүгенге төсле күңелле була. Авыр вакыты була — теш кысып яшисең. Кеше үз гомерендә шуларның икесен дә күрә, кичерә. Әмма ликин, шуның кайсы күбрәк әлегә дигәндә, минемчә, авыр вакыты күбрәк була. Әнә шунысында сынатмаска кирәк. Шунда ир була белергә кирәк. Әнә шуларны күтәрә белергә кирәк. Мин үзем шуларның барысын да үттем. Арысландай ике малай үстердем — беттеләр. Нәриманның этисе гарип булып кайтып үлде. Сезнең кебек чибәр тагын бер егетем бар иде — сугышның соңгысында — Кытай җирендә, кырык бишенче елның августында бетте. Алар гомере миңа калды.

Әмма ликин безне бөтенләй бетерә алмады сугыш. Без яшәрбез әле. Без диюем — менә балаларым Нәриман белән Зөлфия. Әле мин аларның балаларын җитәкләп йөрермен дип уйлыйм...

Барысы да кул чаптылар.

Шәяхмәт карт, рәвешен китереп, стакан белән суны күтәреп эчте дә, мыекларын сыпыргалап ишегалдына чыкты. Өйдә аягүрә баскан килеш Нәриман җырлый иде. Ул Зөлфия ягыннан килгән егетләрнең берсенә кулын биргән, сузып-сузып җырлый.

Атлар атламас инде,
Сине мица, мине сица
Ятлар мактамас инде.

Авыл тып-тын. Карт урамга чыкты. Көн инде яктырып килүгә карамастан, багана башындагы электр лампочкалары җемелдәп утыралар. Хәзер электр ерактан килә шул, кызганып тотмыйлар.

Нәриман һаман бер җыр җырлый. Карт кешегә яшьләр янында җырлау әдәп кагыйдәләренә каршы килмәсә, бабасы икенче бер җыр җырлар иде. Әнә Ташлытау юлы — гомерләр аккан, язмышлар кичергән, бәхет-шатлыклар, кайгы-хәсрәтләр йөреткән олы юл. Шәяхмәтнең бөтен нәселенең — ата-бабаларының, үзенең, балаларының һәм оныкларының бөтен тормыш юлын шушы юл язышкан. Тормышка шушы юл гына шаһит. Ул юлдан күпме ат узган, ул атларда авылдан кемнәр генә чыгып китмәгән, кемнәр генә кайтмаган. Аз гына җил искәндә дә ул юлдан күпме тузан күтәрелгән, ул тузан да, кешеләр кебек, я юлдан сибереп, я өермә булып күчкән. Я Кара Чыршыга таба, я Ташлытауга таба. Ташлытау юлы — Шәяхмәтләр нәселенең шәҗәрәсен язучы. Яшьләр гаеп итмәсә, Шәяхмәт карт мәҗлескә кереп бер җыр җырлар иде хәзер. Бу — аның үз гомерендә иң соңгы җыры булыр иде.

Бу җырны тимер ходлы арбага утырып авылдан чыгып киткәндә аның улы Хәкимулла җырлаган иде. Әтисе-әнисе барында беренче һәм соңгы мәртәбә. Ул җыр болай иде:

Тукта, поезд, тукта, поезд,
Тукта Мамадышларда.
Бер айрылгач, кауша торган
Канат кошларда гына.

Бичара Хәкимулла... Күңеле сизгән икән. Кавыша алмады. Кайтты кайтуын, әмма контузиясеннән айнып бер генә мәртәбә дә адәм рәтле сөйләшеп утыра алмады. Акылына килә алмады. Ә җыры калды. Әйе, бер аерылгач кавышуы кыен, бик кыен бу дөньяда...

Әллә бүген, менә шушы мәҗлестә Хәкимулланың шул җырын җырлап бирергәме икән? Нигә бер генә кеше дә сорамый аны? Бу кияүнең (Нәриманның) әтисе кем? Кайда ул? Бу портретта кем? Исеме ничек иде? Кайда үлде? Нигә бер кеше дә кызыксынмый? Ә бит кешеләр беркайчан да эзсез югалмыйлар. Аларның эшләгән эшләре, сөйләгән сүзләре, балалары, ул балаларга тапшырган гадәтләре, әхлаклары кала, дәвам итә. Ниһаять, җырлары кала. Нигә шуларны искә алмыйлар? Әллә теге җырны җырларгамы?

Әмма, мәҗлескә кереп, карт бу җырны җырламас. Шуны җырласа, ул, йөрәге туктап, шундук егылырмын дип курка. Шуңа күрә ул аны эчтән, йөрәк белән генә җырлый. Әйдә, кычкырып Нәриман җырласын. Яшьләрнең җырлар чагы. Гомер — шулар җырласын өчен көрәштә үткән.

Дөнья тын.

Авыл башында клевер басуы калгып ята. Ул басу зиратка барып терәлгән. Зиратта әле яктырмаган. Анда Хәкимулла ята. Анда Шәяхмәтнең карчыгы Зәйнәп, Шәйхи карт белән карчыгы яталар. Анда Нәриманның бабасы Заһри кода ята. Анысы ничек түзеп ята диярсең. Яшь чагында мәҗлестә җырлап утыру өчен аннан да шәп кеше булмагандыр. Арыш басуы артыннан поезд тавышы ишетелде — Ташлытаудан иртәнге дачный китәдер. Ә Нәриман инде Зөлфияне бер дә кулыннан ычкындырмас. Шуңадыр инде, ул теге җырны кабат башлаган.

Атлар атламас инде...
Сине мица, мине сица
Ятлар мактамас инде.

## Саҗидә Сөләйманова

### Сузган ике кулым

*Туу турында уйлар*

I

Җырдагыдай:
берегез анда хәзер,
берегез инде әллә кайларда.
Тизлек чөры бөтереп алып китте
Бәйгеләрдә мәйдан яуларга.

Ике улым — сузган ике кулым,
хыял кораб сезгә, кис — диңгез.
Дулкыны да кубар, давылы да,
Һәлакәтсез барып җитегез.

Ә мин җирнең үзәк тәңгәлендә,
теләкләрнең теләп изгесен,
ялгыз гына бүген кичәм әле
төнге хатирәләр диңгезен.

Бүгенгедәй:
мартның утыз бере,
Иске Әлмәтнең яңа барагы,
хатыннарның изге газабыннан
иске җирдә тормыш яңару.

Стенада сәгать. Төн уртасы.
Яңа көнгә кала минутлар...
Ашык, бала, алдау көне алда,
Ялганнарга баштук юлыкма!..

Күзләремә карап, сукма, сәгать!..
Йолып калды минут арасы...
Ышан, дөнья, бүген һич харамсыз —
җирдә яңа кеше авазы!

Улым... Гомер юлың кәл иттеме
дөнья күргән шушы сәгатең. —
Ялган белмәс ихлас табигатең,
чын дөреслек эзләү гадәтең.

Шул гадәтең иҗтимагый фәнгә
алып китте, үзенә эз ярып.
Кеше гомерен илләр язмышына
Ялгар өчен кирәк үз җаның.

Кабатлау, я кабатламау өчен
һәр кешенең гомере гыйбрәтле.
Кайнар чакта салкын кала бел дип,
тормыш утка салып өйрәтте.

Кайчан гына әле өебездә
бер юаныч идең, и балам...
Йөрәгемне учыма кысамын да,
салкын акыл белән юл сабам.

Табигатьтә, җәмгыятьтә булсын,
газап белән туа һәр яңа.
Юл башында, юл чатындагыны
иярткерләк бул син, ир бала.

Өйрәнәсең тарих сабакларын,
күзәтәсең дөнья хәлләрен, —
кан түкмичә алу юлы бармы
ил тәненнән дошман хәнҗәрен.

Төрле кануннарның чиге була,
ярышның гына юк чиге.
Яңалыктан безне калдырмаска
вакытын белеп килдең, төпчегем.

Без, өлкәннәр, өреккәндәй иттек
«хобби»лардан, хиппилардан дә.
Кән бизәген йөзгә төрләндереп,
яңа яшьләр уйный әргәндә.

Мамык җептән сугып, ярлык таккан
гади чалбар хәзер кыйммәтле.
Таушалдырып кию зәвыклы ди
ситсы яки киндер күлмәкне.

Кире кагу, үз-үзеңне табу,
ясалмага гомум каршылык...
Үрелгәндә бергә, җил купса да
сыгылмый, әй, сыек талчыбык.

Кабул иттек мыек-сакалларны,
«чәчле» егетләрне, ниһаять.
Мини күлмәкләрен салып, кызлар
озын чалбар кисә, бигайбә.

Бердәмлекнең таныл гомум көчен,
читкә ордың чорның чүп-чарын.
Сүндермичә сакла утлы кузын
юл башында калган учагың.

Вәсвәсәгә һәвәс диссидентлар —
ваемсызга сабак вакыйга.

Бар фәннәрдән өстен ил намусы,
Ватан кануннары катгыйлар.

Сәфәр чыктың тарих эзләреннән,
яу кырында бармы урталык?
Артык осталарны сөйми халык,
остазларга сизелә мохтаҗлык.

Бик оста да һәм остаз да түгел,
ана булып сиңа юл сабам:
юл чатында, юл очында булсын —
Кеше булып кал син, и балам.

Фәлсәфәләр күпме —
яңа чорда
яңа кеше туу хакында.
Кеше — сәнгать,
иҗат ителәдер
яшәгәндә йөрәк катында.

Юк, аннан да алда туа кеше:
саклангандa күңел түрендә,
мәхәббәттә, яшьлек җырында.
Яралгысы йөрәк серендә.

II

Сез гел юлда, өлкәнем дә кечем,
хыял кораб сезгә, хис — диңгез.
Берегез кораб булса, берегез диңгез,
ике ярда хәзер икегез.

Илдә, көндә, еллар шаукымында
тәрбиянең миллион чарасы.
Иң мөһиме: Кеше күңелдә үк
хыянәтсез, шиксез яралсын.

... Карурмандай серле киләчәгем,
Агыйделдәй алкын үткәнем.
Алда нидер көтеп җилкенгән чак —
син булгансың икән, өлкәнем.

Яшәр өчен җайлы урын да юк,
кияр өчен җылы туным да.
Уй-хисләрем укучыларымда,—
көн-төн эштә, мәктәп юлында.

Май бәйрәмен җырлап озатуга —
көтмәгәнчә... көткән минутлар!..
Сүзләр көчсез сөйләп аңлатырга,
күздән чәчрәп чыккан ул утлар —

гомер буе бергә җылынырга
җитәр иде, саклап яндырсак...
Сыкранмасын беркем, тын кал, дөнья —
тавыш сыный нәни ал курчак!..

Иркәләүдән иртә аерганбыз,
читтән хәзер ачык күрәмен,
мин энеңне юындырган чакта
син кыйналып кайтып керәйдең.

Һәм сайладың:
хоккей, бокс, самбо!
Без андыйга гаҗәп битараф,
тамак төбе белән заманча җыр,
дус-иш, өзек кыллы гитара...

Сыгылмалы сөлек гәүдәң белән
кулларыңда йөрдең йөзтүбән...
Бу тынгысыз дөнья төрле хәлгә
әзер итеп сине үстергән.

Ил чакырды — киттең ил сакларга.
Үз юлыңны эзләп, руль тоттың.
Бүгенгедәй: йөрәгемне кагып,
миннән тормыш даулау минутың.

Кабаланып, каударланып килдең,
әзерлексез идек, бишексез.
Сайлап алу мөмкинлеге булса,
сине сайлар идем һичшиксез, —

батырлыгың, җан хөрлегең белән,
интеллигент — нәсел-нәсәбең,
кайчан кереп калды яшь башыңа
тимер йөкләр тарту исәбе?

Ил юллары — шпал, таш, рельслар...
Сезнең иңдә фәннәр — өскорма.
Тизлекләрнең корыч нигезләре,
тигезләнгән таулар, чокырлар.

Яшьлек чаба юлда җан-фәрманга,
калышырдан түгел, узардан!
Юл башлаган һәм туктаган нокта —
җирдә.
Җирдән —
җанга көч-дәрман.

Резин көпчәк җирдән аергачтын,
рейсларда, диләр, арыла —
төшеп-төшеп җиргә таян, чын ул
җиргә кагылышлы ырымнар.

Ни киңәше сиңа, ни табышы,
ай үтәсен елда үтәсе...
Шикләндермә әле, тайга төне,
сискәндермә, салкын иртәсе.

Чаңнар кагып, заман чакырганда
күтәрергә КамАЗ, БАМнарны,
шикләнүне, чикләнүне белми
җилкенәдер егет җаннары.

Алышларсыз, узыш-ярышларсыз
кызу бармый дөнья, аһ, беләм,
тик үз улкаема яшәү телим
йөрәк белән түгел, аң белән.

И өлкәнем, хисси үсмерлектән
иртә чыгып киткән яшь егет,
җәя киереп, күккә баккан чагың —
яшеннәргә янәш яшьлегең.

Сәк чыршылар, ят күршеләр ягы,
бик еракта бездән, читтәсең,
эш кайнаган тормыш уртасында,
ук-җәяңне тартыр чиктә син.

Тимер йөкләр белән шомлы күкләр
арасыннан эзләп урталык,
уфтанучыларны сөйми халык,
юл салучыларга мохтаҗлык.

Ике улым, сузган ике кулым,
хыял кораб сезгә, хис — диңгез.
Корабы да, дулкыны да үзегез,
маякларны барлап үтегез.

Шуңа өстәп сезгә әйтер сүзем —
Җирдә кеше туу хакында.
Кеше — сәнгать,
иҗат ителәдер
сизелгәндә йөрәк катында.

Юк, аннан да элек туа кеше,
тесмерләнә күңел серендә,
мәхәббәттә, яшьлек җырында.
Сүзем сезгә — шушы турыда.

1977

## Салих Баттал

●

Кышкы урманда төн.
Йомшак аланнар...
Агач башларында яфраклар юк,
тик йолдызлар гына калганнар.
Ә агачлар
шундый тирән йокыга талганнар,
әйтерсең лә алар
төшләрендә яфрак ярганнар.
Шундый тынлык,
әгәр берәү шул тынлыкны бозып
«Сине сөям!» дисә —
ялганлар.

●

Көтеп сөйгән кызы килмәсен,
җыештырды егет бүлмәсен.
«Килмәсә дә ярый инде, — ди, —
чөнки бүлмәм рәткә керде», — ди...

●

Йоклыйм. Кемдер шакый ишекне.
Тик булмасам килми төшемне:
кочагымда, имеш, гүзәлем, —
аны җуйсам ничек түзәрем!
Аннан башка сөйгән кешем юк,
шакысыннар, минем эшем юк...

Тордым. Алдым ишек астыннан, —
шул ук кыз бит!.. — язу калдырган:
«Хуш, артык мин сиңа килмәм,— дип,—
Гырлау тансык сиңа миннән», — дип.

●

Картайгач та еллар кыскаралар.
Менә килеп җитәр җәй янә.
Елт-елт итеп көз, кыш, яз, җәй гүя
каруссльдә куышып әйләнә!

Ә мин аның сәен көтәм, еллар
үтмәсен дип түгел, үтсен дип;
тизрәк үтсен, яшьләр тизрәк үссен,
минә аңлар яшькә җитсен, дип.

Фәнис Яруллин

# КУРКУ

ХИКӘЯ

Әмир ничәмә-ничә сәгать Казанның иң караңгы урамнарында, тыкрыкларында йөри. Һич кенә дә өйгә кайтасы килми аның. Кайтмый да мөмкин түгел, урамда кунмассың бит? Ничек тә вакытны сузарга тырышып, теләмичә генә урый-урый өенә кайтып килә. Инде үзләре яшәгән йортка да ерак калмаган иде. Шулвакыт аның колагына кемнәрнеңдер ямьсез итеп көлгәне ишетелеп китте. Әмирне нindидер эчке бер көч шул якка тартты. Анда әзмәвердәй дүрт егет яшь кенә кызны уратып алганнар да, төрле мыскыллы сүзләр яудырып алалар иде. Кызның төсе качкан, кузгалырга да куркып тора.

— Безнең барыбызны да үп,— ди колга буйлысы,— шунсыз җибәрмибез...

— Үбәсе килмәсә биесен, без аңа да риза,— дип кеткелди икенчесе.

— Без аны, егетләр, хәзер биетәбез. Пальтосын салдырып алсаң, өенә кайтып җиткәнче биер. Ну, чибәркәй, пальтоңны үзең салып бирәсеңме, әллә ярдәм итәргәме?

Һәм берсе кызның пальто төймәләрен ычкындырырга да тотынды. Әмирнең инде йөрәге тәмам ярсыган, акылы үзен-үзе белмәс хәлгә килеп җиткән иде. Йөгереп килгән уңайга ул кызны чишендереп торучының аяк астына бик каты итеп берне кундырып та алды. Теге әйләнеп юл кырыендагы карга барып төште.

— Кач,— дип кычкырды Әмир кызга һәм, теге исләренә килеп өлгергәнче, тагын бер-икесенә саллы гына итеп тамызып алды. Әмма төнге әрәкләр, Әмирнең ялгыз икәнен төшенгәч, батыраеп киттеләр. Берсе аның арт ягыннан нindидер каты әйбер белән китереп сукты, икенчесе аягына тибеп җиргә екты. Калганын ул хәтерләми...

Таңны ул больницада каршылады.

— Нәрсә булды, бәбкәм? — дип килеп керде икенче көнне әнкәсе. Ул инде улының нинди сәбәп аркасында больницага эләгүен милиция аша белешкән иде.— Кемнәр болай харап итте? — Әнисе кечкенә сумкасыннан кулъяулыгы чыгарып күз яшьләрен сөртергә тотынды. Әмирнең сөйләшәсе килми иде.

— Нигә эндәшмисең? Бер генә сүз әйт инде ичмасам,— дип өзгәләнде ана. Ләкин Әмир иренен дә селкетмәде.

Шул вакыт палатага врач килеп керде. Ана кеше сүзләр белән врачны күмеп ташлады:

— Бигрәкләр дә әйбәт бала иде бит. Унсигез яшенә җитеп сүзебездән чыкмады. Ни кушсаң, шуны тыңлады. Әллә кемнең гомерен коткарам дип, үзе үлем түшәгенә ятты, мескенем. Ныклап тикшерсәң, ул кыз бер урам себеркеседер әле. Рәтле кызлар төн уртасында йөрмәс.

Әнисенең сүзләреннән Әмир иреннәрен тешләп куйды. Ә ана дәвам итте:

— Рәтле кеше булса, үзен коткаручыны ташлап качмас иде. Больницасына да килмәгән бит. Әллә кемнәр «Скорый» чакырганнар. Яраланган бүреләр дә берсен-берсе ташламый.

— Җитәр сиңа, әни! — дип әйтеп куйды Әмир.— Бүреләр, имеш. Ә менә сез кем?

— И ходаем, әллә акылына зыян килгән инде. Сез, доктор, берүк аның тегенди-мондый сүзен чынга ала күрмәгез. Авыру кеше ни сөйләмәс. Ул этисен дә, мине дә бик ярата. И, онытып торам икән, этиең дә килгән иде бит. Хәзер кертәм. Синең теге кечкенә магнитофоныңны да алып килдек. Музыка тыңларга ярыйдыр бит, иптәш доктор?

Шулай сөйләнә-сөйләнә, ана палатадан чыгып китте.

— Эти дә, магнитофон да кирәкми, кертмәгез,— диде врачка Әмир.— Берсен дә күрәсем килми.

— Ата-анаңа андый шәфкатьсез булырга ярамый,— диде врач.— Күрәсең ич, синең өчен ничек өзгәләнә.

— Беләм мин аларның ничек өзгәләнгәннәрен...

Ә беркөнне Әмир янына үзе коткарган кыз килде. Ул бик кыюсыз иде. Матур зәңгәр күзләрен тутырып Әмиргә карарга да куркып кына исәнләште.

— Сез мине тиргисездер инде, билгеле,— диде кыз. Әмир каршы нидер әйтмәкче иде, кыз ашыгып-ашыгып яңадан сөйләргә тотынды: — Дөрес, дөрес, сезнең урыныгызда булсам мин дә ачуланыр идем. Качып киттем бит. Артыма әйләнеп карарга да курыктым. Шунда телефоннан милиция чакырасы иде дә бит. Курыктым...

Кызның «курыктым» дигән сүзләре Әмирне әллә нишләтеп җибәрде. Үзенең фаҗигасе дә әнә шулай куркудан башланды түгелме соң?

...Көзге көннәрнең берсе иде. Әмирләр үзләренең машиналары белән авылдан кайтып киләләр. Көн бик елак, өзми дә, куймый да яңгыр сибәли. Казанга җитәргә әле шактый юл узасы бар, ә караңгы төшеп килә. Шуңа күрә Әмирнең этисе машинаны бөтен тизлегенә куа. Әмир мондый кызу йөрүләрне ярата, аның үзенең дә менә шулай җилдереп машина йөртәсе килә. Дөрес, ул инде шактый мәртәбәләр руль тоткалады. Машинаны матур гына «иярли» белә. Менә бүген дә ул этисенә үзенең теләген белдерде.

— Әйдә, өйрәнә тор,— дип, этисе рульне Әмиргә тапшырды. Үзе, арткы утыргычка ук күчеп, тәмәке пыскытып җибәрде. Көчле машинаның бик җиңел үзенә буйсынуы Әмирнең күңелен күтәрде. Ул тизлекләрне алыштырды. Машина ярсып чапты. Шулвакыт әллә каян бер карачкы пәйда булды да юл уртасына чыгып басты. Әмир әле бер карарга да килергә өлгермәде, әнисе:

— Туктама,— дип, улын кисәтеп куйды.— Бәлки ул әллә нинди жуликтыр. Берсе кул күтәрсә, бишесе чокырда качып ятадыр. Машинаңны да тартып алырлар, үзеңне дә бәреп үтерерләр.

Әмирнең дә бик туктыйсы килми иде, ул выжлатып кына кул күтәрүче кеше яныннан узмакчы булды. Тегене бәрдермәс өчен машинасын кинәт читкә борды. Әмма... соң иде инде. Төнге юлчының хәрәкәтсез гәүдәсе пычрак юлда аунап калды. Күпмедер ара киткәч, Әмир аңына килеп, машинасын туктатты.

— Нигә туктадың, аңгыра?! — диде аңа әнисе.— Тизрәк моннан качарга кирәк, качарга.

— Соң бит, әни, теге кешене...— Әмир теге кешене юлда калдырып китеп булмый бит инде, бәлки әле ул үлмәгәндер, ярдәм кирәктер димәкче иде, әмма әнисе аңа авыз ачарга ирек бирмәде:

— Төш рульдән, җебегән. Әнә, әтиең утырсын.

Әмир инде үзе дә машина йөртерлек түгел иде, карышусыз гына әтисенә рульне бирде. Атасы үзен бик тиз кулга алып өлгерде, бөтенләй икенче якка кереп китеп, әйләнеч юлдан Казанга юл тотты.

— Карагыз аны,— диде ул.— Бу хакта бер кешегә дә ләм-мим. Төн яңгырлы, эзне бик тиз юар. Юлдан машиналар йөрми диярлек. Әгәр белә-нитә калсалар, беребезгә дә рәт булмас.

Әмир ул көнне ничек кайтып кергәнен һич хәтерләми. Йокысы качты. Подъезд ишеге шыгырдап ачылган саен, сискәнеп, сикереп торды. Менә-менә милиция килеп керер дә бөтенесен алып китәр кебек тоелды аңа.

Ләкин ул көнне дә, башка көннәрне дә аларның артларыннан килүче булмады.

— Әгәр шулай тавышсыз-тынсыз гына үтсә, үзеңә бик шәп магнитофон алып бирермен, улым,— диде әнисе Әмиргә.— Берүк иптәшләреңә ычкындыра күрмә.

— Кеше таптаттык бит, әни, кеше,— диде Әмир, ачынып.

— Нишлисең бит, улым, без бит аны юри таптатмадык. Кермәсен иде машина астына. Бәлки әле ул куркуыннан гына егылып калгандыр. Үлсә яки имгәнсә-нитсә, әллә кайчан артыбыздан эзләп килеп җитәрләр иде. Милиция йокламый ул.

— Барыбер, туктап, без аңа ярдәм күрсәтергә тиеш идек...

Улының бу сүзләренә әнисенең ачуы чыкты.

— Алай бик кешелекле булсаң, бар әнә милициягә. Мин кеше таптаттым диген. Кулымда правам да юк иде диген. Алып китсеннәр әтиеңне төрмәгә.

— Нигә әтине?

— Нигә, имеш. Белмәгән булып маташма. Син инде бәби түгел. Унсигезгә чыктың. Машинасын правасыз кешегә биргән өчен, иң беренче, әтиеңә эләгәчәген беләсең. Кеше таптаткан өчен дә, машинасын сиңа тоттырган өчен дә статья чәпәрләр. Әтиеңнең башы төрмәдә черер.

Әнисе еларга ук керешге. Улы аның сүзләренә каршы да төшмәде, юатмады да. Аның ничектер күңеле каткан иде. Тизрәк килеп тотсалар, җиңелрәк кебек тоелды аңа.

Көн артыннан көн үтә торды. Карлары, бураннары белән кыш якынлашты. Әмирнең әтисе машинасына көн саен диярлек берәр яңалык кертте. Башта ул барлык тәгәрмәчләрен салдырып, алар урынына яңаларын куйды. Иске тәгәрмәчләрне ваклап-ваклап дачада чүпчарлар белән яндырып бетерде. Машинасының сул як крылосында бераз яньчелгән урын бар иде, аны бер якын танышыннан төзәттереп алды. Машинада шикләнер нәрсә калмады, юллар да әкренләп кар астында калды. Алар тәмам тынычландылар. Әнисе улына бик шәп магнитофон алып бирде. Әмир үзе дә тынычлана башлаган иде, ләкин бер хәл өр-яңадан аның күңелен кузгатты...

Сания белән күпме дуслашып йөреп, Әмирнең әле бер тапкыр да аларның өйләрендә булганы юк иде. Ә ул көнне Сания егетне өйләренә чакырды.

— Әйдә,— диде ул,— әни белән танышып чыгарсың. Әллә кайчаннан бирле инде Әмирең белән таныштыр дип йөдәтте. Тик менә...

— Нәрсә менә...

— Әй, ярар инде... Кергәч күрерсең.

Сания ишекне үзе ачып керде.

— Әни,— дип эндәште ул керә-керешкә,— без әле бу. Әмир белән.

— Исәнмесез! — диде Әмир һәм ишек төбендә туктап калды. Киң диван-кроватьта берничә мендәргә сөялеп утырган чырайсыз хатынны күргәч, ул сискәнеп китте. Саниянең әнисен башкачарак, чибәр, таза, Сания кебек алсу йөзле итеп күз алдына китерә иде ул. Ә аның алдында урыныннан да кузгала алмый ятучы бер апа.

— Менә син нинди таза, чибәр егет икәнсең,— диде Саниянең әнисе. Аннары ул кызына карап: — Син бар, кызым, ашарга бирәр нәрсә хәстәрлә, ә без Әмир белән танышa торыйк.

— Син Санияне кыерсыттырма, рәнҗеттермә инде, балам,— диде ул.— Саниянең күңеле бик нечкә. Тик менә тормыш дигән нәрсә генә кырысрак кыланды. Врач булам дип очынып йөри иде, мескенем. Имтиханнарын да бик әйбәт биреп кергән иде, укырга гына туры килмәде. Мин болай булгач, укуын ташлап эшкә урнашты.

— Сез терелерсез, апа,— диде Әмир, бу хатынны юатырга теләп.

— Мин үзем өчен борчылмыйм,— диде ана.— Менә Саниянең генә канаты сынмасын. Әтисенең ташлап китүен бик авыр кичерә. Мин аңлатып-аңлатып карыйм да бит: әтиең әле яшь, авыру хатын белән нишләп торсын, дип, юк, барыбер ярсуы кимеми. Гаделсезлекне бер дә кичерә алмый.

Болар сөйләшеп утырган арада Сания ашарга өлгертте, өстәл әзерли башлады.

— Син, әни, Әмиргә әллә ниләр сөйләмә анда,— диде ул.

— Юк, без синең турыда сөйләшмибез, кызым. Тормыш турында сөйләшәбез. Ә тормышта кешеләрнең бер-берләренә әйтер сүзләре күп.

Күңелле генә гәпләшеп ашап-эчтеләр. Әмир ничектер авыру кеше янында утыруын да онытты. Сәгатенә карагач кына:

— И вакыт соң икән инде,— дип, урыныннан кузгалды. Сания ялт кына савыт-сабаларны җыештырып алды.

— Бар, кызым,— диде анасы.— Әмирне озата чык. Савытларыңны соңыннан юарсың.

Әнисе авызыннан рөхсәт сүзе ычкынгач, Сания дәртләнеп киенергә тотынды. Бүген аның кәефе шәп иде. Әмирнең шулай якын итеп, тартынмыйча әнисе белән сөйләшеп утыруы, рәхәтләнеп чәй эчүе аның күңелен күтәргән иде. Кайвакыт килгән кешеләр никадәр кыстасаң да чәйгә утырмыйлар. Сания андыйларны әнисеннән чиркәнәләр дип уйлый. Андый чакта бик нык хәтере кала. Озак вакыт сөйләшми йөри. Ә бүген аның җаны тыныч. Әмиргә ягымлы сүзләр әйтәсе килә, тик кыюлыгы гына җитми.

— Син әнигә ошадың, ахры,— диде ул, урамга чыккач,— йөзе ачылып китте. Кайвакыт аның авызыннан бер сүз тартып ала алмыйсың. Мин әнә шунысыннан бик куркам: ачулансын, дуласын, тик үз эченә генә йомылмасын иде. Кешегә үз эченә йомылудан да куркыныч нәрсә юк, шулай бит, Әмир?

Әмир андый нечкәлекләрне белми иде, шулай да кызның сүзен хуплап куйды. Ә соңыннан:

— Әниең нәрсә белән авырый соң? — дип сорады.

— Әй,— диде кыз нык әрнү белән.— Бер машина бәргән иде...

Саниянең шушы сүзләреннән соң Әмирнең күз аллары караңгыланып китте. Кайда? Кайчан? Күптәнме? дип сорарга да батырчылыгы җитмәде. Ул сания белән таркау гына саубуллашты. Ләкин аның өенә кайтасы килми иде. Ниндидер бер үкенечле җилкенү белән Казан урамнарын урап йөргәндә, хулиганнарга тап булды. Һәм менә селкенә дә алмыйча больницада ята.

# Шамил Анак

*Шагыйрь Шамил Анак (Мәхмүтов) татар, башкорт һәм рус телләрендә шигырь китаплары аша укучыга яхшы таныш.*

*Дөнья поэзиясен тирәнтен өйрәнгән, атаклы төрек шагыйре Назыйм Хикмәт әсәрләрен татарчага тәрҗемә итеп, аерым китап итеп бастырган шагыйрь үз иҗатында да яңа форма, ритмнар эзли, заманча яңгырашка омтыла. Ш. Анак татар шигырендә ирекле шигырь-верлибр кулланучыларның берсе.*

*Бу айда аңа 50 яшь тула. Шагыйрьне укучыларыбыз исеменнән бәйрәме белән котлыйбыз һәм берничә яңа шигырен тәкъдим итәбез.*

## Көн белән саубуллашу

Менә тагын бер көн үтте
йөзендә саф нур белән,
тынып калган кошлары,
моңсу зәңгәр агачлары,
назлы, җылы туфрагы белән.

Менә тагын бер көн үтте,
гомрем мулрак булды бер көнгә —
бер матурлыкка,
бер мәхәббәткә,
бер табышка.

Менә тагын бер көн үтте,
күңлем тулырак булды бер көнгә —
бер фикергә,
бер чын сүзгә,
бер шат тавышка.

Менә тагын бер көн үтте,
мин олырак булдым бер көнгә —
бер җыерчыкка,
бер хатирәгә,
бер сагышка.

Үткән көн,
син үтмәдең буш,
рәхмәт
һәм
хуш.

## Туган төяк

Өйсез-гаиләсез кеше — ышыксыз,
кая барыр, бәлаләрдән качып?
Бөтен өметләре, бөтен уйлары
бар җилләргә, бар шомнарга ачык.

Ил-төяксез кеше — узгынчыдай,
ят юлларның йота кара тузанын.
Ялгызлыкта тиеш ул күтәргә
чигенә җиткәнче гомер ызаны.

Ләкин ил-төякле тиеш белергә:
шушы җирдә кендекләр киселсә,
бабайларның ятса изге сөяге,
башка җирләр, башка илләр түгел,
нәкъ шушы җир изге синең өчен,
нәкъ шушы җир синең туган төяген.

## Очрашу

Кайчак, узып барышлый,
туктап юл сорыйсың
алтмыш яшәр авыл картыннан,
я күрәсең алты яшәр баланы —
күз тутырып карап кала артыңнан...
Кыска бер очрашу, гади бер гәп —
күпме генә булдыгыз бергә?!
Ләкин нидер кала күңелдә,
гүя кагылдың син бу мәлдә
әллә нинди гаҗәп сергә
һәм ары киттең.
Нинди сер ул — белмисең син үзең дә,
ләкин шатлык алып киттең күзеңдә...
Ә бит очраттың ни бары,
узган чакта тормыш аланын,
бөкрәйгән бер карт белән
үш кермәгән баланы.

## Җир кешеләре

Җиргә мәхәббәтләре шундый зур —
үзләре дә белмиләр аның зурлыгын;
яшиләр, балалардай, сизмичә
йөрәкләрендә шыткан сөю орлыгын.
Иген игәләр, тудыралар, күмәләр,
һәм ачы түгел хәләл икмәкләре;
ваз кичмиләр, күнәләр язмышларына:
нәкъ кичәгедәй яшиләр бүген дә —
яттан белеп җирнең бөтен хикмәтләрен.

Җир белән кушылганнар алар гомергә:
җирме яши аларда,
алармы җирнең терек өлеше —
үзләре дә аермый;
яшиләр җир белән мәңгегә килешеп.

Җир аларны туйдыра, тереклек бирә,
алар исә — җиргә хезмәт күрсәтә,
кызганмыйча колларының көчен;
җан аямый үлемнәргә баралар,
бердәнберләре, аналары-җир өчен.
Бар яклары белән җиргә охшашлар,
хикмәт иясе һәм хәйләсез балалар,
җан тәслимдә дә хәтта
җирнең үзедәй сабыр калалар;
вөҗданнары газапсыз;
мең кат үлеп, мең кат туып җирдә,
тыныч карыйлар зилзиләләр уенына:
иң соңгы юллары да — җиргә:
аналарыдай, сыеналар җир куенына.

## Реквием

*Икенче бөтендөнья сугышы корбаннарына*

Ниндидер сәгатьтә, ниндидер минутта төнлә,
ә нинди сәгатьтә — без белмибез ансын,
мәңгелек елгасыннан, төптән,
үлекләр күтәрелә — сансыз.

Иреннәрен кыскан, күзләрен йомганнар,
күккә төбәгәннәр көлдәй күк йөзләрен,
мәңгелек салкыны бәрә алардан,
безгә күренмиләр үзләре,

җансыз, бозлы карашларыннан
йолдызлар бөрешә төнге ерак күктә,

бөтен үлекләр күтәрелә төптән,
нинди теләкләр били йөрәкләрен —
без белмибез ансын,
ни кычкыра төндә өнсез өрәкләре?

Җирнең бөтен үлекләре күтәрелә төптән,
бөтен яндырылган, асылган, атылганнар,
ни турында ялваралар алар күктән?
Әллә ләгънәт укыйлармы,
мәңгелек йокыларын бүлеп?
Кемгә?
Алар барсы — илле миллион үлек.

## Марсель Галиев

### Еллар чалымы

**Еллар чалымы —**
яры тарайган инеш-суларда,
җилдән каерылып арган талларда.

Еллар чалымы —
шушы заманга яшьтәш сүзендә,
безгә юл биргән остаз күзендә.

Еллар чалымы —
Идел яктысы төшкән күгемдә,
Идел күк борынгы телемдә.

Еллар чалымы —
туган җиремдә, кая карама,
шул җир күтәргән яңа калада.

Еллар чалымы —
бездән калачак бакый дөньяда...
Безнең чалымнар — килер елларда.

### Болгарда

Кура зеңләп куйды
җәя кылы сыман.

Тетрәп киттем.
Үткәннәрдән атылган ук гүя
минем аша үтте.

Ни булды соң әле,
ни булды бу мәлдә?

Археолог пәкесе
ерак бабамның баш сөягенә
тиеп китте мәллә?..

### Тымызык көн

Тымызык көн. Күкләр асылынган.
Офыкларны томан чикләгән.
Җан тарыга, киңәясе килә
күңел билеп алган чикләрдән.

Куныкланган таш өстенә басып,
каршы ярны эзлим ерактан.
Бу җаныңны чайкап алыр өчен
дөнья гүя сулар яраткан.

Бик тирәннән, тетрәүләрдән калкып,
ярга бәрә дулкын кагышы.
Сулар шавы тынган кабырчыктан
ишетелә тояк тавышы.

Ни җитмәгән, әгәр берни тоймый,
бүгенеңдә генә яшәсәң?
Ишетәм күк Болгар шәфәгыннан
ялгыз тавыш: «Минем баш исән!»..

Карачкысын күрәм бу тавышның,
кем искәрер тагын, кем тыңлар?!
. . . . . . . . . . . . .
Берсен-берсе изеп юкка чыга
кабарынып килгән дулкыннар.

## Күзаллау

Мәшәкатьле чуар урам.
Ялкау гына карлар төшә.
Үткән гасыр буйлап барам.

Соры йортлар ышыгыннан
бүрек кадәр эт җитәкләп
ханым үтә купшы гына.

Урам юеш җепшек кардан.
Шәһәр үзәгенә җиткәч,
«барабыз»дан төшеп калам.

Нәни максат — түбән булу,
сатылулар һәм сатулар —
сәүдәгәрләр төбәге бу.

Печән базарында арыйм,
«Кисекбаш»ны күреп калгач,
үз башымны тотып карыйм.

Кыюланган, кызып алган
бер мөсафир җырлап уза.
Җыры язылганмы тузга?

— Байлар кайда саклый икән
безгә диган хәмерләрне,
ханнар әллә үлми микән,
булыр иде каберләре?..

Ә бер чатта чегән кызы
язмышларны юрап тора.
Ышанганнар чират тора.

Мәшәкатьле чуар урам.
Ялкау гына карлар төшә.
Үткән гасыр буйлап барам.

## Оренбург даласында

Утырып байый дала кояшы,
җиргә сеңеп ага ак томан.
Монда хыял — арканнарын өзеп
урә баскан кыргый ат сыман.

Тарихның бу япан киңлегендә
яшерелми берни, ачыла...
Курганнардан-курганнарга басып,
канатсыз кош булып Ай чыга.

●

Төштә миңа берәү килде:
— Мин үземне оныттым.
Хәтеремне кайтарсана,
хәтеремне кайтарсана,
мин телемне оныттым.

Төштә ничек аңлашканны
уянгач мин оныттым.

## Сугыш инвалиды

Ике җирдә кабере бар.
Үзе исән,
кемнәр күргән андый сыналуны?
Бер аягын күмгән туган җирдә,
Европада калган сыңар кулы.

Ике кабере бар...
Үзе яши әле!
Тыныч кына ятмый түшәгендә.
Ыргыталмый калган гранатасын
кулсыз кулы эзли төшләрендә...

## «ЗАМАНДАШ» КОНКУРСЫНА

**Радик Фәизов**

# МӘДИНӘ

хикәя



Райбашкарма председателе Сәлмән абый, гадәттә эшне бик кызу тота торган кеше, бу юлы ашыкмады. Миңа урын бирде дә, бизәк-бизәк чал кергән күркәм башын артка салып, шакмак идәнле кабинетында киләп сара башлады.

Болай капылт кына ник чакыртты бу мине, сүзен ник башламый? Инде ерак юлдан алып килгән салкыннарым да чыгып бетте, иңнәремә кабинет җылысы үтте, ә ул һаман суза. Хәер, Сәлмән Гәрәевич миңа һәр вакыт башка авыл советы председательләреннән бераз аера төшебрәк димме карый. Моның асылын икебез генә белә торган кайбер сәбәпләр дә бар...

Ниһаять, ул өстәле янына килеп утырды, һаман да сер саклаган зәңгәрсу күзләре белән туры гына бер карап алды. Бу караштан күкрәгемдә нидер елкылдап үтте.

— Гөлфара апаң пенсиягә китә бит, Мәдинә, — диде ул.

— Беләм, Сәлмән Гәрәевич, бераз әзерлегем дә бар.

— Эш анда түгел... Эш әзерлектә түгел, иптәш Фәттәхова, — диде ул рәсми тонга күчеп. — Без монда Гөлфара апаң урынына менә сезне чакырырга торабыз. Башкарма комитет председателе урынбасары итеп...

Мин сискәнеп киттем. Көтмәгән идем моны, көтмәгән идем! Күңелемнең бер читенә ялкын кабынды. Ни әйтергә дә белми утырдым. Фәрманнар биреп яшәүләре дә кыен, бик кыен... Мин инде кыз чагымнан бирле егерме ел председатель. Минем кебек язмышлы хатын-кызга моның нәрсә икәнен бер үзем генә беләм. Инде бер баскыч югары күтәреләм икән, бу иртә ашкыну булмас, берәүнең дә иңбашына таянып күтәрелү дә булмас. Минем моңа инде хакым бардыр, шәт.

Сәлмән абый, минем якка күз салгалап, сабыр гына көтеп утырды. Иманым камил, күңелемдә нинди өермәләр күтәрелгәнне, аларның юнәлешен чамалый утырды ул. Әмма сүзе, хәрәкәте белән моны сиздермәде.

— Ашыкмый гына уйлагыз, Мәдинә Хәбировна. Җавабын соңыннан бирерсез, — диде ул.

— Югары үрелү булмасмы соң әле бу, Сәлмән Гәрәевич? Лаеклырак кешеләр дә бардыр, — дидем мин.

— Андыйлар бар барын. Инде сүз салучылар да булды, тик... — ул, күзләре белән генә көлемсерәп, миңа карап алды. — Урынбасар булып кем киләсен райбашкарма председателе үзе дә уйларга хаклыдыр. Шулай бит?

Зур практик ул безнең Сәлмән абый! Мине Көйрәк Мәдинә дип тикмәгә генә йөртмәгәннәрен, тынгысыз җан икәнемне бик яхшы белә. Ә урынбасарына нык таяна алса, аның эше барачагын мин беләм.

Ишеккә килгәндә күзем зур көзгегә төште. Мактансам мактаныйм: керфекләрем астында нурларым сүнмәгән, буй-сыным кызларныкына биргесез, битләремә еллар шәүләсе төшмәгән. Кыскасы, урыным бизәр килешем бар.

Райбашкармадан чыккач та, тизрәк кайтырга ашыктым. Тизрәк ялгыз каласым, өемдә көнелемдәгеләрне тәртипкә салып, иркенләп бер уйланасым килә иде. Артышлы үрен төшеп тигез юлга чыккач, шофер Рафаил:

— Нигә чакыртканнар, Мәдинә? — дип сорады.

— Гөлфара апа пенсиягә китә. Аның урынына мине димлиләр.

Рафаил руль тотып утырган җиреннән кымшынып куйды, әмма ләм-мим дәшмәде. Ул гел шулай: үзенекен бер вакытта да тота-каба гына белгертмәс. Ә инде сүзен әйткәндә, хаклы икәненә бик инанып әйтер.

Минем әле барысын да бизмәнгә салып карыйсым бар, әмма күңелемнең түрендә мәсьәлә инде хәл ителгән, карар проекты язылган, кайбер өстәмәләр генә кертеп, кабул итәсе калган иде. Инде Суыксу күренә башлагач, Рафаилнең сүзен ишетәсем килде.

— Син ни әйтерсең, Рафаил?

— Мин, Мәдинә, кулны каршы күтәрәм! — диде ул.

— Ник алай? — дидем мин, бер дә яратмыйча. Үткән тормышымны, кайгы-хәсрәтләремне дә яхшы белгән Рафаилдән мондый сүзне көтмәгән идем.

— Мактауга алма, Мәдинә, монда сүзнең чыны кирәк, — дип башлады ул. — Халык синнән игелек күрдеме? Күрде, Мәдинә. Әле тагын да күрергә хаклы. Ник дисәк, җырлап эшләр чакларың. Ә бездә менә ничек бит: бер җайлы кеше килеп чыкты исә, аны җәтрәк тегендә... — Рафаил кулын артка, райүзәк ягына селтәп алды. — Ә җайлы кешеләр монда кирәкмимени? Сине ансат кына җибәрергә мин нишләп кул күтәрим? Әле аның тагын башка якларын алсаң...

— Башка якларын калдырып торсаң да ярый, Рафаил! — дип бүлдем мин аны.

* * *

Авылга кайтсаң уйланып-сырланып өйдә утырулар кайда? Капкалап кына алдым да, эшемә менем киттем. Алай да, капкадан чыккач, тукталып калдым. Тәңкә-тәңкә карларын койган кышкы көн шул кадәр хозур, Югары урамнан барлык тыкрыклары күренеп, дәү бер поселоктай киң җәелеп яткан Суыксу аерата ямьле бүген. Әллә күңел түрем яктырып торгангамы бу? Моннан байтак еллар элек «Авыл төзелеше» журналыннан бер яңалыкны бик ошатып, мин яңа йорт торгызучыларга өйне урам буена терәп түгел, ишегалды түренәрәк салырга киңәш иткән идем. Әнә, урамнарыбыз нинди иркенәеп килә! Авыл читендә ап-ак стеналы пекарня, уртасында ике катлы урта мәктәп, аргы якта, зур тәрәзәләре белән көлеп, ясле-бакча карап тора, инеш буенда салына башлаган стадион... Менә бит, башкалардан соңга калып тотынсак та, бик калышмыйбыз. Соңгы елларда гына да күпме нәрсәләр торгызганбыз... Кемнәр килер, кем борчылып йөрер инде монда миннән соң? Белеп торсын, сакалы биленә җиткән низаглар да калдырып китәм әле мин аңа. Менә хәзер дә, икенче каттагы кабинетыма кереп утыруым булды, шундый сакаллы низагның берсе, ишекне ачып, үз аягы белән килеп тә керде.

Иманленең Хәбир иде бу. Кызыл битле, төптәй нык ир уртасы кеше. Каршыма ук килеп утырды, зур сүз, үпкә сүзе әйтергә җыен-

ган төс белән ак кашлары астындагы чәнечкеле күзләрен миңа текәде. Бу аның мине «әзерләве». Менә ул тормышның тырпаеп чыккан бер терсәге: соңгы елларда авыл җирендә җәен колхозның вактөяк эшләрендә генә йөреп, кышның-кыш буе түшәмгә төкереп ятучылар күренә башлады. Хәбир нәкъ әнә шундыйлардан. Хәер, ул түшәмгә төкереп кенә ятмый, дүрт чакрымдагы Имәнледән атнасына ике-өч мәртәбә Суыксуга төшә. Үзенә уңай шартлар тудыруны, төрле хезмәт күрсәтүне дауларга төшә ул. Имәнледә хәзер нибары сигез йорт, алар кечкенә урманлык буендагы аланга ябышкан, купмаска иман китергән кешеләр. Хәбир исә аларның илчесе. Менә ничәмә еллар инде алар Суыксуга күченеп төшүдән баш тарталар, шул сигез йортлы авылга телефон куюны, кибетен, медпунктын җайлауны даулыйлар. Ничә тапкыр кучәргә әйттек, машинасы, аты булыр, йортҗир кузгатканда агачы-бүрәнәсе белән ярдәм итәрбез, дидек. Ә аларның һаман үз кыйблалары кыйбла.

— Ут-күз чыкса, без нишләргә тиеш, Мәдинә? Кычкырып янып бетәргәме? Берәр яман сырхау тисә? Врач килгәнче аякны сузарга. Син шуларны уйлыйсыңмы, юкмы? — дип, бер үк балык башын чәйни башлады Хәбир.

Менә шундый низаглар, кирелекләр талкый авыл советы председателен. Ә минем бүген күңелемне йөгәнләп, уйларымны тыеп торган кыршавым бераз бушап киткән иде. Үземнең сабакташым, егеткыз чакта кулларымны да кыскалап йөргән Хәбирне бу юлы коры тотарга булдым.

— Шуны әйт әле, Хәбир, атнага ничә төшәсең син монда? — дидем мин аңа.

Ул аптырап күзләрен челт-челт йомгалады, әмма җавабын төгәл бирде:

— Өч тапкыр.

— Ничә ел буена?

— Ничә ел дип, гомергә инде.

— Менә бит, сабакташ! Шул гомердә култык астыңа гына кыстыра төшсәң дә, бөтен йорт-җиреңне, мал-мөлкәтеңне ташып бетерә алыр идең. Ә беләсеңме Суыксуга ник күчмисең син?

Бу юлы инде ул дәшмәде.

— Алайса, үзем әйтеп күрсәтим әле. Үткән көзлектә өрлегеңә богыл чаклы бер үгез, сигез сарык, утыз каз, үрдәк түшкәсе асып куйдың син. Менә сине бәйләгән казык!

— Монысын хөкүмәт тә мактый, — диде ул.

— Колхозда кыл да кыймылдатмыйча, хуторда яту хисабына түгел. Монысын инде, сабакташым, берәү дә мактамый.

— Бер юньле үнәрең булмагач аны...

— Укы! — дидем мин. — Укыган кешегә эш муеннан. Бүген таңда колхозга ничә комбайнчы, тракторчы җитми. Анысын үзең дә бик беләсең. Укы башкалар кебек, эшлә башкалар кебек!

Холыксыз Хәбир пырылдап чыгып китәр дигән идем, сүзләрем үзәккә тидеме, алай итмәде.

— Тәки кузгалмый булмас микәнни, Мәдинә? — диде ул уйга калып.

— Булмас, Хәбир, шунсыз булмас! Тармаклар эреләнә, авыллар эреләнә, күмәк хуҗалыкның тагын да күмәкләшә бару заманы бит бу. Ә син куак артында ялгыз яшәмәк буласың...

Хәбир китүгә ишекне лештер генә ачып, Хәлимә килеп керде. Урынымнан торып каршысына килдем, ябык иңнәреннән тотып аулакка, шкаф ышыгындагы тирән креслога утырттым. Җәллим шушы баланы, аны күргән саен йөрәкләремә кан сава.

— Җанашым минем, ни хәлләрең бар?

— Әйбәт, Мәдинә апа, рәхмәт,— диде ул, гел суга тыгудан, бәрәңге, кер юудан ярыла башлаган куллары белән тез башларын сыпыргалап.

Минем яныма моң-зарын сөйләргә йөрми Хәлимә, андыйны белми ул. Азрак тынычлану, ял итү өчен килә ул монда. Мин кайчак аны кабинетымда калдырып, үзем чыгып та йөргәлим. Кайнаналар киленнәрен җәберләп яшәгән заманалар үтте, дип сөйләүчеләр булса, алар ялгыша әле, төрле хәлләр була.

Урта мәктәп бусагасыннан фермага атлады, сыер сава башлады Хәлимә. Кояштай балкып, янып торган кыз иде, үзе шикелле үк яшь тракторчы егет Идрискә кияүгә чыкты. Икесе дә акыллы гына, юаш кына, бик пар килгәннәр, бәхетләре дә түгәрәк буласы иде. Идриснең әнисе — Күгәрчен Әминә — үзе күгәрчен чаклы гына, пышылдап кына сөйләшә торган нәрсә, әмма бик җете, җегәрле хатын, бар зәһәрен, усаллыкларын, йортка килен төшкәнче дип, эчендә яшереп саклаган икән. Көн юк Хәлимәгә бу йортта. Бар эш: бура хәтле сыерны, ничәмә баш сарыкны, каз-үрдәкне карау, Идрисне көн дә таң белән әзерләп, ашатып-эчертеп озату, кичен каршы алу, йорттагы тавык чүпләп бетермәслек башка вак-төяк эшләр, барысы да, барысы да Хәлимәгә. Болар бит фермадагы нинди авыр хезмәт өстенә. Инде башкасын әйтмим, фермадан төшешенә самавар чәен дә куеп каршыламый киленен Күгәрчен. Килене аз гына сүз әйттеме, кайнана башын тотып урын өстенә ава. Атналар буена, күз яшьләре белән тукып, улына киленен әләкли. Әй Идрис, эштә нинди булган егет, монда исә әнисе сүзеннән чыга алмый...

Йомшак креслода эреп, башын иңенә салган килеш йокымсырап киткән Хәлимәнең сулып калган битләренә, таралып төшкән кулларына карадым да, йөрәгем тагын телгәләнеп алды. Үзем, үзем гаепле... Вакытында чарасын күрмәдем, ярдәмгә килә белмәдем шушы балага. Мин, хатын-кыз башым белән, нинди азгыннарны, исерек-башларны авызлыкларга йөрәгем җиткән Мәдинә, шул Күгәрчен Әминәсенә юл куеп тордым.

* * *

Кичке эшләрем, чәйләрем бик җәһәт булды бүген. Улым Рөстәм үз бүлмәсенә кереп китүгә, диванга менеп кунакладым. Түрдә ут та кабызмадым, телевизорны да куймадым. Пыяла ишектә Рөстәмнең ябык иңсәсе, әтисенекедәй кабарынкы маңгаена төшкән бөдрә чәчләре күренә. Унынчыда быел, бар белгәне: «Очучы булам!» Кичләрен бик озаклап утыра. Күрче, китабына иелүләренә кадәр әтисенә охшаган... Рөстәм әтисез үсә, үзем шушындый чибәрлегем белән тол утырам... Монысына да үзем гаепле...

Аякларыма юрган каплап, уңайлап утырдым. Яле, Мәдинә, моңарчы ничек яшәдең син, председатель булып нилэр майтардың?

...Бала чагым... Ачык ишектә әтиемнең кәтүмкә асылган киң җилкәсе. Мин аның йөзен, күзен дә хәтерләмим, бары тик кәтүмкә аскан җилкәсе исемдә. Авыл советында секретарь булып эшләгәндә әниемне дә җирләдем. Ни әтиемә, ни әниемә балалык бурычымның ичмасам бер өлешен дә кайтара алмый калдым. Егерме өч яшьлек кыз вакытымда мин инде Суыксу авыл советы председателе идем.

Эшли башлавымның беренче еллары. Көзге караңгы төндә ишегемне шакыдылар. Йөрәгем урыныннан куба, кулларым ишек келәсен күтәрә алмый. Ферма каравылчысы Мифтахетдин агай икән.

— Авырсынмасаң, фермага гына менеп төш әле, кызым. Бер эшнең шаһиты булырсың, — ди ул.

Тышта якты, беренче кар төшкән. Батырланган булам. Фермага менсәм, тез буыннарым тагын йомшый. Азык кухнясы артындагы аулакта кулларына пычак тоткан ике бәндә: ветсанитар Исмагыйль бе-

лән көтүче Гарәфи. Ә җирдә быел гына күпме артыннан йөреп, акча түгеп күрше районнан алып кайткан нәселле таналарның берсе, ак маңгайлысы. Җанашым, җанашым! «Бездә моның әнисен уздырган сыер юк, тәрбия кыла белсәгез, сөтне биреп күрсәтә әле бу сезгә!» — дип мактап бирделәр. Менә... тәрбия кылдык...

— Юньсезләр! Ни эшләгәнегезне беләсезме?!

Башлары иелгән, таптаналар.

— Жәлке, Мәдинә, жәлке. Нишлик, үзе кушты, иртәгә әзер булсын дип кисәтте.

Иртүк мин колхоз председателе Хаҗи Мортазин янында. Илле яшьләрендә, өстәле янында да ничектер башын югары чөеп, сынын катырып утыра торган сәер бер кеше. Болай ярсып янына беренче керүем. Кыза күрмә, Мәдинә, кыза күрмә!

— Бу ни бу, Хаҗи абый! Нәсел танасын егып суялар...

Елмая. Көмеш тешләре күренеп китә, йөзе елмая. Ә сүзләре нинди?!

— Аягын сындырган. Менә ветсанитардан белешмә.— Өстәлгә, минем якка, кәгазь кисәге килеп төшә. Өзгәләнәм, аның йөзендә дә аз гына борчылу, уйлану күрәсем килә.

— Соң, Хаҗи абый, тамырга балта белән чабу бит бу!

— Ә миңа ни боерасың? Запчасть кирәк, трансформатор кирәк, тегесе-монысы кирәк. Ә анда... майламыйча берсе дә купмый, җанкисәгем. Мин анда үлгәндә чалып калган үләксә ите күтәреп бара алмыйм! — Шадралы йөздә кинәт ялтырап киткән күзләр балтырларымны, бөтен буй-сынымны карап ала.— Менә сезнең кебек чибәр ханымнар йөрсен иде анда. Бәлки башкача да кубар иде...

Шушы минутта үземә бер ачыш ясыйм: бездә колхоз председателе булып Хаҗи Мортазин утырганда һаман да шул бишкә сатып алтыга алу булачак икән. Минем бөтен эшем шушы Мортазин белән тарткалашуга кайтып калачак икән.

Мортазин безнең Суыксуга Хәтнәдән, анда район беткәч килде. Башта ук халык аның колхозда фатир-йорт була торып та семьясын алып килмичә, көн саен унике чакрымдагы Хәтнәсенә кайтып йөрүен яратмады. Миңа калса, колхоз председателенең читтән килгән кеше булуы бигрәк тә шәп: аның янына туган-тумача, дус-иш кебекләр сукмагы тар була. Әмма ул шушы колхоз җирендә тормыш итәргә тиеш. Аның әллә кайдагы авылына кайтып йөрүләрен халык колхозны ташлап киту дип саный.

Ә вакыты нинди иде? Тирә-як күршеләр тернәкләнеп килгән ул заманда безнең колхоз, безнең авыллар әле бер хәерче, җимерекләр утравы иде. Урнашның да абзары сыерлар өстенә ишелергә тора, бозауларныкының түбәсе ачык, елның-елында терлек азыгына кытлык, күпме мал үлә... Бер генә авылда да юньле клуб юк, мәктәпләр ремонт сорап шыгырдый, медпунктлар җитешми... Җыелышларда, авыл советы сессияләрендә һәркем шул турыда сөйли, күпме карарлар языла, ә эш һаман элеккечә, һаман да шул бер урында төймә төю иде.

Менә төн йокыларымны йокламый әзерләнгән беренче сессиям. Халык алдында беренче тапкыр күңелемне ачып, уйларымны күтәреп чыгуым.

— Ауган-түнгәнне, ватык-сыныкны санап вакыт үткәрмик әле, җәмәгать! Санап кына аларның саны кимемәс. Бүген безгә иң хаҗәте ни дә, чират башындагысы нәрсә? Менә шуларны конкрет билгелик тә, эшкә керешик. Кем башлый?

Бер-беренә караштылар, кайберләре астыртын гына, уйдырып кына көлемсерәп куйды... Ә мин басып торам, көтәм, эчләрем тулы ут. Шулай ук аңламаслар, күңелләре кузгалмас, ялгызым гына басып торырмын микәнни? Юк, яшь депутат шофер Хәмбәл күтәрелә:

— Исәпләгез әле, иптәшләр: язын-көзен Суыксудан олы юлга

чыкканчы гына да күпме машина ватабыз, күпме горючий ягабыз, йөрәк итен күпме ашыйбыз? Шул өч чакрым арада ник күтәрмәскә дамба?

Хәмбәл кузгатып кына җибәргән иде, башкалар күтәреп алдылар. Ялгышкансың син, Мәдинә. Үзең генә сызып йөрмисең икән әле. Бер дә алай түгел икән. Әнә, Хабил нәрсә ди?!

— Торф булып шул торфны кайдан ташыйбыз. Акчаны юлга салып йөрү түгелме бу?! Бездән күршеләр көлә. Ә үзебездә торф юкмы? Тулып ята торф Түнтәр буйларында. Бульдозер белән өстен ачып җибәр дә, төя машинаң түнгәнче!

— Ә Суыксу астында нинди болын рисвай булып ята. Ел саен су баса, юшкын утыра. Борын төбендә бит. Ник карамаска шуны, ник үлән чәчеп үстермәскә?

— Ничә генә трактор ике сменада эшли икән безнең? Ә авылларда күпме яшьләр, ир-егетләр трай тибә... Башка колхозлар ел саен кеше укыта. Нигә безгә дә укытмаска?

— Җитәкчелек юк бездә. Туасы көнне кайгырта белүче юк!

Каты әйтте халык, ачынып, күңел түреннән алып әйтте. Тик тиенгә түгел, ботакка тиде. Сессиядә барысына да баш кагып утырган Хаҗи абый иртәгесен кулын гына селтәде.

— Андый эшләргә тотынырга бездә техникасы кайда да, башкасы кайда, җанкисәгем? Басуларга тирес чыгарасы бар, тракторларны ремонтка җибәрү графигы өзелә. Җыелышта анда акыл сатуы ансат, ә план өчен мин җавап бирәм.

— Ә әйбәтләп, төптәнрәк уйласаң, Хаҗи абый...

— Син әнә үзара салымыңны бел дә, кое-чишмәләреңне бел, җанкисәгем!

Шунда кемдер битемә, муеннарыма үзенең пычрак, юеш куллары белән орынып алдымыни... Гарьләнүемне күрсәтәсем килмәде, тизрәк чыгып киттем.

Авыл советының аның үз акчасы юк дәрәҗәсендә. Зур-зур каралтылары, яңа культура йортлары, мәктәпләре, кибетләре булган матур авылларны күрсәгез, белеп торыгыз: монда авыл советы председателе фәрманлы, ә колхоз председателе бик дәрманлы кеше. Хаҗи Мортазин исә безнең колхозның киләчәгенә, авылларыбызның иртәгесе көненә битараф иде.

...Диванда утырган җиремнән аякларым оеды, кымшанып куйдым. Шул чактагы борчуларым, васвасәләрем кире кайткандай, йөрәгем кага башлады. Алай да әрсез, кеше сүзеннән курыкмаган вакытларым бар иде...

Менә мин райбашкармада. Кабинет ишеген ничек ачып кердем, Сәлмән абый каршысына ничек килеп утырдым — үзем дә белмим. Бик авыр ул кеше өстеннән сүз күтәреп йөрүләре, үзеңне мең тапкыр хаклы санасаң да авыр. Битләрем уттай яна, кулларымны кая куярга белмим, үзем, Сәлмән абыйга күтәрелеп карарга да кыймыйча, эчемдәге катуларымны таратам. Бер заман күз кырыем белән генә Сәлмән абыйга караган идем, өстемә салкын су койдылармыни... Райбашкарма председателе мине тыңлый, ә үзенең чыраенда аңларга теләүнең әсәре дә юк, чыраенда — эч пошу...

— Ник туктадыгыз әле, иптәш Фәттахова, дәвам итегез, — диде ул һәм... авызын кулы белән каплап иснәп куйды!

— Башка әйтер сүзем юк! — дидем мин күңелем кайтып. Дөньясын күрәсем килми иде бу минутта, аяк астында идән ярылса, шунда төшеп китәргә әзер идем.

— Хаҗи ул шулайрак инде... — диде Сәлмән абый тел төбен яшереп кенә һәм тагын да томанлы итеп бетерде: — Ә болай сезнең авыл советы бик арттагылар рәтендә түгел үзе, иптәш Фәттахова...

◆ радик фәизов ◆ мәдинә

Ни әйтергә теләгәндер, ул вакытта да төшенмәдем, әле дә булса анык кына белмим. Райбашкарма председателе безнең авылларда булгалый, әмма Мортазинга бернинди дуслык, аеруча игътибар галәмәте күрсәтми иде. Шулай да алар электә, Хәтнә район үзәге заманнарда, бергә эшләгәннәр, әшнә булганнар дигәнне ишеткәләгән идем. Һәрхәлдә, райбашкарма председателенең Хаҗи Мортазинны яклау ягында икәнен төшенеп алдым.

Көзлектә иртә башланган карлы-бозлы яңгырлар аркасында бездә бәрәңге алу озакка сузылды. Туңдырып, аз гына кар да төшкән бер иртәдә без, хатын-кызлар, югары басуга менеп киләбез. Каршыбызга — бригадир Закирҗан. Ул ерактан ук кулын болгый:

— Бәрәңге бетте, хатыннар! Йөрмәгез азап чигеп.

Башка хатынар шунда ук кире борылдылар. Мин исә бригадирны көтеп, якасыннан алырдай булып торам.

— Ничек бетсен?! Кичтән дүрт гектар бәрәңге калды бит... Башың бетәрлек эш бит бу!

Бригадирның коты алына.

— Зинһар, бетермә мине, Мәдинә. Үзе кушты... Төнлә сукалатып ташларга кушты. Райкомнан курка... — дип пышылдый.

Хаҗи Мортазин ише җанын мамыкка төргән бәндәләр бездә тагын бар, тагын байтак иде шул әле.

Мин боларга түземлегем бетеп, райком секретаре Габбас Сәламовичның үзе янына киттем. Секретарь дикъкать белән, бүлдерми тыңлый. Әле мин сөйләп туктагач та дәшми утыра. Аннары урыныннан торып, каршыма килеп баса.

— Тәк, тәк... — Аның кырыс соры күзләре, җанымнан кер эзләгәндәй, миңа текәлә. — Авыл советы председателе колхоз председателе өстеннән жалоба күтәреп йөри инде, алайса. Шулай аңларгамы моны?

Аның бу карашыннан, бу сүзләреннән коелып төшсәм дә, җавапсыз калмыйм. Мин дөреслек эзләп юлга чыккан кеше, барысын да күтәрергә, барысына да түзәргә тиеш.

— Ничек теләсәгез, шулай аңлагыз, Габбас Сәламович. Мин булганны, бары булганны гына сөйләдем.

— Барысын да сөйләмәдегез шул, иптәш Фәттәхова. Ә Мортазинның хатыннар артыннан сөйрәлүе, яка астына салырга яратуы?

Әллә сөйләгәннәремне гайбәткә саный, әллә инде барысын да ишетәсе килә, белмәссең.

— Анысын, коммунист буларак, үзеннән сорарсыз!

— Ә сезнең үзегез турында да мәгълүматлар бар әле бездә, мәсәлән, шәл бәйләвегез, мамык белән сату итүегез...

Утырган урындыкларыма кадәр чайкалып киткәндәй була, әмма бу юлы да җавапсыз калмыйм.

— Безнең як халкы моңарчы ирләр тапкан акчага түгел, хатыннар шәл бәйләп алган акчага көн итте, Габбас Сәламович! Сез моны үзегез дә беләсез. Дөрес, минем хәзер моңа мохтаҗлыгым юк. Әмма мин, авыл кызы, бала чагымнан шәл бәйләп үстем. Кичләрен әле дә кулыма алгалыйм. Монысы хак. Ә минә мамык белән сату итүем — нахак. Кем җиткерде сезгә мондый әшәке гайбәтне?! — Минем сулышым каба, йөрәкләрем сикерә, елыйсыларым килә. Ә секретарь исә тып-тыныч.

— Ә менә сез, иптәш Фәттәхова, председатель итеп кемне күрсәтер идегез?

— Үзебезнең авылдан Мифтахетдинов Хәйдәр авыл хуҗалыгы институтын бетерә. Инде укырга да яшь егет килеш кенә кермәде. Бригадир булып байтак еллар эшләгәч, үзем булышып керттем, Габбас Сәламович.

— Ай да Фәттәхова! — дип көлә секретарь, ә сүзен бик рәсми, сөер итеп очлый. — Кайтыгыз да әйбәтләп кенә эшләгез, иптәш Фәттәхова. Сез — авыл советы председателе — колхоз председателенә юнәлеш бирергә, кыенлыклар белән бергәләп көрәшергә тиешле.

Ир-атлар, зур эш башында торганнары да, хатын-кыз халкыннан тел төбендәге яшерә алабыз дип, бик тә ялгышалар. Мин инде сүз башында ук сиздем: райком секретаре минем якта, минем якта иде! Шулай да ул көнне өйгә кәефем кырылып кайтып кердем. Башка вакытта эшләрем белән артыгын кызыксынмаган ирем Сәүбән дә моңа игътибар итте.

— Бик чуарланып йөрисең әле син бу арада, Мәдинә.

— Чуарлану түгел бу, дөреслекне эзлим.

— Һе, дөреслек... Юлы бик бормалы аның. Инерция дигән нәрсә бик көчле бездә.

Сәүбән, Сәүбән!..

...Уйларым үзгәреп, айнып киткәндәй булдым. Инде Рөстәм булмәсе ишегендәге ут сүнгән, тышта кичтән күтәрелгән җил дә басылган, өй эче дөм караңгы, моңсу тынлык урнашкан иде. Күкрәгемә каты төер килеп укмашты. Юрганыма төренеп байтак утыргач кына иңнәрем җылынып, күкрәгемдәге төер таралып китте. Керфекләрем чыланды...

Без, хатыннар, аеруча эш башындарак торган хатыннар, мәхәббәтне саклый белмибез. Аны җаваплылык тойгысы белән янәшә куеп, матур букеттай саклап, кадерләп кенә, югары күтәреп бара белмибез. Шуңа күрә күпчелегебез яшьләй тол кала.

Сәүбән белән без егет-кыз вакыттан ук бер-беребезне белеп, яратышып өйләнештек. Сәүбән авылдагы бик хәсиятле гаиләдән иде, яшьтиләреннән буй-сынга да ныграк, холкы да җитди булып үсте. Укытучы, оста математик, читтән торып укыды, югары белем алды. Тату тордык. Ул минем районнан килгән кешеләр белән янәшә машиналарда утырып йөрүләремә, кайчак соңрак калып кайтуларыма да уңайсызлану, көнләшү галәмәте күрсәтмәде. Андый тойгылардан өстен иде Сәүбән. Еш кына әле мине чәен әзерләп, вак-төяк эшләрне дә карап каршылый иде. Бәлки ул, сау-сәламәт, тыныч, сабыр холыклы кеше, миннән башканы көткәндер, кайгыртуыма мохтаҗ булгандыр. Мин исә аның күңелен аңлап бетермәдем, вакытым җитмәде, дөресрәге, моңа омтылмадым. Ә соңыннан инде саксызлык ук күрсәттем. Менә хәзер утырам инде...

...Сәүбәннең «инерция көче» дигәне рас килде. Мин күңелем әрнеп дәү абыйларның ишекләрен шакый башлаганнан соң да Хаҗи Мортазин безнең колхозда берничә ел председательлек итте.

Берзаман шулай колхозларда отчет-сайлаулар башланыр алдыннан Мортазин белән мине райкомга чакырдылар. Башта секретарь янына Мортазин кереп китте, мин алгы бүлмәдә калдым. Бераздан Габбас Сәламович звоногы белән генә ярдәмчесе Розаны чакырып кертте. Ә Роза секретарь яныннан чыкканда әллә ялгыш, әллә юри инде, ике катлы ишекләрнең тышкысын аз гына ачык калдырды. Мин, теләсәм-теләмәсәм дә, секретарьның Мортазинга әйткән соңгы сүзләрен ишеттем:

— Фәттахова монда килеп синең ваемсызлыгыңнан, булдыксызлыгыңнан гына зарланып йөрде. Ә синниләр генә әйтеп бетермәдең... Кем икәнеңне күрсәттең инде...

Кабинеттан чыкканда Хаҗи абыйның тәмам сөмсере коелган, ул бер мескенгә әйләнеп калган иде. Аның миңа рәнҗүле карашын әле дә онытасым юк. Артыннан чыгып нидер әйтәсем, ни өчендер гафу үтенәсем килде. Ләкин мине шунда ук кабинетка чакырдылар.

— Әлегә үзегез генә белегез, иптәш Фәттәхова. Иптәш Мортазин үзен башка эшкә күчерүне сорый. Ә Хәйдәр Мифтахетдинов кандидатурасы турында без монда уйлашырбыз. Мин аның әтисе Мифтахетдин абзыйны яхшы беләм. Төпле кешеләр алар,— диде Габбас Сәламович һәм сүзсез генә кулымны кысты. Мин аны бик яхшы аңладым: Мортазин кебек җитәкчеләрдән котылу райком секретарьларына да уен эш түгел икән.

Отчет-сайлау җыелышына райкомнан вәкил булып килгән Нурзадә: «Иптәш Мортазин сәламәтлеге какшау сәбәпле бу җыелышта үзен председатель вазифаларыннан азат итүне сорый. Хөрмәтле Хаҗи Сәетгәрәевичкә колхоз производствосын үстерүдә күп көч һәм хезмәт куйганы өчен райком исеменнән рәхмәт белдерәбез. Ә аның урынына үзегезнең авылдан Хәйдәр Мифтахетдинов кандидатурасын тәкъдим итәбез!» — дигәч, халык Суыксуның ат абзарыдай шыксыз, ат абзарыдай салкын клубының тәбәнәк түшәмен күтәрә язып кул чапты. Кәефеннән зарланып үзен хәзер үк Хәтнәсенә кайтарып җибәрүне сораган Хаҗи Мортазинны ишеккә кадәр алкышлап озаттылар. Мин әле аның артыннан аяк тибеп, идән дөбердәтерләр, сызгырып калырлар дип тә курыккан идем. Ярый әле, халыкның күңеле киң...

Хәйдәр инде укуын бетереп, район авыл хуҗалыгы идарәсендә берәр ел эшләгән, үзебезнең колхоздагы хәлләргә бик көенеп, берүзе тотынып, тырышып карыйсы килеп йөри икән. Шуңа күрәдер, җыелышта үз исеме аталгач, ялындыру, чытлыклану галәмәте күрсәтеп тормады. Халык алдына чыгып басты да, маңгаена төшеп торган куе чәчләрен бер якка сыпырып үз сүзен әйтте:

— Олы агайлар, абыйлар, апалар, мин — риза! — диде ул.— Тик минем бер шартым бар: бер-беребезгә таләпчән булыйк! Сез шуңа ризамы?

— Риза! — диде зал бер күкрәктән. — Бергәләп тырышыйк!

Шул көнне үк Хәйдәр правление утырышы җыйды. Кереш сүз ясап, Мортазиннан калган «мирасларны» санап тормады ул. Турыдан-туры эшкә тотынды.

— Ахунҗан абый, без быел күпме мал симертәбез? Дәүләткә күпме ит сатабыз? Кварталлап ясалган расчетларың бармы? — диде ул зоотехник Ахунҗан абыйга.

— Расчетлар ни әле... Төзеп бетерәсе бар...

— Бер атнадан минем янга төгәл расчетлар белән керәсез! — диде Хәйдәр һәм сорап куйды. — Менә сез, дөнья күргән кеше, шуны әйтегез әле: сыерларга башакны оннан биргәндә яхшымы, әллә саламга ярма болгатып биргәндәме?

Ахунҗан абый кече күңелле, уенчак сүзле кеше, председательнең рульне кая тотканын абайламады.

— Әлбәттә инде, оннан, Хәйдәр энем. Сыер малы бөртек яратамыни, әйттең сүз, хи-хи... — дип кеткелдәп куйды.

— Шулай булгач, нигә сыерларга башакны сыер яратмаган бөртек белән бирәсез? Урнаштагы тегермән нигә ярма яра, он тартмый?

Ахунҗан абый бик уңайсызланды, тирә-ягына карап алды. Ләкин аны яклап сүз салырга җыенучы күренмәде. Хәйдәр куйган сорау барысын да уйга калдырган иде.

— Анысын әнә ферма мөдиреннән сорарсыз инде, — диде Ахунҗан абый.

— Ферма мөдиреннән сез сорарсыз, иптәш Шакирҗанов! — диде Хәйдәр.— Мин — колхоз председателе. Минем терлекчелек өчен тулы җаваплы, ферма мөдирләре белән эшләргә тиешле зоотехнигым бар.

Кешеләр астыртын гына бер-беренә карашып алдылар. Беркемгә дә каты бәрелмичә, шаян сүз кыстыргалап кына утырырга күнегел-

гән иде шул моңарчы. Дилбегәнең нинди кулга эләккәнен хәзер сизделәр. Безнең колхоз тарихында яңа бер утырыш иде бу. Бар халыкны, шул исәптән минем үземне дә, барыннан да бигрәк моңарчы авылга атна араларында гына кайтып йөргән Хәйдәрнең колхоздагы хәлләрне безнең үзебездән дә яхшы белүе гаҗәпләндерде.

Ул көнне мин өйгә ничек кайтканымны да белмим. Аякларым белән җиргә басыпмы, аркама үсеп чыккан канатларым белән очыпмы? Ә өйдә мине Сәүбән үз хәбәре белән каршылады.

— Мәшәкать чыгып тора әле, Мәдинәкәй. Мине Ташкүпергә директор итеп җибәрмәкчеләр. Олы юлга җыен,— диде ул, күңелсез хәбәр әйткәндәй. Ә үзе мине кочаклап, битләремнән үбеп алды, үзенең куанычы күкрәгенә сыймый иде. Сәүбән безнең Суыксу мәктәбендә, гомумән мәктәпләрдә математика фәнен укыту тәртипләреннән канәгать түгел, кабинет системасы, факультативлар кертү турында планнар корып йөри иде. Димәк, үзен директор итеп кая гына җибәрсәләр дә барачак.

— Ничек була инде бу? — дидем мин ни уйларга да белмичә.

— Ә мин ризалык та бирдем инде, — диде Сәүбән.

Аптырашта калдым. Инде күпме ишекләр шакып, йөз суларымны түгеп теләгемә ирешкәч кенә... Колхоз белән җитәкчелек итәргә күпме өметләр баглаган, ярдәмнәр вәгъдәләгән кеше килгәч кенә... Сессияләрдә үзем белән бергәләп кайгырышкан олыларга, авылдашларга хыянәт иткән төсле... Юк, юк, мин авылымны, эшемне ташлап китә алмыйм!

Сәүбән белән бер-беребезгә сыенып, шушы диванда бик озак утырдык без ул кичтә. Ахырда киләсе уку елына кадәр мин монда калып торырга дигән карарга килдек.

Алты чакрымлы Ташкүпердән бара-кайта йөрүне бер дә авырга алмады Сәүбән, «эштән соң бер җилләү ул» дип, аннан да канәгать иде. Ул арада язы, аның арты җәе дә үтеп китте, көзе җитте. Ә минем мәшәкатьләрем арта гына бара: кыр эшләре аз гына җиңелгәч тә Суыксудан олы юлга дамба күтәртә башлыйсы, яңа салып чыккан медпунктка кирәк-ярагын, шәфкать туташын табасы, салынып беткән ясле-бакчага өстәлләр, тәбәнәк урындыклар, идән паласлары, уенчыклар, балаларны утыртыр өчен чүлмәкләр юнәтәсе, армиядән авылга кайткан егетләрне каршылау турында уйлыйсы, тагын меңләгән мәшәкать чыгып кына тора иде.

Әле көзләр җиткәч тә без Ташкүпергә күчеп китә алмадык. Китә алмадык, имеш?!. Утырма ичмасам!.. Мәхәббәтемне саклый белмәдем, Сәүбән кебек иремне башка берәүгә үз кулларым белән биреп җибәрдем диген...

Көзге бер кичтә, аяк аслары бик пычрак булып әллә инде бер ай кайтмый торганнан соң, Сәүбән гадәттәгедән иртәрәк, мин эштән төшкәнче үк кайтып керде. Бусагадан сәер атлап керүләреннән, күз карашыннан ук сискәнеп, имәнеп киттем: бу элекке Сәүбән түгел, бу минем Сәүбәнем түгел иде... Керсез күңелле, икейөзлеләнүне белми торган кеше иде Сәүбән. Миннән ни дә булса яшереп тормады.

— Мин китәм, Мәдинә. Мин башка берәүне яраттым,—диде ул.— Башкасы белән, зинһар, бер-беребезне түбәнсетмик. Бергә кичергән тормышыбыз хакына...

Мин шунда баскан урынымда коелып төштем.

— Кем ул? — дип кенә сорый алдым.

— Укытучы. Быел килде, — диде Сәүбән.

Вакыт яраларны дәвалый, тормыш акрынлап булса да үз сукмагына кайта икән ул. Менә Сәүбәннән башка торуыма да ничәнче ел китте... Үземә дә сүз салучылар, күңелем кузгалулары булмады түгел. Менә әле район авыл хуҗалыгы идарәсенә быел гына башка җир-

дән килеп урнашкан берәү көзлектә безнең колхозда булып киткән иде. Аның да тормыш иптәше үзенә ияреп килмәгән, башка берәүне тапкан. Әйбәт кеше күренде ул миңа.

Туктачы, тукта,ниләр хыялланып утырам соң әле мин болай? Кичтән алып шушы кара төнгәчә тормышымнан зарланып, күңелем елап утырам түгелме... Мин шушында күпме маңгай тирем, йөз суым, күз яшьләрем тамган Суыксуны хәзерге көненә җиткерү хакына үзенең мәхәббәтен югалтуга кадәр барып җиткән Мәдинә... Ничәмә еллар бергә эшләгән кешеләремне, Мифтахетдин бабайларны, үземнең яклавыма мохтаҗ Хәлимәләрне ташлап... Фикерләрем тәмам чуалды, кан басымым күтәрелеп, колакларым шаулый башлады. Бая көндез карарымны бик ашыгып чыгармадым микән дигән шик килде.

Ә бит әле күңелемнең түрен татлы кытыклап, нур сибеп торган уйларым, хыялларым бар иде. Шушында, Суыксу җирендә... Кабинетымда авылның генеральный планы эленеп тора. Икешәр катлы йортлар тезелеп киткән урамнары, асфальт түшәлгән мәйданнары, уртасында матур буасы булган бер яңа авыл безнең Суыксу. Ә кемнәр тагын да яңарак итәр минем авылымны? Моның өчен тагын бик күп, бик күп эшләр башкарасы бар бит әле.

Уйларым тәмам чуалып ни хәл итәргә дә белмичә утырдым-утырдым да, үксеп мендәремә капландым.

* * *

Иртән идарәгә менүемә, Хәйдәр мине үзе янына чакыртып алды. Ул куе чәчләрен маңгаеннан сыпырып куйган, күңеле бик күтәренке, ниндидер зур куанычы бар иде.

— Нигә чакырганнар кичә, Мәдинә апа? — диде ул һәм минем җавабымны да көтмәстән, үзенекен сөйләп китте: — Эшләр пешәргә тора әле безнең, Мәдинә апа. Кичә Казан шалтыратты. Культура йортына дигән силикат кирпечне алып кайта башларга мөмкин. Синең өлешкә тагын бер куаныч. Мин Булатов белән сөйләштем: культура йортында балалар өчен музыка мәктәбе ачу бик тә мәгъкуль эш диде.

Шунда Хәйдәр миңа күтәрелеп карады:

— Тукта әле, Мәдинә апа, ни булды сиңа?!

— Мин ни... бер язуымны гына онытып калдырганмын... Хәзер киләм... — дидем мин һәм тизрәк кабинетыма чыгып киттем. Ашыга-ашыга телефоннан райбашкарма номерын җыйдым. Сәлмән абый, көтеп кенә утыргандай, трубканы шунда ук алды.

— Гафу итегез, Сәлмән Гәрәевич, мин монда кире уйлап торам әле, — дидем мин.

— Шулаймыни? — дип сузды ул гаҗәпләнгән һәм бераз үпкәсен дә белдергән тонда. Байтак сүзсез торгач, өстәп куйды: — Ярый, үзегезгә карагыз тагын, иптәш Фәттахова. Монда... кандидатлар бар иде үзе...

Шунда өстемнән тау-ташлар, иңнәремнән моңарчы күрелмәгән әллә ниндидер авырлыклар төшкән кебек булды. Ниндидер үкенү хисе күңелне шакый башлаган иде дә, мин аны тыңлап тормадым, секретарем Зөлфиргә эндәштем:

— Хәсибуллина Әминәне чакырт әле, Зөлфирә.

— Күгәрчен Әминәсенме? Ни бар, Мәдинә апа? — диде Зөлфирә бераз аптырабрак.

— Сөйләшәсем бар!

Яңа эш көнем башланып китте.

# Бердах,

каракалпак шагыйре

*Бердах (чын исеме — Бердимурат, Каргабай угылы) — каракалпак халкының классик шагыйре, каракалпак язма әдәбиятына нигез салучы. Ул моннан 150 ел элек Арал диңгезе буенда балыкчы семьясында туа. Башлангыч белемне авыл мәктәбендә ала, соңрак мәдрәсәгә керә. Ләкин, тормыш шартлары авыр булу сәбәпле, мәдрәсәне тәмамлый алмый. Шулай да ул, үзлегеннән күп укыганга күрә, заманының укымышлы кешеләреннән берсе булып танылa. Бердах күп язган һәм шигырьләрен халык алдында дутарда уйнап, җырлап әйтә торган булган. Аның күп шигырьләрен халык бүгенгегә кадәр саклап, китереп җиткергән. Бердах лирик, сатирик һәм дидактик характердагы шигырьләр иҗат иткән. Күләмлерәк әсәрләреннән — «Ахмак патша», «Шәҗәрә», «Ерназар бай», «Амангелди» һ. б. күрсәтергә мөмкин. Бердах 1900 елда 73 яшендә вафат була.*

*Быел Бердахның 150 еллык юбилее ил күләмендә зурлап уздырылды. Мәскәүдә, Ташкентта, Нөкистә һ. б. шәһәрләрдә шагыйрьгә багышлап тантаналы җыелышлар үткәрелде. Каракалпак АССРның башкаласы Нөкистә шагыйрьгә зур һәйкәл ачылды. Күп кенә нәшриятлар Бердахның сайланма шигырь китапларын чыгардылар. Шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү юнәлешендә тагын башка байтак чаралар күрелде. Без журналның бу санында, юбилей мөнәсәбәте белән, Бердахның берничә шигырен укучыларыбызга тәкъдим итәбез. Шигырьләр Бикә Рәхимова тарафыннан турыдан-туры каракалпак теленнән тәрҗемә ителде.*

## Диңгез балыгын бирмәде

Ау салдым барып диңгезгә,
Диңгез балыгын бирмәде.
Алла, нәләт салдың безгә,
Көз җитте бит, ник күрмәдең?

Ил-нәсел бүленеп бетте,
Әүлиялар түнеп бетте,
Ачлыктан йорт үлеп бетте,
Диңгез балыгын бирмәде.

Менә шундый хәлләребез,
Ишәймәде малларыбыз,
Бармы алда юлларыбыз?
Диңгез балыгын бирмәде.

Дәһшәт белән дулкын орды,
Каһәр булып давыл торды,
Бер галәмәт заман булды,
Диңгез балыгын бирмәде.

...Бердимурат булам үзем,
Ялган имәс әйткән сүзем,
Бар дөньяны күрде күзем,
Ходай саулыкны бирмәде.

## Кем әйтер?

Атасыннан яман туса,
Аны яхшы дип кем әйтер?
Акылсыз һәм надан булса,
Аны галим дип кем әйтер?

Адәмне адәм димәсә,
Азамат кадрен белмәсә,
Елаганнарны күрмәсә,
Аны гадел дип кем әйтер?

Явыз гөнаһсын белмәсә,
Белеп, дарына элмәсә,
Һәммәне бердәй күрмәсә,
Аны патша дип кем әйтер?

Елаганны юатмаса,
Эшне уңайга тартмаса,
Ил татыганны татымаса,
Аны солтан дип кем әйтер?

Хак-нахакны белешмәсә,
Гаделсез хөкем эшләсә,
Төйнәлгән эшне чишмәсә,
Аны казый дип кем әйтер?

Гарипкә нәзер салмаса,
Фәкыйрьгә файда кылмаса,
Өзекне ялгый алмаса,
Аны бай ул дип кем әйтер?

Муйнына пута [1] салмаса,
Нәфесен тыя алмаса,
Сүзендә мәгънә булмаса,
Аны суфи дип кем әйтер?

Кара суны тондырмаса,
Кара ташны сындырмаса,
Чүлгә авыллар кормаса,
Аны башчы [2] дип кем әйтер?

Сүзендә хикмәт булмаса,
Чишмәдәй агып тормаса,
Теленнән баллар таммаса,
Аны чәчән дип кем әйтер?

## Эзләдем

Заманга соң нәрсә булды,
Былбыл урынын козгын алды.
Дөньяга хәтерем калды,
Фикердәшем эзләдем мин.

---

[1] Пута — бу очракта муен яулыгы, шарф.
[2] Башчы — бу урында юлбашчы.

Еракта туган-кардәшем,
Ни кайгыга төште башым.
Батыр егет булса янда,
Дөреслекне эзләр идем.

Арбаның ике тәртәсе,
Минем ыру ике җәпле.
Йөрәге арыслан затлы
Халык улын эзләдем мин.

Ак сөт имгәнмен анадан,
Үзем бәхетсез саналмыйм.
Ач өчен көеп-янамын,
Аңа хак юл эзләдем мин.

Юлыннан адашып калган,
Кайгысыннан гаҗиз булган
Ярлы-гарипне яклаган
Шәфкатьлене эзләдем мин.

Әгәр тапсам чараларын,
Үзгәртер идем түрләрне [1],
Гөлчәчәк итеп җырларне,
Рәхмәт сүзен эзләр идем.

Кадими китаптан качтым,
Нәвоидән акыл җыйдым,
Фозули җырга өйрәтте,
Остазларны эзләдем мин.

Бердимурат хакның колы,
Сахрада үскән былбылы.
Кайда гына сайрасам да,
Халкым юлын эзләдем мин.

## Салым

Былтыргыдан быел яман,
Парә-парә килде заман,
Ярлы халык исән калмас,
Бигрәк зурдан килде салым.

Минем ярый ишәгем бар,
Сатып түләрмен бер базар,
Ярлы күршем, ач Ерназар,
Ничек түләр ул салымын.

Ул фәкыйрьнең һичнние юк,
Ач карыннан башкасы юк,
Сатарга бер тавыгы юк,
Аптыратты аны салым.

Өендә ач балалары,
Иртәдән ач карыннары,

---

[1] Түр — бу урында идарә, власть күздә тотыла.

7*

Күзләрдән акты яшьләре,
Ай-яй, кыен булды салым.

Байбәтчәләр, ишан, мулла... —
Аларга салым нигә юк?
Күздән яшьләр кибәрме бер,
Килерме бу көткән хаклык?

## Яшь киленгә

Кашың кара, билең нәзек,
Уң кулыңда якут йөзек,
Буй-сыныңны бүген күрдем,
Бигрәк чибәрсең син, сеңлем.

Чәчең кара, йөзең ап-ак,
Озын керфек, авызың уймак,
Матур борын, нечкә бармак,
Килбәт ягың килгән, сеңлем.

Йөзең балкый якты айдай,
Туган анаң синең кандай,
Сүзең ширин, телең балдай,
Пәри заттан артык, килен.

Күренеп тора акыл-уең,
Тал чыбыктай зифа буең.
«Алдым-бирдем» — туең ясап,
Тиң түгелгә биргәннәр бит.

Атаң шул синең мал сөяр,
Зур кәрванга калым төяр.
Искелекләр җиңә килер,
Бәхтең шулай булды, сеңлем.

Хурлык, газап булыр көнең,
Елау белән үтәр тенең,
Иркен сулап өнең чыкмас,
Авыр тормыш килде, сеңлем.

Шул яшеңнән башың иеп,
Тоткында син калма торып,
Бу йортның тиз ишеген яп,
Бирешмә, сеңлем, тиңең тап.

## Мәрди Рафиков

# ИДЕЛКӘЙНЕҢ АК ТАШЫ

### Учак

Дөньяда ике көчле булса, аның берсе Идел дияр идем. Үзе болай салмак кына, сабыр гына аккан кебек, ә үзе, кеше кадәр кешене таң калдырып, корыч кебек чыкылдап торган тау ташны ярып төшкән. Шаян дулкыннарын кагып уйнарга текә яр теләдеме икән Иделкәй? Әллә яшел урман куенында изрәп яткан түгәрәк тауның бөтен яшерен байлыгын һәм матурлыгын кешегә күрсәтергә ниятләгәнме? Төсле катламнарны ачкан. Алары кояш нурларында зиннәтле таш сыман җемелдәп күзне камаштыра.

Ә аста учак яна. Аның күңелгә рәхәт тавышы ишетелә: яр читенә дулкын кагып чыгарган һәм кояшлы җилдә кипшенгән агач-богач утта урман коры-сарысы шикелле шарт-шорт килә. Учакның әчкелтем күксел төтене тау чишмәсе юлындагы уйсулыкка, аның җиләкле һәм мәтрүшкәле аланына тарала. Ә алан артында, тауга үрмәләгән юкәлекләр арасында, шәүлегән кычкыра. Ул сызгырырга өйрәнүче малай кебек итенә дә, кинәт туй мәчесенең сискәндергеч авазын чыгарып куя. Аргы киртләчтән аңа икенчесе җавап бирә.

Юрий Вячеславовичның яңгыр теләүче бу кошларда гаме юк. Ул бөтен күңеле белән шөгыленә бирелгән. Учакка менә тагын берничә агач кисәге атты. Ут, шуны гына көткәндәй, талпынып куйды, аннары, ялкын телләрен сузып сикерә-сикерә, сөремле чиләкне ялый башлады. Чиләктәге шулпа да, ташыр хәлгә җитеп, күпереп чыкты. Юрий Вячеславович шуны гына көткән иде. Ул чишмә буенда балык чистартучы егеткә кычкырды:

— Салырга вакыт. Түгәрәклә!

Егет, көмештәй балыкларны савытка алып, учак янына ашыкты.

Учак дөрләтүче кеше белән кичә үк танышканмын булып чыкты. Кама тамагы гипс руднигына барырга җыенгач, районда кайбер мәгълүматлар бирделәр. Фамилиясен ишеткәч исә күңелгә аеруча якын булып китте. Куркусыз партизан Полетаев шикелле пәһлеван затны күз алдына китердем. Ә минем белән үзен бик басынкы тоткан яшь кеше күреште. Ялгышмадым, «Полетаев» диде, «Юрий Вячесла-

вович» дип өстәде. Шул кеше кайнаша учак янында. Базык гәүдәле, киң җилкәле. Маңгае да киң һәм тигез. Түгәрәк йөзе җитдилек бирә. Менә ул бизәге кырылган агач кашык белән шулпа чумырып алган да сөйләнә-сөйләнә тәмен татый:

— Балык шулпасын ихлас яратам. Ашаудан бигрәк пешерүе тәмле. Хәзер бергәләп авыз итәрбез. Кыстатмыйча ашарсыз. Шәп чыккан! — Аның, шулпадан бигрәк, бүгенге шөгыленнән канәгать булуын сизеп торам. Ул минем фикерне раслагандай һәм очынып киткән сыман боерык бирә: — Кашыкларыгызны әзерләгез! Ә минеке үзем белән: кая күчсәм дә, аш кашыгы белән касканы калдырмыйм.

Кызык кеше булып чыкты бит, әй! Техникум тәгәлләгәч, Донбасс шахтасына тау мастеры итеп җибәргәннәр. Матур бизәкле, чүмеч тикле агач кашык, каска биргәннәр. Каска киеп шахтага төшкән. Буш вакытта кашыгын алып иптәшләре белән елга буена балык шулпасы пешерергә йөргән. Шулай гадәтләнгән. Енисей ярының карьер хуҗалыкларында смена начальнигы, биш инженер, шахта начальнигы булып эшләгәндә дә шул гадәтен онытмаган. Гадәтен дә, каска белән кашыгын да. Идел буенда рудник директоры итеп билгеләнгәч тә чемоданга беренче булып кашык белән каскасын салган. Рудникка да егерме ел элек, мастер чакта кулына алган касканы киеп керә. Ял көннәрендә шахтерлар белән Идел буена чыкканда инде бизәге кырылган кадерле кашыгын ала һәм яңа җирдә беренче мәртәбә бүгенгечә тәмле балык шулпасы пешереп күрсәтә.

Ә бүгенге табынны яшел чирәм өстендә ачканнар иде. Аякларны бөкләп утырып, мактый-мактый кайнар шулпа ашыйбыз. Тау урманында шәүләгән өзгәләнә. Ә якында гына кечкелдек дулкыннарында кояш нурлары уйнатып Идел ага. Ул дулкыннарны ак теплоход кузгата бугай. Кызык, үзен су өстендә гамьсез генә чайкалып утыручы кара кәләпүшле аккошка тиңлиләр: пароходым-акчарлагым, имеш. Ә ул, чынлап баксаң, гипс ташы кебек ак икән.

Теплоход кинәт кычкыртып җибәрде. Юрий Вячеславович сискәнеп китте. Иделгә карап алды да:

— Безгә килә дип торам,— диде.

Мин аның йөзендә үзгәреш сиздем. Ул күңелсезләнгән һәм җитдиләнгән кебек иде.

Гадилеге үзе белән. Анысы кеше буларак. Ләкин ул җилкәсендә үзгә йөкне — җитәкченең эш өчен җаваплылык йөген дә йөртә. Бүген, нәфесе белән дип әйтимме, елга буена ял итәргә чыккан. Ә үзенең күзләре мөлдерәп Иделгә карый. Баржа көтә Юрий Вячеславович. Яр буе складында вакланган гипс ташы күп тупланган. Тизрәк аны озатырга кирәк. Заказчылар да телеграмма яудыралар. Ә монда баржа юк. Төяү краннары икенче көн колга кебек тора. Бөтен тормышын тынгысызлыкта үткәргән кеше өчен бик кыендыр андый көтүләр, эчке әрнү, хәтта ярсу тудырадыр. Шул галәмәт йөзгә сугадыр, безгә сәер җитдилек булып чагыладыр.

Ә учакта мәтрүшкәле чәй пешә. Аның борынны кытыклаган тәмле исе яшел печән һәм мәтрүшкәләр үсеп утырган аланга җәелә, хәтта Идел ярына җитеп аңкып тора.

Теплоход борылыш артына китеп күздән югалды. Ул күтәрелгән дулкыннар ярга бәрелеп чупылдашып алдылар да юкка чыктылар. Анда хәзер тик керәшәләр генә очалар иде. Бу нәфис кошлар уктай атылып киләләр дә йомшак күкрәкләре белән суны сөзеп-ярып үтәләр. Артларында су, балык уйнагандагы шикелле, бөтеркәчләнеп кала. Алар тын Иделдә шулай рәхәтләнеп су керәләр.

Шушы бәләкәй җан ияләрен нык беләкле, ихтыярлы шахтерларга тиңлисе килә. Идел кискән ярда үз итәрлек катламны эзләп табалар да, кечкелдек томшыклары белән туктаусыз чокып, шахтер теле

белән әйтсәк, штольня ачалар. Яр буйлап тезелеп киткән менә шул штольня-ояларда әртил булып көн күрәләр, бала чыгаралар. Идел өстендә көзге томаннар торганда моңсуланып китсәләр дә, язга чыккач, тау урманында күке тавышы җәйри башлагач, яр ояларына тагын кайталар. Шул ояларын сипли, ә яңасын ача башлыйлар.

Кешеләр дә гипс шөгыленә яр карлыгачларыннан өйрәнделәр микән? Алар да, су читендәге ак таш катламын кәйләләр белән чокып, штольняләр ачып караганнар. Бу гасыр башында ук булган. Берен ташлап икенчесен ачканнар, өченчесен... Ләкин әллә ни эчкә үтә алмаганнар. Текә ярдагы карлыгач оясыдай уелдыклар шуннан калган. Алар кешенең изалану шаһиты булып һәм серле мәгарәләрне хәтерләтеп торалар. Ярым ишелгән һәм авызларына куак сарган шул тау куышларыннан әкиятләрнең килбәтсез җен-пәриләре килеп чыгар төсле тоела.

Ә кешеләр иң дәү штольняны — җир астына керү юлын—түгәрәк тауның Идел ярган кыясында ачканнар. Йөзләрчә мең тонна гипс байлыгын шуннан алалар. Юрий Вячеславович штреклар буйлап тышка чыгарылган һәм тегермәндә тартылган шул гипс онын тәяп озату өчен атлыгып баржа көтә иде.

## Мәгарә

Җиде кат җир асты мәгарәләрендәге маҗаралар турында китаплардан укыган бар иде. Ә менә хәзер штольня дигән олы капкадан үзебез мәгарәгә керәбез. Профсоюзның рудник комитеты председателе, шахтер Кәрим Халиков алдан бара, мин арттан юыртам. Табельчы кыз Рәйсә Ибраһимова янына туктап каска һәм иңгә элә торган электр фонаре алабыз да, җилгә иярэп, тагын эчкәрәк үтәбез.

Менә тамаша! Яп-якты бер үзәккә килеп чыктык. Уң кулда — ашханә. Сул якта — җир өстендәгечә матур бизәлгән бүлмәләр. Ишекләренә язылган: «Смена начальнигы», «Бораулау һәм шартлату эшләре мастеры». Кызыл почмагы да, душ һәм бүтән көнкүреш бүлмәләре дә шунда. Бары да әкияттәге кебек таш диварлы. Ә ашханәнең идәненә келәм кебеген дә җәйгәннәр.

Тау мастерының «куышында» утырып җир астында йөрер юлыбызны билгелибез. Фәлән штректан фәләненә күчеп, фәлән камерага тикле барырга исәплибез. Ә фәлән дигәне саннар белән йөртелә, мәгарәдә төгәл адрес булып тора. Чөнки штреклар шәһәр урамнары кебек сузыла. Шул урамның ике ягында гипс ташы актарып алынган номерлы камералар тезелгән. Алары йортларны хәтерләтә. Мәгарә шәһәре диярсең!

Без, тәпиләп бара торгач, өченче штрекка килеп чыктык. Кәрим алтынчы камера янында туктап калды:

— Беренче мәртәбә гипс ташы белән менә шушында очрашкан идем инде,— диде ул.— Аннары көрсенеп куйгандай итте: — Әй, ул чакларны күз алдына китерсәң!..

Кәрим үзенең хикәяте белән безне үткән көннәргә алып чыкты. Илленче еллар башында була бу. Рудник өчен үзгәреш заманы. Тачкага алмашка атлы вагонеткалар килгән. Кәрим үзедәй нык беләкле егет Госман Сибгатов белән ул чагында шушы камерадан вагонеткаларга таш төягән. Әй, ул чаклар...

Смена төгәлләнергә күп тә калмаган иде инде. Бик арыткан. Атлар да үшән генә йөри. Суфия аларны әледән-әле чыбыркы белән дәртләндереп ала. Якынрак килеп селтәнгәндә, аягын вәлүккә бәреп

сызланган чаклары да була. Анысын егетләр күрсә, билгеле, авыз ералар: җир астында, янәсе, җәннәт кенә түгел... Хәер, үзләре дә уфылдыйлар.

— Госман, шушы зәхмәтне күтәреп салыйк әле,— ди Кәрим, чүмәлә хәтле ташка күрсәтеп. Таш гөрселдәп вагонеткага төшә. Ә икенчесе кыймылдатырлык та түгел. Зур чүкеч белән дөмбәслиләр. Ярыгы күренсә, чөй җибәрәләр. Кулларыннан көнозын кәйлә, чүкеч, көрәк төшми.

Суфия тулы вагонетканы элдертеп китте. Ә беравыктан тагын ат пошкырганы ишетелде. Ул да түгел Нюра аваз салды:

— Вагон төште, егетләр, күтәрергә булышыгыз әле.— Егетләрне каршылады да, үзенчә акланырга тотынды:— Тизрәк җитим дип, атка бераз суккалаган идем дә... шап вагон җиргә! Күтәрә генә алмыйм бит.

— Ярар, сайрама, рәхмәт әйтсәң, күтәрербез.

— Икенче дилбегәңне турырак тот. Рельсы дигәч тә...

Вакыт, вакыт!

Суфия Мөбәракшина, Нюра Матвеева, Кәрим һәм Госманнарда гына түгел, ә рудник тарихының үзендә шундый эзләр калдырып киткәнсең ич син! Ә Шакир бабай Корбанов кебек ветераннарны тыңласаң, эзләрең тагын да тирәнрәккә киткәнен күрәсең. Суки дигән авылның Большаков атлы бай урысы шушы тауда алебастр заводы корган. Кече Мәрәтхуҗа авылының Корбан батрак малае Шакир әртилчеләргә кушылып, көнгә ун-унбиш тиен хакына, монда килеп кәйлә белән таш чокый һәм шул ташны завод мичләрендә яндыра башлаган. Ташын тачкага җигелеп ташыганнар. Шушы михнәтле һөнәр атадан балага, баладан оныкка күчә килгән. Кәйлә белән лампа да озак яшәгән, тачка да адәм затының беләк егәрлеген байтак какшаткан.

Тарихны тыңлыйсың, вакыт дигән үлчәгечнең дәвер эзләрен капшыйсың — соклануың арта. Барыннан да бигрәк кешенең үзенә сокланасың. Нинди зат бу адәм баласы, дисең, нинди холыклы?! Үткәнендә күргән авырлыкларны да ләззәт белән сөйли белә. Әйтерсең лә кәйлә тотмаган, әйтерсең лә ун тиен хакына җан тирен чыгарып тачка этмәгән! Ул ләззәтләнеп сөйли, ә син, гыйбрәтләнерлек һәм чагыштырырлык сәләтең булса, мыегыңа үзең чорна. Бүгенге шахтерларның эшен күреп куануларын да искәрмичә калма!

Вакыт дигәнең бүгенгегә килеп төртелгән икән, шөкер, бүгенгесе — шатлыклы.

Без шахтер Кәрим хезмәткә старт алган җирдә басып үткәнгә бәләкәй сәяхәт ясап кайттык та, кузгалып, электр белән гөлт иткән дүртенче штрекка чыктык. Безне тау хәтле үзбушаткыч куып җитте. Ул тормозлары белән хәтәр пошкырып яныбызга туктады. Кабинадан шоферның башы күренде.

— Исәнмесез, Кәрим Идиятович!

— Бик әйбәт, Саша.

— Болай кая юл тоттыгыз?

— Унберенче штрекка.

— Унберенчегә! Җәяүләп!..— Шофер гаҗәпләнеп баш селекте дә кабина ишеген ачты.— Тиз барып җитә алмассыз, утырыгыз, әйдә!

Кәрим миңа ымлады да:

— Алдынгы шофер янына бер утырып карыйк әле,— диде. Аннары, ат куалаучы кызларны хәтерләп булса кирәк, шаяртып куйды:— Рельстан җиргә шапылдамаса.

Монда шапылдарлык түгел иде. Шоферлар юлны укып йөриләр: тиешле һәр урында күрсәткеч-кисәткеч билге куелган. Ул борылышта да бар, түшәм түбәнәйгән җирдә дә. Штректа һава агымын тоткарлаучы капкага җитәрәк тә, икенче катка менеп киткән (анда да штреклар ачалар) авыш юлга борылганда да шәһәр урамнарындагы шикелле билгеләр күрәсең.

Рудникның баш инженеры Владимир Петруцик белән сөйләшүем искә төшә.

— Штрекларның озынлыгы йөз чакрым исәпләнә,— дигән иде Владимир Борисович. Җир асты шоферлары менә нинди озын юл йөриләр. Анысы бер хәл. Тәртипле булулары хәйран итә. Каршы очрашканда, машиналарының кече күзләрен җемелдәтеп, бер-берен сәламләп алалар. Ә сигнал дигәннәрен җиң очы белән дә пипелдәтмиләр. Юл күрсәткеч билгеләргә ихлас буйсыналар. Штректа җәяүле шахтер очратсалар, машинаны туктатып, хәлен-юлын сорыйлар, юл уңае туры килсә, амбар кебек кабинага алалар.

Күпме үткәнбездер, Александр Тананов машинаны туктатты.

— Мин уңга борылам,— диде ул, экскаватор үкереп эшләгән якка ымлап.— Сез унберенчегә турыдан гына чыгарсыз.

Без кабинадан төштек. Машина кузгалып үз юлына китте.

— Булган шофер,— диде Кәрим, күзе белән озатып.— Бар бездә андый егетләр. Шофер Ринат Гыйльметдинов, экскаваторчы Александр Дорофеев... Тегеләй әйтсәк: ут чыгаралар, чакматаш диярсең.

Ул мактанмый иде. Ул нибары горурлыгын белдерә иде. Ә кешенең хезмәтен таный һәм горурлана белү үзе бер матур сыйфаттыр бит. Авыр хезмәттә беләгән ныгытып җитәкче эшкә күтәрелгән иптәшнең шахтер хезмәтенә сокланып һәм горурланып каравы пичектер күңелгә якын, шатлыклы иде.

Йөз ун метрлы «тыкрыкны» артта калдырып, унберенчегә чыктык. Уночение камера гөлт иткән. Өстә, доломит түшәм астында жуылдау ишетелә. Анда гипс катламын бораулыйлар.

Шикәрдәй ак таш кыяда кеше күреп туктап калдым. Ул менә шундый горур күренде, хәтта бермәлгә аптырап киттем. Гипстан яхшы сыйфатлы цемент эшлиләр. Гипсны медицинада кулланалар. Гипс белән сарайлар, заллар бизиләр. Гипстан батырларның исемен мәңгеләштергән мәһабәт һәйкәлләр иҗат итәләр. Каршыдагы кыяда да һәйкәл түгелме соң?! Унике метрлы кыяда электр боравы белән шпурлар тишүче кеше, чыннан да, мәйданнарга куелган горур һәйкәлгә охшаш иде. Ләкин ул, шахтер данын үстереп, бу минутта да корыч боравы белән тау токымына үтә иде. Кәрим кулын авызына бүрәнкәләп куйды да шул җанлы һәйкәлгә мөрәҗәгать итте:

— Эшең җайлы барамы, Госман?

«Һәйкәл» безгә йөзе белән борылды. Аның бите пинжәге кебек ап-ак, кашлары да гипс онынннан «бәсләнгән» иде.

— Җиңәм!— дип кычкырды ул кыядан.— Циклы белән тапшырам, рәхәтләнеп шартлатсыннар.

Бу — өченче штректа Кәрим белән бергә эшли башлаган, бүген тау токымын бораулауда рекордлары белән танылган Госман Сибгатов иде.

Вакыт, вакыт! Син мәгарәдә дә могҗизаларың күрсәтәсең. Кеше синең белән бергә, тау токымын адымлап актарып, өченчедән унберенче штрекка килгән. Хәзер монда да ут чыгара.

Күрше камерада борау жуылдый. Анда Геннадий Смирнов эшли. Ул да, Идел ярындагы керәшәләр кебек, кыяда актарына. Безне күрү белән зарын сиптерә башлады:

— Бүгенге планны үтәмим, Кәрим Идиятович.

— Ни булды, Геннадий Николаевич?

— Синякка тертелдем.

Кәрим «һе» диде дә, кыяга сөялгән баскычтан бораулаучы янына менеп китте. Озак кайнаштылар. Ниһаять, Геннадий, канәгать елмаеп, Кәримгә кул бирде һәм аңа баскычтан төшәргә булышты. Кәримнең кулында әәңгәрсу ангидрит кисәге иде.

— Менә шушы таш азаплый инде шахтерны. Татары да, русы да синяк ди үзен. Күз төбендәге «фонарь»га ошатып әйтәләр,— диде ул. — Ә чакматаш эләксә — бәланең бәласе. Очкын гына чыгара.

Сөйләшә-сөйләшә, без алдан билгеләнгән юл буйлап машиналар янына киттек. Бераздан экскаватор тавышы ишетелде. Икенче катта да куәтле җир асты экскаваторы эшли иде. Электр машиналары. Дөньяңны күчерерлек. Шоферларга сулу алырга да бирмиләр. Ярышып кара син мәгарәнең шул аждаһалары белән. Бик тиз тының кысылыр.

Ә теге елларда кеше машина белән дә ярышкан. Кеше икәнен күрсәтү өчен, үҗәтлек белән көрәшкән.

Кәримнәр рудникка аяк баскан елларда вагонеткага гипс ташы төяүчеләрнең күкрәк терәп ярышкан чаклары була. Сменага унбиш тоннаны чама дип саныйлар. Ә Николай Терентьевич Мокшин уфылдамыйча утызны бирә. Шушы әгъзалы машинаны берсе дә уза алмый. Бервакыт штрекка ОМ килә. Ә икенче көнне җир астында «Мокшин ОМны җиңгән» дигән хәбәр тарала. Кеше шулай беренче җир асты экскаваторын узып эшләгән. Мәгарәдә машина белән кеше очрашкан заманда шулай булган. Ә хәзерге аждаһалар белән мәйданга чыгып кара! Берсе-берсе сменага алты йөз тонна таш төйи. Адәм баласы, көрәк, кәйләсен куеп, җиде кат җир астында шундый куәт алган.

Тәгәрмәчкә утырткан бораударны күр син! Шахтер, зиһенен куертып, тау куышындагы мастерскоендә үзйөрешле бораулау установкасы төзегән. Баш механик Андрей Солоненков, баш инженер Владимир Петруцик, баш энергетик Юрий Агафонов һәм Өмет Мөхәммәдуллин чын конструкторлык хезмәте үтәгәннәр.

Шул могҗизаны карыйбыз. Харис Гобәйдуллин һәм Анатолий Петровтан торган экипаж алтынчы штрек түшәмендә калган токымны бораулыйлар. Түшәм астында берьюлы алты бора жуылдый. Түбәнгә ярма гипс коела. Кеше машинаның эшен күзәтә, юнәлеш бирә. Шулай шәбрәк!

Инде төш тә җиткән икән. Тау цехы кешеләре ашханәдә тамак ялгарга туктадылар. Пешекче Рифа Гайнуллина тәлинкәләргә кайнар аш сала башлады. Җир асты һавасын итле токмач исе басты.

## Җилкуарлар

Җилкуар исемен ишеткәч, авыз тәмсезләнә язды. Безнең җир өстендә тырай тибүче шалапайга якты йөз күрсәтмиләр, аны әрлебирле тәгәри йөрүче дала дүңгәләге урынына күрәләр. Тере дүңгәләккә сүз әйтәсе килеп авыз ачылып тора. Бу сүзне җир астында ишеткәч тә бермәлгә аптырап калдым. Карале, дим, мәгарәгә дә тәгәрәп кергән икән. Усал сүз тамакка килеп тертелде — чыгам, көйдерәм дип атлыга. Ә баксаң... мәгарәнең җилкуарлары би-ик тә хөрмәттә икән. Мария һәм Бибинур, Зинаида һәм Александрадан, гомумән, тузан-вентиляция хезмәте кешеләреннән башка шахтерлар «эһ» тә итә алмыйлар икән. Штольнядан фәлән чакрымдагы штректа көн буе эшләп кара әле син, тының бик тиз кысылыр. Тузаны борак онығай уйнап теңкәгә тияр.

Ә монда брезент җиңсә бәргәләнә. Ул җан бирүче көлтә кебек лепердәп-сикергәләп ала. Җир астының җилкуарлары шул җиңсә белән камерага Иделнең тәмле, саф һавасын суырталар.

Һава шахтерга ипи кебек, су кебек кирәк, ул дәрт тә, көч тә алып килә. Җилкуарлар тузан, газ кебек нәмәстәкәйләрне өфертеп чыгаралар. Аннары бозылган җил-һавага мәгарә буйлап типтереп йөрергә ирек бирмиләр: чыгарыр юллары бар, капкалары бар. Капкаларның берсен ябалар, берсен ачалар. Юлың белеп йөр, янәсе, тизрәк бар җилкугыч торбасына. Тәмле һавага да, бик үк таралып-нитеп китмәсен дип, коридор ясап куялар. Шахтерга мондый һава сулап эшләве җиңел.

Кайсыдыр тау куышында утырган җилкуарлар, ягъни операторлар, эңгер кешеләренә дә саф һава әзерләп куйганнар иде. Карт мастер Иван Михайлович Лизунин шартлатучыларны бүген дә өч группага бүлде. Эш йөкләде. Үзе басмалы автомашина алып һәм Вил Галиев, Геннадий Фадеев, Вәкил Садыйков белән бергә алтынчы штрек түшәмендә калган гипс ташларын куптарып төшерергә китте.

Мәгарәгә табигый тынлык урнашты. Әйтерсең лә монда байгыш та керен карамаган. Тик кайдадыр таш арасыннан саркыган тамчы гына чултылдый. Икенче яктан мәгарә чишмәсенең саңгырау авазы ишетелә. Ул гүя шушы таш диварлар арасында кысылып калуына, җылы, сөйкемле кояшны күрә алмавына уфтана. Үзендә ташып торган дәртенә юл таба алмаган кеше дә ничектер сукрануан була: аны күрмиләр, янәсе, хәлен аңламыйлар. Янәсе, әнә ничек тибә бит аның йөрәге.

Көн саен, эңгер төшкәч, шушы шомлы тынлыкка унау керәләр. Шартлату хикмәтләрен алып һәм өчәрләп бүленеп, даладай тау цехының төрле почмакларына юнәләләр. Мастер иң җаваплы һәм хәтәр участокка бара.

Алтынчы штрек.

Карт мастер электр фонаренең яктылыгын түшәмгә юнәлдерде. Анда керәшә оясыдай шпурлар тишелгән. Шпурларның һәркайсы исәптә, һәркайсы бораулаучылар төзегән схемада күрсәтелгән. Иван Михайлович шул схеманы карап алды, аннары егетләргә эндәште:

— Әйдәгез, хәерле сәгатьтә!

Вәкил машина кабинасына керде. Вил белән Геннадий күперчеккә менеп бастылар.

Бераздан унике метрлы түшәм астына күтәрелделәр. Машина күперчегенә баскан хәлдә, шпурларга шәмгә охшатып төрелгән патронлы аммонит салырга керештеләр. Тишекләрне «кызыл шәм» белән тутыралар да кабызгыч куялар. Кабызгычлар шнур белән тоташтырыла. Ай-һай, вак эш, тамбурлап чигү чиккән кебек. Сабырлык кына җитсен, каерылган муен гына түзсен.

Мәгарә тамчысы чултылдый-чултылдый вакыт санады. Түшәм асты гипсын тамбурлап чыкканчы сәгатьтән артык узды бугай. Егетләр шөкерана кылып таш идәнгә төштеләр. Автомашина читкә алынды. Мастер, кесә фонарен төбәп, Вил белән Геннадийның эшен тикшереп чыкты. Эштән канәгать калгач, шнур сузарга һәм прожекторларны куркынычсыз урынга күчерергә кушты. Ә берничә минуттан алар, шнур сузып, күрше штрекның стенасына ышыкландылар. Геннадий Федорович бүген җаваплы дежурный иде. Ул транзистор кебек тартмалы конденсаторны корды да, нидер пышылдап, кнопкага басты.

Әйтерсең лә дөнья җимерелде.

Шартлау авазы, штрекка сыймыйча, диварларга бәргәләнә-бәргәләнә, мәгарә эченә таралды, батыр белән сугышып җан бирүче әкият аждаһасыдай иңрәп-иңрәп юк булды. Әле генә егетләр эшләгән

урында, Яңа ел кичәсенең сөйкемле кар бөртекләре кебек, гипс тузаны гына җемелди иде.

Тынлыкны башлап Геннадий бозды.

— Өйдәгеләр дә, шаять, ишеткәндер,— диде ул.— Кәстрүлләрне шалтырата башларлар.

— Сиңа аш җитештерүдәме соң уйлары. Телевизор каршында утыралардыр әле, мөгаен.

— Бүген бишенче сериясе шул. Әй, ул кызның маҗаралары. Үзе чибәр дә инде, каһәр.

Егетләр чибәр кыздан бигрәк эшләреннән канәгать, шуңа күнелле әңгәмә кузгатканнар, күрсенүләре исә күңелне очындырган шатлык белән бер иде.

— Безнекеләр беренче дөмберне көтеп кенә торалар,— диде Геннадий, гәпне дәвам иттереп.— Җир тулап тәрәзә зыңгылдадымы, димәк, бер сәгатьтән мин кайтам, димәк, чәй куя башларга ярый.

Сүзгә Вил дә кушылды. Ул каш астыннан серле генә карап елмайды да:

— Мин киткәндә үк табын әзерли калганнар ие,— диде.— Мөгаен, көтәләрдер. Туган көнем бит әле бүген, егетләр.

Барысына да берьюлы шүрәле кагылгандай булды, барысы да берьюлы рәхәт елмаеп һәй-һәйләп җибәрделәр. Барысы да сүзен әйтергә ашыкты.

— Ник алдан ук белгертмәдең, Вил Хәйдәрович?

— Котлыйбыз, дускай.

— Нишләп торасың, әйдә, сыпырт өеңә.

— Рәхмәт, егетләр,— диде юбиляр.— Тагын берне гөрселдәтәбез дә, кыенсынмасагыз, мин йөгерәм.

Икенчесе булачак гаражның ремонт мастерское урынында гөрселдәде. Вил кайтырга чыкты.

— Саубуллашмыйм, егетләр,— диде ул, борылып.— Кайтканда миңа сугылырсыз.

— Уйлап карарбыз.

Вил чыгар юлга йөгерде, ә башкалар икенче һәм өченче группага ярдәмгә киттеләр. Беравыктан еракта, группалар эшләгән унынчы һәм унберенче штреклар ягында, саңгырау шартлау авазлары ишетелде. Ул, тоташ гүелдәп, урман артындагы күк күкрәүне хәтерләтә иде.

Штрекларда тынлык урнашты. Тик каядыр куәтле вентиляторның үкереп эшләве ишетелде. Җилкуарлар шартлау булган штреклардан, үзләре салган коридор буенча, газ һәм тузан суырта башладылар. Мәгарә операторлары төнге сменага килүче шахтерлар һәм транспортчылар өчен саф һава әзерләргә тиеш.

Әңгер кешеләре дә, кичке табельчы кыз Асия Хәсәновага каска һәм фонарьларын калдырып, чыгу юлына борылдылар. Штольня авызында аларны Иделнең йомшак җиле каршылады. Ул кулларга сеңгән аммонит исен кагып төшергәндәй итте.

Бу вакытта төпсез күл суыдай кучкылланган күк гөмбәзендә йолдызлар чекерәешә, ә нечкә билле ай гүя мәгарә түбәсендәге урманга эленеп уйланып калган иде.

## Баскычлар

Иделгә көз килде. Иртә-кич елга өстендә куе томан тора. Ул томан күңелгә авыр кургаш булып тоелган суны да каплый, судноларның юлын да киртәли. Теплоходлар, баржа этүче буксирлар, хәлебезне аңлагыз дигән сыман, ачы итеп кычкырталар. Тик йөзмә кран

гына, берни дә булмаган кебек һәм чыгырларын туктаусыз шыгырдатып, штольня авызындагы складтан киң баржага гипс ташы төйи. Гипсны яр кырыена кадәр бульдозер белән эттереп китерәләр.

Тау цехыннан шахтерлар чыкты. Митингта булганнар. Аны рудникның партбюро секретаре Чыңгыз Шәймәрдәнов үткәргән. Шимбә өмәсе оештыру турында сөйләшкәннәр. Хәзер тау өстендәге поселокка кайталар. Сукмаклар яр буйлап килә дә текәлеккә төртелә. Телә-сә-теләмәсәләр дә, шунда сөялгән киң басмалы баскычлардан күтәрелергә туры килә.

Юрий Вячеславович Полетаев белән аның эш бүлмәсендә очрашканда да сүзебезне шул текә яр баскычларыннан башладык. Төгәлрәге, директор үзе кузгатты шул баскычлар турында. Күңелендәген бушату, уй-фикерләрен уртаклашу өчен.

— Олысы бар, кечесе бар. Бөтенесе дә шуннан сөйрәлеп менә бит,— дип куйды да ул борчылуларын сөйли башлады.

Әйе шул, гипсны бульдозер белән күчерергә була. Ярдан баржага кран белән ыргытасың. Ә кешеләр бит таш түгел. Кешеләрне кран чүмечендә күтәреп булмый. Алар җир асты кыясын җимереп чыгалар да, яр кырыйлап үзләре салган сукмак белән баскычка киләләр. Басмасына басасың — шыгырдап куя. Икенчесенә күтәреләсең — тагын ыңгыраша. Нишләмәк кирәк, кеше тез буыннарын калтырата-калтырата саный менә: өч йөз алтмыш дүрт басма — шул кадәр сыкрану. Култыксаларга тотынып менгән шахтер өчен баскычның озынлыгы шул сыкрану белән исәпләнә түгелме соң?

Юрий Вячеславович тынып калды. Бераздан, кисәк кенә талпынып, алдындагы ниндидер кәгазьләрне кырыйга этәреп куйды. Кыска, юантык бармакларын тырпайтып, уч төбе белән күзгедәй ялтыраган өстәлгә шапылдатты һәм, алмасарлыктан котылгандай, әйтеп салды:

— Бик вакыт баскычны бульдозер белән төрттерергә. Асылмалы юл кирәк. Ансыз кешеләрнең рәхмәтен ишетә алмассың.

Кара, нинди шәп буласы икән. Тау шуган кебек кенә төшәсең. Иделкәйнең бөтен матурлыгын карый-карый, күңелең белән хәтта каршы ярның нарат урманына үрелеп һәм бетмәс ләззәт алып күтәреләсең. Талуларың сизелмәс була...

Чишелеп киткән Юрий Вячеславовичның сөйләвен тыңлыйм да ниндидер бер канәгатьләнү кичерәм. Кеше үткән эзне югалтса, бик кирәкле мәсьәләне хәл иткәндә әйле-шәйле, алмасар булып йөрсә, чын җитәкче булыр идеме? Эзен югалткан — адашкан, ал маякны күрмәгән — юлдан язган. Полетаев үлчи, исәпли белә. Үз чамасын белеп, коллектив мөмкинлеген күреп эш итә.

Рудник та текә баскычның басмаларын шыгырдатып күтәрелгән. Җитмеш ел элек, тирә-як авыллардан килеп ялланган крестьяннар Большаков заводының учагын кабызгач, гипсны яшәү хакына, тамак хакына кәйләләр белән чокыганнар. Большаков алебастр белән Мәскәү базарына җиткән, сезонлы эшләүче крестьянның азаплы хезмәтенә ун тиен түләп кесә калынайткан.

Завод совет кулына күчкәч, кәйләне корыч борау белән алыштырганнар. Ярдәмгә аммонит килгән. Кеше уйланган. Дизельле станция корып, кул боравын электр боравына алыштырган. Тачка урынына атлы вагонетка кергән. Тагын бер баскыч күтәрелгәннәр.

Дәүләт электр линиясеннән көчле егәрлек, куәтле автомашина һәм электрлы төягечләр кергәч, эш тагын да җайлана төшкән. Ләкин проблемалар кала. Ансыз тормыш юк, үсеш юк. Үз биләмәсендәге проблемаларны барлый һәм ил ихтыяҗларыннан чыгып күрә белмәгән җитәкче күкрәк кага алмый. Хакы юк батыраерга. Җитәкче булырлык дәрәҗәгә күтәрелмәгән ул.

Юрий Вячеславовичны кул хезмәтенең яшәве борчый. Шахтерлар электр бораууларын кул белән кысып жуылдаталар бит. Азаплы бу хезмәт. Ләззәте аз аның. Бик аз! Карьер хуҗалыкларына, рудникларга заманча камилләшкән куәтле машиналар, бер үк урыннан торып горизонталь һәм вертикаль бораулаучы установкалар кирәк. Шул куәтне иҗат итәргә кайсы конструкторлык бюросы, кайсы завод алына? Бүген тел дә ачма. Чөнки сериягә куя алмыйсың. Чөнки илдә мондый рудниклар санаулы, елга күп дигәндә бер дистә машинага ихтыяҗ булыр. Кемгә йөкләсең шундый кыйммәт эшне? Ә йөкләргә кирәк. Иртәме-соңмы йөкләрләр аны.

Ул өметен ышаныч белән әйтте дә, монысы да калмасын дигән кебек, күңелен тырнаган бер шиген бәян итте.

— Ә бүгенгә рудник осталары төзегән машина белән эшлибез,— диде.— Тау куркынычсызлыгы хезмәткәрләре ни әйтер. Алар катгый халык.

Директор мәгарәдә без күргән күчмә установка турында сөйли иде. Рудникның инженер-техникларында үзе фикер уяткан. Тегеләре җир асты мастерскоенда төзеп-монтажлап куйганнар. Завод-анасы булмаса да, исем кушылган: СБУ-76 — «үзйөрешле бораулау установкасы», җитмеш алтынчы елда төзелгән, димәк. Ә беренче установканың туган елы — җитмеш. Хәйран эшлиләр. Берьюлы алты бораy белән вертикаль шпурларны шытырдаталар гына. Чын иҗат җимеше: сериягә куярсыңмыни!

Сүз уңаенда бүлмә белән танышам. Җиһазлы. Стенада директор өчен махсус эшләнгән диаграмма бар. Үсеш юлын, күпме гипс әзерләнүен күрсәтә.

Стена буендагы шкафны карыйм. Шүрлегенә гипс ташы үрнәкләре куелган. Кар кебек аппагы бар. «Синяк» күренә. Мәрмәр плитә итеп шомартылганы ята. Тау токымыннан табып алынган ниндидер җәнлекнең баш сөяге дә директор коллекциясенә эләккән. Шкаф өстендә Юрий Вячеславовичның шахта-рудниклар гизгән каderле каскасы да тора. Бәхетле кашык та, мөгаен, ерак түгелдер, ял көнен көтәдер.

Ә күрше бүлмәдән директор урынбасары Җәүдәт Хәйруллинның телефон трубкасына өзеп-өзеп кычкырганы ишетелә: «Мәскәү. Мәскәү». Ул шулай башкала белән гипсны җибәрү юлын, транспорт мәсьәләсен ачыклый. Ә Идел гипсына ихтыяҗ зур, ул илнең күп шәһәрләренә китә. Соңгы елларда гипс юлы тагын да озайды: мәгарә чималын төягән суднолар Совет иле флагы астында Скандинавия илләренә чыга. Валютага китә Иделкәем гипсы, илне баета!

Җитмеш алтының декабрендә директорны Мәскәүгә, товарлар экспортлау советы утырышына чакыралар. Дөньяны күп таныган белгечләр Идел ташы турында да сүз алып баралар. Иделкәйнең ак ташы валюта товарына яраклы дип бәяләнә. Илнең эчке ихтыяҗларын башка карьерларга йөкләп, Кама тамагы гипс руднигы әзерләгән ташны тулысы белән дөнья базарына кую турында карар кабул ителә. Швеция, Финляндия, Норвегия, Дания фирмалары күпләп заказ бирәләр. Рудник ил каршында яңа баскычка күтәрелә.

Юрий Вячеславович тартмадан калын папка алып өстәлгә куйды. Тышына эре итеп «Экспорт» дип язылган. Телеграммалар «Кама тамагы руднигы, Полетаев» исеменә ява...

Без урамга чыктык. Инде шахтерлар поселогында ут алынган, ә астагы йөзмә кран, чыгырларын шыгырдатып, Иделкәйнең ак ташын баржага төйи иде.

## Мәдинә Маликова

# КАМЧАТКА ЕРАК ТА, ЯКЫН ДА

Камчатка сүзен ишетүгә, ут һәм төтен атып торган янартаулар, кайнар чишмәләр, гейзерлар, яз көннәрендә елгаларга сыймый, ярларга ташып чыккан кыйммәтле кызыл балыклар, шул балыкларны тәпие белән аулап торган көрән аюлар күз алдына килә.

Дөрес, китап-белешмәләр Камчаткада балык һәм урман промышленностеның үсеше, бәрәңге һәм кәбестә уңышының артуы (Камчаткада иген чәчмиләр), Петропавловск-Камчатскийның 250 мең кеше яши торган зур кала икәнлеге, анда драма театры, пединститут, музейлар, техникумнар, музыка мәктәпләре барлыгы турында сөйлиләр. Хуҗалык һәм культура өлкәсендәге уңышлары өчен Камчатка өлкәсе — Ленин ордены белән, ә Петропавловск-Камчатский шәһәре Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән булуын да беләбез.

Ләкин үзең анда барырга чыккач, күңел болар белән генә ризалашмый. Ни дисәң дә, җир чите бит ул! Ил-62 самолеты анда тугыз сәгать оча. Илдәге иң зур авиалиния буйлап шунда хәтле барып җиткәч, моңарчы күрмәгән-ишетмәгәнне күрәсе иде.

Беренче карашка җир чите күз күнеккән күренешләр белән каршы ала. Казандагыдан кечерәк, Бөгелмәдәгедән зуррак яңа аэропортта халык айкала, шәһәргә китә торган автобусларда тыгынлык. Бездәгечә үк, гостиницаларда урын булмый. «Авача» гостиницасының икешәр кешелек, душлы, кайнар сулы номерына урнашу өчен алдан ук хәбәр итеп куярга кирәк икән.

Кайда соң монда экзотика, кайда романтика?

«Камчатская правда» газетасы редакциясендә мине күптәнге танышлары кебек каршы алдылар. Минем Татарстаннан икәнемне белгәч, журналист Александр Петров:

— Беләбез, беләбез,— диде.— Сезнең якташыгыз Энәс Галимов бездә редактор урынбасары булып эшли. Эш белән чыгып китте әле. Мин үзем дә татарлар белән аралашып үскән кеше. Чиләбе өлкәсенең Пласт шәһәреннән бит мин, бәләкәй чакта татарча бик яхшы белә идем.

Ул арада бүлмәгә нык бәдәнле, ачык чырайлы, гади генә бер ир кеше килеп керде. Әле генә Беринг атавыннан килеп төшкән икән. «Алеут йолдызы» дигән район газетасының җаваплы секретаре Юлий Александрович Арбитжер.

Беринг атавыннан? Мин ашыгып-кабаланып аның турында укыганнарымны искә төшерергә тотынам. Томанлы Командор атаула-

ры... Анда кояш бик сирәк чыга. Андагы комлы ярларда диңгез мәчеләренең чакрымнарга сузылган ятаклары бар.

Ә Арбитжер Казан турында сөйли:

— Казаннанмы? Беләбез Казанны. Без андагы мех комбинатына диңгез мәчеләренең тиреләрен җибәреп торган идек.

«Шушымыни инде җир чите? — дим мин эчемнән генә.— Кая соң аның ачылмаган серләре? Кайда шул серләрне яшергән җиде ябык капкасы, шул капка төпләренә сакчы булып баскан, кеше җиңә алмаслык кыенлыклары, шуларны җиңү өчен җанын фида кылырга әзер торган ашкын күңелле кешеләре?»

Кайчандыр бу калага нигез ташын мәшһүр Витус Беринг салган. Аңа исем дә Беринг экспедицияләренең кораблары «Изге Петр» һәм «Изге Павел» хөрмәтенә кушылган. Шәһәр капкасы урынында ике багана басып тора, аларның башында ике кораб. Ул корабларның җилкәннәре океан җилләреннән мәңге киерелмәслек һәйкәл булып кына калганнар микәнни инде?

Урамга чыксам — кара буран купкан: җепшек карны биткә янгын сүндерүчеләр насосыннан сиптерәләрмени!

— Менә, чын Камчатка көне инде бүген,— ди Саша Петров.— Циклон килде.

— Озаккамы инде бу?— дип сорыйм мин.

— Кем белә. Бәлки өч көннән туктар, ә бәлки атна буена сузылыр.

Бәхеткә каршы, иртән торуга буран тынган иде. Урамнарда халык юлларны, баскычларны биек көртләрдән әрчи иде. Яшькелт-зәңгәр Авача култыгында вак, ак дулкыннар йөгерә, Ленин урамының бер ягын хасил иткән причалларда һәм култык уртасында—кораблар тора. Карлы түбәләре белән иртәнге кояш нурларын беренче булып тотып алган, линейка белән сызгандай туры, текә күкрәкле сопкалар ирексездән күз карашын үзенә тарта иде. Буяулар ачык, кискен, һава саф, якты иде.

Бу иртәдә мин Камчатканың, чыннан да, башка бер җиргә дә охшамаганча, үзенчәлекле җир икәнен күрдем. Романтиканы йөгереп үтеп барышлый, өстән генә эзләү ярамаганын, ком, балчык катламнары астындагы асылташларны күрә белгән геолог шикелле, мондагы тормышның мәгънәсен, тирән катламнарын күрергә, кешеләрнең күңелен, омтылышын бөтен катлаулылыгы белән өйрәнергә кирәклеген аңладым.

Тирәнрәк үтеп кергән саен, бу яктагы кешеләрнең эшчәнлеге һәм язмышы белән бөтен ил язмышы арасында күбрәк бәйләнеш күрдем, үзем өчен күбрәк үрнәк һәм гыйбрәт алдым.

## Балыкның да саны бар

Камчатканың иң зур байлыгы — балык. Балыкны Тын океанда, Беринг һәм Охот диңгезләрендә төрле оешмалар, колхозлар тота.

Петропавловск-Камчатский шәһәре янында Сероглазка (Күккүз) исемле поселок бар. Бу поселокта яшәүчеләр Ленин исемендәге балык тоту колхозына берләшәләр. Поселок Авача култыгы буена, сопка күкрәгенә урнашкан, анда катлы-катлы торак йортлар, яңа мәктәп, ике катлы идарә бинасы, культура сарае — кыскасы, бай хуҗалыкларда була торган бөтен нәрсә бар. Диңгезләр, океаннар айкап кайткан кораблар колхозның үз пирсына кайтып туктыйлар. Колхозчылардан йөзгә якын кешенең үз машинасы бар, бик күпләр Авача култыгын һәм Паратунка елгасын үзләренең моторлы көймәләре һәм глиссерлары белән иңләп-буйлап йөриләр.

Бу байлыкларның барысын да балык китергән. Ә Сероглазка кешеләре балыкны эзләп табарга да, тотарга да гаҗәп осталар!

Председатель урынбасары Владимир Васильевич белән партоешма секретаре Александр Иванович Сафатов утыз милләт кешеләре арасында татарларны да — капитан Җәмил Хөснетдиновны, кораб врачы Дамир Хәбибуллинны, агач эше остасы Кашшаф Габдрашитовны мактап телгә алдылар. Елмаешып, шуны да өстәделәр, Кашшаф аш пешерергә дә хәйран оста икән, капитаннар аны үзләре чакырып торалар икән.

Бөтен илдә муллыгы белән дан тоткан бу колхоз турында, аның уңган кешеләре турында гел мактау сүзләре генә язасы килә. Владимир Васильевичның кабинет тәрәзәсеннән күренеп торган Авача култыгының гүзәллеген, аннан чыгып киткән корабларның озын юлларын Камчатканың кичке шәфәгы төсле ачык-алсу, сары-кызыл буяулар белән тасвирлыйсы килә. Әмма колхозчыларның да, Владимир Васильевич белән Александр Ивановичның да йөзләре җитди һәм кырыс. Алар фикеренчә, бүгенге көндә мактанырга җитәрлек нигез юк, чөнки колхозның кереме кими, план тулмый, диңгезләрдә балык азәйгән.

Әле күптән түгел генә без барыбыз да диңгездәге балыкны исәпсез-хисапсыз итеп күз алдына китерә идек. Аны чәчәсе дә, карап үстерәсе дә юк, әзер уңышны җыеп алырга гына кирәк дип уйлый идек. Хәтта балыкны ничаклы күбрәк тотсаң, ул шул кадәр күбрәк үрчи дигән караш та яшәп килә иде. Аны тоту, эшкәртү-тозлау, туңдыру, консервлау, ыслау, ашламага яки терлек азыгына он итеп тарту өчен яңадан-яңа кораблар, йөзмә базалар, комбинатлар, заводлар салынды һәм бу тәзелеш хәзер дә дәвам итә.

Мин үзем Петропавловскидагы балык комбинатының дүрт катлы итеп салынган өр-яңа цехларын карап, аларның яктылыгына, иркенлегенә, уңайлыгына хәйран калып йөрдем. Цехлар шәп, тик аларны бөтен көченә эшләтергә чимал җитенкерәмәве сизелеп тора иде.

Ә менә элеккерәк елларда тотылган балыкны эшкәртеп өлгерергә йөзмә базалар һәм комбинатларның көч-куәте җитми иде. Балыкчы диңгездә сөякләре шыгырдаганчы эшләргә ярата, планны арттырып үтәргә тырыша: трап-ятьмәләр бер салганда балыкны көтүе белән — бишәр тонналап берьюлы палубага күтәрәләр, трюмнарга көмеш кебек елкылдап тере балык елгасы агыла. Капитан, куанып, җыйган уңышны эшкәртүче базаларга тапшырырга ашыга. Ләкин аның кебек уңганнар тагын да бар икән. База янында балык тапшырырга чиратка башка кораблар тезелгән. Кайчак, чират килеп җиткәнче, трюмдагы балык үзенең тиешле кондициясен югалта. Аны диңгезгә ташларга туры килә. Балыкчы күңеле сызлый сызлавын, әмма ул үзен, әлеге дә баягы шул, балыкны ничаклы күбрәк тотсаң, шул кадәр күбрәк үрчи дигән фикер белән юата да, көрсенеп, яңадан диңгезгә ашыга. Планны үтәргә, рекордлар куеп, ярышта беренчелекне яуларга тели ул. Балыкчыларның кайсы белән сөйләшсәң дә, бу хакта әрнеп һәм сызланып әйтелгән сүзләрне ишетәсең.

Алай эшләргә ярамаганын һәркем аңлый, әлбәттә. Кимчелекләрне бетерү чаралары күрелде — балыкны тоту белән үзе үк туңдыратозлый торган траулерлар, йөзмә базалар күбәя барды. Ләкин көннәрдән бер көнне Охот диңгезенә сельдь балыгы тотарга килгән кораблар буш әйләнеп кайттылар. Күпләрне аптырашта калдырды бу хәл: кая киткән ул балык?

Тикшерә башладылар һәм ачыкладылар: балык дигән җан иясенең дә үз көе, тормышының үз җае бар икән. Диңгездә аның үрчи торган урыннары, үсә, симерә торган төшләре бар икән. Суга кире ташланган балык боламыклары, төптән сөйрәлеп йөри торган траплар

ул урыннарны балык үрчү-үсү өчен яраксызга әйләндергән икән. Шуның өстенә, сыдырып тотып торганда, балык үсеп җитәргә өлгерми икән. Элекке карашларны үзгәртергә, диңгезләрдә балык муллыгын саклап калу өчен чаралар күрергә туры килгән. Хәзерге вакытта Охот диңгезендә һәм Беринг диңгезенең ярга якын суларында сельдь тоту тыелган. Балык үрчү һәм үсү урыннарын саклау чаралары күрелә, диңгез балыкларының чирләрен ачыклап, аларны дәвалау юнәлешендә гыйльми эзләнүләр алып барыла. Элеккерәк елларда диңгездәге балык та чирле торгандыр, аны дәваларга кирәк дигән уй кемнең башына килгән!

Ленин исемендәге колхозның 35 корабы да, башка кораблар белән бергә, путинага [1] китәләр. Ләкин алар элеккечә сельдь, лосось, треска, камбала түгел, лимонелла, минтай кебек моңарчы табыннарда күренмәгән балыклар тота башладылар.

Тәрәзәсеннән зәңгәр һәм иркен Авача култыгы күренеп торган кабинетта менә шулар хакында сүз барды. Колхоз җитәкчеләре бу хәлләрне ачынып, үзләрен гаепле санагандай сөйләделәр.

Хәзерге вакытта уылдык чәчү чорында кыйммәтле балыклар берәмләп диярлек санала, аларның бер өлешен тоталар, үрчү өчен кирәк кадәресен елга тамакларына таба уздырып җибәрәләр. Бу эш фәнни нигезгә корыла, елга буйларында балык үрчетү заводлары салына.

Бездән бик еракта, җир читендә кузгалган бу мәсьәләләр безнең тормышыбызга да якыннан кагыла. Бу багланыш тозлы селедканы барыбыз да яратып ашаганы һәм балыкның кунак табынында да, көндәлек өстәлдә дә үз урыны, кеше организмы өчен кирәкле һәм файдалы ризык булганы өчен генә дә түгел. Шулай ук һәр атнаның чәршәмбесендә илнең барлык ашханәләрендә (шул исәптән Камчаткада да) балык көне игълан ителгәнгә дә түгел. Эш шунда ки, кеше белән табигатьнең үзара мөнәсәбәтенә Камчатка бик ачык һәм гыйбрәтле мисал булып тора.

Әйдәгез, үз җиребездәге табигать байлыкларына борылып карыйк әле. Бездә дә бит торналарны, аккошларны, тургай-бытбылдыкларны санаган кеше юк иде. Алар кимегәннән-кимеделәр, ләкин моңа безнең җаныбыз нык әрнемәде. Табигатьнең теле юк, кешене алдан кисәтеп куймый ул, ләкин үз законнары белән санашмауны, үз биләмәләренә тупас рәвештә бәреп керүне кичерми һәм аның җавабы бик кискен һәм аяусыз була.

Тәрәзәсе Авача култыгына караган кабинетта мин менә шул турыда да уйладым. Үткәннәргә аек карап, киләчәк хакында җитди уйланган, табигатьтә булган үзгәрешләр өчен үзен шәхсән җаваплы санаган кешеләр бездә дә күбрәк була барсын иде дигән теләк туды. Дөресрәге, һәркайсыбыз җир-суның һәм һәртөрле тереклекнең киләчәге өчен борчылып, кайгыртып яшәсәк иде.

## Камчатканың «ак тап»лары

Шулай ук җир читендә дә әлегә кадәр кеше аягы басмаган, тикшерелмәгән, өйрәнелмәгән урыннар калмаганмыни инде дип сораучылар булыр. Хыялый күңелле кешеләрнең, бигрәк тә яшьләрнең, аркасына биштәр асып, таякка таянып, чытырман-сазлыклар, биек таулар аша иң беренче булып узасы, карталарның моңарчы ак калган урыннарына үз куллары белән үзе ачкан күлләрне, тау-үзәннәрне зәңгәр, коңгырт, яшел буялар белән буяп куясы килә. Тире киемнәр киеп, этләр җиккән нарталарда, кара бураннар аша билгесезлеккә ашкынган тәвәккәл сәяхәтчеләрнең образлары аларның төшенә кереп йөдәтә.

[1] *Путина — балык тотуның бер чоры.*

Заманнар нык үзгәрде хәзер, шулай да бу кешеләрнең дәртен сүндерергә иртәрәктер әле. Дөрес, хәзерге вакытта эт җиккән нарталарда йөрүче сирәк, эт белән барып җитәрдәй урыннарга да вертолет очыралар. Ләкин «ак тап»лар әле бар Камчаткада, бар. Мәйданына берничә Европа иле сыярлык зур ярымутрау бит ул. Күп төрле ул Камчатка — төньягында тундра, уртасыннан янәшә ике тау сырты сузыла, алар арасында куе ылыслы урманнар, кырлар, Охот диңгезе ярында үзәнлекләр, Тын океан ярларында сопкалар. Һәм бу җир буйлап беренче булып сәяхәт кылучылар да бар. Мин шуларның берсе — Рәүф Әминович Бикмаев белән таныштым.

Рәүф Әминович Мордовиядә туып үскән, 1958 елда Казан университетын тәмамлаган, хәзерге вакытта Камчаткадагы геологик экспедициянең баш инженеры булып эшли. Бөтен өлкә буйлап таралган 22 геологик партиянең әзерлекле булуы, техника белән тиешенчә тәэмин ителүе, нәтиҗәле эшләве өчен җаваплы кеше. «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнгән.

Күп еллар геологик партияләрнең җитәкчесе булып, Камчатканың шактый өлешен җәяү йөреп чыккан ул. Иң зур горурлыгы — алтын ятмаларын табып, аның күләмен билгеләп, тикшерүләрнең тулы комплексын башкарганнан соң, ул файдалы казылмаларның чыгарылуын һәм халык хуҗалыгына тапшырылуын күрү.

Романтикларны сәяхәтчеләрнең, геологларның башыннан үткән көтелмәгән хәлләр, истә калырлык вакыйгалар кызыксындыра. Билгеле инде, мин Рәүф Әминовичтан шулар хакында сорадым.

— Була инде андый хәлләр,— диде ул.— Һәм аларның һәркайсыннан үзең өчен бик мөһим нәтиҗә чыгарып куясың...

Рәүф Әминович табигать белән ялгызы калып сөйләшергә, серләшергә ярата икән. Камчаткада җәй кыска була: май ахырында гына кар эри, октябрьда янә ява башлый. Әмма көзен, август урталарында ул гаҗәп матур була: шеломайник, абага үләннәре кешене күмәрдәй биек булып үсеп җитә, урман аланнарында кара бөрлегәннән татлырак җиләк — жимолость пешә. Шуның өстенә җылы кояш, саф һава, чиста елгалар, тук аюлар, боланнар. Геологка аның таш-туфрагы да мең төрле серен әйтеп кала бит.

— Чүкечемне ала идем дә, тирә-юньне ялгызым әйләнеп кайта идем,— дип сөйли Рәүф Әминович.— Шулай бер заман йөргәндә күрәм: сопка үреннән киштә сыман булып гранит кисәге тырпаеп тора. Андыйны кулы белән тотып, чүкече белән китеп карамыйча геолог җаны ничек түзсен соң! Менеп киттем үрмәләп. Тотынган гына идем, әлеге таш урыныннан купмасынмы! Орынганны көтеп кенә торган икән. Миңа читкә сикерергә кирәк иде, ә мин, куркудан башым эшләмичә, аска чаба башладым. Мин йөгерәм, артымнан лавина килә — ташбалчык агып төшә. Аңыма килсәм, бер чокырда ятам, өстемнән түшәм ясап, теге гранит каплап куйган. Кымшанып карыйм — бәхетемә каршы, бер җирем дә сынмаган, имгәнмәгән. Кул-аяклар сыдырылган да, баш кына бераз миңгерәйгән. Шул вакыйгадан соң мин кагыйдәләргә ихтирам беләнрәк карый башладым. Кагыйдә буенча, геолог ялгызы йөрергә тиеш түгел.

Ярый, анысы инде геологның үз саксызлыгы аркасында, аяк астыннан килеп чыккан бәла булган. Бу якларда аның күге дә тыныч түгел бит әле!

Бер көзне Камчатканың төньягында аларның партиясен кар басып киткән. Партия инде җәйге эшләрен тәмамлап шәһәргә кайтып китәргә җыенган булган. Ләкин өлгерми калганнар, һич көтмәгәндә, Октябрь бәйрәме алдыннан циклон килгән.

— Өстебезгә бер метр калынлыкта кар салды, беркая чыгып булмый. Монда кар көпшәк, җепшек була.— Рәүф Әминович ул чакта

кичергәннәрен исенә төшереп, күрсенеп куя.— Безнең ашарга беткән, итекләр тишелгән, өстәвенә рация эшләми. Ә буран инде атна буе котыра, туктарга да уйламый кебек. Болай булса безне беркемнең дә таба алмасын белеп торабыз.

Беркөнне җил улавы аша баш өстебездә таныш гөрелте ишетелде, аннары палаткабыз янына вертолет килеп төште. Безне эзләү өчен төньяктан полярникларны, коткаручыларны чакырып китергәннәр икән. Шуларның берсе эзләп тапкан. Үзеңнең кадерле кеше икәнеңне тоюшул хәтле күңелле, ил хакына, кешеләр хакына таулар-ташлар актарырдай буласың.

Рәүф Әминович хәзер зур җитәкче, инде гаиләсеннән озакка аерылып торасы да юк, ике баласын тәрбияләүгә күбрәк игътибар бирә ала. Ләкин һаман кыр партияләрен сагына икән әле.

— Җәй җитсә, күңел алгысый башлый,—ди ул.—Үзең йөрү, үзең күрү, җир байлыгын үзең табу, бөтенесен үз кулың белән эшләү рәхәт. Әнә, безнең Зәбих Абделхакович Абдрахманов кебек булсаң иде!

Зәбих Абделхакович утыз елдан артык Камчаткада казылма байлыклар эзләгән, геологлар арасында зур абруй казанган. Хезмәт Кызыл Байрагы орденына лаек булган. Инде олыгайгач, кешеләр пенсиягә чыгу турында хыяллана торган яшькә җиткәч, Алжирга, Сахара чүленә киткән! Кое суыннан чыгып, кызган табага баскандай, дымлы салкыннан эссе комга! Түзә бит геолог дигәнең! Түзә генәме, кеше эшли алмаганны башкарып чыга. Геолог Абдрахманов эссе ком астында алтын ятмалары эзләп тапкан. Үзе һаман, Камчатканы сагынам, шунда әйләнеп кайтам әле, дип яза икән.

— Шундыйларны күргәч, минем дә иң мөһим ачышларым алдадыр әле дигән ышаныч туа,— ди Рәүф Әминович.

Өлкән буынга алмашка яшьләр үсә. Әле менә бер партиядә Казан университеты студенты Шамил Хәсәнов практикада булып киткән. Белемле, күркәм холыклы, тырыш, уңган студент геологларга бик ошаган, укуыңны тәмамлауга эшкә безгә кил дип, аны чакырып торалар икән.

Кыскасы, романтиклар кирәк, аларга эш күп әле Камчаткада.

## Җиде кат җир астын күреп

Вулканолог. Янартауларны өйрәнүче галим. Сирәк очрый торган һөнәр бу. Бүгенге көндә иң романтик, иң кызыктыргыч профессия.

Вулканнарны өйрәнү буенча дөньяда иң зур гыйльми учреждение — вулканология институты — Петропавловск-Камчатскийда урнашкан. Аның дүрт катлы озын бинасының еш уелган тәрәзәләреннән өч вулкан — Коряк, Авача, Козельский вулканнары күренеп тора. Текә күкрәкле, очлы башлы пәһлеваннар, җитәкләшкән балалар кебек, итәкләре белән бер-берсенә тоташканнар. Алар каланың кабатланмас бизәге, бу як табигатенең күрке булып, каян карасаң да, карашны үзләренә җәлеп итеп торалар. Аларның күкрәкләрендә болытлар сыенып ял итә, кайвакыт болыт пәрдәсе, җирдән аерылгач та, бөтенләй үк күтәрелеп китә алмыйча, ярты юлда тукталып кала да, сопкаларның биленә күксел шәл урагандай итә: аларның карлы түбәләре нурга күмелгән килеш кала, итәкләрендә күләгә ята. Сопкалар иртәнге кояш нурларын иң беренче булып тотып алалар һәм кичке шәфәкъ яктысын үзләреннән бик озак җибәрмиләр. Ул яктыда сопка түбәләреннән күгелҗем томан күтәрелгәне күренә. Бу — томан түгел, җир сулышы, вулкан авызларыннан чыккан пар һәм төтен...

Бу вулканнар фонында институтның эшчәнлеге аеруча зур сергә уралган сыман булып тоела.

Бүгенге көндә институтта 130 фәнни хезмәткәр эшли. Аларның ал-

тысы — геология-минерология фәннәре докторлары, илле биш кеше — фән кандидатлары.

Институтны хәзер бөтен дөнья белә. Мондагы галимнәр Толбачик вулканы янында яңа вулканнар атачагын алдан ук әйткәннәр, аның урынын һәм вакытын билгеләгәннәр.

Табигать галимнәрнең сүзен раслады. 1975 елның июнендә, билгеләнгән урында җир ярылып, бер-бер артлы өч урыннан ялкын бөркеп чыкты, ком, туфрак, сөрем баганалары дистә чакрым биеклеккә күтәрелде, күктән таш яуды, эрегән таш — лава елгалары акты, тигез җирдә өч яңа сопка пәйда булды.

Сирәк була торган бу дәһшәтле күренешне күзәтергә чит илләрдән галимнәр, хәбәрчеләр килде.

Табигать галимнәрнең кыюлыгын, көчен, белемен сынарга, аларның мәгълүматларын арттырырга сүз биргән диярсең.

Бу күренешне үз күзләре белән күргән кешеләр айлар үткәч тә айный алмый, шаккатып сөйлиләр, кичергәннәрен тасвирлап бирә алмаудан гаҗиз булалар. Мин очраткан кешеләрдән бары берәү генә бу хакта бик тыныч итеп, бер дә исе китмәгәндәй итеп сөйләде. Ул да булса геология-минерология фәннәре кандидаты, вулканолог Фәрид Кутыев иде.

Камчатка кешеләре үзләренең итагатьле, тәрбияле булулары белән, үз-үзләренең дәрәҗәсен яхшы белүләре белән аерылып торалар. Алар ачык йөзлеләр, һәр сүзне җиренә җиткереп, тәмләп әйтергә яраталар, пөхтә киенәләр, алар арасында арыган-талчыккан, ашыккан-кабаланган кеше сирәк күренә.

Фәрид Кутыев сабырлыгы, төгәллеге, интиллегент кыяфәте белән хәтта алар арасында да аерылып тора. Модага туры китереп түгәрәк сакал үстергән, озынча йөзле, нурлы коңгырт күзле, биек, туры сынлы бу ир-егет шактый яшь әле — утызны гына узган.

Фәрид Мордовиядә туган, Ленинградта үскән, укыган. Аның этисе Шакирҗан абый, гражданнар сугышы елларында ятим калган бала, үсеп белем алган, геолог булган. Ул илнең төрле өлкәләрендә дә, чит илләрдә дә казылма байлыклар эзләүдә катнашкан. Сугыш вакытында чолганышта калган Ленинградта кое казу өчен су ятмалары эзләгән, аннары полк комиссарлары мәктәбен тәмамлап, алгы сызыкка киткән. Тыныч еллар әйләнеп кайтуга, тагын экспедицияләр, озак-озак аерылып торулар. Кечкенә Фәрид этисенең дала җилләре исен алып кайтканын зарыгып көткән. Ул биргән ташларны, ул күрсәткән фоторәсемнәрне кызыксынып караган. Камчатка турында да беренче тапкыр ул этисеннән ишеткән, аның Авача култыгы, янартаулар турында, Паратункадагы кайнар күлләрдә коенуы турында сөйләгәннәрен тылсымлы әкият сыман итеп тыңлаган. Үсә төшкәч, ул, этисенә ияреп, якынрак экспедицияләргә дә чыккалаган. Кыскасы, дөньяның зур, җирнең күп төрле, хикмәтле икәнен кечкенәдән белеп үскән Фәрид.

Бу урында Шакирҗан абый улының үзенә алмашка үсүенә, этисе һөнәрен сайлавына бик куанган дип дәвам итәргә кирәк иде шикелле. Ләкин тормыш кагыйдәләргә сыймый, кеше күңеле дә тирән, катлаулы. Шакирҗан абый улының тынычрак һөнәр сайлавын теләгән. Мыек чыгып килә торган яшь егет исә, этисенең сүзенә каршы килеп, Ленинград университетының геология факультетына кергән.

— Ул чакта үзеңне бик акыллыга санийсың бит, эти-әни фикере белән исәпләшеп торасың килми, — ди Фәрид.

— Ник алай дисез, геолог һөнәрен сайлап ялгыштым, дип уйлыйсызмы әллә?

— Эш анда түгел. Бүгенге акылым булса, этиемне аңларга тырышыр идем, ныграк уйланыр идем.

Университетны тәмамлагач, Фәридне аспирантурада калдыралар. Ул анда петрография — ташларны өйрәнү фәне белән шөгыльләнә. Геологик экспедицияләр белән Карелиядә, Уралда, Тянь-Шаньда, Байкал буенда, Колымада, Тын океан буйларында була, файдалы казылмалар эзләүдә катнаша. Борынгы вулканнар белән кызыксына башлый. Шул уңай белән Камчаткага фәнни киңәшмәгә килә, аны вулканология институтына эшкә чакыралар.

Шулай итеп, Фәрид турында, әтисе юлыннан китте, дип әйтергә ярыйдыр. Ләкин яшь буын өлкән буынны кабатлап кына калмый, ул ераграк атларга, акылы, карашы белән тирәнрәк үтеп керергә, күбрәкне аңларга тиеш. Табигатьнең бу законын Фәрид үз тормышы белән раслый.

Аның романтикага карашы да бөтенләй башкача, үзенчә.

Әйтик, менә мин геологларны җилдән-кояштан бөтен тәне каралган, черки талаудан шешенгән, тузан баскан, куллары көрәк кебек тупасланган, биштәр асып йөреп аркасы бөкрәйгән, якыннарын сагынып йөзләре саргайган, тамагына юньле ризык ашамаганга, ябыгып хәле беткән итеп күз алдына китерә идем! Андый геолог бозлы суга да бата, янган урман эчендә дә кала. Үзе җан ачысы белән җир казый, чокырлар белән тау буйларын ермачлап бетергәч, ниндидер таш табып, сөенеченнән кыргыйларча бии, сикерена...

Шулай булгандыр элегрәк, Шакирҗан абыйлар заманында, геологлардан нәкъ шундый түземлек, фидакарьлек таләп ителгәндер. Шакирҗан абый улының геолог һөнәрен сайлавына каршы килгән икән — моның сәбәбе «романтика»ның шул яклары булмадымы икән әле!

Ә менә Фәрид — ак йөзле, пөхтә, үз-үзен караганы әллә кайдан сизелеп торган Фәрид — зур ышаныч белән:

— Геолог комфорт ярата,— ди.

Кырда, палаткада нинди комфорт, нинди уңайлык?

— Геолог уңайлыкны үзе ясый ул,— ди Фәрид.— Иң беренче эш итеп палатканы куяр өчен коры, ышык урын сайлый. Аның ягулыгы да, чиста суы да, азык-төлек сакларга карлы чокыры да янында гына булырга тиеш. Ә учак ягу, ялкынга карап утыру — үзе бер җан рәхәте бит ул.

Шәһәр квартирында чакта Фәрид үзен бу рәхәттән мәхрүм итәргә теләмәгән: ул кухнясында кирпечтән менә дигән камин ясаган, аның капкачларын, чүплек башыннан табып кергән бакыр калайлардан челтәрләп, борынгы бай йортларындагыча затлы итеп уеп эшләгән.

Гомумән, Фәрид дөньяның бер рәхәтеннән дә үзен мәхрүм итәргә ашыкмый. Аның өч бүлмәле квартирының түрендә, лампалар яктысында аквариум тора, анда ефәк койрыкларын болгап, алтын балыклар йөзә, нечкә суүсемнәр чайкала, әкәм-төкәмнәр пыялага ябышып тора. Фәрид шул балыкларны күзәтергә ярата. Минем өемдә аквариум югын белгәч, ул:

— Мин сезне кызганам,— диде.

Галим Фәрид Кутыев рәсем ясарга, хатыны, ике кызы белән чаңгыда йөрергә, балык тотарга ярата. Аның дуслары күп, җәйге айларда аның өеннән кунак-төшем өзелми. Аның белән сөйләшер өчен әдәбият өлкәсендә дә шактый әзерлекле булырга кирәк. Ул, мәсәлән, Тукай шигырьләренең русчага кайбер тәрҗемәләрен «балта белән юнып эшләнгән» ди һәм моның өчен борчыла.

Фәрид дус-ишләр белән җыелып утырырга, әбисе Әминәдән калган көмеш самавардан чәй эчәргә ярата, аш-суның кадерен, җор сүзнең тәмен белә.

Толбачик вулканнары атканда, башка галимнәр белән бергә, Фәрид тә анда булган. Янартау башыннан ургылып чыккан ялкынны

тикшерүдә Кутыев ясаган, фотоаппарат шикелле җыйнак һәм җиңел спектографлар зур җиңеллек китергәннәр.

Вулканологларны киноларда күргән бар. Аларны җәһәннәм авызы кебек кайнап торган кратерга кергән итеп, яисә лава елгасы белән тау астына агып төшкән итеп хәтерлим.

Ләкин Фәриднең үз фикере тагын бүтән:

— Мин, үз эшемне төгәлләүгә, аннан тизрәк кайтып китәргә ашыктым,— ди ул.— Тикшерүләр алып бару ифрат кыен иде: бар токымнарны көл-тузан каплап итә. Өстән корым-тузан, таш ява, җирдән лава кысрыклый.

Уйлап-уйлап карыйсың да, Фәрид белән килешәсең: галимнең фидакарьлеге тора салып янган утка керүдә түгел бит, аның батырлыгы, кыюлыгы — табигатьнең фән өчен, кешелек өчен гаять кирәкле, әмма моңарчы беркем дә чишә алмаган серен чишүдә! Һәм бу батырлык һәр чакта та тышкы бизәкләргә бай булмый, чөнки ул галимнең гакылында ясала.

Фәрид Кутыев җирнең 80—100 километр тирәнлегендә барган процессларны өйрәнә. Хәзерге заман бораулау скважиналары нибары 8 километр тирәнлеккә генә төшә ала. Шуңа күрә аннан да тирән катламнарны өйрәнү өчен вулканнар атып чыгарган токымнар белән эш итәргә туры килә. Кайбер галимнәрнең фикеренчә, җирдәге барлык каты токымнар вулканнарның эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Әгәр бу дөрес икән, төрле файдалы казылмаларны эзләп табуда вулканологларның хезмәтләре гаҗәп зур роль уйнаячак, чөнки алар нәкъ менә шул 80—100 чакрым тирәнлектә барлыкка килә.

Кутыевның хезмәтләре белән таныша башласаң, хәтта фән әһеле булмаган кешегә дә аларның күп тармаклы булуы, төрлелеге күренеп тора.

Рудалар эзләү, тирән катламнарда алмазлар ясалу процессларын өйрәнү, термаль суларның каты токымнар белән үзара бәйләнешын тикшерү. Вулканнарны квалификацияләү буенча башкарган гыйльми хезмәте өчен ул ВДНХның бронза медале белән бүләкләнгән. Аның фәнни докладлары чит илләргә дә җибәрелә, ул үзе дә немец, инглиз телләрендә чыккан фәнни журналларны укып бара һәм кайбер мәсьәләләрдә үзенең чит ил галимнәреннән алгарак киткәнен дә яхшы белә.

Әгәр ул төрле проблемаларны чишәргә омтыла икән, бу гыйльми эшнең заманча стиле. Чөнки Фәрид, бик хаклы рәвештә, хәзерге вакытта ачышлар күбесенчә төрле проблемалар кисешкән нокталарда ясала дип исәпли.

Вулканология институтында миңа значок бүләк иттеләр. Значокның уртасыннан җир тетрәвен язып бара торган прибор — сейсмограф сызган кебек сызык үтә, ә аста — өч янартау. Аның эскизын Фәрид Кутыев ясаган. Институтта значокка конкурс игълан ителгәч, ул да үзенең рәсемен китергән һәм беренче урынны алган.

Бу значок Фәриднең дә җир сулышын сизеп-тоеп яшәвен күрсәтә һәм күңелендә иҗат уты, эзләнү дәрте януын тасвирлый сыман тоела миңа.

* * *

...Камчатка. Җир чите. Бездән меңнәрчә чакрым ераклыкта ул. Әмма безне аның белән тыгыз җеп бәйли. Без бер Җирдә, бер илдә яшибез. Һәм нинди генә мөһим эшкә тотынсак та, аның нәтиҗәләре барыбызга да кагылачак.

# БЕРДӘМ САФТА

Илебез күгендә Октябрь кояшы балкый. Ләкин бу көн үзеннән-үзе генә тумады. Властьны яулап алу өчен хезмәт халкына самодержавиегә каршы рәхимсез көрәшергә, күп кан коярга туры килде. Бу тарихи көрәштә илебезнең барлык милләт хезмәт ияләре катнашты. Интернационализм байрагы аларны бердәм сафка туплады, җиңелмәс союзга берләштерде. Рус, украин, грузин, казакъ, татар, башкорт һәм башка халык вәкилләре азатлык өчен бердәм көрәшкә Беренче рус революциясе елларында (1905—1907) ук күтәрелделәр. Нәкъ менә шул елларда,— дип язды В. И. Ленин,— «Россиянең изелгән халыклары арасында милли-азатлык хәрәкәте кабынып китте»[1]. Бу бигрәк тә күп төрле милләт халыклары яши торган окраиналарда ачык чагылды. Аерым алганда, элекке Казан губернасы революцион көрәш учакларыннан берсенә әверелде. Монда халыкның өчтән бер өлеше татарлар булып, алар белән янәшәдә генә руслар, чувашлар, удмуртлар, марилар, башкортлар һ. б. яши иде. Шулай ук Астрахань, Саратов, Сембер, Оренбург, Уфа губерналарында һәм Уралда төрле милләт вәкилләре яшәгәнлеген әйтеп үтәргә кирәк. Кыскасы, ил халкының 57 проценты рус булмаган милләт вәкилләре була. В. И. Ленин җитәкчелек иткән большевиклар партиясе алар арасында киң аңлату эше җәелдерүгә, революцион көрәшкә тартуга, буржуаз милләтчеләр йогынтысыннан саклап калуга күп көч куйды. Иң мөһиме — партия төрле милләт хезмәт ияләрен самодержавиегә каршы көрәшкә хәзерләде. Бу уңай белән массаларны интернациональ тәрбияләү өлкәсендә большевиклар алдында нинди зур, катлаулы бурычлар торуын күзаллау кыен түгел. Бүген исә, хаклы рәвештә, Ленин партиясе аларны намус белән үтәп чыкты дип әйтә алабыз.

Массаларны интернациональ тәрбияләү юлында партиябез эшчәнлеген тагы да тулырак өйрәнергә, тирәнрәк аңларга ярдәм итә торган һәр яңа факт зур кызыксыну тудыра. Бу мәкаләдә, әлеге мәсьәләгә кагылышлы яңа табылган кайбер архив мәгълүматлары җирлегендә, сүз башлыча 1905—1907 нче елларда РСДРПның Астрахань һәм Урал комитетлары эшчәнлеге турында барачак. Бу районнарның игътибар үзәгенә алынуы һич очраклы түгел. Төрле милләт вәкилләре, шул җөмләдән татарлар да яшәгән әлеге төбәкләрдә татар большевиклары зур аңлату эшләре алып баралар. Бу елларда аларның күбесе Казаннан китәргә мәҗбүр булып, үзләренә яшәү урыны итеп Уфа, Оренбург, Чиләбе, Екатеринбург шәһәрләрен сайлыйлар. Алар җирле РСДРП комитетлары белән бәйләнешкә кереп, хезмәт ияләре, шул исәптән изелгән халыклар арасында киң пропаганда эше алып баралар.

Күренекле революционер Хөсәен Ямашевның якын иптәше һәм көрәштәше Гафур Коләхметов татар әдәбияты тарихында беренче булып революционерлар образын иҗат иткән әдип. Аның «Яшь гомер», «Ике фикер» кебек күләмле әсәрләре, шулай ук байтак хикәя һәм мәкаләләре безгә яхшы мәгълүм. Ялкынлы революционер һәм интернационалист буларак, ул үзе дә 1905—1907 нче еллар революциясендә актив катнашкан. Әдип 1907 елда Оренбургта Х. Ямашев чыгарган беренче большевистик «Урал» газетасы белән дә актив языша. Ул яшәгән фатир большевикларның яшерен очрашу, легаль булмаган җыелышлар үткәрү урынына әйләнә. Һәм бу хакта Казан большевиклары гына түгел, бүтән төбәкләрдә дә белеп торганнар. Мәсәлән, 1904 елдан РСДРП члены, большевик Зариф Садыйков, 1905 елның декабрендә Казан партия оешмасы тар-мар ителгәннән соң, Астраханьга күчеп китә. Килүенең икенче елында ук ул анда, җирле РСДРП комитеты каршында, татар группасы оештырып

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә, 23 том, 267 бит.

җибәрә. Группа шәһәрнең мөселман халкы арасында пропаганда эше үткәрү белән шөгыльләнә, татар телендә листовка һәм өндәмәләр басып чыгара. Татар революционерлары идея һәм оештыру эшчәнлегендә дә җирле социал-демократлар оешмасы белән тыгыз бәйләнештә була. Шунысы кызык, Зариф Садыйков Гафур Коләхметовның бертуган энесе Әбделмән белән бер фатирда, Католическая урамында Перуанскийлар йортында яши. Бу факт исә татар группасының Гафур Коләхметов аркылы «Урал» газетасын алдырып, аны халык арасында таратуы турында да ышаныч белән сөйләргә нигез бирә. Җирле властьлар З. Садыйков һәм Ә. Коләхметов артыннан яшерен күзәтү оештыралар. Бу ике революционерның икмәк пешерүчеләр арасында агитация эше алып барулары һәм 1907 елның маенда забастовкага җитәкчелек итүләре ачыклана [2]. Пристав ярдәмчесе 1908 елның 4 мартында Астрахань полицмейстерына түбәндәгеләрне хәбәр итә: «...Коләхметов һәм Моратов (З. Садыйков — Р. Б.) (хәзерге вакытта) Шәрифуллин тарафыннан чыгарылучы «Идел» газетасына язышалар; Моратовның урамда ниндидер бер рус хатын-кызы белән сөйләшеп торганын күргәннәр, ә Коләхметов бу арада каты авырый»[3].

М. Гайнуллинның «XX йөз башы татар әдәбияты һәм публицистикасы» дигән китабыннан мәгълүм булганча, 1907 елның җәендә Гафур Коләхметов Астраханьга энесе янына килә һәм анда өлкән большевик Зариф Садыйков белән таныша. Аннары алар бергәләп Бакуга китәләр. Кызганычка каршы, бу сәяхәтнең төп максаты билгеле түгел, әмма ул гади күңел ачу максатыннан чыгып ясалмаган дип әйтергә тулы нигез бар. Бу чорда Бакуда танылган революционер Нариман Нариманов, шулай ук профсоюз җитәкчеләреннән большевик С.-Д. Якубов актив эш алып баралар. РСДРПның Баку комитеты каршында революцион «Һиммәт» оешмасы да бик нәтиҗәле эшли. Гафур Коләхметов Казанга 1907 елның көзендә генә әйләнеп кайта.

Югарыда әйтелгәнчә, Зариф Садыйков группасы Астрахань большевиклар оешмасы җитәкчеләре белән тыгыз элемтә тота. Ләкин бу бәйләнешне кемнәр тормышка ашырган соң? дигән сорауга төгәл генә җавап бирүе кыен. Шулай да кайбер мәгълүматлар булуын әйтергә кирәк. 1908 елның 21 гыйнварында Саратовта Петр Алексеевич Милюцкий белән Федор Антонович Сидоров (ул Василий Александрович Овчаров исеме белән дә йөри) кулга алына. Тиздән аларны Астраханьга алып киләләр, чөнки В. А. Овчаров РСДРПның Астрахань комитеты члены буларак гаепләнә. Ул 1884 елда Оренбург шәһәрендә туган, 1898 елда Уральск һөнәр училищесын тәмамлаган. 1902—1906 нчы елларда Оренбургта, аннары Ташкентта яши. Бераздан Ашхабадка, Бакуга һәм, ниһаять, Астраханьга килеп чыга. Кулга алынган чагында аңардан рус һәм татар телендә язылган куен дәфтәре табалар. Бу дәфтәрдә Уфа, Царицын, Казан һ. б. шәһәрләрдә яшәүче большевиклар адреслары да була. Менә шундыйлардан берсе: «...Казан, Екатеринская урамы, Юнысовлар йорты... Коләхметов Гафур». Шунда ук: «...Ибраһим Моратов, Казан»[4]. Овчаровка бу адресларны З. Садыйков (И. Моратов) яки Ә. Коләхметов биргән булуы мөмкин. Шулай ук Гафур Коләхметовның үзенең дә аның белән очрашуы бик ихтимал. Кыскасы, Астрахань большевиклар оешмасы җитәкчеләре арасында З. Садыйков группасы белән бәйләнештә торучы кешеләрнең булуын кистереп әйтергә тулы нигез бар. В. А. Овчаров — аларның берсе. Үкенечкә каршы, бу кешенең шуннан соңгы язмышы билгесез. Соңгы вакытта аның 1909 елның февралендә төрмәдән чыгарылып, махсус полиция күзәтүе астында да яшәгәнлеге ачыкланды. Ул шул елның 4 мартында качып китә, ләкин тиздән янә кулга алына һәм Астрахань төрмәсенә ябыла.

Астрахань губерна җандармериясе идарәсенең Милюцкий һәм Овчаров (Сидоров) эшенә кагылышлы материалларны өйрәнгәндә кызыклы гына башка фактлар да табылды. Алардан сорау алганда, жандармнар РСДРПның Астрахань комитеты секретаре «Ибраһим»ның[5] нинди кеше булуын ачыкларга маташалар. Монда сүзнең Зариф Садыйков турында баруы ихтимал. Чөнки ул комитет документларына шундый имза куя торган булган. Шунысы игътибарга лаек, беркадәр вакыт узгач, шундый ук исем Уфа большевиклар оешмасында күренә башлый. Тарихчы Е. И. Рябухин үзенең кита-

[2] Астрахань өлкә дәүләт архивы. 286 фонд, 1 тасвирлама, 498 эш, II том, 472 бит.
[3] Шунда ук.
[4] Астрахань өлкә дәүләт архивы, 286 фонд, 1 тасвирлама, 499 эш, 129 бит.
[5] Астрахань өлкә дәүләт архивы, 286 фонд, 1 тасвирлама, 489 эш, 129 бит.

бында Зариф Садыйковның «Ибраһим» кушаматы белән йөрүе турында язса да, моны раслап бернинди документаль мәгълүматлар китерми.

Ниһаять, күптән түгел мәсьәлә тулысынча ачыкланды: Свердловск өлкә партия архивыннан кызыклы документ — Уфа губерна жандармерия идарәсе карарының күчермәсе табылды. «1909 елның 14 гыйнварында Уфада,— диелә анда,— мин... ротмистр Плотто, РСДРПның Уфа оешмасына... керүче Брагинский, Покатило, Евремов, Григорьев, А. А. Черепанов, Садыйковның даими язышып торуларын тикшереп, түбәндәгене ачыкладым: ...6) Садыйков (Зариф Шәрипович) ул сул юнәлештәге төрле газеталарда «Ибраһим» кушаматы белән хәбәрче булып эшләгән, РСДРПның Уфа оешмасында член булып торган, шәһәрдә татар телендә легаль булмаган әдәбият чыгару өчен типография оештыру эшенә билгеләнгән...» [6] Шул рәвешле, Зариф Садыйков Астрахань большевиклар оешмасы составында зур эш алып барган, аның җитәкчеләреннән берсе булган, большевикларның таныклыгын тутырганда «Ибраһим» дип имза куйган. Беренче рус революциясе елларында Астраханьнан китәргә мәҗбүр булган З. Садыйков Уфада, рәхимсез террор шартларында да үзенең күп кырлы революцион эшчәнлеген дәвам иттерә.

1905—1907 нче елларда башка урыннарда да татар большевикларының милли группалары оеша. Шундыйлардан берсе — Казан партия комитеты каршындагы татар группасына эзлекле марксист-ленинчы Хөсәен Ямашев җитәкчелек итә. Группа массаларны интернациональ тәрбияләү өлкәсендә зур эш алып бара, татар теленә тыелган әдәбият тәрҗемә кыла һәм басып чыгара, митинг һәм забастовкалар оештыра. Сүз уңаена, илнең Көнчыгыш район партия оешмаларының РСДРПның III съездыннан соң ук махсус конференциягә җыелуларын да искәртү әһәмиятле. Анда Астрахань, Казан, Пенза, Самара, Саратов, Сембер, Нижний Новгород һ. б. партия оешмаларыннан, Көнчыгыш бюросыннан, РСДРП Үзәк Комитетыннан делегатлар катнаша, җирле оешмаларның докладлары тыңлана. Казан вәкиле «комитетта татарлар арасында махсус эш алып баручы бер татар иптәшнең эшләве» турында белдерү ясый һәм болай дип дәвам итә: «Кышын татар приказчикларының махсус массовкалары булды... Татар телендә махсус нәшрият эшли, листовка һәм брошюралар... (чыгарыла)» [7].

Шундый ук группалар Уфа, Чиләбе һәм Троицкида да төзелә. Ижевск һәм Глазов социал-демократик группалары удмурт крестьяннары арасында нәтиҗәле эш җәелдереп җибәрәләр. Әлеге группалар җитәкчеләре бер үк вакытта РСДРП комитетларының тулы хокуклы члены булып торалар. Гомумән, массаларның революцион көрәшенә җитәкчелек итүче һәм аларга дөрес юнәлеш бирүче бу группалар ленинчыл пролетар интернационализм принципларын гамәлгә ашыру өчен күп көч куялар.

Уралда яшәүче мөселман хезмәт ияләренә революцион көрәш идеяләрен җиткерү максаты белән РСДРПның Урал өлкә комитетына да татарлар арасыннан даими рәвештә бер вәкил сайланып килгән. Шулай ук Екатеринбург большевиклар комитетында да ниндидер бер «билгесез татар кешесе» эшләве мәгълүм. Аның комитетта күренекле роль уйнавы, массалар арасында югары абруй казануы турында түбәндәге факт та бик ачык сөйли: ул 1908 елның 10—11 маенда Златоуст шәһәрендә үткәрелгән РСДРПның Урал өлкә конференциясенә Екатеринбург партия оешмасыннан делегат итеп җибәрелә. Бу хәл жандармнар игътибарыннан читтә калмый. «...Билгесез татар шәхесе турында тулырак мәгълүматлар туплавыгызны, аның артыннан күзәтү оештыруыгызны һәм аны якын арада ябып куюыгызны үтенәм»,— дип яза Самара губернасының жандармерия идарәсе начальнигы Пермьдәге коллегасына [8]. Ул кем һәм ниндирәк кеше булган соң? Кызганычка каршы, бу сорау тарихчылар өчен бүген дә сер булып кала.

Бу елларда нәкъ менә шундый большевиклар җитәкчелегендә әлеге регионда яшәүче халыклар телендә, ягъни рус, татар, чуваш телләрендә листовка, өндәмә, брошюралар бастырып чыгару һәм тарату киң колач ала. Ул әһәмиятле кәгазьләрдә милли мәсьәлә турында Ленин программасы киң пропагандалана, партиянең башка мөһим карарлары урнаштырыла, изелгән халыкларның милли-азатлык хәрәкәтен үз максатларында файдаланырга тырышкан буржуаз милләтчеләрнең мәкерле ниятләре

---

[6] Свердловск партия архивы. 41 фонд, I тасвирлама, 49 эш, 112 бит.
[7] Шунда ук.
[8] Свердловск партия архивы. 41 фонд, I тасвирлама, 150 эш, 36 бит.

фаш итељә, царизм политикасы хурлык тамгасы белән билгеләнә. Бер үк вакытта большевиклар татар телендә үз газеталарын чыгаруны да максат итеп куялар. Оренбургта большевистик «Урал» газетасы шуның нәтиҗәсе буларак чыга башлый. Укучы бу газета эшчәнлеге турында Г. Ибраһимовның «Урал һәм уралчылар», Х. Хәсәновның «Революционер-интернационалист» һәм «Большевистик Урал» газетасы кебек тирән эчтәлекле хезмәтләре, шулай ук башка чыганаклар аркылы таныша ала. Газетаның татарлар арасындагы революцион хәрәкәттә генә түгел, ә башка мөселман халыклары арасында да бик зур роль уйнавын искәртеп узарга кирәк. Патша хөкүмәте аны тиз арада ябарга ашыга. Хөсәен Ямашев яңадан, бүтән урында, шундый ук газета чыгару теләге белән яна башлый. Большевиклар бу фикерне хуплап, аны эшкә ашыру чараларын күрәләр. Мәсәлән, РСДРПның Урал комитеты органы булган «Уральский рабочий» газетасының 1907 елгы беренче санында өлкә бюросының 10 сентябрьдән 3 октябрьга чаклы финанс отчеты басыла. Анда татар газетасы булдыруга 20 сум бүлеп бирелүе турында әйтелә. Аның ярты ай эчендә генә җыйналуын күздә тотсак, ул заман өчен бу шактый зур сумма. Янә бер факт. РСДРПның Урал комитеты члены Кириевскийны («Червоный») кулга алганда, аннан хат табалар. «Казанга җибәрелгән татар кешесе кайтып җитмәде,— диелә анда,— шулай да бирегә 55 сум салып озатыгыз, без үзебез шрифт алырга кеше җибәрербез»[9].

1907 елның 27 сентябрендә Урал өлкә партия конференциясе булып, анда Пермь һәм Вятка округларыннан, Пермь, Екатеринбург, Чиләбе, Златоуст, Миньяр, Мотовилиха, Сим һәм Уфа шәһәрләреннән делегатлар катнаша. Анда башка мәсьәләләр белән бергә мөселманнар арасында революцион эш алып бару проблемасы да тикшерелә. Конференция бу мәсьәләдә, Урал партия работникларының 1907 елгы июль киңәшмәсе карарын раслап, «әлегә татар техникасының (типографиясе — Р. Б.) оештырылмаганлыгын һәм татар социал-демократик газетасының чыга башламавын» билгеләп үтә[10]. 1907 елның 8 августында Екатеринбургта, партия җитәкчеләре бөтенесе дә диярлек кулга алыну сәбәпле, татар телендә газета чыга алмый кала. Тентү вакытларында РСДРПның Урал өлкә комитеты секретаре Рядкина өендә җирле партия оешмаларына өндәмә табыла. Анда большевикларны мөселман эшчеләре арасында социаль-демократик идеяләр таратырга чакырган юллар да була, шулай ук өлкә комитетының татар телендә газета чыгару өчен тиешле чара күргәнлеге искәртелә[11].

Екатеринбургта татар телендә газета чыгарып булмаганлыктан, тиздән шундый ук омтылыш Чиләбедә ясала. Бу хакта мәгълүматларны башка хезмәтләрдән, аерым алганда Р. И. Нәфыйков һәм Е. И. Рябухин хезмәтләреннән табарга мөмкин.

Җыеп кына әйткәндә, В. И. Ленин җитәкчелегендәге большевиклар партиясе массаларны интернационализм рухында тәрбияләүгә гаять зур игътибар бирә һәм аны тормышка ашыруда революцион көрәшнең бай арсеналыннан файдалана. Урыннарда төрле милләт эшче һәм крестьяннарының бердәм чыгышлары оештырыла, алар өчен үз телләрендә листовка, өндәмә һәм көндәлек басмалар чыгарыла.

РСДРП комитетлары каршында милли группалар үсеп чыга. Моны Астрахань һәм Урал партия оешмалары тарихын өйрәнү дә ачык раслый булса кирәк. Шартларның үтә кыен булуына да карамастан, һәркайда большевиклар милли мәсьәләне хәл итүгә ленинчыл, пролетар позицияләрдән якын киләләр. Астрахань, Урал, шулай ук Казан, Уфа большевикларының бер үк төрле көрәш формалары һәм методларын кулланулары аларның эшенә бердәм үзәктән юнәлеш бирелүе турында сөйли.

Ләкин бу өлкәдә безгә байтак кына әһәмиятле һәм кызыклы фактлар әлегәчә билгеле түгел, күп нәрсәне ачыклыйсы бар. Туган якларыбызда барган революцион хәрәкәт һәм милли азатлык көрәшенең һәр этабы җентекләп өйрәнүне таләп итә. Биредә 1905—1907 нче еллар революциясендә татар большевикларының башка милләт хезмәт ияләре белән бергә иңгә-иң торып көрәшүен күрсәтүче кайбер фактлар гына китерелде. Ә Бөек Октябрь социалистик революциясе чорында исә бу бердәмлек бөтенләй яңа югарылыкка күтәрелә. Хезмәт ияләре, интернационализм байрагы астына тупланып, авыр һәм данлы көрәштә җиңеп чыктылар. Илебез халыкларының какшамас интернациональ дуслыгы һәм бердәмлегенә революцион көрәш елларында нигез салынды.

**Р. БӘДЫЙГОВ,**
Казан дәүләт университеты аспиранты

---

[9] Свердловск партия архивы, 41 фонд, 1 тасвирлама, 18 эш, 55 бит.
[10] Шунда ук, 19 эш, 77—78 битләр.
[11] Свердловск өлкә дәүләт архивы, 180 фонд, 1 тасвирлама, 83 эш, 56 бит.

Әмирхан Еники

# ХӘТЕРДӘГЕ ТӨЕННӘР



1929 елның көзендә мин «Кызыл Татарстан» газетасында штаттан тыш хәбәрче (хроникер) булып эшли башладым. «Штаттан тыш»ның нәрсә икәнен аңлатып тору кирәк микән? Кыска гына итеп әйткәндә, ул болай: мин редакциянең даими сотрудникгы булып саналмыйм һәм айлык тәгаен бер хезмәт хакы да алмыйм. Мин көнлекче сыйфатындагы бер кеше: кушсалар — эшлим, кушмасалар — тик йөрим. Эшем исә төрле җирдән хәбәр ташу. Әгәр табып китергән хәбәрем яраса, басыла калса, миңа бераз гонорар тия, басылмаса — бер тиен дә тими, билгеле.

Бу эшкә мине редакциянең җаваплы секретаре Мөрти Якуп иптәш чакырткан иде. Әлбәттә, мин бик тәҗрибәсез идем, чөнки моңарчы әле минем редакцияләр тирәсендә бер дә эшләп караганым юк иде. Шуңа күрә минем эшем белән дә Мөрти Якуп үзе җитәкчелек итә иде. Һәр көнне ул мине берәр оешмага яки учреждениегә барып, фәлән кеше белән сөйләшергә яки фәлән нәрсәне белеп кайтырга дип кушып җибәрә. Мин барам, сорашам, сөйләшәм һәм кайтып, ишеткән-белгәнемне язам да Мөрти агайга китереп тапшырам. Ул шунда ук укып карый да, ярарлык булса, чираттагы номерга җибәрербез дип әйтә. Ярамаслык булса, йомарлый да кәрзингә ташлый һәм яңадан язып китерергә куша. Кыскасы, минем эшем тулысынча Мөрти Якуп кулында иде.

Мин инде, билгеле, кадәри хәл тырыша торган идем, чөнки хәбәрнең үтүе ул минем өчен хаят мәсьәләсе иде. Үтсә — мин тук, үтмәсә — юк. Әйтергә кирәк, минем матди як бик хөрти иде ул чакларда. Еш кына ун тиен, унбиш тиен табалмыйча, «ураза тотып» үткәргән көннәр дә булгалый иде. Өстә иске пальто, башта чүпрәк кепка, аякта сай ботинкалар — шулар белән салкын кышны да үткәреп җибәрергә туры килде. Ни әйтсәң дә, яшь чак, башта куе чәч тә бар иде әле — ничек тә түзәргә, бирешмәскә була иде. Билгеле инде, мин гонорар көнен бәйрәм таңын көткәндәй сабырсызланып көтеп ала идем. Ялгышмасам, ул чакта да айга ике тапкыр бирәләр иде. Башта штаттагы кешеләр (бәхетле кешеләр!) хезмәт хакларын алалар, шуннан соң, бер-ике көн узгач, гонорар да бирә башлыйлар.

Ул елларда редакциянең кассиры булып Харис абзый Фәйзуллин эшли иде. Тарихта билгеле шәхес. Заманында дәреслекләр чыгарган һәм «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыткан кеше. Композитор Җәүдәт Фәйзинең атасы. Бу урында тагын шуны да әйтеп үтәсем килә: бер-ике ел элегрәк мин Харис абзыйның өендә, аның уллары Мидхәт белән Җәү-

дәт янында да булгалаган идем. Җәүдәт ул чагында кыска гына хикәяләр язу белән мавыга иде. Без аның язганнарын тыңлый идек тә: «Син, егет, ахрысы, Чехов булырга чамалыйсың!» — дип әйтә торган идек. Соңыннан Җәүдәт музыкага кереп китте һәм шунда үзенең талантына лаек чын урынын да тапты. Әмма каләмен дә ташламады. Безнең композиторлар арасында ул татарча әйбәт яза белгән бердәнбер кеше иде дисәм, һич тә хата булмас, минемчә. Мәгълүм булганча, Җәүдәт Фәйзи музыка сәнгате турында күп язды һәм берничә бик әйбәт китаплар да калдырды.

Инде янадан Харис абзыйның үзенә килсәк, ул урта буйлы, юка гәүдәле, ак чырайлы, элекке зыялыларны хәтерләткән мөлаем бер кеше иде. Менә шул кеше редакция коридорының караңгы бер башындагы кечкенә чолан шикелле кассаның бәләкәй генә тәрәзәсеннән безгә, ведомостька кул куйдырып, акча бирә торган иде. Бухгалтер, счетовод кебек работникларның барлыгын хәтерләмим. Юк иде шикелле. Бөтен эшне — ведомостьлар төзүне дә, банктан акча алып кайтып өләшүне дә — шул бер Харис абзый башкара иде бугай. Һәрхәлдә, мин бары тик аны гына белә идем.

Ике атнада җыелган гонорарның күләме дә бер дә тигез булып чыкмый иде. Кайчагында бик аз тия, ә кайчагында ярыйсы гына да төшкәли иде. Ләкин иң күп төшкән чагында да барыбер очны-очка ялгап булмый иде. Күрәсең, «эшләп табуым» бик чамалы гына булгандыр инде.

Әйткәнемчә, мин хәбәр ташучы. Көн дә берәр җирдән хәбәр табып китермичә калмыйм, ләкин аларның барысы да газета битенә эләкми, шактый өлеше туп-туры кәрзингә китә торган иде. Аннары бик күбесе вак кына хәбәрләр, эрерәкләре ни сәбәптер сирәк языла иде. Шуңадыр инде, бер материал да минем үз фамилиям белән дөньяга чыкмады. Ваклары имзасыз гына басыла, ә зурракларына берәр төрле псевдоним куя идем. Хәер, «төрле псевдоним» дип бик арттырып җибәрәм түгел микән?! Чөнки бер псевдоним гына минем хәтеремдә сакланып калган, ләкин аны да менә хәзер нигәдер ачасым килми.

Башта әйткәнемчә, минем «хуҗам» Мөрти Якуп иде. Бу юанрак бәдәнле, шоп-шома битле, җитез-хәрәкәтчән кеше бик күптәнге газетчы һәм редакциянең барлык эшләрен үз кулында тотучы иде. Билгеле, ул миңа өйрәнчек малай итебрәк карый иде. Шулай да минем аңа бер төрле дә үпкәм юк. Киресенчә, исемә төшкәндә рәхмәт кенә әйтәсе килә, чөнки хәлем авыр чакта ул миңа эш биреп, күпмедер дәрәҗәдә мине бөлгенлектән коткарды. Кызганычка каршы, мин аның соңгы язмышын белмим.

Кыскасы, мин бары Мөрти агай кушуы буенча гына йөрим, табып кайткан хәбәрне дә тик аңа гына тапшырам. (Газетаның баш редакторы ул чакта бүе-сыны һәм калын, кара тартәле күзлекләре белән дә Михаил Кольцовны бик нык хәтерләткән Сафа Борһан иптәш иде. Ләкин бер генә тапкыр да миңа аның янына керергә туры килмәде.) Хуш, нинди рәк хәбәрләр табып китерә идем мин?.. Бер-ике генә мисал. Күптән түгел Яңа бистәдә ябылган мәчетләрнең берсе кичләрен бала тавышы белән елый, имеш, дигән хәбәр халык арасында таралды. Бөтен җирдә шуны сөйлиләр. Ниһаять, бу хәбәр редакциягә дә килеп керде. Әлбәттә, аңа ышанучы юк, бары кызык өчен тагы да куертып сөйлиләр генә. Ләкин шулай да Мөрти агай мине чакырып алып задание бирде: бар, шул уйдырманың кемнән, нәрсәдән чыкканын үз күзең белән күреп, үз колагың белән ишетеп кайт, диде. Задание бик сәер, әкәмәт тоелса да, мин кичкы кичләрнең берсендә тәвәккәлләп Яңа бистәгә чыгып киттем. Бардым, елый торган мәчетне эзләп таптым. Башта урамга җыелган карт-корылар янында туктап, елаган тавыш ишетелмәсме дип тыңлап тордым. Аннары нидер ишетелгән шикелле булгач, мәчетнең эченә кереп, мана-

ра баскычыннан кыек астына үтеп, дөм-караңгыда тагын колак салып, көтеп тордым. Баксаң, шунда оялаган мәче башлы ябалак елап утыра, имеш! Мин бу кошның кыек астыннан очып чыкканын үз күзем белән күреп төштем. Икенче көнне редакциягә килгәч, бөтен ишеткән-күргәнемне Мөрти агайга сөйләп бирдем. Хәзер инде әйтә алмыйм, бу турыда газетада бирәр нәрсә чыкты микән, юк микән?.. Ләкин күп еллар узгач, мин шулай да «Мәчет елый» дигән бер хикәя язып бастырдым.

Икенче мисал. Шул ук елның көзендә, Проломный (хәзерге Бауман) урамындагы бер йортның кечерәк залында «Красин» бозваткычына багышланган күчмә фотокүргәзмә оештырылган иде. Бозваткычның Төньяк боз диңгезендә йөзүен күрсәткән күп кенә фоторәсемнәр куелган иде анда. Исеме дә аның «Красин панорамасы» дип атала иде. Миңа менә шул күргәзмәне барып карарга һәм аның хакында бер заметка сыман нәрсә язып бирергә кушылды. Мин бардым, карадым һәм язып та бирдем. Ул тиз генә газетада басылып та чыкты. Ләкин газетаны кулыма алып карагач, минем күзләрем шар була язды: ахыргы биттә эре хәрефләр белән «Кирасин панорамасы» дип басылган иде. (Ягъни безнең лампага сала торган «керәчинебез» була инде.) Минем моңа, әлбәттә, эчем бик пошты, ләкин Мөрти агай төзәтү-мазар биреп тормады. Ул чакларда шуның ише симез хаталар газета битләрендә еш киткәли һәм аңа газета кешеләренең артык исләре дә китми иде. Тик зур политик хата китсә генә сискәнеп аякка баса торганнар иде.

Мин эшләп йөргәндә редакцияләр хәзерге Ленин урамындагы почтага каршырак, «Икенче Советлар йорты» дип йөртелгән матур бинаның икенче катына урнашкан иде. Һәм бу берләшкән редакцияләрнең уртак исемен «ГӘЖУР» дип атыйлар иде. Шундагы ике-өч бүлмәдә дүрт редакция — «Кызыл Татарстан», «Крестьян газетасы», «Азат хатын» һәм «Чаян» журналлары эшләп яталар. Бары баш редактор Сафа Борһанның гына аерым кабинеты бар, калганнар исә зур бүлмәдә кечкенә өстәлләр билиләр. Беренче бүлмәнең ишегеннән кергәч, уң кулда Галиәсгар абзый Камалның бик кечкенә өстәле тора. Шул өстәлдә ул зур башын иеп, редакциягә килгән вак-төяк игъланнарны тәрҗемә итеп утыра. Сотрудниклар арасында яше белән аңардан да өлкән кеше юк иде бугай. Хәер, тагын бер өлкән кеше булса, ул «Йолдыз», «Кояш»лар заманыннан бирле газеталарда эшләп килгән, бик остарган, хәбәрләрне дә бик күп ташучы репортер Гариф абзый Латыйпов иде. Калганнар исә алардан күп яшьләр.

Галиәсгар абзый үзенең кечкенә эшен шактый иртә бетереп, сәгать бер-икеләрдә үк редакциядән чыгып китә торган иде. Ул башкалар белән күп аралашмый, күп сөйләшми, аңа монда кызык та түгел шикелле, тик ара-тирә Такташ белән генә уен-көлке сөйләшеп ала — шулай хәтеремдә калган минем. Атаклы драматургны артист дуслары күбрәк тарткан булса кирәк, чөнки миңа аның «Болгар», «Амур» тирәсендәге сыраханәләрдә Бари Тарханов, Вәлишин, Мохтар Мутиннар белән бергә утырганын күргәләргә дә туры килде.

Ә ишектән сул якта, Галиәсгар абзый өстәленә каршы гына Һади Такташ өстәле тора. Ләкин Такташ ни сәбәптер өстәле янында аз утыра, күбрәк бүлмә уртасында әрле-бирле йөренә. Шул чакта авыз эченнән генә нидер кабатлап, ниндидер шигъри өзекләр әйткәли. Минем үземә дә ишетеп калырга туры килгәләде:

Миннән соң туачак җырчыларның  
Даны күмәр минем атымны,  
Ләкин,  
Еллар сезгә зур бер легенданы  
Саклап алып барган шикелле,  
Алып барыр шушы хатымны...

. . . . . . . . . . . . . . .

Мин бу гаҗәеп юлларның кайдан, нинди шигырьдән икәнен белми идем әле. Әмма сизәм, моңарчы ишетелмәгән яңа нәрсәдән булырга тиеш. Тик соңыннан, басылып чыккач кына белдем: «Киләчәккә хатлар»дан икән бу хикмәтле юллар!

Димәк, Такташ нәкъ шул чакларда үзенең соңгы поэмасын язган, утырып кына түгел, йөри-йөри, авыз эченнән генә тәкърарлый-тәкърарлый да иҗат иткән. Һәрхәлдә, минем шулай дип әйтәсем килә.

Һади Такташ.... Аның хакында белгәннәремне язасы килү мине бик күптән борчый иде инде. (Бу «төеннәрне» сүтәргә керешүем дә башлыча шуның аркасында булды дияргә ярый.) Дөрес, мин Такташны якыннан белә идем дип мактана алмыйм. Шулай да 1925 елның ахырыннан алып, шагыйрьнең үлгән көненә кадәр миңа аны урамда, җыелышларда, әдәби кичәләрдә күп кенә күрергә, шигырь укуын яки сүз сөйләвен еш кына ишетергә туры килде. Шулай ук тар кругта, иптәшләре арасында көлеп-сөйләшеп торган чакларын да күргәләдем һәм читтәнрәк булса да тыңлап та торгаладым. Әлбәттә, безне таныштыручы булмады. Һәм бу гаҗәп тә түгел, чөнки Такташ шөһрәтенең зенитына күтәрелгән гаять популяр шагыйрь, яше беләндә миннән шактый олы, ә мин ул чакта әле язучыларның җыелышларына, шәкерт шикелле, бик ихлас йөрүче, «Безнең юл»да берничә вак-төяк зәгыйфь кенә нәрсәләр бастырган яшь-яшь кенә үсмер егет идем. Шулай да Такташ мине күреп тә, танып та белә иде. (Әнә шул җыелышларга йөрү аркасында инде.) Әле күптән түгел, Хатип Госман миңа: «Син бит мине Такташ белән таныштырдың, без өчәү сөйләшеп тә утырдык»,— дип әйтте. Мин үзем инде моны хәтерләмим, ләкин Хатипның сүзләренә ышанам; димәк, үзем кебек бер яшь егетне атаклы шагыйрь белән таныштыра алгач, без инде бер-беребезне яхшы ук белгән булып чыгабыз.

Аннары бер вакытны без, бер төркем яшь язучылар, Вахитов заводының бүрәнә клубына әдәби кичә үткәрергә бардык. Төркемдә Такташ белән Кутуй да бар иде. Хәер, бу барудан мин бик кәефсезләнеп кайттым. Хикмәт шунда, минем мондый кичәгә беренче мәртәбә генә катнашуым иде. Шуның өстенә укуым да начар, каушап калуым да мөмкин иде. Шуңа күрә мин кичәне алып баручы Кутуйга әйттем: мине алданрак, Такташка кадәр чыгар, дидем. Чөнки Такташ кичәнең «кадагы», аңардан соң чыгып укуның бер кызыгы да булмаячак,— моны бик яхшы белеп тора идем. Без инде икәү генә калган да идек. (Алданрак чыгып сөйләүчеләрнең кемнәр икәнен хәзер әйтә алмыйм — онытылган, кызганычка каршы.) Ләкин Кутуй ни өчендер минем үтенечне тыңламады, тотты да бик зурлап Такташка сүз бирде. Такташның гаять популяр чагы, аның чыгуын халык көтеп кенә тора. Менә ул башын ия төшеп, ашыкмыйча гына сәхнә уртасына чыгып баса. Залда утыручылар аңа бер шаулап кул чабып алалар. Шагыйрь залга карап елмая, сүзен башлаганчы аз гына көттереп тора. Әгәр берәр көлке шигырен укырга җыенса, башлап үзе сабыйларча бер көлеп куя. Халык та, билгеле, аңа ияреп, елмая-көлә башлый. Әнә шулай авызын ачмас борын ук инде шагыйрь тыңлаучыларын күпмедер дәрәҗәдә сихерләп тә өлгерә. Такташ сәхнәдә үзен бик гади һәм иркен тота иде. Ниндидер бер самимилек, сөйкемлелек бөркелеп тора иде аның бөтен кыяфәт-торышыннан. Шигырьләрен исә аз гына мишәр акценты белән гаҗәеп ягымлы, үтемле итеп сөйли иде. Миңа калса, бу җәһәттән Такташны уздырган башка бер язучы яки бер шагыйрь дә булмагандыр — һәрхәлдә, мин берәүне дә белмим, хәтерләмим. Хәтта бик оста сөйләүче, матур тавышлы Кутуй да тыңлаучыларны Такташ хәтле үк әсир итә алмый иде. Йә, шулай булгач, Такташтан соң сәхнәгә чыгып кара инде! Билгеле, мин чыгып сөйләүдән баш тарттым.

Вакыт узып, редакциядә эшли башлагач, мин инде Такташны көн дә диярлек күрә идем. Әлбәттә, сүз алышу, сөйләшүләр дә булгандыр, тик

сүзләр бит, кызганычка каршы, безнең хәтердә язылып калмый. Яки бик сирәге генә, бик мөһим бирәр момент белән бәйләнгәннәре генә сакланып калса кала. Редакциядә чакта Такташ белән азмы-күпме аралашуның бер мисалы итеп шуны да әйтә алам: яңарак чыккан «Дус кеше» исемле, кәгазь тышлы юка гына беренче китабымны мин аңа язып та биргән идем. Ул китап мәрхүмнең архивында сакланмадымы икән дип хәзер дә әле уйлап куйгалыйм.

Эшләрем бик шәптән булмаса да һәм матди ягым бик хөрти булса да, редакциядә эшләве күңелле иде. Кешеләре кызыклы иде. Аннары көлке күп иде — ул чакта кешеләр юктан да көләргә, көлке уйлап чыгарырга яраталар иде. Такташ үзе юмор капчыгы, Исмәгыйль Рәми бик чая телле, Кутуй — фантазер. Тик бу урында шуны өстисе килә. Такташның бик уйланып калган, бүтәннәрдән читләшеп, үзалдына гына башын иеп йөргән чаклары да була иде. Ә менә Кутуйның андый чагын мин күрмәдем диярлек. Әйтергә кирәк, ул елларда Кутуйның бик парлак чагы иде. Исеме бөтен җирдә шаулый, үзе гаять өлгер-житез... Менә ул редакциягә озын, нечкә сыйраклы әкәмәт бер кош шикелле килеп керә. Өстендә сары эт тиресеннән теккән, тезләренә дә житмәгән, шунлыктан гәүдәсен бик калынайтып җибәргән галәмәт йонлач, авыр тун, ә нечкә аякларында кыска галифе дә обмотка урап кигән кара ботинкалар. (Меховойлар тегеп чыгарган андый туннар бер вакыт бик модага кереп киткән иде. Шундый туннарның бер чуарын Такташ та киеп йөрде. («Тун трагедиясе»н хәтерләгез.) Кутуй килеп керү белән редакция бүлмәсе җанланып китә. Барысы да «Кутуй!» да «Кутуй!» дип төрле яктан аңа дәшә башлыйлар. Ул үзе дә бүлмә буйлап бөтерелә, бөтен өстәлләрне йөреп чыга, барысы белән дә кул биреп күрешә. Тавышы көр, кычкырып, кызыклы итеп сөйли һәм гел генә диярлек берәр төрле яңалык та китерә — кешеләр бер мәлгә эшләрен дә онытып торалар...

Мин аның редакциядә эшләп утырган чагын күрмәдем диярлек. (Өстәле дә юк иде шикелле.) Газетаның штаттагы сотрудникы идеме, түгелме — ул кадәресен дә белмим. Әмма аның үз исеме яки «Һималай» имзасы куелган зур-зур мәкаләләре һәм рецензияләре газета битендә бик еш чыгып тора иде. Ихтимал, ул да минем шикеллерәк редакциянең ирекле бер кешесе булгандыр, ләкин дә инде бөтенләй аерым исәптәге, бик кирәкле һәм бик авторитетлы кешесе — бу кадәресе минем өчен бәхәссез иде.

Алар, ягъни Такташ белән Кутуй, бик дуслар иде. Җан дуслар дип әйтсәм килә, чөнки алар — аерылгысыз, кая гына барма, алар гел бергә!.. Җыелышларда, кичәләрдә, театрда жиңел сөякле Кутуй белән салмаграк хәрәкәтле Такташ, энә белән җеп шикелле, гел бер-берсенә тагылып йөриләр — шулай калган минем хәтеремдә. Ә бит болай чынлабрак караганда, алар бер-берсеннән шактый нык аерылалар иде. Табигатьләре дә бер түгел, иҗатларында да охшашлык юк. (Сүз бирелә башлыча аларның шигырьләре турында бара.) Такташ басынкырак, сабыррак, кешеләр белән мөгамәләдә йомшаграк булса, Кутуй, киресенчә, дәртлерәк, кайнаррак, кискенрәк кеше иде. Такташ көчле талант, шигърият чишмәсе, ә Кутуй — эрудит, поэзияне бик шәп белүче, әмма шигърияте ягыннан Такташка караганда йомшак, зәгыйфьрәк. Гомумән, икесе ике төрле шагыйрь. Янәшә куеп та булмый аларны, минемчә...

Соң, алайса, каян килә алар арасындагы әлеге чын дуслык? Дөрес, алар икесе дә бик популяр шагыйрь, татар әдәбиятының ике йолдызы [1], исемнәрен дә һәр вакыт диярлек гел бергә кушып сөйлиләр,— һичшик-

[1] Нигъмәти үзенең бер мәкаләсендә («Безнең юл», 1927 ел, 6—7 саннар) биш язучыны татар әдәбиятының биш йолдызы дип атаган иде. Болар — Такташ, Кутуй, Нәҗми, Толымбайский һәм Туфан.

сез, шушы нәрсә дә аларны бер-берсенә бик якынайткан булырга тиеш. Ләкин моның белән генә дуслыкны аңлатуы читен. Ә бәлки табигатьләрендәге әнә шул аермалык башлыча аларны бер-берсенә тарткан-бәйләгәндер дә?.. Мондый хәлнең булуы, минемчә, бик мөмкин. Һәрхәлдә, алар арасындагы дуслык вакытлы һәм очраклы моментлар аркасында гына түгел, ә зуррак, тирәнрәк сәбәпләр нәтиҗәсендә, әйтик, күңел таләбеннән, тирән симпатиядән, соклanудан, ниһаять, бер-берсенә мохтаҗлыктан туган булырга тиеш. Ике шагыйрьнең үзара мөнәсәбәтләрен азмы-күпме үз күзләрем белән күргәнлектән, мин бары әнә шулай гына аңлата алам. Әмма бу дуслыкның ахыры ни белән бетте соң? Хәер, тарих моны белә, тарихка мәгълүм. Шулай да мин үзем күреп белгәнне дә сөйләргә телим, тик бераз соңга табарак.

Инде тагын редакциядәге хәлләргә кайтыйк. Әйткәнемчә, анда һәртөрле мәзәк, кызык, көлке сүз күп була торган иде. Менә шундый кызыкларның берсе: көннәрдән бер көнне игъланнар өчен коридорда эленеп торган кара тактада үзеннән-үзе стена газетасы сыман нәрсә пәйда булды. Башта кемдер көлке бер әйбер яза да шуны тактага кнопка белән кадап куя. Аңа ияреп икенче берәү тагын нидер язып элә. Җыелышып укыйлар, шаулап көлешәләр, һәм шуннан китә дә инде: һәркем ни дә булса язып, беркетә башлый — кара тактаның буш урыны да калмый. Контроль дә юк, редколлегия дигән нәрсә дә юк, теләсәң ни яз, полный хөрлек! Тик газетага охшасын өчен редакция художнигы «Сыбызгы» дигән матур гына баш ясап, тактага ябыштыра. Аннары, озак та үтми, Такташ көзге Ташаяк ярминкәсеннән бер кызыл билле калай сыбызгы да алып кайтып, шуны әлеге исем өстенә элеп куя. (Ул елны атаклы Ташаяк ярминкәсе соңгы мәртәбә булды шикелле — шулай хәтеремдә калган.)

Хәзер инде «газетаның» исеме дә бар — «Сыбызгы»! Хәтта түгәрәк кәпәчле калай сыбызгы да эленеп тора. Билгеле, кара тактага кнопка белән беркетелгән «материаллар» да «газетаның» исеменә бик туры килә — болар торганы редакция кешеләренең бер-берсеннән көлеп, бер-берсен үртәп язган нәрсәләре... Шундыйларның берсе ничектер хәтердә сакланган. Редакциягә алып менә торган киң баскычның нәкъ борылмадагы стенасында ике куыш бар иде. Куышларның берсендә шәрә хатын-кыз статуясы басып тора, ә икенчесе — буш, статуясы әллә югалган, әллә төшеп ватылган. Кыскасы, симметрия бозылган. Һәм менә кемдер «Сыбызгы»га шундыйрак тәкъдим язып беркетә: симметрияне саклау өчен әлеге буш куышка шагыйрь Исхак Хәйруллин белән тәрҗемәче Абдулла Төхфәт, анадан тума чишенеп, алмашлап басып торсыннар иде! Моны укып без барыбыз да рәхәтләнеп бер көлештек. Чөнки икесе дә бик кечкенә буйлы бер тигез Исхак белән Төхфәт теге буш куышта статуя урынына басып торыр өчен бик тә туры киләләр иде.

Тагын шунысы да кызыклы: моның ише көлкегә эләккән кешеләр ничектер үпкәли дә, ачулана да белмиләр иде. Күрәсең, үзләре дә җавапсыз калмаганнардыр инде.

«Сыбызгы» шул хәлендә күпме дәвам иткәндер — ул кадәресен әйтә алмыйм, чөнки мин хроникер булып бер дә мантый алмагач, бушка «эшләп» йөрүне ташлап, озакламый редакциядән китәргә мәҗбүр булдым. Кыскасы, чыкмады миннән гәзитче!

Мин яңадан меховойда эшли башладым. Электә бер монда эшләп киткән идем инде, хәзер тагын шунда кайттым. Хезмәт хакы алып эшләүгә ни җитә!

Бу — утызынчы елның язы иде. Язучылар тирәсеннән бөтенләй ераклаштым дияргә ярый, барып күренеп йөрергә вакытым да юк, аннары әллә ни теләгем дә юк иде. Тик читтән генә ул тирәдәге хәлләрне

ишеткәли идем. Ләкин минем максат та ишеткәнне түгел, күргәнне язу. Ә ул чакта күргәннәрдән иң зурысы, иң нык хәтергә сеңеп калганы — бу Һади Такташның күмү вакыйгасы... Әйе, менә Такташ үлде... Салкын, шыксыз, караңгы декабрь аенда... Ничек кенә моны акылга сыйдырырга, ничек кенә кабул итәргә?! Бу шул кадәр көтелмәгән бер вакыйга булды ки, беренче ишеткәндә моңа ышануы да, моның белән килешүе дә мөмкин түгел иде. Юк, кабул итми күңел. Әле кайчан гына сау-сәламәт йөргән утыз яшьлек тап-таза кеше үлеп китсен, имеш!.. Күпләр аның авырып ятуын да ишетми калдылар булса кирәк. Хәер, мин үзем ничектер ишеткән идем, ләкин күңелемә ник бер шик яки шом килсенче! Гомумән, ул елларда без үлем турында уйлый да белми идек әле. (Дөресен генә әйткәндә, мин Такташның нидән, ничек итеп үлүен хәзер дә әле аңлап җиткәнем юк. Тифтан диделәр, әмма врачлар тифны гына җиңәргә тиешләр иде кебек...) Ләкин ни генә уйлама, күпме генә үрсәләнмә, аяусыз хакыйкать бу: Такташ үлгән, Такташ юк инде.

Көтелмәгән зур үлем кешеләрне хәрәкәткә китерә. Битараф калу мөмкин түгел. Менә мин дә кайгылы хәбәрне ишетү белән завкомга йөгереп бардым, аннары кем беләндер директор янына да кердек. Тәкъдимебез шул: цехларда кайгы митингысы үткәрәсе иде һәм шагыйрьнең җеназасына эшчеләрдән делегация сайлап җибәрәсе иде. Такташның никадәр популяр шагыйрь булуы бәхәссез, аның исемен ишетмәгән кеше юк. Директор, рус кешесе булса да, моны яхшы белә икән, шуңа күрә безнең тәкъдимне хуплап каршы алды. Төшке аш вакытында эшчеләрне бер цехка җыеп, кыска гына кайгы митингысы үткәрелде һәм шунда ук шагыйрьне озата барыр өчен коллектив исеменнән биш-алты кешелек делегация дә сайланды. Алар арасында мин дә бар идем. Тәнәфестән соң без, сайланган кешеләр, ашыга-ашыга шәһәргә киттек.

Юлыбыз — Татар мәдәнияте йортына (хәзерге ТЮЗ бинасына). Такташ аның түбәнге фойесында җир өстендәге иң соңгы төнен уздырды. Бүген аны шуннан алып чыгачаклар.

Декабрь көне тиз сүнә, тиз караңгылана. Димәк, озатуны да тиз тотарлар... Без килеп җиткәндә Мәдәният йорты тирәсендә халык шыгрым тулы иде. Кешеләрне эчкәре кертмиләр икән инде. Соңгы бәхилләшүчеләр әкрен генә урамга чыгалар. Шулай да безне, мехчылардан килгән делегация булгач, эчкәре уздырдылар.

Менә стеналары гарәп стилендәге нәкыш белән бизәлгән тар, озын гына зал. Уртасында озынча өстәл, өстәл тирәсендә кара каймалы кызыл табут. Табутта Такташ ята. Сап-сары йөз, очлаеп киткән борын, күзләре йомык. Мин әле хәзер дә мәет йөзенә карый алмыйм, ә яшь чагымда туры караудан бөтенләй кача торган идем. Ләкин барыбер күз төшә, төшмичә кала алмый. Әмма соңыннан мәет йөзе күз алдыннан озак китмичә мине газаплый...

Әйткәнемчә, шагыйрь белән хушлашу туктатылган, залда язучылар да Такташның иң якыннары гына калган иде. Почет каравылы да тора иде әле. Менә тагын каравылны алыштырдылар. Кемдер миңа да басарга кушты. (Язучылар барысы да үз нәүбәтләрен үткәргәннәр күрәсең инде.) Мин шагыйрьнең баш очына бастым. Һәм безне бүтән алыштыручы булмады, шул сәбәпле шактый озак басып торырга туры килде. Соңгы әзерлек, соңгы минутлар!.. Мәетне фоторәсемгә төшерү башланды. Фотограф, ялгышмасам, газет-журналларда бик күптән эшләп килгән чүл гарәбедәй кара-көрән Солтан абзый иде. Башта ул табут янында шагыйрьнең иң якыннарын — хатынын, сеңелесе белән энесен төшерергә җыенды. Үзенчә аларны табутның бер ягына тезеп бастырды, ләкин төшереп алырга өлгермичә калды; нәкъ шул мизгелдә хәсрәттән бик бетеренгән Гөлчирә ханым, үксеп, Такташның күкрәгенә капланды. Һәм бу хәл берничә мәртәбә кабатланды. Ә мин табутның икенче ягында гына басып торам — аз гына селкенергә, кыймылдарга

иа ярамый. Иреннәр тыелгысыз дерелди, яшьләрем менә-менә бәреп чыкмакчы, белмим, ничек кенә чыдап калганмындыр инде... Солтан абзый да шактый җәфаланды, шулай да ул үзенә кирәк мизгелне тотып, ахырда төшереп алды.

Бу эш беткәч, табут янына язучылар тезелде. Алар шактый ишле иде. Солтан абзый язучылар белән эшен тиз бетерде. Шуннан соң кешеләр таралды, без дә, ниһаять, каравыл постын калдырдык... Табут янынган тик Гөлчирә ханым гына китмәде. Ул миңгерәүләнер дәрәҗәгә җиткән иде шикелле... Миңа, соңыннан күп җеназаларны күреп үткәргән кешегә, мәет өстендә Гөлчирә ханым кебек шул кадәр авыр газап кичергән икенче берәүне күрергә туры килмәде дисәм, һич тә хата булмас.

Вакыт җитте шикелле... Инде мәетне алып чыга да башларга тиешләр. Ләкин күмү комиссиясенең членнары ни өчендер бер бүлмәгә кереп киттеләр. Алар артыннан башка язучылар да иярде. Калган берничә кеше — без дә кызыксынып шунда кердек. Сүз әйтүче булмады. Без ишек төбендә генә басып торабыз, ә түрдә комиссия членнары аягүрә генә сөйләшәләр. Табутны беренче башлап кемнәр күтәреп чыгарга тиеш, һәм чыккач, күмү мәрасиме ничек, нинди тәртиптә барачак — сөйләшү менә шул хакта иде.

Әйткәнемчә, бирегә мәрхүмнең замандашлары барысы да диярлек җыелган, тик алар арасында Кутуй гына юк иде. Табут янында да күренмәде ул. Ахрысы, килмәскә булгандыр... Күренеп йөрмәскә... Хәер, килмичә каламы соң?! Кутуй үзенең Такташын озатырга килмәсен, имеш! Кем ышаныр моңа?!

Нәкъ менә комиссия членнары үзара тыныч кына киңәшләшкән чакта ишек төбеннән аның соңгы вакытларда «югалып» торган ачык тавышы ишетелде:

— Иптәшләр, рөхсәт итегез әле миңа да бер сүз әйтергә!

Түрдәгеләр барысы да бу көтелмәгән тавышка борылып карадылар һәм кайберәүләр аптырап, кайберәүләр исә уңайсызланып, бер мәлгә ни әйтергә белмичә тынып калдылар. Ахырда комиссия членнарыннан берсе, ялгышмасам Закир Гали, артык гаҗәпләнүдән булса кирәк, сүзә төшеп:

— Ку-туй?!— дип куйды, аннары кинәт кызып:— Каян килеп кердең әле син, кем чакырды? Такташка синең бернинди дә мөнәсәбәтең юк, хәзер үк чыгып кит!— диде.

Кутуй тагын нидер әйтергә омтылып карады, ләкин аңа авыз ачарга да ирек бирмәделәр. Бу юлы инде берничә кеше, кайсы ачуланып, кайсы үтенгәндәй итеп, чыгып китәргә куштылар. Шуннан соң Кутуйның тавышы ишетелмәде, чыгып китте булса кирәк, хәер, мин артыма борылып карарга ничектер җөрьәт итә алмадым.

Кечкенә бүлмәдә әнә шундый хәл булып алды. Ләкин вакыйга моның белән генә бетмәде әле. Шагыйрьнең гәүдәсен Мәдәният йортыннан алып чыккач, Кутуй юл буе диярлек күтәрешеп барырга күпме генә омтылып караса да, аны табутка якын җибәрмәделәр. Зиратка барып җиткәннән соң, кабергә туфрак ташларга хәтта көрәк бирмичә үзен азапладылар. Кыскасы, шагыйрьнең мәете тирәсендә чуалып йөрүчеләрдән кайберәүләр үлгән Такташны тере Кутуйдан әнә шулай «сакларга» тырыштылар.

Инде хәзерге укучыларның исләре китеп, бу ни эш, Кутуйга ни булган, сәбәп нәрсәдә соң дип сораулары бик табигый. Әмма ләкин безгә, шул хәлләрне күреп уздырган кешеләргә, моның сәбәпләре билгеле иде. (Һәрхәлдә, тарих өчен бу сер түгел.) Кыска гына итеп әйткәндә, эш менә нәрсәдән гыйбарәт: утызынчы елның башындарак булса ки-

рәк, әдәбият дөньясында зур шау-шу куптарган «җидегәнчеләр» дигән кечкенә бер төркем язучылар «фаш ителде». Менә шуларның берсе һәм иң күренеклесе Гадел Кутуй икән [1]. Әлбәттә, бу сенсация иде. Әле кайчан гына әдәби хәрәкәтнең эчендә кайнаган дәһшәтле Кутуй үзе дә «гөнаһлы», «гаепле» бер кеше булып чыга. Ләкин бу очракта аның өчен бәхетсезлек моның белән генә бетми. Саф күңелле, намуслы Такташ мәрхүм кичәге дустының «юлдан язуына» чынлап ышанган булса кирәк, «җидегәнчелек» фаш ителгәннән соң бер шагыйрьгә җавап итеп язган шигырендә ул Кутуйга шактый ямьсез исем тагып уза. Билгеле инде, кайберәүләргә Кутуйны үлгән Такташ янына якын җибәрмәс өчен бу да җитә кала. (Әнә бит Такташ үзе Кутуйдан ваз кичкән, янәсе!) Кыскасы, Такташның үлеме һәм аны җирләү Кутуйның әнә шундый бик авыр, мөшкел чагына туры килә. Әмма ул, һичнигә карамастан, Такташны озатырга килеп җитә, кусалар да, табуты артыннан бер адым да калмыйча ияреп бара, шагыйрьнең гәүдәсен җиргә биргән чакта, кысыла-кысыла булса да кабер якасында басып тора — күпме чыдамлык һәм «әрсезлек» кирәк булгандыр аңа?!. Үлмәскә тиешле дуслык хакына!

Әгәр Такташның гомере булып еллар узу белән «җидегәнчелек»нең принципсыз бер кешедән чыккан, соңыннан исә гаять күпертелгән уйдырма, юк бер эш икәнлеген белгәч, бик ихтимал, ул Кутуйдан үзе үк: «Кәбәм, кичер мине!»— дип гафу да үтенгән булыр иде. Әмма шагыйрьнең күзләре мәңге ачылмаска йомылган иде инде. Күп хәлләрне күрергә өлгермичә китеп барды ул бу фани дөньядан!

Әйтергә кирәк, Һади Такташның җеназа мәрасиме моңарчы күз күрмәгән дәрәҗәдә зур матәм белән узды. Декабрь көне шактый салкын булуга карамастан, халык урамны бөтен иңе белән тутырып, язгы ташудай агылып барды. Бигрәк тә укучы яшьләр, студентлар күп иде. Такташ аларның иң сөекле шагыйре иде ул заманда.

Матәм митингысы Ирек мәйданында үткәрелде. Кемнәрнең нәрсә сөйләгәнен хәтерләү мөмкин түгел хәзер, тик гарнизон начальнигы Якуб Чанышевның гына бик ялкынлы нотык тотуы ничектер истә калган. Митингтан соң күмү мәрасиме Арча кырына таба юнәлде.

Такташка әзерләнгән кабер хәзерге ял паркы эчендәге кечкенә зиратта иде — табутны иңнән төшермичә җәяүләп кенә шунда илттеләр. Анда да кемнәрдер нотык тотты. Ә кабер күмелеп беткәч, Якуб Чанышев китергән гарнизон солдатлары берничә тапкыр мылтыктан атып, шагыйрьгә соңгы хөрмәт салютын бирделәр.

...Җирләү шуның белән бетте, тәмамланды. Суык та көчәйде, өшеп бөрешкән халык та ашыгып тарала башлады. Элек кабер очында таза киенгән берәр чиста карт утырып кала торган иде. Янәсе, ләхетендә уянган мәетнең фәрештәләргә биргән җавабын ишетер өчен... Бусы бер әкият кенә... Әмма кеше мәет булса да ялгыз калмаган. Гүя ул үзе: «Китмәгез әле барыгыз да!» дип үтенгәндер кебек...

Көн әкрен генә сүнде, зират өстенә томанлы караңгылык иңде.

Шушы урында аз гына туктап торасым килә. Мине һаман бер нәрсә уйландыра: ни өчен мәрхүм Такташ үзенең әлеге җавап шигырендә Кутуйга махсус тиеп узды икән? Төп сәбәп нәрсәдә? Кутуйның «җидегәнче» булуы өчен генәме? Әлбәттә, чынлап ышанса, Такташның аңа мөнәсәбәте үзгәрмичә калмас иде, ләкин бит ул Кутуйны үтә яхшы белгән кеше, ачыктан-ачык аңа авыр сүз ташлаганчы, башта бик нык

[1] Бу мәсьәлә белән кызыксынган кешеләр шул еллардагы матбугатны актарып карасыннар.

уйларга тиеш иде кебек. Каләм язганны соңыннан балта белән дә юнып булмый диләр ич! Әллә тагын берәр төрле сәбәп булды микән? Әйтик, алар арасыннан элегрәк, «җидегәнчелек» ачылганчыга кадәр, берәр кара мәче йөгереп узмадымы икән? Кайчагында бик якын дуслар арасында да андый хәлләр булгалый бит. Хәер, бу очракта моны бик икеләнеп кенә фараз кылырга мөмкин... Ә бәлки Такташның үз хәле аны шулай каты әйтергә мәҗбүр иткәндер? Чынлап та! Алар арасында күптән килгән якын дуслыкны һәркем белә, ә хәзер исә Кутуйны әнә нинди ямьсез эштә гаеплиләр — я, ничек итеп аның турында дәшмичә калырга мөмкин ди?!. Моны бит көтеп торучылар да булгандыр, билгеле... Аннары Такташның үзенә һәм иҗатына кайбер вульгар тәнкыйтьчеләр тарафыннан бәйләнүләр дә һаман булып тора. Шулай ук ТАПП сафында да аны, берәүгә дә куймаган таләпләр куеп, зур кисәтү белән генә калдыралар. (Бу хакта ТАППны чистарту комиссиясенең йомгаклары белән танышырга була. «Атака» журналы, 1930 ел, 8—9 саннар).

Менә шундый шартларда яшәгән шагыйрьнең үзен акларга да, якларга да һәм үз нәүбәтендә бүтәннәрне аяп тормаска да мәҗбүр булуы гаҗәпмени?! Уйлап карагыз, шул ук 1931 елны Такташ үз әсәрләренең беренче томына язган сүз башында моңарчы иҗат иткән шигырьләренең басылырга хаклы һәм тиешле булуын исбат итәргә тырыша! Бу факт үзе генә дә күп нәрсәләр турында сөйли түгелме соң?!

Без, гомумән, Такташның тормыш юлын начар беләбез. Бигрәк тә соңгы гомерен һәм... вакытсыз үлемен диясем килә минем... Елларга бүлеп, айлап, атналап өйрәнелмәгән әле ул. Шуңа күрәдер инде күңелдә төрле уйлар туа һәм күп сораулар хәзергә җавапсыз да кала.

Гадел Кутуй Такташка караганда бер унбиш ел чамасы озаграк яшәде. Шул сәбәпле минем аның белән танышлыгым да якыннанрак һәм дәвамлырак булды. Дөрес, башта бу танышлык бик өстән генә иде; әлеге әдәби җыелышларга катнашып йөргәнлектән, мин аны беләм, ул мине күреп белә — бары шул кадәр генә иде. Аннары яшь аермасы да шактый зур, шуның өстенә исем ягыннан да безнең аралар ерак, бик ерак иде. Асылда мин әле бөтенләй «исемсез» диярлек, ә ул «Кутуй» дигән исеме белән әдәбият дөньясында шаулый иде инде. Татар поэзиясендә беренче футурист шагыйрь — һәрхәлдә, үзен шулай дип игълан иткән кеше. Кайнар заман. Кутуй шул чактагы әдәби хәрәкәтнең үзәгендә тора; трибунада ул, матбугатта ул — яза, бәхәсләшә, ярсый... Яшь, чибәр, гаять дәртле, энергияле, үзе бик оста оратор, тавышы көр, шигырьләрен ялкынлы пафос белән сөйли; күп укыган, бик күпне белә, русчасы шәп, татарчасы да әйбәт. Кыскасы, ул өстен, күп өстен иде бездән ул чагында.

Шулай да без, әйткәнемчә, таныш идек, әмма бу танышлык аратирә күрешкәләп һәм сөйләшкәләп йөрүдән узмады диярлек. Ә «җидегәнчелек» шау-шуы купкан вакытларда мин инде, гомумән, язучылар тирәсеннән шактый ераклашкан идем. Көндез меховойда эшлим, кичләрен хезмәтне фәнни оештыру институтында (бар иде шундый институт) укып йөрим, шул сәбәпле язучылар арасында кайнашырга вакытым да, әллә ни теләгем дә юк иде. Шулай да мин үземчә Кутуйны яхшы ук белә идем шикелле. Чөнки ул йомылып, серле кыяфәткә төренеп йөрүчеләрдән түгел иде. Бөтен бары белән ачык кеше, сүзгә юмарт кеше. Теләсә кем белән бик тиз таныша, бик ансат сөйләшеп китә. Теләсә кем алдында да үзен хөр, иркен тота, әмма һавалану яки ялагайлану кебек нәрсә юк иде аңарда. Сүзен, фикерен туры әйтергә ярата һәм... бик алай хәтер дә саклап тормый иде. (Хәер, бу сыйфат ул заманда күпләргә хас нәрсә иде.) Минем үземә дә аның туры сүзен

татырга туры килде. Мин бит баштарак зэгыйфь кенә нәсерләр язгалый идем. Мәхәббәт турында язылган шундый бер нәсеремне аңа да күрсәттем. Кутуй укып чыкты да туп-туры әйтте:

— Кемгә кирәк бу? Башка язар нәрсә тапмадыңмыни? Ташла!— диде. Һәм игътибарсыз гына нәсеремне кире үземә тоттырды. Билгеле, миңа авыр булды. Ләкин Кутуйдан мондый каты хөкемне ишеткәч, мин инде ул әйберне башка беркемгә дә күрсәтергә җөрьәт итмәдем.

Әйтергә кирәк, ул заманда мәхәббәтнең үзе турында гына язу мактаулы эштән саналмый иде. Язган чакта да аны, ягъни мәхәббәтне, производство белән яки сыйнфый көрәш белән бәйли белергә кирәк иде. Фатих дус та бит бер шигырен юкка гына «Машиналар арасындагы мәхәббәт» дип атамагандыр инде... Хәтта Такташның «Мәхәббәт тәүбәсендә» дә бу «бәйләү» бар: хәтерлисездер, аның кызы — комсомолка, ә егете — наборщик.

Гомумән, минем язу эше ул елларда бер дә көйләнә алмады. Язганым бик аз, булган кадәресе дә, нә эчтәлеге, нә формасы белән дигәндәй, игътибарны җәлеп итәрлек түгел иде. Дөрес, телең бар дип әйтәләр иде әйтүен, әмма бер тел белән генә ерак китеп буламыни?!. Кыскасы, мин ул чакта әдәбият дөньясына ничектер ансат кына кереп китә алмадым, хәтта керер-кермәс кире чыгып торырга да туры килде. Монда гаеп атта да, тәртәдә дә булгандыр дип уйлыйм.

Табигый, һәркемнең үз юлы, үз язмышы. Объектив һәм субъектив сәбәпләр билгели аны. Минем замандашларым арасында әдәбиятка шактый җиңел кереп китүчеләр һәм тиз арада танылып өлгерүчеләр дә булды. Күрәсең, аларның бәхетеннән әлеге ике төрле сәбәпләр үзара бик тәңгәл-туры килгәннәрдер инде. Менә шундыйлардан иҗат юлын аеруча уңышлы башлаган бер замандашым турында Кутуй хәтта: «Безнең әдәбиятта да Толстой кебек язучы туып килә», дигән сүзләрне дә әйткән иде. (1928 елны Лев Толстойның йөз еллыгына багышланган тантаналы җыелышта.) Мин үзем бу сүзләргә артык гаҗәпләнмәдем дә, чөнки, бердән, зур өметләр уяткан егетнең бик күтәрелеп барган чагы иде, ә икенчедән, Кутуйның кайчан шулай чаманы югалтып җибәрүен дә белә идем. Кызганычка каршы, бер мактауда гына түгел — шундый ук чамасыз, әмма кире мәгънәсендәге чыгышлары да булгалады аның... Ләкин аңардагы бу гадәтне бары аңа гына хас нәрсә итеп күрү дөрес булмас иде, чөнки чәчеп мактау яки бетереп ташлау үзенә күрә бер шаукым иде ул чакларда... Әйе, безнең әдәбиятка юлыбыз да, үсүжитлегүебез дә, шулай ук керткән өлешебез дә бер булмады. Чебешне көз көне санproblemлар. Менә яшәдек, көчебездән килгән кадәр яздык, әдәбиятыбызны күпмедер дәрәҗәдә үстердек, баеттык та шикелле, әмма беребез дә, мәгълүм ки, Лев Толстой була алмадык. Чак кына да ичмасам. Даһилар кабатланмый икән ул!

Такташны күмгәннән соң, мин Кутуйны шактый озак вакыт күрмичә тордым. Хәер, кайда күрәсең — үзем редакцияләргә барып йөрмим һәм, беләм, Кутуйның да ул тирәләрдән эзе суынган чагы. Урамда гына очратмасам, башка урын да юк. Әмма шулай да без Кутуй белән нәкъ шушы чорда ныграк танышып, якынаеп киттек. Моңа башлыча уртак танышларның булуы ярдәм итте.

Шуларның берсе — Шәйхулла Утяшев иде. Буйга озын-таза, төскә бик чибәр кеше иде ул, тик бер күзен кара материядән түгәрәкләп кискән япма белән каплап йөри иде. (Гражданнар сугышы вакытында әллә акларга, әллә кызылларга олаучы малай булып барган чагында пуля тиеп, бер күзен югалткан булган.) Минем замандашлардан аны бәлки хәтерләүчеләр дә бардыр әле, чөнки егерменче елларның урталарында Шәйхулла Утяшев та язучылар белән аралашып йөргән иде. Әдәбиятны бик яхшы белә иде ул — «Безнең юл»да аның иҗат психо-

логиясе турында язган бер мәкаләсе дә басылып чыкты. Кутуй белән алар педагогия институтында бергә укыганнар, күптәнге танышлар. Ләкин мин Шәйхулла белән якыннан аралашып йөри башлаган чакта, ул инде математика укытучысы иде. (Мин үзем дә аңардан математика дәресләре алып йөрдем.) Шуны әйтергә кирәк, башта әдәбият белән мавыгып та, соңыннан теге яки бу сәбәпләр аркасында бүтән тармакка күчүчеләр безнең заманда аз булмады. Саный китсәң, аларны шактый җыярга була. Хәер, һәр заман өчен дә бу табигый күренеш булса кирәк, чөнки сәнгать белән әдәбият претендентларны нечкә иләктән үткәрергә ярата. Аннары кешенең теләге белән мөмкинчелеге дә күп кенә очракта туры килеп бетми. Туры килсә дә, төшеп калуың бар — тормыш ул һәр вакытта бездән көчлерәк.

Шәйхуллада Кутуй белән кайчан очрашуымны хәзер инде төгәл генә әйтә алмыйм. Һәрхәлдә, утыз өченче елдан да иртәрәк булмаска тиеш. Әйткәнемчә, безнең очрашмаганга шактый вакыт узган иде. Шулай да мин Кутуйда бертөрле дә үзгәреш тапмадым диярлек. Ә бит шундый көтелмәгән зур бәхетсезлек һәм авыр кичерешләрдән соң аның эчке халәтендә нинди дер үзгәрешләр булырга тиеш иде. Булмыйча калуы мөмкин дә түгел. Әмма тыштан элекке Кутуй! Дәртле, көләч, хәрәкәткә җиңел, сүзгә юмарт!.. Ихтимал, ул эчендәгесен яшерә белгәндер, ихтимал, мин дә күрә-сизә белмәгәнмендер. Ничек кенә булмасын, мин менә хәзер күпме генә уйлансам да, аның зарланып яки акланып сөйләгәнен һич тә искә төшерә алмыйм. Бәлки вакыт дигән нәрсә аны тынычландырып өлгергәндер, чөнки «җидегәнчелек» вакыйгасыннан соң ике ел чамасы үтеп киткән иде инде. Юк, шулай да бу вакыйга турында сүз булмыйча калмагандыр, ышанмыйм, әмма... онытылган, бары Кутуйның гадәттәге көләч йөзе дә дәрт бөркеп торган какча кыяфәте генә истә калган.

Шулай ук Такташ турында да... сөйләшмичә калу мөмкинмени?! Һәрхәлдә, мин үзем сүз ачмыйча калмаганмындыр инде. (Такташны күмгән чакта ни булганын искә төшерү дә җитә бит). Әмма кырык биш ел вакыт узганнан соң, Такташ турында Кутуй фәлән әйтте, тегән әйтте дип аның исеменнән сүз сөйләргә мин җөрьәт итә алмыйм. Тик шуны гына әйтә алам, Кутуйдан Такташка карата мин начар сүз (мәсәлән, хәтере калудан үпкәләү, рәнҗү кебек сүзне) ишетмәдем, ишетсәм — андый сүз хәтердә ничек тә сакланыр иде. Заман алар арасын бутап ташласа да, үлгән Такташ белән тере Кутуйны бер-берсенә каршы кую, минемчә, мөмкин түгел иде.

Әйткәнемчә, Кутуйның кәефе әйбәт иде. Бер очрашуны әле дә булса оныта алмыйм. Июнь аеның иркә-йомшак, таманча гына эссе, бик матур бер көне иде. Табигатьнең әле кул тимәгән яшь, саф, ләкин инде тулыланып, җитешеп килгән чагы. (Һәм кешеләрне дә яшәртә торган чак). Нәкъ шундый көнне без өчәү — Кутуй, Шәйхулла, мин — ничектер туры килеп очраштык та, гүя алдан сүз куешкандай, кая да булса шәһәр читенәрәк чыгып китәргә уйладык. Билгеле, буш кул белән генә барасы килми иде, әзрәк капкаларга анысын-монысын да алырга булдык. Кесә төпләреннән акчаларыбызны кырыштырып чыгардык, ләкин, һәр вакыттагыча, акчабыз җитәрлек түгел иде. Шуннан Кутуй гадәттәге өлгерлеге белән: «Туктагыз, мин өйгә кереп чыгыйм әле»,— диде. Ул чакта аның квартирасы Комлев урамында, ишегалдындагы бер агач йортта иде. Шунысы кызыклы, бу йортның капка номеры да җиде иде. Туры килүен кара син!.. Кутуйның көлгән булып, әмма ачынып: «Бу каһәр суккан җиде» дән минем котыласым юк, ахрысы»,— дип әйткәне дә бар.

Кутуйның чыкканын без урамда көтеп тордык. Бераздан ул чыкты, ләкин акча урынына бүлмә ишегенә кертеп куела торган зур гына бер

йозак күтәреп чыккан иде. «Менә шуны илтеп сатабыз!»— диде ул, малайларча бер ваемсызлык белән. Өчәүләшеп Чехов базарына таба киттек — ул елларда «Толкучка» да шунда иде. Тимер-томырлар рәтендә йозакны күрсәтеп йөри торгач, без аны бер татар агаена күпмегәдер саттык та. Иш янына куш булды һәм без бар акчабызга яшел суган, пешкән йомырка, кара икмәк, аннары юл өстендәге кибеттән бер шешә кызыл шәраб та алып, рус зиратына таба атладык. Зиратны үтеп, Казанкага караган тау битенә чыктык та шундагы яшел чирәмгә бик әйбәтләп кенә аякларны сузып урнаштык. Кутуй өеннән бер кечкенә стакан да эләктерергә онытмаган икән, шуның белән кызыл шәрабны чиратлашып, ашыкмыйча гына эчә-эчә, әңгәмәгә керешеп киттек. Бу урында шуны әйтергә кирәк, Кутуй эчү белән һич тә мавыга торган кеше түгел иде. Эчкәндә дә бик аз эчә һәм шул аздан да бик тиз кәефләнә иде. Бүген исә аның бу «эчүне» оештыруда активлык күрсәтүе, бердән, компания өчен булса, икенчедән, бәлки җәй башының шушы гаҗәеп матур тансык көне өчен дә булгандыр. (Мондый көнне үтә тәүфыйк иясе дә азрак кәефләнеп утырудан тыела алмас иде. Безнең инде әйткән дә юк!) Шулай да йозак сатып, шәраб алу бу, башлыча, очрашу шәрәфенә иде. Шәйхулла Кутуйның күптәнге дусты, минем белән дә беренче тапкыр гына утыруы түгел. Безнең аралар әкренләп якыная, гадиләшә бара. Сүзләр дә килешә кебек, һәрхәлдә, минә шулай очрашкан чакларда без бик теләп, иркенләп ачык сөйләшәбез. Минем аңа мөнәсәбәтем элек тә, хәзер дә бер төсле, ягъни бернинди конъюнктура белән бәйләнмәгән, ул шуны сизә һәм үз нәүбәтендә миңа карата да ышану, үз итү күрсәтергә тырыша иде. Билгеле, бүгенге очрашу да әнә шул әкренләп туып, ныгып килгән дуслыкның дәвамы иде. Тау битендә кырын ятып «сыйланган» чакта Кутуй миңа, иске портфеленнән чыгарып, бер фоторәсемен дә бүләк итеп бирде. Рәсем артына түбәндәге сүзләрне язган иде: «Янәкәй иптәшкә истәлек — йозак истәлеге. Г. Кутуй 18.6. 33».

Әмма бу очрашуның чын яме, мәгънәсе үзара ашыкмыйча, иркен генә сөйләшеп утыруда иде. Гәп нәрсә турында? Замана турында, агымдагы вакыйгалар турында, әдәбияттагы хәлләр турында, ихтимал, хатын-кыз турында да. Кемнең ни сөйләгәнен хәзер искә төшерү һич тә мөмкин түгел, ләкин сүзнең нәкъ әнә шул темалар тирәсендә әйләнгәнен бер дә шикләнмичә әйтергә була. Чөнки болар «мәңгелек темалар», чөнки без балигъ булганнан бирле шулар турында уйлыйбыз һәм җай чыккан саен дуслар үзара сөйләшәбез. Менә илле ел инде...

Кутуйны тыңлавы күңелле. Тиз сөйли, ачык сөйли, кызыклы итеп сөйли ул. Еш кына зур фикер ияләренең, мәшһүр язучыларның әйткән сүзләрен кулланырга ярата. Хәтерем ялгышмаса, ул андый кешеләрнең тирән мәгънәле тапкыр сүзләрен махсус дәфтәргә язып та бара иде шикелле. Ничек кенә булмасын, Кутуй тыңлаучыны авызына карата белә иде. Дөрес, аның һәр әйткәне белән килешмәскә дә мөмкин, еш кына бәхәсләшәсе дә килеп китә — ул бит үзе дә бәхәсләшергә бик ярата иде. Үз сүзендә нык торып, ләкин каш җимереп түгел, елмаеп кына. Ә елмаю аның кыяфәтендәге иң характерлы билгесе (чалымы), хәтта урам буйлап кызу-кызу ялгыз китеп барган чагында да йөзеннән елмаю китми — шулай сакланып калган ул минем күз алдымда.

Тау битендә күңелле сөйләшеп, кәефләнеп утырганнан соң Кутуй белән без тагы да якыная төштек. Без инде хәзер очрашканда исәнләшеп узып китүчеләр генә түгел, ә күпмедер дәрәҗәдә дус, үз кешеләр — һәр вакытта туктап, хәл-әхвәл сорашып, сөйләшеп тә торабыз. Ничектер көтеп, теләп алынгандай була иде бу иттифакый очрашулар— һәрхәлдә, минем өчен ул шулай иде.

Мин инде аның өенә дә баргалый идем. Капкасына «7» каккан агач өйгә барып керү белән нәкъ каршыда гына озынча, таррак бүлмә — Кутуйның эш бүлмәсе. Сул кулда ялан кадәр зур зал, анда Галимә ханым балалары белән. Сары бөдрә чәчле бик матур кыз бала хәтеремдә калган.

Бүлмәдә стена буйлап әллә кушетка, әллә тар гына караваг, кечкенә өстәл һәм бер генә урындык тора. Кутуй үзе кушеткага күчеп, урындыгын миңа бирә. Сөйләшеп китәбез...

Бәлки нәкъ шушы урында әйтергә кирәктер, Кутуй язучылар тирәсеннән китеп торырга мәҗбүр булса да, үзен әдәбияттан киткән кеше дип һич тә санамый иде. Юк, китү турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Ул әдәбият белән яши, әдәбият дөньясындагы бөтен яңалыкларны белеп тора, һәм иң мөһиме — ул яза, уңга-сулга карамыйча яза. Әлбәттә, ул әдәбиятка кайтачак! Мәсьәлә тик вакытта гына.

Ә хәзергә әле ул шул ук тел-әдәбияттан укытып йөри (мәсәлән, төзүчеләр институтында) һәм үзенә хәерхаһ яки аңардан читләшмәгән кешеләр белән бик теләп аралаша, йөрешә дә иде. Менә безнең арада башланган якынлашу да тора-бара гаилә мөнәсәбәтләренә дә күчте; Кутуй Галимә ханым белән бездә бер-ике тапкыр кунакта булды, мин дә хатын белән аларда кунакта булгаладым.

Аннары, минемчә, Кутуйның театр дөньясы белән дә арасы бер вакытта да өзелеп тормады. Әүвәлгечә ул театраль кеше, спектакльләрне калдырмый, артистлар белән дә һаман яхшы, якын мөнәсәбәттә. Бу уңай белән кызыклы бер эпизодны искә төшерәсе килә. Шул елларда кайбер артистлар карта уйнау белән мавыгып киткәннәр иде. Ял көннәрендә яки спектакльдән буш кичләрдә әле берәүнең, әле икенченең квартирасына җыелып, бик иркенләп карта сугарга утыралар. Моңа һәр даим актив катнашучылар Сәет Булатов, Гали Ильясов, Шакир Шамильский һәм театрның баш художнигы Мортаза Абдуллин иде. Мортаза минем бик якын дустым иде, шуңа күрә аңа җыелганда мин дә уенга катнаша идем. Уен, билгеле, акчага — «Рамс» дигән гади бер уен. Менә шушы уенга бер-ике тапкыр Кутуй да катнашты. Ләкин картадан бәхете юк икән — гел оттыра иде ул. Һәм бу гаҗәп тә түгел иде. Чөнки карта уены кешенең характеры белән бик нык бәйләнгән. Кутуй кебек тынгысыз, сабырсыз кеше бер вакытта да чынлап уйный да, юньләп ота да алмый ул. Ә менә*мәрхүм Сәет Булатов һәр вакытта да ота торган иде. Кутуйның бәхете, күрәсең, башка нәрсәдә булгандыр.

Заман дәрьясы ургылып, сикереп ага. Берәүләр өскә калка, икенчеләр төпкә китә. Ул да булмый, өстәгеләр төпкә чума, ә төптәгеләр өскә сикереп чыга. Шулай ага заман дәрьясы!

Утыз бишенче елның көзендә, ниһаять, Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы басылып чыкты. Әсәр шунда ук игътибар үзәгенә дә эверелде. Ябырылып укый башладылар, телдән төшмәс булды, хәтта геройларның прототипларын да эзләргә тотындылар. Әсәр бит мәхәббәт турында, яхшы хатын белән шактый тотрыксыз ир турында, ә бу ул еллар әдәбиятында сагындырган, тансык тема иде. Шуның өстенә повесть, исеменнән күренгәнчә, укыр өчен җиңел алым белән (хатлар рәвешендә) язылган да. Кыскасы, «Тапшырылмаган хатлар» Кутуйның моңарчы язган әсәрләре арасында иң уңышлысы һәм отышлысы булып чыкты. Бәлки шуңа күрәдер, ул инде бу әсәреннән соң вакытын һәм көчен поэзиядән бигрәк прозага бирә башлады.

Шулай итеп, Кутуй берни булмагандай, яңадан әдәбиятка килеп керде, яңадан үз урынына кайтты, элекке шикелле яңадан популяр язучыга әйләнеп китте. Дәрт, энергия, үзенә бик нык ышану — Кутуйдагы менә бу сыйфатлар аңа түзәргә һәм җиңәргә, теләгенә ирешергә

мөмкинлек бирде. Рухи какшамау, нык булу иҗат кешесе өчен иң зарури нәрсә икән ул!

Кызганычка каршы, Кутуйның эшләре җайлангач, безгә озак аралашырга туры килмәде. Утыз алтынчы елның җәендә мин Казаннан китеп бардым. Гомумән, ул елларда миңа күбрәк читтә яшәргә туры килде. Шул сәбәпле Кутуй белән дә арабыз өзелде.

Соңгы очрашуыбыз безнең сугыш башланган көннәрдә булды. Мин янарак кына Урта Азиядән кайткан идем. (Сугышның башлануын да юлда гына ишетеп белдем). Билгеле, бик киеренке, бик борчулы көннәр иде. Сугыш бездән каядыр еракта башланса да, һәркем аның дәһшәтен сизә, һәркем бары шул хакта гына уйлана иде: чын сугышмы, зур сугышмы бу, озакка барырмы, кайчан бетәр ул? (Ә җиңү мәсьәләсенә килгәндә, бу хакта ике төрле фикер юк иде кебек: күпләр сугышның көзгә чаклы ук инде безнең җиңү белән бетәчәгенә бик нык ышанып торалар иде. Хәтта немецларның бөтен чикләр аша безнең илгә утлы ташкындай ургылып керүләренә дә карамастан). Шул ук вакытта һәркем үз язмышы, үз хәле турында да уйланырга мәҗбүр. Шәһәрдә бик кызу мобилизация бара, кешеләр военкоматтан чакыру көтә, мин дә шуны көтеп йөрүчеләрнең берсе идем. Кайчан чакырырлар, кайчан алырлар, кая җибәрерләр — менә нәрсә бер дә баштан чыкмый иде.

Ихтимал, шушы эчке киеренкелек, борчылу-уйланулар аркасындадыр инде, кайткач та кемнәр белән очрашуым,ниләр күрүем ничектер ачык кына хәтердә калмаган. Әмма Кутуй белән очрашуыбыз хәтеремдә яхшы сакланган, чөнки бу очрашу үзенә күрә кызыклы гына булды. Ул көннәрдә язучылар Матбугат йортына күп йөриләр иде. Кайсылары газетага тиз генә нидер язып китерә, кайсылары редакция кушуы буенча хәбәр-информация ташый, ә бүтәннәр, эшләре булса-булмаса да, бер-берсен күрер өчен, яңа хәбәрләр ишетү өчен Союз идарәсенә киләләр. Мин дә яңа гына кайткан эшсез кеше булгач, шул тирәгә баргалап йөрим. Менә шундый кызу көннәрнең берсендә без Кутуй белән Матбугат йортының ишек төбендә очраштык. Ул мине күрү белән үк гадәтенчә кычкыра биреп: «Һа, Янәкәй, син түгелме соң бу?!» — дип, ашыгып яныма килде. Без дусларча кулларны кысып, җылы гына күрештек. Миннән кайчан, кайдан кайтуымны тиз генә сорашып алды. Кутуй һәр вакытта берәр эш белән ашыгып йөри торган кеше, мин инде безнең беренче күрешүебез шушы кыска гына сүз алышу белән бетәр дип уйлаган идем, ләкин ул бу юлы Матбугат йортына кереп тормыйча, мине ни өчендер колхоз базарына таба нәртеп алып китте.

Казанда әле тормыш искечә бара, магазиннар ачык, ашханәләр, рестораннар ачык, базары да гөрләтеп сатуын итеп ята. Кутуйдан кайчагында балаларга хас сәер генә эшләр чыгып куйгалый иде. Менә ул мине катык-сөт сатучы апалар янына алып барды да, очрашу шәрәфенә дигәндәй, шуларның берсеннән ике шешә кайнаган сөт сатып алды. Аннары бер буш прилавка табып, аякларыбызны салындырып утырдык та, шешә авызыннан гына бөрчекле куе сөтне тәмләп эчә-эчә, сөйләшә башладык. Дөресрәге, ул миңа сөйләргә кушты. Нәрсә сөйлим соң дигәч, ул: барысын да, диде: кайларда булдың, ниләр күрдең, нәрсәләр эшләдең, берсен дә калдырма!.. Хәзерге шартларда үткән эшләрне сөйләп утыруның хаҗәте юк та кебек иде, шулай да мин аңа үз хәлемне кыскача гына сөйләп бирдем. Шуннан соң ул миннән, инде монда нишләргә уйлыйсың? дип сорады. Менә военкомат чакыруын көтеп йөрим, дидем мин. Сүз, билгеле, шунда ук бүгенге гадәттән тыш хәлләргә күчте. Сугыш башланганга күп булса бер атна чамасы вакыт узгандыр, әмма ул инде һәркемнең язмышын үзенә бик нык бәйләп өлгергән иде. Тик ачык кына белеп булмый әле: ни дәрәҗәдә куркыныч бу һәм озакка барырмы икән? Кутуйның бу турыда нәрсә әйткәнен хәтерлә-

мим, ләкин истә калганы шул — мин аңарда артык хәвефләнү, борчылу кебек нәрсә сизмәдем. Хәер, бу сугышның нинди сугыш буласын аңлап житкермәү һәм шуңардан туган беркадәр ваемсызлык ул көннәрдә бик күпләргә хас иде шикелле.

Әле дә хәтеремдә, нәкъ шул көннәрдә күз күргәнрәк бер иптәш миннән сорый:

— Таранның нәрсә икәнен беләсеңме?— ди.

— Юк, белмим,— мин әйтәм.— Нәрсә соң ул таран?

— Таранмы? Ха, ул шундый коточкыч нәрсә, әгәр безнекеләр аны ходка жибәрсәләр, фашистларның бөтенесен таптап-изеп бетерәчәкләр!

Озак та үтми, бу иптәш үзе дә фронтка китеп барды. Дүрт елдан соң без яңадан очраштык. Ул кырык беренче елның каты сугышларында булган, аннары пленга эләккән, фашистлар лагеренда яткан, ахырда лагерьдан качкан, партизаннарга кушылган. Сугышны да партизан булып тәмамлаган. Менә аның дүрт ел эчендә фронтларда үткән юлы. Хәзер инде таран турында ләм-мим, таран күптән онытылган. Чөнки сугыш турында башта уйлаган белән соңыннан үзең күреп белү ул — жир белән күк арасы. Хәер, бу урында аны гаепләп буламыни? Дошманны жиңү мәсьәләсендә ул түгел, кайбер маршаллар да заманында ялгыштылар. Ә нинди михнәт-авырлыклар кичереп, күпме корбаннар бәрабәренә без фашистларны жиңүгә ирештек — моны кырык бишенче елны инде жиде-сигез яшьлек бала да белә иде.

Өстәп тагын шуны әйтәсем калган, минем таныш егетем зур бер аманәт белән кайткан иде. Ул Абдулла Алиш белән бер лагерьда булган икән. Моның качарга жыенганын белгәч, Алиш аңа әйткән: әгәр исән-сау илгә кайта алсаң, хатынымны табып, аңа һәм балаларыма минем сәламемне тапшыр, мондагы хәлемне сөйлә дигән. Егет шул аманәтне житкерергә теләвен миңа белдерде. Һәм мин Рокыя ханымны чакырып, аларны күрештергән дә идем. Соңыннан ул егет каядыр гаип булды. Аның әллә исеме Исмәгыйль, әллә фамилиясе Исмәгыйлев иде — хәзер инде, утыз елдан артык вакыт узгач, ачык кына хәтерли дә алмыйм.

Булмаса тагын сугышның башына күчик әле. Колхоз базарында Кутуй белән кайнаган сөт эчә-эчә дусларча ачык кына сөйләшеп аерылышканнан соң, берничә көн узгач, Тукай клубында жыелышып, Сталинның халыкка мөрәжәгатен тыңладык. Бик нык истә калды бу вакыйга... Мөрәжәгатьне трибунадан Кутуй укыды. Бөтен кеше аны шылт та итмичә тыңлап торды. Сталинның һәр сүзен ул чакта ничек кабул итүебезне әйтеп тору кирәк микән?! Пәйгамбәр сүзе дә андый кодрәткә ия булмагандыр. Шуның өстенә Кутуйның көчле-көр тавыш, ачык дикция белән, берниндн акцентсыз, ноктасын ноктага, өтерен өтергә туры китереп укуы да тыңлаучыларны беткәнче биләп алды. Уку беткәч тә әле алар күпмедер вакыт тып-тын калып, селкенергә дә кыймыйча тордылар. Әмма эмоциональ тәэсирдән тыш Сталин мөрәжәгате безгә — моңарчы жиңелрәк уйлап йөргән кешеләргә сугышның искиткеч колачын, дәһшәтен, ил өстенә нинди зур, житди куркыныч килүен, һәрбер кешене нинди авыр, жаваплы сынау көтүен беренче мәртәбә бөтен тирәнлеге белән ачып бирде. Юк, бу сугыш турында хәзер: «Менә тиздән бетәр, фашистларны безнең армия ике-өч ай эчендә тар-мар итеп ташлар», дип һич тә уйларга ярамый иде. Шул ук вакытта Сталин үзенең мөрәжәгатендә: «Жиңү безнең якта булачак!» — дип, бик нык ышанып һәм ышандырып әйтә. Бу мөрәжәгатьне тыңлаганнан соң кешеләр ничектер бердән житдиләнеп киткәндәй һәм уйчанланып калгандай булдылар.

...Язучыларның күбесе үз эшләрендә, фронтка китмәгәннәр иде әле. Мин белгәннәрдән тик Муса гына юк, Муса гына бик иртә китеп бар-

ган. Миңа инде аны күрергә туры килмәде. Үз хәлем дә әллә ничек шунда, чакыру көтеп, һаман эшсез йөрим. Шулай каңгырып йөргәндә Мин Шабайны очратып, аның белән танышып киттем. Кыю, үткен егет иде ул бу чакларда. Кайсыдыр газетага көн дә хәбәрләр ташый — мин дә аңа ияреп, фабрик-заводлардагы митингларга баргаладым. Ләкин болай, ятим бозау шикелле, кешегә тагылып йөрү эш түгел иде. Ә чакыру килми дә килми. Азмы-күпме алып кайткан акчам да бетте диярлек. Яшәү турында нидер уйларга кирәк иде. Ахырда мин Наркомпроска барып, үземә эш сорадым. Нарком урынбасары — ялгышмасам, Мөэминов дигән кеше — күп сөйләшеп тормыйча, мине Татарстанның бер районындагы ятим балалар йортына эшкә җибәрергә булды. Кулыма приказ бирделәр һәм, иртәгәдән калмыйча, чыгып китәргә дә куштылар. Мин эшкә урнашуыма куанып, өйгә кайттым да, юлга чыгарга кичтән үк әзерләнеп, үзебезнең бакчада йокларга яттым. Ә иртән иртүк, әле кояш та чыгып өлгермәс борын, инәй килеп, мине әкрен генә уятты.

— Улым, тор әле, менә язу калдырып киттеләр,— диде ул борчылуын сиздергән тавыш белән.

Мин, күземне ачып, аның кулындагы язуны алдым. Бу военкоматтан килгән повестка иде. Һәм бу көн унсигезенче июль көне иде. Язмыш!.. Шулай итеп, мин, бүген районга чыгып китәсе урынга, повесткада кушылган кружка, кашык һәм бер пар чиста күлмәк-ыштан алып, военкоматка киттем. Шул китүдән инде мин өйгә яңадан кайта алмадым. Татвоенкоматның зур ишегалдында берничә көн торганнан соң, безне төнлә белән сафларга тезеп, вокзалга алып киттеләр. Төн уртасы булуга карамастан, военкомат капкасы төбендә бихисап халык җыелган иде. Әниләр, апалар, сеңелләр, сөйгән ярлар, якын туганнар колоннаның ике ягыннан урам тутырып, кыюраклары исә сафлар эченә дә кереп, китүчеләрнең беләкләренә тотынып, иңнәренә сарылып, кызу атлаудан тирләп-пешеп, төенчекләре белән вокзалга чаклы озата бардылар. Минем хәлем җиңелрәк иде — озатучы булмады. Өйдәгеләр белмичә калдылар... Аннары безне кызыл вагоннарга төяделәр дә, сызылып кына таң аткан чакта фронт тарафларына алып киттеләр.

Әнә шул сугышның беренче көннәрендә очрашканнан соң миңа инде Гадел Кутуйны яңадан күрергә дә, аның белән хәбәрләшергә дә туры килмәде. Дөрес, фронттан мин аңа бер хат язган идем, әллә алган, әллә юк — белмим, ләкин аңардан хат-хәбәр булмады.

Мәгълүм ки, Кутуй кесәсендә бронь булуга карамастан, үз ирке белән фронтка киткән кеше, гади солдат булып, дошманга каршы сугышкан, батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнгән, ниһаять, фронтта партия сафына кергән, кыскасы, үзен чын патриот итеп күрсәткән кеше. Җиңү көнен күрү бәхетенә дә ирешә иде ул... Бәлки без аны югалтмаган да булыр идек, әгәр дә ки...

...Кутуйның әлеге бер дә яратмаган, шомланырга мәҗбүр иткән «7» саны һич көтмәгәндә аны тагын бер мәртәбә үзенең ыргагына эләктерә. Монысын инде миңа мәрхүм Гази Кашшаф сөйләде. Кырык дүртенче елның көзендә булса кирәк, Кутуй кыска гына вакытка Казанга кайткач, аны армия сафыннан алып, сәнгать эшләре идарәсенең начальнигы итеп куймакчы булалар. Кандидатура бик лаеклы — Кутуй сәнгатьне бик яхшы белә, үзе бай эрудицияле, гаять уңган эшлекле кеше иде. Ләкин аның кандидатурасы югары бер урында расланырга тиеш була. Менә шул раслау вакытында кемдер бик җитди генә: «Ул бит «җидегәнче!» — дип әйтеп куя. Һәм шушы бер сүз Кутуйның язмышын хәл итәр өчен җитә кала. Ул яңадан фронтка китеп бара. Ахырын без беләбез — фронт шартларында каты авырып, кыска гына вакыт эчендә ул үлеп үк китә... Әйе, әгәр дә ки... «Әгәр дә ки» — бик үкенечле сүз!

Инде иң соңгысы. Фронтта чакта мин кайбер күргән төшләремне язып куя торган идем. Бу гадәтемне фронттан кайткач та тиз генә ташлый алмадым. Менә бер аерым кәгазьгә түбәндәге шушы төшемне дә язып куйганмын. Вакыйгасын һич үзгәртмичә, тик тел җәһәтеннән аз гына төзәткәләп, минем аны бирегә дә күчерәсем килде.

«Казан вокзалы, имеш. Ләкин мин күреп өйрәнгән вокзалга ничектер бер дә охшамаган. Өстәвенә, вокзал алдындагы мәйданны да биек такта койма белән әйләндереп алганнар. Менә шул мәйданга мин әллә кайдан гына килеп кердем. Ерак та түгел бер эскәмия янында Кутуй басып тора, имеш. Җирдә чемоданы, солдат капчыгы, ә эскәмиядә, кулына яшь кенә бала тотып, Галимә ханым утыра, имеш... Ашыгып, Кутуй янына бардым... Башта без кочаклаштык, аннары, кулларыбызны җибәрмичә, озак кына бер-беребезгә карашып тордык. Кутуй кара костюмнан, яланбаш, кысыла төшкән кара күзләре миңа нигәдер бик җитди карыйлар... Ул бер дә үзгәрмәгән, ябыккан дип тә булмый, тик шунысы гаҗәп — бите аның шадра, имеш. Әмма шадрасы килешә икән үзенә.

Мин Кутуйның үлгәнен беләм икән инде, шуңа күрә аның вокзалга төшүе турында эчемнән генә болай уйлыйм, имеш: «Менә ул яңадан бер вакытта да әйләнеп кайтмас, мәңге торыр урынына китәр өчен төшкән. Шуңа ул бик җитди, шуңа кайгылы...»

...Без шактый озак карашып тордык. Әмма ләкин ул миңа бер сүз дә әйтмәде, мин дә аңа бер авыз сүз әйтә алмадым.

Галимә ханым эскәмиядә башын күтәрмичә елап утыра. Аның кыяфәте бөтенләй үзгәргән — озынча битле, ябык, кара хатын, имеш».

Бу төшне мин кырык биш енче елның унсигезенче июлендә, ягъни Кутуй үлгәннән соң бер ай вакыт узгач күргәнмен һәм шул ук көнне язып та куйганмын. Кайчагында уйлаганың төшкә керә, диләр. Бик мөмкин, чөнки ул чакта без югалган якын кешеләребез, дусларыбыз, иптәшләребез турында еш кына уйлана идек әле.

1977 ел, август.

Равил Кукушкин

# ВИТАМИНЛЫ ШИГЫРЬЛӘР

*Иҗат портретына эскизлар*

1957 елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында яшь шагыйрь Шәүкәт Галиев лирик шигырьләр авторы буларак катнаша. Бирегә ул, үз тавышын ишеттерү белән бергә, каләмдәшләренең һәм, гомумән, бөтен татар сәнгатенең үсешен дә өр-яңадан күздән кичерү бәхетенә ирешә. Күренекле балалар шагыйре Бари Рәхмәтнең дәртләнеп-илһамланып, елмая-елмая, шигырьләр сөйләвен Ш. Галиев аерым бер эчке дулкынлану, ләззәтләнү хисе белән тыңлый. Өлкән каләмдәшенең шигъри талпынышы яшь шагыйрь күңелендә нindидер серле бер көч уяткандай тоела, аны үзе артыннан яңа киңлекләргә чакырып ишарәли...

Әнә ул, сүзсез генә башын иеп, әле берничә сәгать элек үзе сокланып тыңлаган шагыйрьнең гәүдәсен самолетта Мәскәүдән Казанга алып кайтыша... Шигъри эстафетаны тапшыру өчен язмыш әйтерсең лә алдан шундый шартлар әзерләп куйган... Олы шагыйрьнең әлеге биеклектә, шигырьләре очышын дәвам итәргә теләгәндәй, соңгы тапкыр тирбәлүе гүя яшь каләмдәшенә үзе яулаган биеклекне күрсәтү өчен кирәк. Яшь шагыйрь исә, булачак остазы белән бергә, әйтерсең үзенең төп шигъри очышына әзерләнә... Кем белә, шагыйрьдә юморга һәм балалар әдәбиятына булган олы мәхәббәт очкыны да беренче тапкыр чын-чынлап әнә шунда кабынгандыр...

Һәм инде менә егерме ел буе ул, шигъри эстафетаны дәвам итеп, үстерә килә. Балалар поэзиясе Ш. Галиев иҗатының төп көзгесе ул. Бүгенге көнгәчә чыккан утыз китабының егермесе балаларга адресланган булуы да, нәкъ шушы өлкәдәге уңышлары өчен 1972 елда аңа республикабызның Г. Тукай исемендәге премиясе бирелү дә шул хакта сөйли. Һәм, әлбәттә, барыннан да элек, бу турыда аның әсәрләре, шигырьдән-шигырьгә үсә-ачыла барган осталыгы сөйли.

Лирикада да, юмор өлкәсендә дә үз тавышын тапкан шагыйрьнең шигъри таланты ни өчен шушы юнәлештә үсеп китте соң? «Яңа көйләр» исемле беренче китабы турында ук Әхмәт Фәйзи: «Ш. Галиевнең җыентыгы безнең поэзиядәге бик күп бертөрле иске көйләр арасында үзенә колак салырга мәҗбүр итә торган «яңа көйләр» булып яңгырый»,— дип язган иде. Шагыйрьнең «Әткәйгә хат» поэмасы, лирик җырлары, балладалары, хикмәтле шигырьләре, шулай ук «Сөзгәк үгез маҗаралары» исемле юмористик поэмасы, «Фокусник килгән авылга», «Шалт, Мөхәммәтҗан», «Мәхәббәт уставы» һәм башка бик күп юмористик шигырьләре күптән инде укучыларның яраткан әсәрләре булып әверелде. Ләкин, минемчә, Ш. Галиевнең лирикасы — аның үз уңышы булса, юмор-сатирасы — татар поэзиясенең уңышы. Соңгысы әле бөтенләй диярлек бәяләнмәгән, ләкин, һичшиксез, безнең татар әдәби тәнкыйте ул хакта үз сүзен бер әйтер. Инде шагыйрьнең балалар өчен язылган шигырьләренә килгәндә, алар — моны һич икеләнмичә әйтергә мөмкин — күп милләтле совет балалар поэзиясенең иң матур үрнәкләре рәтенә куярлык, аның уңышы итеп бәяләнерлек әсәрләр.



Димәк, Ш. Галиев иҗаты турында сөйләшкәндә иң элек балалар өчен язылган әсәрләренә тукталабыз икән, бу аның иҗатын чикләү түгел, ә бәлки үткән һәм әле үтәчәк шигъри очышын бөтен дәвамлылыгында һәм биеклегендә бер бөтен итеп күрү теләге.

Ш. Галиевкә кадәр балалар шигъриятендә төп игътибар балага тормыш турында төшенчә бирүгә — аны табигать, җәнлекләр, кеше, хезмәт-профессия, туган ил, бәхетле бала чак һ. б. белән таныштыруга юнәлдерелә иде. Ә балалар психологиясен ачу, ничектер, иненче пландарак кала килде. Заманның күтәренке рухын, ирекле күмәк тормыш матурлыгын балалар күңеле аша ачып бирүче шагыйрьләрнең берсе Б. Рәхмәт булды.

Ш. Галиев балалар поэзиясенә әнә шушы кыйммәтле һәм төп үзлекне югалтмаска, аның үстерелергә тиешлеген аңлап килде. Тик ул тематиканы шушы яссылыкта төрлеләндерү юлыннан китмәде — үзенчәлекле юмористик танып белү аша чынбарлыкның яңа катламнарын тикшерергә керешә. Аңа эзләнергә, иҗади экспериментлар үткәрергә, аларны вакыт сынавы аша уздырырга кирәк иде. Ул турыдан-туры татар балалар поэзиясе традициясенә: фольклор, Тукай, Ә. Фәйзи, Б. Рәхмәт иҗатларына таянды.

Ш. Галиев шигырьләре күктәге йолдызлар кебек сибелеп, төрлесе төрле зурлыкта, төрле яссылыкта бер-берсеннән аерылып торалар. Шагыйрь юмористик анализ аша гадәти генә нәрсәне дә кырыкка ярып карый белә. Шуңадыр, аның шигырьләрен тематик яктан чыгып кына системага салу-аңлату мөмкин түгел.

Ш. Галиев шигырьләре иң элек үзләренең тематик... «сәерлеге» һәм шаян характерда булулары белән игътибарны җәлеп итә. Әлеге сыйфат аерым җорда язылган әсәрләрдә генә түгел, аның бөтен иҗаты буенча сузылып килә; шигырьдән-шигырьгә көчә барып, художестволы фикерләү үзенчәлеген һәм иҗат принцибын билгеләүче төп факторга әверелә.

Чыннан да... аның кыярлары — түбәтәйле, песие — мөгезле һәм сакаллы; чебешләре самолетта оча, куяны физзарядка ясый, ә шөпшәсе, мылтык көпшәсеннән атылып... филне бәреп ега. Әйе, «колакны торгызырлык» сәер хәлләр ич һәм алар шаянлык белән бергә үрелеп килә.

Шагыйрь үзенең бер китабын «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр» дип атаган иде. Әлеге «гаҗәп» сәерлек һәм «мәзәк» шаянлыкның болай янәшә торуы, үзара тыгыз бәйләнештә килүе бер дә очраклы түгел. Чыннан да, сәерлек — юморның аерылгысыз бер үзлеге бит ул. Мәшһүр Чарли Чаплин әйткәнчә, бөтен комик ситуацияләр — гадәти булмаган шартларда гына ачылырга мөмкин [1].

Юмористик иҗат принцибы гадәти системалылыктан читкә чыга, чынбарлыкны ул «бер читеннән» (Н. В. Гоголь) эләктереп ала. Ш. Галиевнең «Узып киттем мин автобусларны» шигырендә, мәсәлән, Шәвәли җәяүләп... автобус, троллейбус, «Волга», «Жигули»ларны артта калдырып китә. Башта шикләнебрәк торсак та, без соңыннан моңа ышанабыз — ул аларны туктап торганда узган икән...

Әйе, предметлар без күрергә гадәтләнгән үзлекләре белән генә яшәми. Кайчакта аларның очраклырак билгеләре дә «баш калкыта». Әлеге мисалда да шулай: машина турында сүз чыккач, без иң элек аның хәрәкәт итү үзлеген күзаллыйбыз. Ләкин ул туктап та тора лабаса. Юмор чынбарлыкны әнә шундый «туктап калган» моментында

[1] Кукаркин А. Чарли Чаплин. М., 1960, 74 бит.

электереп ала да инде. һәм безнең туктап торырга кирәк булганда, хәрәкәт итүебез — алдануыбыз — көлке тудыра.

Шулай итеп, беренчедән, гадәти күренешләр дә кинәт сәер үзенчәлекләре аша экзотик бер тамашага әверелеп килеп баса; икенчедән, тасвирланган объект күпкырлы булып ачыла (очраклы һәм, әлбәттә, асыл үзлеге белән дә); өченчедән, әлеге каршылык аша ачылган образ безгә көчлерәк тәэсир итә һәм хәтердә озаграк саклана. Димәк, юмористик әсәр тормышны «бер читеннән» генә электерсә дә берәгәйле электерә.

Юмор-сатира чынбарлыкны билгеле бер киселештә алып өйрәнә. Тормыш күренешләренә «зурайткыч пыяла» (Маяковский) аша карау гадәти, күзгә күренмәгән вак кына нәрсәләрне дә ачык итеп, калку итеп күрү, җентекле анализ ясау мөмкинлеге тудыра.

Юмор-сатирадагы сәерлек теманың тормыш үзегеннән «читкә китүе» яки кайбер арттыру-киметүләр белән генә чикләнми. Автор еш кына чынбарлыкның реаль контурларын бөтенләй «ватып ташлый». Әйтик, «Балыктан кайткач» шигырендә бала кармагын... болытлар арасына сала:

**Тилгәннәр әйләнеп йөри**
**Калкавыч асларында.**
**Бәртәсләр өере йөзә**
**Ак каен башларында.**

Ләкин боларның судагы болыт, каен, тилгән шәүләләре икәнлеген белгәч, әлеге сәерсенү югала — без яңадан реаль тормышка кайтабыз. Чынбарлык безнең күз алдыбызда үзенең чын төсен ала. Тик бу кайту — дөньяга шигъри караш, күңелдә шаянлык тойгысы алып кайту.

Күрүебезчә, көлү принцибы күп төрле «җимерү»-үзгәртүләрне үз эченә ала. Алар үзләренең реальлекләре белән фантастик, хыялый булулары белән реаль. Дөньяга юмор аша карау — үзенчәлекле танып белү чарасы. һәм ул җитдилектән аз гына да ким түгел (артык булмаса). Дөньяның кайсыбер бик мөһим якларына бары тик көлү аша гына үтеп керергә мөмкин [1].

Безнеңчә, балалар дөньясында көлү генә барып җитә торган мөһим почмаклар аеруча күп. Балалар дөньясы — үзенчәлекле һәм гаҗәеп сәер дөнья. Теге яки бу темага балаларча «ачкыч»ны нәкъ менә юморның гына бирә алуы да очраклы түгелдер.

Билгеле, сәерлек юмор-сатирага гына карамый. Ул киңрәк төшенчә. Ләкин аны авторның оригинальлеккә омтылуы итеп кенә аңлау да дөрес булмас иде. Сәерлек ул — бала (кеше) психологиясе үзенчәлеге. Аның бала психологиясенә таянган булуы гына үзенаклый һәм ул, үз чиратында, теге яки бу теманы балаларча телгә күчереп, бала күңеленә шигъри ачкыч биргән хикмәтле поэтик табыш булып әверелә.

Сәерлек ул — баланы билгеле бер дәрәҗәдә каршылык алдында калдыру. Аның педагогикадагы проблемалы укыту белән бер үк принципка таянуын күрми мөмкин түгел. Димәк, шагыйрь һәр шигырен проблемалы ситуациягә кора. Димәк, шигырьдә бала өчен поэтик һәм педагогик орлык алдан ук салынып куела.

«Бозны кем алган?» шигырендә, мәсәлән, кулына боз тотып йөргән нәни кызны күрәбез:

**Ә салкын боз торган саен эри,**
**Кыз шуңа тыз-быз чабып йөри:**
**— Мин аны өйгә алып керәм, ди,**
**Мич алдына куеп киптерәм, ди,**
**Җып-җылы иттерәм, ди.**

Кыз шулай эшли дә, тик.. бозы гына югала. Аның бозын укучы белән бергәләп эзләргә туры килә. Инде эшнең серенә төшенгән баланың сөенечен күз алдына китерү авыр түгел. Шулай итеп, гади генә табигать күренеше белән танышу да бала өчен олы бәйрәмгә әверелә. Шунысы характерлы, әлеге сәерлек бала психологиясе үзенчәлегенә — бу очракта аның тәҗрибәсезлегенә нигезләнеп туа. Нәни кыз урынында берәр олы кеше булса, сәерлек безне ышандыра алмас иде.

---

[1] Бахтин М. Кара: А. З. Вулис. Метаморфоза комического. М., 1976, 108 бит.

Димәк, Ш. Галиев шигырьләрендәге сәерлек, бер яктан, даими фикерләү һәм сәнгать закончалыкларына таянса, икенче яктан, һәр очрак яңа эчтәлек, яңа чишелеш, яңа сәерлек, яңа шигъри табыш сорый, һәр очрак бала рухиятенең конкрет чагылыш формасын таләп итә.

Авторның көлке ясау арсеналындагы алымнарны берәм-берәм санап тормастан (бу мөмкин дә түгел), фикерләү үзенчәлекләренә, иҗат процессының объектив психологик закончалыкларына таянып, образлар ясалышындагы өч төрне: логик-рациональ, картиналы-халәт, ироник-пародияле төрләрне аерып карарга мөмкин.

Беренче төргә без шагыйрьнең рациональ фикерләүгә нигезләнеп оешкан образларын кертәбез.

Баланың танып-белүе, логик фикер йөртә башлавы турыдан-туры сүзләр доньясына бәйле. Чөнки ул кечкенәдән һәрнәрсәгә туган теле аша, андагы төшенчәләр аша карарга өйрәнә. Ш. Галиев исә телгә аеруча игътибарлы, аеруча сизгер. һәр сүзнең аның шигъри мәгънәсе белән күрү теләге шагыйрь иҗатында махсус каламбур алымы үсешен китереп чыгарган. Төрле мәгънә аңлаткан сүзләрнең яки сүзтезмәләрнең охшаш яңгырашына нигезләнгән бу алым шигырьгә комизм — шаяру төсмере бирә, сүз үткенлеге тудыра. Ш. Галиевтә омоним, омограф һәм шаян этимологиягә таянган бик күп матур үрнәкләр очратабыз:

**Без безсез яшәмибез,**
**Безсез без эшләмибез —**
**Итекче без өчебез.**
**Өчебезгә ике без.**

Сүз-төшенчәләр белән шагыйрь, оста жонглер таш чөеп уйнагандай, җиңел эш итә. Бала аларның төрле төсләр, төрле формалар алып чиратлашу картинасын йотылып күзәтә. Баланы тел нечкәлегенә өйрәтү, аңа тел күнекмәсе бирү ягыннан да моның әһәмияте зур. Ә бит чынлап торып карасаң, бу сүз уйнаклавы гына түгел, бу — шигъри уен, шигъри шаяру.

Омоним сүзләр кайчакта әсәрне оештыручы төп көчкә әверелә. Шагыйрьнең «Балалар туп уйныйлар», «Чабалар», «Менә нинди чебиләр» һ. б. шигырьләре телнең әнә шул хасиятенә корылган. Каламбур эффектының табышмакларга килеп керүе дә әлеге охшашлыкның кинәт ачылып китү үзлегенә бәйле:

**— Кәтүче сумкасы таптым,**
**һәм өйгә алып кайттым.**
**— Кәтүчегә бирмәдеңме!**
**— Юк, сыерга ашаттым!**

Телнең этимологиясен ачканда да, охшаш яңгырашлы сүзләр капма-каршы мәгънә ала:

**Шәвәли әйтә:**
**— Ялгыш сөйлиләр**
**«Бала-чага» дип,**
**Бала чакмый бит!**
**Әйтергә кирәк:**
**«Бала-чаба» дип.**

Баланың һәр сүзне туры мәгънәсендә аңларга тырышуы бик табигый. Авторның «Сикерткә», «Сарыкмахерская» шигырьләре дә нәкъ әнә шушы принципка нигезләнеп туган.

Шагыйрь телебездәге бер генә сүзне, бер генә хәрефне дә игътибардан читтә калдырмый. Шәвәли әнә сүзләрне гел үзенчә күрә:

**Бабай тикмәгә**
**Таянмый таяк.**
**«Таяк» эчендә**
**Бар икән «аяк».**

Елан чагуның да үз хикмәте бар икән — «чагу» эчендә «агу» бар.

«Кызык» палиндромы шулай ук телдәге «сәерлек»нең бер ачык гәүдәләнеше. Ул балаларны үзенең оригиналь формасы белән җәлеп итә. Ике яктан да бер төсле укыла торган сүзләрдән төзелгән әлеге шигырьнең нигезендә яткан 20 сүзне табу өчен авторга татар теленең бөтен сүз байлыгын яхшы белү таләп ителә. Шунысын да истә тотыйк: биредә шагыйрьнең иҗат мөмкинлекләре соң дәрәҗәдә чикләнгән — ул шушы 20 «сәер» сүзгә бәйле. Әйтергә кирәк, шагыйрь үз бурычын уңышлы үтәп чыккан. Әлеге палиндромны укыгач, күңелгә бер уй килә: 20 сүзле тел материалы белән шигырь язып булгач, безнең 50 000 (!) сүзле телебездә ниләр тудырмаска мөмкин! Авторның әлеге эксперименты безне әнә шул турыда уйланырга этәрә.

Ш. Галиевнең бу тәҗрибәсе очраклы түгел. Ул 1964 елда олылар өчен язылган «Куркыныч Аюлар»ында ук тел үзенчәлекләренең кызыклы һәм шигъри ягын ачып күрсәткән иде. Димәк, тәҗрибәләр дәвам итә.

Тел сәерлегенә корылган шигырьләр тормышның үзеннән түгел, ә бәлки тел үзенчәлекләреннән чыгып ясалалар. Шуңа да теләсә нинди сүз охшашлыгын, яки очраклы билгене шигырь нигезе итеп алу үзмаксат булмаска тиеш. Бу ясалмалыкка китерә. Ш. Галиевнең башлангыч чор иҗатында әлеге мавыгуны һәм бик үк уңышлы килеп чыкмаган тәҗрибәләрне күрми мөмкин түгел. «Тылсымлы көзге» җыентыгына кергән «Минем күркәм», «Тиеннәр», «Тукмак», «Куык», «Бурыч» шигырьләренә, мәсәлән, нәкъ менә шул кимчелек хас.

Шагыйрь телдәге омоним сүзләрне, төрле сүз уйнатуларны тормыш күренешләрен, бала психологиясен чагылдыруда да актив куллана. Алар шигырьгә, башка тасвирлау чаралары белән аралашып, аерым бер алым-образ буларак килеп керәләр. Бу очракта эффект та зуррак. Чөнки тел үзе генә көлке була алмый. Ә инде билгеле бер психологик-комик ситуацияләрдә ул юморны көчәйтеп җибәрә. «Пәрәмәч», «Бораү», «Бабай килә» һ. б. шигырьләрдә, әйтик, аның роле кечкенәдән түгел. Авторның «Сызгырып йөрим», «Мунча керттеләр», «Пешмәгән ул», «Яхшы мин-минлек» исемле сатирик шигырьләре дә, нигездә, әнә шул сүз уйнату, каламбурлык эффектына корылганнар. Гомумән, көтмәгәндә ялтырап килеп кергән үткен сүз уйнатулар аның бөтен иҗаты буйлап бик юмарт сибелгән, алар башка образлар системасында эретелгән хәлдә зур шигъри көчкә әвереләләр.

Рациональ-логик образлар, барыннан да бигрәк, логик фикерләү үзенчәлекләренә нигезләнеп ясалалар. Бала фикерләвенең каршылыклы характеры бирелә юмор тудыручы шигъри чара булып китә. Логик контрастлык бик күп төрле формаларда гәүдәләнә. Бер очракта ул, әйтик, «сәер каршылыкны»—алогизмны логик чишү юлы белән ясала.

Башта без, көтмәгәндә, уйламаганда, күрмәгән, ишетмәгән «ят» каршылык алдында калабыз:

**Велосипед Актүшкә**
**Кирәк димсең ни эшкә!**

Инде алга таба әлеге каршылык кинәт үзенең логик чишелешен таба:

**Бик кирәк ул аңарга —**
**Арттан җәяү чабарга!**

«Җәл» шигырендә көлү укучыны логик «адаштыру», икенче логик яссылыкка күчерү юлы белән ясала: юкәгә менеп атынган малай агачны сындырып каты гына егылып төшә, һәм кешеләр барысы да кызганып үтә:

**— Җәл, дигәннәр, җәл бик тә,**
**Харап булган бит юкә!..**

Шәвәли дә, гадәтенчә, безне «адаштырып» ала:

**Йөгерә торгач Шәвәли**
**Тәмам өйрәнеп җиткән, —**
**Йөз метрлы араны да**
**Илле метрда үткән.**

Рациональ-логик образлар логик санау юлы белән дә ясала. Бирелә мәгънәләре белән төрле дәрәҗәдә торган предмет-төшенчәләр бер логик рәткә куеп бирелә.

әйтик, «Эш күп, эш күп» шигырендә бала «эш» дигән логик җепкә уенын да, рәхмәт әйтүне дә кертеп карый.

Баланың белеме дә, тәҗрибәсе дә аз булу — күп нәрсәне тышкы яктан — механик күзаллауга, механик кабул итүгә китерә. Әлифә әнә кәбестәнең кабыкларын әрчеп бетерсә дә, һаман эченнән кәбестәсен таба алмый интегә («Ә кәбестәсе кайда?»), шәһәрдән кайткан Эльвира исә бозауларның сыерны имүен күреп: «Бозаулар сыер ашый»,— дип куркып кала. Ә Вәлит кишерне тартып чыгара алмагач, «ай-һай, бабай нык каккан» дип шакката.

Бала телдәге образлы тәгъбирләрне, читләтеп сөйләшүләрне гел үзенчә аңлап эш итә. Аның үсәрменме дип көзгедән карап торуы да («Көзге янында»), редискадан витамин эзләве дә («Витамин эзли»), урамга чыгып «туфли ашаган асфальтның тешләрен эзләп йөрүе» дә шул хакта сөйли.

Бала фикерләвенең каршылыклы характеры логик гомумиләштерүләрдә дә нык сизелә. Бала һәр очраклы нәрсәдән зур гомумиләштерүләр чыгарырга мөмкин. Авторның «Шәвәли көче», «Ялгыш юлда», «Ни югалттың» шигырьләре шушы үзенчәлеккә корылган.

Реаль чынбарлыкны үзләштерә-үзләштерә, бала еш кына фантазия ярдәмендә төрле сюжет, мавыктыргыч бәйләнешләр уйлап чыгара. «Әлләкем» шигырендә әнә мәче үзенең мыегын кәҗәгә биреп, аның сакалын һәм мөгезен ала. «Мөгез чыгару»ның ни икәнен дә ул шуннан соңгы вакыйгалар аша белә. Әлеге гыйбрәтле, сатирик шигырь-чуалтмыш, әлбәттә, баланың бу бәйләнешләрне әйбәт үзләштергән булуы турында сөйли. Шагыйрь «Ник соң әле итек җитмәде?» мәзәгендә мондый төр уенны логик санау чуалтмышы итеп тә тәкъдим итә.

Төрле механик буталуларны да бала шундый шигъри уен итеп кабул итә. Котбетдин мәргән, мәсәлән, чаңгы таягы белән төлкегә суга, әмма егылган — каз булып чыга. Шуннан ул мылтыгын ала, тик аткан саен... я кәҗәсе егыла, я бозавы җиргә ава, ахыр чиктә төлке аның үзен атып яралый...

Рациональ-логик образларга характерлы арттыру-киметүләрне бала бик тиз эләктереп ала һәм бик җанлы кабул итә. «Очты киптергеч» шигырендә ул юри генә булса да куркуга кала:

**Күлләвекләрне**
**Төшеп киптерер,**
**Инеш суларын**
**Эчеп бетерер!..**

Авторның «Тәмлетамаклар», «Тәмле күмәч» шигырьләрендәге юмор да әнә шушы эффектка — арттыру-киметүгә бәйле төстә туа.

Кайчакта логик арттырулар абсурд дәрәҗәсенә җиткерелә. «Шәвәли ярдәме»ндә, мәсәлән, Вәли мәктәпкә ашыга. Ул өлгерсен дип:

**Әбисе күкәйләр әрчеп,**
**Тозга ук манып тора,**
**Тагын да тизрәк булсын дип,**
**Шәвәли кабып тора!**

Мондый арттыруларда логик фикер үзенең орбитасыннан ычкынып китә һәм ул көлү объектына әверелә.

Рациональ-логик образларның логик дедукциягә охшавын да әйтеп китәргә кирәк. Бередә билгеле бер гомуми тезис хосусый чишелешкә башлангыч нокта, чыганак, нигез була. Бу тезистан соң килгән конкрет ачылу аның белән төрлечә (без аларның кайберләрен карап та үттек) каршылыкка кереп, көлү тудыра. «Уйлый торган машина» шигырендә, әйтик, без алдан «килешеп» куябыз.

**Ах, булсачы минем өчен**
**Уйлый торган машина.**

һәм ул була да... Малай аңа уйларга кушып чыгып китә. Кайтса, теге уйсыз-нисез тик басып тора:

**Синең өчен уйлаганга**
**Синең кебек булдым, ди.**

Алдагы шартлы сөйләшү — шартлы тезис соңыннан конкрет логика белән каршылыкка керә, хосусый логиканың без көтмәгәндә яңадан килеп чыгуы зур эффект тудыра.

Шагыйрь «Хәлим, Сәлим, Мәсәлим» циклында да нәкъ әнә шушы принципны куллана. Биредә без бер-бер артлы үсеп килгән өч малай белән очрашабыз. Гомуми әлшарттан безгә әнә шул мәгълүм. Инде аның конкрет-хосусый чишелеше башлана:

**Таң белән уяндылар,**
**Кармакларын алдылар,**
**Балыкка кузгалдылар.**
**— Кояш чыкты! — ди Хәлим.**
**— Чыгып килә! — ди Сәлим.**
**— Күренми... — ди Мәсәлим.**
**Һәркем әйтә дөресен,**
**Күрәлгән кадәресен.**

Ә инде кайтканда, кересенчә, Мәсәлиме «баеган» ди, Сәлиме «баеп бара» ди, Хәлиме «баемаган» ди.

Дөньяга өч кырлы призма аша карау, әлбәттә, шагыйрьгә чынбарлыкны чагылдыруда зур мөмкинлекләр ача. Аның башка төр образ-алымнар белән аралашып, баланың рухи дөньясындагы иң аулак почмакларына үтеп керә алачагы бер дә гаҗәп түгел. Без бу шигырьләргә әле тулыланасы, байыйсы, үзенең өр-яңа ачышлары белән укучыларны сөендерәсе цикл итеп карыйбыз.

Ш. Галиев иҗатында ясалыш һәм психология биру үзенчәлеге ягыннан икенче төр юмористик образларны — картиналы-халәт образларын аерып карарга мөмкин. Алдагы образларның төп таяну нигезе логик фикерләү булса, әлеге төр образлар, башлыча, предметлы, тоемлы фикерләүгә, сиземле кабул итүгә нигезләнәләр:

**Карагыз итекчегә:**
**Ул, интегә-интегә,**
**Шундый зур итеп тегә —**
**Шундый зур итек тегә —**
**Тирәли йөреп тегә,**
**Эченә кереп тегә,**
**Өстенә менеп тегә!**

(«Филгә итек тектеләр».)

Бала үзе дә бит тормышны нәкъ әнә шулай конкрет-картиналы итеп күзаллый. Дөрес, аны тышкы конкретлык итеп кенә аңларга ярамый. Авторның «Физзарядка ясый куян» шигырен исә төшерик. Төгәл детальләр аша тышкы һәм эчке халәт картиналарының бер бөтен булып китүен шагыйрьнең «Маэмай бара күргәзмәгә», «Аптекада очрашу», «Ерткыч» шигырьләрендә дә күрәбез.

Әйе, шигырьнең эчке үсеше күзгә күренеп торган конкрет картиналардан гына тормый. Бу уңайдан, «Мин» шигыренең юмор туу үзенчәлегенә, аның тасвир-белдерү мөнәсәбәтенә якынрак килеп карыйк. Биредә «Тыйнак мин» дигән логик тасвир, гәрчә алда килгән «Мин шук малай, үткен малай, ут малай, мин бик уңган, бик өлгер, бик тапкыр мин, җыйнак мин» кебек юлларның дәвамы булып килсә дә, шигырьнең исеме һәм бөтен бер образлар системасы каршында берүзе торып кала. Чөнки алда санап кителгән сыйфат-сүзләр тасвирлауның артык «куертылуы» һәм аларга ияреп килгән «мин»нең еш кабатлануы нәтиҗәсендә үзләренең логик мәгънәләрен югалталар. Алар «тыйнак» төшенчәсенең кересен аңлаткан эчке белдерүгә әвереләләр. «Мин — тыйнак» сүзе геройның шигырь системасыннан саркып чыккан яңа сыйфаты каршында көчсез булып кала, ул ышану түгел, юмор гына тудыра.

Күргәнебезчә, шигырьнең бар көче — аның белдерүендә. Шигъри мәгънәне логик төшенчәләрдән генә эзләү хата булыр иде. Шигъри образга килеп кергән сүз, мөстәкыйльлеген һәм элеккеге гадәти мәгънәсен югалтып, образлар системасы җирлегендә яши башлый, аның шигъри әһәмияте дә әнә шуннан чыгып бәяләнә. Шуңа да кайчак сүзнең төп мәгънәсенә караганда очраклы бер үзлеге (әйтик, аның формасы, нинди авазлардан торуы һ. б.) шигырьнең төп идея-фикерен ачуда зуррак эш башкара. Ул әсәрнең эчке үсешенә якын торганлыктан, кеше психологиясен чагылдыруда да турыдан-туры катнаша. Һәм әлеге психологиянең, рухи халәтнең күренмәле, картиналы булып китүе дә нәкъ менә аңарга бәйле. Бу төр образлар әнә шундый нечкә тасвир чаралары ярдәмендә тудырыла. Шагыйрь бередә җанлы күзәтүгә таяна һәм эчке халәтне бөтен мөмкинлекләрдән файдаланып ача. Нәтиҗәдә индукция методына нигезләнгән образ, һәртөрле вак детальләрдән җыелып, кешенең иң нечкә күңел тирбәлешләрен дә ачып бирүче шигъри образ булып җитешә. Ш. Галиев иҗатында аларның гаять киң һәм күп төрле кулланышын очратырга мөмкин.

Кайчакта ул печенье ашамыйча, «ви-ви-ви-ви-ви, витамин күбрәк» дип, яшел чирәм йолкучы бәбкә авазы булып тәсмерләнә. Кайчак без аны песи баласы белән танышып кергән тычкан баласының кичерешләрен күрсәтүче морфологик чара итеп күрәбез:

**Теш кайрады**
**Бүген мыр-мыр.**
**Дер-Дергә ни**
**Булырдырдыр...**

Ә кайчак ул үзенчәлекле синтаксик әйләнмәләр рәвешен ала. Халәт тәсмерләре төрле кабатлаулар ярдәмендә бирелергә мөмкин.

Ш. Галиев шигырьләренең рифмалары мәгънә-халәт тәсмерләренә аеруча бай. Чөнки рифма, бер яктан, балалар шигыренең нигезе булган ритмга буйсынып, икенче яктан, тасвирны мәгънәви яктан ачыклап, бу ике үзлекне үзендә берләштереп килә.

Ш. Галиев янәшә рифмаларны яратып куллана. Алар халәт нюансларын ачуның хәрәкәтчән һәм җанлы бер алымы булып китәләр.

Картиналы-халәт образлары тудыруда шулай ук эпитетларның роле бик зур. Алар үзләренең кыскалыклары һәм эчке халәтне гаҗәп төгәл тотып алулары белән аерылып торалар. Менә бала яңгыр астына керә һәм «рәхәткә батып чыланып йөри» («Яңа зонтик»). Янсә ул караңгылык белән очраша:

**Ирек кереп каранды:**
**Бүлмә тулы караңгы.**
**Үзе болай тып-тыныч,**
**Эче тулы куркыныч.**

«Файдалы җиләк» шигырендә нәни герой тәмләп кенә трамвайда җиләк ашап кайта. Бакса, янәшәдә генә бер кыз да бар икән:

**Мөлдерәп утыра әнә**
**Бер апаның кызы да...**

Әлеге «мөлдерәп» утырган кызның эче-тышы безгә әнә шулай бер сүз аша онытылмаслык итеп гәүдәләндерелә. Бу төр образларда бала психологиясенең теге яки бу үзенчәлеге турыдан-туры үзе үк тасвирланырга мөмкин:

**Усал эт күргәч,**
**Ул болай диде:**
**Мин тәмле түгел,**
**Ашама мине.**

(«Шәвәли хәйләсе».)

«Бораү» һәм «Тешем сызлый» шигырьләре дә бала рухының эчке үсеш-үзгәрешен, аның психологиясендәге төрле үзенчәлекләрне күрсәтүләре белән шагыйрь иҗатында аерылып торалар.

Кайбер шигырьләрдә без баланың үз гаебен тиз генә башкаларга күчерергә куярга яратуын («Ясыйр», «Кадак», «Күнегү» һ. б.) күрәбез. Әлеге «кеше гаепләү» үзенчәлеге, гомумән, юмор-сатирада аерым бер алым буларак киң кулланыла.

Шулай ук көчсезләрнең (кечкенәләрнең) көчле-зур нәрсәләрне җиңеп хур итү моментлары да шактый еш очрый. Котбетдин әнә сабан туе батырын, батыр икәнен онытып, селтәп үк бәргән. «Ерткыч» шигырендә бәби генә песинең бозау хәтле этне куркытуы тасвирлана.

Шулай итеп, картиналы-халәт образларында без шагыйрьнең бала психологиясен тирән һәм нечкә итеп тоюын, иң әһәмиятлесе, аны ниндидер ясалма матур рамка — «теплицалар»га салмыйча, бөтен чынлыгында, каршылыгында — реаль яшәешендә җанлы-сиземле итеп тасвирлап бирүен күрдек.

Ш. Галиев иҗатындагы тагын бер төр юмористик образларны күзаллап үтик. Болары — ироник-пародияле образлар. Без алда карап узган беренче төр — логик образлар контрастлык, икенче төр — картиналы образлар охшашлык ассоциацияләренә таянсалар, әлеге өченче төр образлар янәшәлек ассоциациясенә нигезләнеп туа. Димәк, биредә бер үк вакытта бер-берсенә охшаган һәм бер-берсенә контраст каршылыкта торган янәшә ике объект (предмет, халәт, төшенчә һ. б.) алына. Образлар ясалышындагы һәртөрле чагыштыру, метафора, параллель һ. б. нәкъ әнә шушы принципка нигезләнә.

«Рус казлары: га-га-га» шигырендә, мәсәлән, мәче бөтенләй көтелмәгән, икенче яссылыкта торган төшенчә — тәрҗемәче белән чагыштырылып тасвирланган:

**Русча мәче: мияу, ди,**
**Татарча да: мияу, ди,**
**Анда-монда йөри мәче!**
**Шул мәллә тәрҗемәче!**

Инде әлеге төр образларга психологик яктан, геройның характер үзенчәлекләре кебек зур «күзәнәкләр» яссылыгыннан чыгып карыйбыз икән, ике объект урынына биредә герой һәм аның прототибы алына. Белгәнебезчә, бу ике төшенчә һәр вакыт янәшә яши: алар үзара охшаш һәм шул ук вакытта капма-каршы полюста торучы ике көч. «Жираф белән Зариф» шигырендә әнә ике герой бер-берсен «ерактан таныйлар»:

**Муен дигәнең,**
**Берсенең — озын,**
**Берсенең — кыска.**
**Муен дигәнең,**
**Кыскасы — кара,**
**Озыны — чиста...**

Күрәбез, биредә аларны берләштереп һәм контраст итеп капма-каршы куйган уртак нәрсә — муен. Алар бер-берсен «муеннан таный». Билгеле бер предмет (үзлек) әнә шулай чагыштырылып, пародия рәвеше алып, күренмәле-сиземле көлке объектына әверелә. Шигырьнең исеменә генә игътибар итегез: хәтта алар да бер-берсенә охшаган һәм охшамаган булулары белән әлеге принцип үзенчәлеген искәртеп торалар, ягъни, үзенә күрә, «ачкыч» ролен үтиләр. Мондый исемнәрне дә, мондый образларны да шагыйрь иҗатында бик еш очратырга була.

Әнә бер малай чәчәкне иснәп: «Ай-һай, хуш исле!» — ди.

**Чәчәк тә аның**
**Борынын исни, —**
**Бу бәя белән**
**Бер дә килешми...**

(«Чисталыкны тикшерү».)

Дөрес, кайчакта бу ике объектның берсе булган кеше (пародия объекты) шигырьдәге образлар системасына алай турыдан-туры катнашмый да. Хәер, җанлы һәм җансыз нәрсәләрне тасвирлаганда, гомумән, пародия кешегә карый. Бер генә җансыз предмет та үзе генә көлке объекты була алмый. Алар бары кеше кыяфәте алып кына көлкегә әвереләләр.

Җәнлекләр дөньясыннан кешеләргә күперчек салуны без «Билет тикшергәндә» шигырендә бик ачык күрәбез. Җәнлекләр трамвайда бара. Ул да түгел, билет тик-

шерә башлыйлар. «Йоклаганга салышма, хәйләңне беләбез»,— дип, бер аю куянны төрткәләргә керешә. Ә тегесе нишли дисез?

**Салып куян беретын,**
**Алып бирә билетын:**
**«Хөрмәтле Аю ага, сез**
**Нигә яла ягасыз!**
**Кайбер малайлар гадәтен**
**Куяннарга тагасыз!»**

Күргәнебезчә, биредә автор җәнлекләрне кешеләштереп кенә дә калмый. «Кайбер малайлар»ның начар гадәтен «җәнлекләштереп» карауларына куян зур үпкәсен белдерә. Шулай итеп, «кешеләштерү» һәм «җәнлекләштерү»ләр ярдәмендә арага берьюлы ике күперчек салына. Әсәрнең балаларча җылы юмор белән өртелеп реаль яңгыраш алуы да шушы шартлылык — күперләр ныклыгына бәйле бит. Көлү үзе дә шушы пародия аша туып, «үзеннән-үзе» барлыкка килә.

Кайчакта пародия «ясалып ук бетми» — ул геройның теге яки бу үзлегенә дәгъва буларак тәкъдим ителә. «Шөпшә» шигырендә, мәсәлән, шөпшә көпшәдән атылып филне бәреп ега һәм фил дә, үз чиратында, аңа көпшәгә кереп атылу белән яный. «Физзарядка ясый куян»да да шул ук хәл — куянны тота алмагач, аучы иртән торып куян сыман физзарядка ясарга керешә. Бу, әлбәттә, көлү эффекты тудыра.

Пародия объекты үз-үзен кабатлап килеп тә көлү уята: әнә тауга менгәндә «Майла... маайлаа...» дип сөйрәлгән көпчәкләр, таудан түбән төшкәндә, «майламасаң майлама, җайламасаң җайлама!» дип ничек җиңел генә тәгәриләр... «Бабай килә!» шигырендә дә «Бабай килә» дип куркып йөргән малайлар бер заман «Бабай китә!» сүзеннән курка башлыйлар.

Әлеге ироник-пародияле образлар функциональ яктан да гаять үтемле һәм төрле-төрле. Автор идеясе биредә еш кына гыйбрәтле картиналар аша гәүдәләндерелә. «Курыкма, тимим!», «Кызык гадәт» шигырьләрен генә искә алыйк. Шунысы кызык, биредә кайчакта пародия ягы өскәрәк чыга:

**— Безнең холодильник ЗИЛ!**
**— Һи, Зилне без беләбез.**
**Ә менә безнеке Җил —**
**Форточкадан эләбез!..**

«Сунарчы кайта» шигыре дә шундый ук характерга ия. Бу шигырьләрдә безнең игътибар янәшә килгән ике объектның көтелмәгәндә кушылуыннан туган эффект — пародик суратка юнәлә.

Ләкин ирония ягы көчлерәк үсеш алган шигырьләр дә шактый еш очрый:

**Булыр иде чистарак,**
**Булыр иде урынлы,—**
**Чәй кәгазенә төреп**
**Өйдә тотсаң борынны...**

Ә кайчакта алар бертигез дәрәҗәдә ачылалар:

**Хәлим, Хәлим, теләсәң дә**
**Һич яшерә алмассың —**
**Маңгаеңа үсеп чыккан**
**Күршеләрнең алмасын!**

Без алда карап үткән өч төр юмористик образлар, әлбәттә, гел болай «чиста килеш» кенә килмәскә дә мөмкин. Аларның көче — арапашып килүләрендә, аларның көче — бала күңелен, бала җанын тирәнрәк, тулырак, күпкырлырак һәм кызыклырак итеп тәкъдим итә алуларында. Шагыйрьнең иң яхшы шигырьләре нәкъ әнә шундый «синтез» образлардан тора да.

Ш. Галиевнең балалар өчен язган шигырьләре турындагы сөйләшүне юмор-сатирага гына кайтарып калдыру — шагыйрь иҗатын нык чикләп кую булыр иде. Җитди жанр аның шигырьләрендә торган саен киңрәк урын ала бара. Моны без авторның «Күңелле сәфәр» китабында бик ачык тоябыз. Ш. Галиев үзенең иҗат юлын җитди жанрда башлады. Аның юл башына билгеле бер дәрәҗәдә яңадан әйләнеп кайтуы бик табигый. Әлбәттә, бу — юмор белән баетылып, үзгәреп кайту. Без әлеге үзгәрешне шагыйрьнең олылар лирикасында да күрәбез. Аның башлангыч чорга хас «кичерешләр лирикасы» хәзер ике төп юнәлештә — сюжетлы балладалар һәм хикмәтле сүз әйтү юнәлешендә үсеп китте. Балалар өчен язылган җитди шигырьләрендә дә шулай: алар я берәр хикмәтле сүз әйтүгә, я нинди дә булса шигъри табышы булган гыйбрәтле вакыйгага корылганнар. Танып белүдә һәм балага тәрбия бирүдә аларның нәкъ әнә шул «хикмәтле» яки «гыйбрәтле» ягы төп шигъри көчкә әверелә дә.

Авторның җитди шигырьләргә кайтуының төп сәбәбе шулай да — рухи бөтенлеккә сусау булса кирәк: кеше дөньяда көлеп кенә яши алмый. Бала да шулай. Чынбарлыкны көлү аша гына иңләп карау мөмкин түгел. Юмористик принцип, әйткәнебезчә, чынбарлыкны «җимерә». Ә бит бала өчен реаль чынбарлык бәйләнешен сиземләү дә, җитди рәвештә әрнү, кызгану, ярату, нәфрәтләнү кебек тойгыларны кичерү дә бик мөһим. Бу — тормыш таләбе. Кеше шуңа күрә туктаусыз рухи бөтенлеккә, эчке хисләр гаммасының тулылыгына омтыла да. Ш. Галиев җитди шигырьләре белән әнә шул бөтенлекне алып кайтты. Моны авторның чынбарлыкны системалы итеп күрергә теләве дип тә аңларга кирәктер. «Күңелле сәфәр» китабындагы табигать һәм аны саклауга багышланган, шулай ук Хәлим, Сәлим, Мәсәлим турындагы шигырьләрнең дә цикл булып тууы әнә шул хакта сөйли.

Бу урында авторның Шәвәли образы хакында берничә сүз әйтеп үтәсе килә. Белгәнебезчә, Шәвәли унбиш елдан бирле шагыйрь иҗатының аерылгысыз бер герое. Шунысы кызык, автор кичергән бөтен иҗат үзенчәлекләрен аңарда да күрергә мөмкин. Әйтик, соңгы вакытта ул юмористик герой гына булудан туктап, лирик яктан да ачыла башлады. Һәм ул тагын да ачыкланыбрак китте. Авторның йөзләп шигыре Шәвәли турында. Ул — балаларның үз герое — чын-чынлап типик образ. Аңарда балаларга хас бөтен үзлекләр бар, ул аларны үз исеме астында берләштереп, җыеп килә.

Әмма Шәвәлигә масштаблы индивидуальлек сыйфатлары җитмәвен дә әйтергә кирәк. Шагыйрь иҗатында «Камырша» кебек кабатланмас индивидуаль йөзе булган геройларны күбрәк күрәсе килә. Без автордан Чуковскийның «Бармалей», «Юындыр», Тукайның «Шүрәле», «Су анасы» кебек эре колачлы, онытылмас образлар күтәргә тулы хакыбыз бар — иҗатын күзаллау шундый нәтиҗә ясау мөмкинлеге бирә.

Ш. Галиевнең иҗат мөмкинлекләре зур. Ул үзенең укучыларын нәкъ балаларча ачкычта табылган гүзәл шигъри табышлары белән әле бер генә сөендермәс. Чөнки шагыйрь үз шигырьләренең балалар күңеленә, алар рухына, җан сораган витаминнар кебек үк, кирәкле һәм кадерле икәнен яхшы белә.

Роберт Миңнуллин

# КИЛӘЧӘК БУЫН ХАКЫНА

*Бүгенге балалар әдәбияты турында уйланулар*

Безнең балалар әдәбияты зур традицияле, күренекле әдипләре, татар совет әдәбиятының алтын хәзинәсенә кергән әсәрләре булган бай әдәбият. Әмма соңгы елларда гомуми әдәбиятыбыз фонында ул тоныкланып, югалып калды шикелле. Чыннан да, менә ничә еллар инде бер тирәдә таптана. Алга да китми, артка да калмый. Тотып алып селкеп салырлык урта кул әсәрләр дөнья күрә торса да, күтәреп алып мактарлык, вакыйга, бәйрәм булырлык, бөтен союз укучысына тәкъдим итәрлек әсәрләр соңгы берничә елда бик сирәк күренә. Сүз дә юк, күренекле язучыларыбыз Шәүкәт Галиевнең, Ләбибә Ихсанованың актив эшләүләре, чын мәгънәсендә талантлы әсәрләр иҗат итүләре күңелне күтәреп җибәрә. Укучыларыбыз талантлы әдипләр — Ш. Рәкыйпов, Х. Халиков, А. Тимергалин, Р. Батуллин, Р. Мингалимов, Ф. Шәфигуллин язган әсәрләрне дә көтеп алалар, яратып укыйлар. Шулай да балалар әдәбиятының гомум торышы һаман да үзгәрешсез кала бирә. Сәбәп нидә соң?

Бездә ни өчендер балалар әдәбияты бары тик балалар өчен генә дигән караш яшәп килә. Чынлыкка мотлак туры киләме бу? Безгә калса, өлешчә генә. Әйтик, без әле булса Тукайның «Кәҗә белән Сарык»ын, «Су анасы»н, «Гали белән Кәҗә» сен яттан беләбез. Перро, Андерсен әкиятләрен, «Мең дә бер кичә»не бирелеп укыйбыз. Гайдар әсәрләрен яратабыз. Ике-өч яшьлек малайларга-кызларга кушылып «Крокодил Гена җыры»н җырлап йөрибез. Мультфильм күрсәтә башласалар, кырык эшебезне кырык җирдә ташлап, телевизор экраннарына капланабыз. Ә бит алар балалар өчен иҗат ителгәннәр. Аларга безнең бер катнашыбыз да юк кебек. Күрәсең, чын сәнгать әсәре балаларга да, олыларга да бердәй тәэсир итә. Ә менә урта кул әйберләрне ни балалар, ни олылар кабул итә алмыйлар. Шуңа күрә балалар әдәбиятына «баласытып», кимсетеп карау бөтенләй хак түгел.

Балалар әдәбияты — балалар язучылары эше генә дип уйлау да бар әле бездә. Ә менә әдәбият тарихына күз салсак, моның киресен күрәбез. Татар әдәбияты классикларының күпчелеге балалар әдәбиятын зурлар өчен әдәбияттан аерып карамаган. Алар нәниләр өчен дә классик әсәрләр биреп калдырганнар. Тукайны гына алыйк. Без аның «Туган тел»ен, «Шүрәле»сен, «Ел фасыллары»н, «Бала белән күбәләк»ен, балаларга атап язган тагын бик күп шигырьләрен телебез ачылуга ук көйләп йөрмәсәк, ул шигырьләр безнең күңелләргә ана сөте белән кермәсә, Тукай безнең рухи дөньябызда бу кадәр олы булып, мәгърур булып яши алыр идеме? Һәрбер татар укучысы Тукайның колач җитмәс иҗатына нәкъ әнә шул шигырьләр аша килә түгелме соң? Ә Галимҗан Ибраһимов? «Яз башы», «Карт ялчы», «Көтүчеләр» «Табигать балалары»... Татар укучысы өчен Ибраһимовның бөеклеге шушы хикәяләр-

дән башлана лабаса! Укучы язучының зурлыгына, бөеклегенә ышана. Чөнки Ибраһимовның иҗаты кечкенәдән үк аның аңына, канына сеңгән. Ә инде кечкенә чакта укыганнар, ишеткәннәр, күргәннәр — алар гомерлек! Ә Такташ, Җәлил, Фатих Карим... Рус әдәбиятыннан Пушкин, Толстойлар, Маяковский һәм башкалар... Дөрес, балалар әдәбияты, аеруча поэзия, гаҗәп тә катлаулы һәм күпләрне куркыта торган өлкә. Хәтта Блок, Пастернак, Есенин кебек титаннар балалар өчен язарга тырышып та, уңышсызлыкка очраганнар...

М. Горький балалар әдәбиятын зур бер «суверен держава» дип атаган иде. Күргәнебезчә, төп әдәбият белән әлеге «суверен держава» арасында тирән дипломатик мөнәсәбәтләр урнашып җитмәгән әле бездә. Ә инде ике держава арасында шул мөнәсәбәтләр урнашмаса, алар үзара янәшә сыешып яшәмәсә, нәтиҗәләр бер дә матур булмас шикелле.

Инде соңгы вакытта дөнья күргән әсәрләргә күз салыйк. Повестьларның күбесе «Яшь ленинчы» газетасы белән «Ялкын» журналында басылып чыкты. М. Хәсәновның «Шайтан малае», Җ. Рәхимовның «Девон хәбәрчесе», Ф. Яруллинның «Язмышлар язылганда», Ф. Шәфигуллинның «Бер малай, өч аргамак», Р. Хафизованың «Без әле кайтырбыз» повестьлары. Болар һәммәсе узган елда — Бөек Октябрьның 60 еллык юбилее елында дөнья күргән әсәрләр. Шунысы характерлы, повестьлар үзләренең вакыйгалары белән дә 60 елны иңлиләр, бер-берсен эзлекле рәвештә дәвам иттерәләр, вакыйга һәм фикер үсешләрен тулыландыралар, көчәйтәләр. Әйтик, «Шайтан малае» гражданнар сугышы чорын тасвирлый. Бәләкәй генә татар малаеның олы батырлыгын чагылдыра. Шушы кечкенә вакыйганы язучы шактый матур детальләр аша күрсәтеп бирә алган. Җ. Рәхимов исә үзенең «Девон хәбәрчесе» повестенда бүгенге нефть якларындагы сугыш алды елларын, сугыш чорын сурәтли. Андагы кечкенә геройлар — Напалиун, Питыр, Бытбылдык Әхәт, Нәби, Мәрди авыр сугыш елларында үссәләр дә, бәхетле малайлар. Алар беренче булып буровойны күргәннәр, беренче булып вышкага менгәннәр, шуннан бөтен дөньяны күзәткәннәр, беренче булып нефть исен иснәп караганнар. Шөгер нефте тора-бара ул малайларның язмышына әверелгән. Гомумән, автор геройларының кичерешләрен, хыялларын җылы гына тасвирлаган. Бу бәләкәй повесть та Татарстан нефтенә багышланган әсәрләр рәтенә басарга хаклы.

Ф. Шәфигуллинның «Бер малай, өч аргамак» повесте сугыштан соңгы авыл тормышына багышланган. Автор үзенең әсәрен укучыга түбәндәге мондый юллар белән тәкъдим итә. «Бала чагыбыз басулары... Игеннәр хуш ис бөрки, чикерткәләр сайрый, юл читендә зәңгәр чәчәкләр балкып утыра — барысы да нәкъ безнең бала чактагыча. Тик хәзер инде монда башка малайлар урак урдыра... Дәһшәтле сугыш еллары һәм сугыштан соңгы авыр еллар икмәгенең кояштай балкып табынга килгәнче нинди юллар узуын беләләр микән дә, тракторлар аз чагында җир эшкәртүнең, икмәк үстерүнең кыенлыкларын, кырыс романтикасын күз алдына китерәләр микән алар?

Бу әсәрдә сугыштан соңгы бер урак өстенең ике-өч кенә көне турында сүз бара. Бу әсәрнең асылында — икмәк. Шуңа күрә бәләкәй героем Рәсимнең уй-тойгыларына, кичерешләренә, аның кешеләргә, атларга, хезмәткә һәм, ниһаять, икмәккә булган мөнсәбәтенә бүгенге укучылар битараф калмаслар дип өметләнәм». Авторның өмете акланды. Повестьтан соң авторга укучылардан бик күп хатлар килде. Язучының әлеге сүзләре чыннан да әсәрнең идея-эчтәлеген, бөтен асылын ачып бирә. Ләкин хикмәт икмәктә генә түгел.

Повестьның уңышы ни белән аңлатыла соң? Иң элек, әлбәттә, татар совет әдәбиятының әлеге чорны чагылдыруда бай тәҗрибә туплавы беләндер. Аннары авторның материалны төгәл белүе, тирән кичерүе һәм әдәби осталыгы да үзенекен итә... Повестьның үзәк герое Рәсим — сугыштан соңгы авыл малайларының типик вәкиле. Дөньяга нингидер бер ачу саклап яшәүче, шул ук вакытта ат кебек эшләүче Борһанны да без тиз арада танып алабыз. Күрәсең, һәр авылның үз Борһаны булгандыр. Рәсимнең әнисе дә, бригадир хатын да таныш шикелле. Аларның килеш-килбәтләре һәм сөйләшүләре дә хәтергә сеңеп кала. Гомумән, образлар истә калырлык һәм тулы канлы итеп иҗат ителгәннәр.

яшь кешенең шәхес буларак формалашуы, гадәттә, мәктәпнең соңгы классларына туры килә дигән фикер яши. Ә баксаң, повесть герое Рәсим — дүртенче классны тәмамлаган бот буе малай — шәхес буларак инде өлгереп килә икән. Аның каты күңелле Борһан белән бәхәсләре — чын мәгънәсендә көрәш. Малайның теләк-омтылышлары, эчке каршылыклары оста тотып алынган. Ул Борһанның усал, кансыз икәнлеген дә, эшнең авыр буласын да белә. Ләкин сер бирми. Күңелендәге эчке бер омтылыш, үзенең батырлыгын исбатлау теләге малайны шунда этәрә. Нәтиҗәдә, малай җиңүче булып чыга. Ә бит шул малайлар хәзер басуларда иген үстерәләр, КамАЗ төзиләр, тормышның төбенә җигелеп тарталар. Әсәрдәге психологик тирәнлек, нечкәлек сөендерә, ул үзенең табигыйлеге белән күңелне бөтереп ала. Аю егарлык кайбер малайлар, егетләр урамда бер эшсез трай тибеп йөргән бүгенге көндә бу әсәрнең актуальлеге, бәясе бермә-бер арта. Кыскасы, Ф. Шәфигуллин «Бер малай, өч аргамак» повесте белән үз иҗатын да, балалар әдәбиятын да бизәде диясе килә.

Ф. Яруллинның «Язмышлар язылганда» повесте туган җиргә, аның табигатенә, хезмәткә мәхәббәт хисләре белән сугарылган. Ул бер чите белән демографик проблемага да кагылып китә. Авылларда яшьләр азайган заманда әлеге әсәрнең язылуы, әлбәттә, әһәмияткә ия. Аның сюжеты катлаулы түгел. Председатель кызы, лирик «мин» нең апасы сигезенче классны бетергәч, башкача укырга теләми, авылда калып эшләргә була. Шул ният белән ул умартачылар курсында укып кайта. Умарталыкта эшли башлый. Аның энесе, ягъни лирик «мин», аңа һәрчак ярдәм итеп йөри.

Умартачы кыз образы шактый кызыклы, шулай ук каршылыклы да итеп иҗат ителгән. Бар да тәртиптә кебек. Ләкин повестьтагы бер нюанс сискәнергә мәҗбүр итә. Һәм ул әсәрнең башыннан алып ахырына кадәр дәвам итеп, төп максатка нык кына басым ясаган шикелле. Ул да булса, лирик геройның артык күп акча белән мавыгуы, байлык белән кызыксынуы, бик күп матур әйберләрне байлыкка, материальякка кайтарып калдыруы. Бу — кайберәүләр тормышында бәлки, чыннан да, шулайдыр. Әмма, ничек кенә булмасын, малайның мещанлык, комагайлык сыйфатлары (автор моны үзе дә сизми булса кирәк) күңелдә авыр тәэсир калдыра. Менә берничә мисал:

«Уйлап табучыларга премия бирәләр. Миңа нәрсә әләгер икән?..

Ә премиягә нәрсә бирәсең?..

Миңа зарплата язарсыңмы соң, әти?..

Рәйхәнә апаның умарталары баллый башласа, баербыз әле...

Маташып карармын, әмма бушка түгел, түйганчы бал ашатырсың...

Һәр елдагы кебек быел да сабан туе алдынгыларны бүләкләүдән башланды. Безнең өй эченнән генә беркемне дә андый бәхет көтми иде. Әти председатель булгач, үзен-үзе бүләкли алмый. Әни врач, район кешесе санала. Врачларга премия дә, бүләк тә юк. Менә Рәйханә апага хет бирәр яулык бирсәләр, ярап куяр иде».

Повестьның буеннан-буена малайның менә шундый фәлсәфәсе дәвам итә. Әсәрдәге кайбер конфликтлар да, кыз белән ата арасындагы бәхәсләр дә шул фәлсәфәгә корылган. Инде шушыннан чыгып, малайның кем булып үсәсе көн кебек ачык.

Роза Хафизованың «Без әле кайтырбыз» повесте да мөһим темага язылган. Пионер тормышы турында, пионер эшләре турында язу, гомумән, мактаулы эш. Чөнки балалар әдәбиятының «күтәрелмәгән чирәме» — әле булса мәктәп, пионерия һәм укучылар дөньясы. Авторның бу темага тотынуы гаҗәп тә түгел. Ул мәктәпләрдә еш була, пионер проблемалары белән яхшы таныш, укучыларның уй-кичерешләрен аңлый, тоя белә. Әсәрдә вакыйгалар бар, материал бар, характерлары белән бик үк яңа булмасалар да, персонажлар да бар. Ләкин бирелә әнә шуларны бергә укмаштыра торган җилем юк — илаһи сәнгать юк. Автор вакыйгаларны бер-бер артлы тезеп, сөйләп чыга. Әмма вакыйгаларның фәлсәфи эчтәлеген ачу юк, психологик тирәнлек җитми. Повесть бит нәни хикәя түгел, ул бер генә катлы булмаска тиеш. Анда төрле пластлар, катламнар булуы да шарт.

Повестьның теле дә мактанырлык түгел. Дөрес, һәркемнән Әмирхан Еники осталыгын яисә Хәсән Сарьян телен таләп итеп булмый. Әмма үзебезнең гап-гади татар телебез бар бит әле. Язучы үзенең туган телен яратырга, хөрмәт итәргә бурычлы! Әсәрдә игезәк алымнар, игезәк чагыштырулар, игезәк җөмләләр бик күп. Әй-

тик, менә мондыйлар: «Әти белән әни бездән көлеп җибәрделәр... Әни, елмаеп, башымнан сыйпады... Ул миңа карап елмаеп куйды... Әти аңа карап елмайды... Ул рәхәтләнеп көлеп җибәрде... Әти белән Габдрахман абый көлеп куйдылар... Айсылу пырхылдап көлеп җибәрде... Үзләре рәхәтләнеп көлешә башладылар... Мостафа абый елмаеп җибәрде... Ул Фәүзия апага карап елмаеп куйды... Әни елмаеп куйды... Габдрахман абый көлеп җибәрде... Абыем көлемсерәп куйды... Абый шунда ук көлеп җибәрде...» Боларны укыгач, укучы да, һич югында, елмаеп куячак. Әгәр дә авторга нәшрият тарафыннан ярдәм булса, үзе дә җаваплырак караса, повесть, әлбәттә, уңышлырак чыгар иде.

Яшь буын бабайлар һәм әтиләр данын мирас итеп алды. Хәрби-патриотик тәрбия мәктәп елларыннан ук башлана. һәм батырлык турында без балаларга һәр даим исләренә төшереп торырга тиешбез. Ә батырлык һәрчак янәшәдә генә: игенче батырлыгы, эшче батырлыгы, солдат батырлыгы. «Комсомольская правда» газетасында чыккан «Бары дүрт секунд» исемле мәкаләне һәркем укыгандыр. Аның беренче битендәге моңсу йөзле, ләкин бөркет карашлы татар егетенең рәсеменә карап һәркем тетрәнгәндер. Үзенең гранатасы өстенә күкрәге белән капланып һәлак булган, ләкин үз гомере исәбенә иптәшләрен һәм командирларын коткарып калган совет солдаты ул. Газинурлар, Бари Шәвәлиевләрнең энесе. Балалар язучыларына әр-яңа материал. Ләкин батырлык темасына алынырга теләүче язучылар бездә күп түгел. Ә батырлык дәвам итә...

Ш. Рәкыйпов батырлыкка баш ия, батырлыкка ышана торган язучы. Ул бер үк темага язса да, әсәрдән-әсәргә яңа формалар эзли, таба һәм шуның белән ота да. «һәйкәлләр янында» повесте да үзенчәлекле формада язылган. Ул татар халкының күренекле полководецы генерал Гани Сафиуллин батырлыгына багышланган киноповесть. Патетик-публицистик рухта, күтәренке тонда язылган бу әсәрне патетик поэма дип тә атарга булыр иде. Дөрес, ул бигүк йөгерек укылмый. Нишлисең, формасы шундый. Без киноповестьлар укып үсмәгән бит, ә экраннардан карап өйрәнгәнбез.

Хикәя жанрында исә, өлкән һәм урта буын язучылар белән бергә, яшьләр дә актив эшли. Мәсәлән, вакытлы матбугатта кызыклы гына хикәяләр белән Ш. Маннапов, Н. Әхмәдиев, Р. Низамиев, Р. Гыйззәтуллин һ. б. яшьләр катнашты. һәркайсы үз темалары, үз стильләре белән килүче яшь хикәячеләрнең узган ел күренгән әсәрләре күңелдә өмет уята. Ә менә өлкәннәрдән Гариф ага Галиевнең соңгы вакытта аеруча активлашып китүе яшь укучылар өчен зур куаныч булды. Аның бигрәк тә «Безнең Сафуаныбыз» хикәясе күңелдә торып калган. Ул җан җылысы белән өртелгән. Язучы яшь буынга битараф түгел, балаларга хөрмәт белән, мәхәббәт белән мөрәҗәгать итә.

Ш. Бикчуринның «Табылдык» хикәясенә дә тукталып узасы килә. Фәрит исемле малай мәктәптән кайтканда машина астына кереп баручы көчекне, урамда йөрү кагыйдәсен бозып булса да, коткарып кала. Аңа милиционердан шактый эләгә, әлбәттә. Малай көчекне өенә алып кайта һәм урамда йөрү кагыйдәләренә өйрәтә башлый. Этне өйрәтә-өйрәтә, ул үзе дә урамда йөрүнең бөтен кагыйдәләрен, юл тәртипләрен өйрәнеп бетә. Ә көчек, әлбәттә, шул килеш кала, бернәрсәгә дә өйрәнә алмый... Әсәр табигый итеп, балаларча язылган, рәхәтләнеп укыйсың, рәхәтләнеп елмаясың. Нәкъ менә шундый хикәяләр җитми дә инде безгә.

Соңгы вакытта табигый агышлы, табигый диалогларга, табигый уйлануларга корылган хикәяләр языла башлады. Мәсәлән, яшь язучы Камил Кәримов теле, стиле, шигъри фикерләве белән башка хикәячеләрдән аерылып тора. Балаларның эчке дөньясын хикәя юлларына күчерә белүче бу егет киләчәктә әйбәт хикәяче булыр дигән өмет бар. Ә Р. Мингалимовның «Бүген төнлә күккә кара» һәм «Ансар» хикәяләре исә үзләренең хыялга бай, чишелешләренең көтелмәгән булулары белән яңача яңгырыйлар. Риф Мөхәммәтовның турыдан-туры мәктәп тормышына кагылышлы кыска-кыска хикәяләре шулай ук җылы гына тәэсир калдыра. Балалар вакытлы матбугатында әкиятләргә дә мул гына урын бирелә. Араларында Җ. Дәрзамановның «Язбикә», Г. Латыйпның «Дәл-дәл дөя», Э. Касыймовның «Серле курай» әкиятләре кызыклы гына язылган. Ләкин әкиятләрнең күбесе һаман да иске калыпка тутырылган «старомодный» әкиятләр, аларның авторларын «татар халык әкиятләре язучылар» дип атыйсы килә. Фән-техника заманында мондый гына әкиятләр укучыларны һич тә канәгатьләндермидер.

Халкыбызның театр сәнгатенә аерым бер мәхәббәте, хөрмәте бар. Ул балалар арасында да шулай. Бер бәйрәм дә спектакльсез-тамашасыз үтми диярлек. Балалар өчен махсус пьесалар булмаса, зурларныкын алып куялар, «хан заманыннан» калган пьесаларны эзләп табалар. Ничек итсәләр итәләр, барыбер куялар. Укучыларга әр-яңа пьесалар белән очрашу бәхете еш эләкми элегүен. Шулай да узган елда алар ике пьесалар җыентыгы алдылар: Т. Миңнуллинның «Иптәш командир», Батулланың «Пәһлеваннар иле» китаплары. «Иптәш командир» пьесасы сугыш чоры балаларының батырлыгына багышланган. «Кайда хаклык, кайда дөреслек?» исемле мажаралы комедия бүгенге мәктәп тормышын чагылдыра. Алар һәр икесе балаларның рухына туры килә, «балалар дулкынына» көйләнгән әсәрләр. «Гафият турында әкият» дигән пьеса-әкият тә җор тел белән кызыклы, мавыктыргыч итеп язылган. Аны укыганда туктаусыз көләсе килү хисен кичерәсең. Ләкин шуны искәртергә кирәк, биредә әкият жанры белән реаль тормыш вакыйгалары бутала кебек. (Бу Батулла әсәрләрендә дә сизелә.) Персонажлар әреплəшкән вакытта артык реалистик итеп әрепләшәләр. Бер-берсенә «карт җен», «хәшәрәт» һ.б. дип дәшәләр. Әйтик, пьесадагы җен карт та булсын, юхасы да бик кыяфәтсез булсын, ди. Ләкин әкияттә каргану да әкиятчә һәм, әлбәттә, мәдәни булсын иде. Әйтик, дию пәрие убырлы карчыкка «чибәрем» дип дәшсә, шүрәлене «акыллым» яки «фикер иясе» дип үртәсәләр, ничек җанлы чыгасы.

Батулла китабына курчак театрлары өчен дүрт пьеса кертелгән. Аларның икесе Казан курчак театрында уңыш белән уйнала. Бу үзе үк пьесаларның уңай якларын раслап тора. Шулай да авторның, кирәксә дә, кирәкмәсә дә, иске сүзләр белән артык мавыгуы сизелә. Гомумән, телгә, сүзгә карата талымсызлык, әледән-әле очрап торган дорфалык һәм ясалмалык пьесаларның тәмен җибәрәләр. Алардагы җыр текстлары да, безгә калса, канәгатьләнерлек түгел. Әсәрләрне бизәмиләр, киресенчә, аерылып, әсәрдән бүселеп чыгып торалар алар.

Узган елда мәктәп яшендәге укучыларга кайбер публицистик әсәрләр дә тәкъдим ителде. Шуларның берсе — В. Ихсанованың «Тырыш хуҗалар илендә» исемле китабы. Ул укучыларны партиябезнең XXV съезды куйган олы бурычлар белән таныштыра, унынчы бишьеллыкка сәяхәткә алып чыга, бишьеллыкта эшләнгән һәм эшләнәчәк зур эшләр турында укучылар күңеленә барып җитәрлек итеп сөйли. Автор үзен иркен сизә, кем белән әңгәмә алып барганын яхшы аңлый, әңгәмәдәшләрен нәрсәләр кызыксындырганын яхшы белә. Китапның буеннан-буена авторның үткен телле публицист һәм тәҗрибәле педагог булуы сизелеп тора.

«Таулар, үзәннәр иленә сәяхәт» исемле китап М. Госмановның элекке әсәрләренә аваздаш. Укучыны ул ерак тарихка алып китә, Туваның бүгенгесе белән таныштыра. Азия үзәгенең экзотик гүзәллеге, кабатланмас табигате укучы күңелен шундук яулап ала. М. Госманов, галим буларак та, язучы буларак та, балалар өчен әйбәт китап язган.

Табигать турында, тереклек, кош-корт турында язганда балалар психологиясен, яшь спецификасын исәпкә алмаска да мөмкин дип санаучылар бар. Ләкин үзенең тормыш тәҗрибәсе белән баладан уздырган язучы табигатьне күрә белүе белән дә, табигатькә соклана, гаҗәпләнә белүе белән дә баладан калышмаска бурычлы. Аның табигатькә бала күзе белән дә, язучы күзе белән дә, табигать белгече буларак та каравы мәҗбүри. Табигать, кош-корт турында язылган һәр әсәр балаларны кешелекле итеп, гуманлы итеп тәрбияләүгә хезмәт итәргә тиеш. Бу җәһәттән, Г. Хәсәновның «Ялкын»да басылган парчалары матур тәэсир калдыра. Г. Шәрәфинең «Яшь ленинчы»дагы «Күрше малае» исемле хикәяләр циклы да кечкенәләр өчен атап язылган. Тереклеккә, табигатьтәге һәртөрле җан иясенә мәхәббәт хисләре җор тел белән язылган хикәяләрдә шулай ук зур урын алган.

Балалар өчен язылган шигырьнең беренче вазифасы — Туган илгә, кешеләргә мәхәббәт тәрбияләү, шул ук вакытта бала күңеленә туган телебезнең тәмен, тирәнлеген, нечкәлеген, шигърияттен сеңдерү. Биредә инде гадилек кирәк. Корней Чуковский үзенең «Икедән бишкә кадәр» китабында балалар шигыренең 13 хасияте бар дип искә ала. Менә шуларның берничәсе:

— Шигырьнең һәр строфасы рәссамга материал булырга тиеш. Ягъни шигырь юллары күз алдына килерлек булсын.

— Шигырь музыкаль булырга тиеш.

— Рифмалар мөмкин кадәр бер-берсенә якынрак булырга, ягъни янәшә булырга тиеш.

— Шигырьнең һәр ике юлы, һәр строфасы төгәлләнгән булырга тиеш һ. б.

Бездә әле К. Чуковскийның әлеге принципларын күпләр белми, белсә дә кулланa алмый кебек. Кайсы гына балалар китабын алып укысаң да, алар традицион халык җырлары калыбына шыплап тутырылган булыр: 8 дә 7, 8 дә 7. Бу бертөрлелек нәниләрне, әлбәттә, арыта, туйдыра. Өстәвенә рифмалар да янәшә түгел. Нәтиҗәдә шигырьнең динамикасы, тыгызлыгы, бөтенлеге югала. Андый шигырьне бала хәтерендә калдыра алмый. Ә инде хәтердә калмый икән, шигырьне балалар яттан сөйләп йөрми икән, шигырь үз максатына ирешмәде дигән сүз. Нәниләр поэзиясендә, образлар белән беррәттән, шигырь техникасы һәм шигъри тел дә зур әһәмияткә ия. Шигырь нәниләр өчен мавыктыргыч уенга әверелергә тиеш. Әмма уенга әйләнерлек, ритмик яктан төрле рәвешләр алган шигырьләр юк дәрәҗәсендә аз иҗат ителә.

Нәниләр өчен язылган шигырьләр туган телне өйрәнүнең беренче күнекмәләрен бирә. Шуңа күрә дә биредә сүзгә аеруча сак булу шарт. Шигырьдәге сүзләр зәвык белән сайлап алынган булырга тиеш. Сүз тезмәләре, шигырь юлларының юаннерларча эшкәртелгән булуы зарури. Чөнки бала нәкъ шул яшьтә үз теленең тәмен, кадерен белергә өйрәнә. Бу яшьтә аны үз телен яратучы, хөрмәт итүче итеп тә тәрбияләргә мөмкин, киресен дә эшләп була.

1977 елда Б. Рәхмәт, З. Туфайлова, Р. Мингалимовның сайланма шигырьләре укучылар кулына барып ирешә. Нәшрият төсле рәсемнәр белән бизәлгән ике бөртек китап та чыгарды. (Р. Фәйзуллинның «Көмәч пешерүчеләр җыры» исемле шигыреннән гыйбарәт булган уч төбе кадәр китап һәм Р. Бәшәровның матур гына ун шигырьдән торган «Бәйрәм» исемле җыентыгы.)

Балалар поэзиясендә өлкән шагыйрь Зәки Нури актив эшләде. Аның вакытлы матбугатта чыккан шигырьләре дә, «Уйлан да син, елмай да син» исемле яңа җыентыгына кергән сатирик һәм юмористик парчалары да Зәки Нурига гына хас чәнечкеле юмор һәм үткен сатира белән сугарылган. Алар укучылардагы кимчелекле яклардан көлә, матур гадәт һәм әхлакый нормалар өчен көрәшә...

Роза Хәлиуллинаның «Чүкеч — нәни булышчы» җыентыгында матур гына шигырьләр бар. Ләкин бик наив һәм эшләнеп бетмәгәннәре дә юк түгел. Мәсәлән, «Чүкеч» шигыре болай төгәлләнә:

**Кулга чүкеч алганнар**
**Ташка кадак кагарлар,**
**Хезмәт кадерен белерләр,**
**Бәхетләрен табарлар.**

Ә бит бала бу сүзләрне укыгач ук, бәхетле булыр өчен, һичшиксез, кулга чүкеч алырга кирәк икән, дип уйлаячак һәм әтисен кибеткә чүкечкә йөгертәчәк. «Ә чүкеч тотмаганнар бәхетсез буламы?» — дип тә сораячак.

Ә менә бу дүрт юллык шигырьне ни дип аңларга?..

**Шырпы тартмасына сыйган**
**Нәп-нәни эт, һай, матур.**
**Бик үртәсәң, түш кесәңә**
**Керер дә... ырлап ятыр.**

«Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Я өрәкме, нәрсә бу?» дигән шикелле, нәрсә бу? Шигырьме бу? Ни өчен әлеге җыентыкка килеп кергән ул? Аңлашылмый.

Р. Мингалимовның «Бәхетле исем» китабына укучыга таныш шигырьләр белән күп кенә яңа әсәрләр дә тупланган. Кереш сүз авторы Х. Камалов болай ди: «Р. Мингалимов шигырьләре табигый килеп чыга, берничнди ясалмалылык, үз сүзен укучыга көчләп тагарга тырышу кебек нәрсә аңарда сизелми. Ул үгетләрен дә, мораль чисталыкка, сәяси сизгерлеккә өйрәтүен дә, артык нык сиздермичә, ләкин күңелгә мәңгегә сеңеп калырлык итеп сәнгатьчә тәкъдим итә белә... Аннары бала өчен шигырь-

нең мавыктыргыч булуы бик кирәк бит әле. Бу яктан да Р. Мингалимов татар балалар поэзиясендә үзенә күрә ачышлар ясый. Ачышның асылы болайрак: автор баланың хыялга бай күңелен үзенә ияртә белә, табигый булмаган хәлне дә табигый итеп ала һәм шул контраст-хикмәт белән бала күңелен җәлеп итә». Чынлап та, Рөстәмнең балалар поэзиясендә үз юнәлеше, табышлары бар. Аның киң колачлы фантазиясе, бала күңелендәге зәңгәр хыялга тәңгәл килеп, аның белән бергә үрелә бара. Ул баланың үз фантазиясе булып кабул ителә. Шагыйрьнең нәни геройлары беразсәеррәк тә, хыялыйрак та. Әмма кайчакта шагыйрь үзе шул хыялый малайларны да уздырып җибәрә. Малайларның түгел, аксакалларның да күз алдына килмәслек образлар тудыра, үзе дә сизмәстән, хыял стихиясенә бирелеп китә. Аның шигырьләренең балалар күңеленә барып ирешүенә тоткарлык ясый торган бер «ләкин» дә бар. Ул — шигырь техникасының кайбер очракларда артык катлаулы булуында. Р. Мингалимов зурлар шигърияте́ндә үзе кулланган формаларны, шигъри техниканы, әйләнмәләрне турыдан-туры балалар поэзиясенә күчерергә тырыша кебек. Шигырьдә форма белән эчтәлек ярашмаса, балалар аны кабул итә алмыйлар — укый башлагач та абыналар да, шигырьне әйләнеп үтәләр. Мәсәлән, Э. Межелайтис та гаҗәп катлаулы шагыйрь. Үзе балалар өчен дә яза. Аның әнә шул шигырьләре шул кадәр гади, самими, хәтта Межелайтис язганына да ышанасы килми. Күрәсең, бу ике поэзия бер-берсеннән халәтләре, хасиятләре ягыннан нык аерылалардыр.

Әдхәт Синегуловның «Чалгы җыры» китабындагы беренче шигырь үк сагайтып җибәрә. «Көнебез бакчада үтә, без әлегә — нәниләр» дигән юллар бар анда. Ә бит безнең беребез дә «мин бәләкәй язучы» димәгән кебек, дөньядагы бер генә бала да «мин бәләкәй, мин нәни»дип әйтмәс. Бу сүз җыентыкта бер генә урында да очрамый әле. Ул — шагыйрьнең үз сүзе, бала сүзе түгел, ул — шагыйрьнең бала булып кылануы. Күрәсең, баланың кызык та, мавыктыргыч та дөньясына үтеп керә алмау, бала күңелен аңламау, белмәү авторга коры, ясалма шигырьләр тудырырга булышкан. Менә тагын «Уенчыклар уены» исемле шигырь. Ул түбәндәгечә тәмамлана:

**Үгез ялгыш шул чакны**
**Сөзде екты курчакны.**
**Көлке булды шул чакны.**

Бала булса, әлбәттә, бу усаллыктан курчакны җәлләп елап җибәрер иде. Кайгырыр иде, курчакны юатыр иде. Ә лирик герой, ягъни автор, шушы хәлдән авызын ерып тора. Әгәр дә чистартып, иләп, җилпеп чыгарсаң, әлеге җыентык сыйфаты ягыннан бу кадәр фәкыйрь булмас иде. Чөнки әйбәт кенә шигырьләр дә бар анда.

С. Шакирның «Яңгыр тамчысы» китабы гадәти шигырьләрдән тора. Арада җылы гына язылганнары бар, табышлар да очрый. Тик менә «Милиционер Ханнан» шигыре бераз гаҗәпкә калдыра. Степа дәдәйнең киресе буларак, ул кечкенә — йомгак кебек. Әмма кечкенә булса да, аннан бер дә ким түгел:

**Көтүдәге үгез качкач,**
**Милиционер Ханнан**
**Аның мөгезеннән тотып**
**Җиргә аударып салган.**

Көтүдән качкан үгезләрне дә хәзер милиционерлар эзли микәнни? Югыйсә, аларга башка эш тә җитәрлек ләбаса! Аннары качса да, үгезне нигә җиргә аударып салырга тиеш әле ул? Шигырь болай тәгәлләнә: Ханнан сабантуйда үзе хәтле ике пәһлеванны җиргә сала да мәйданнан чыгып китә. Аңа бүләк өләр. Ләкин ул кул гына селти: «Мин — милиционер Ханнан, бурычымны үтәдем», — ди. Бәй, тегә пәһлеван дигәнебез хулиган яки рецидивист булып чыккан түгелме соң? Милиционерның бурычы нәкъ шуларны тоту бит...

Җ. Дәрзамановның «Солдат булдым» исемле җыентыгы И. Әхмәдиевнең матур рәсемнәре белән бизәлеп чыккан. Шагыйрьнең балаларны яратуы, аларга изге бер эш эшлисе килүе күренеп тора. Аның геройлары тиктормаслар, шаяннар, беркатлылар һәм сөйкемлеләр дә. Җәүдәтнең шигырьләре якты, җылы, хәрәкәтчән. Аларда артык сүзләр, артык җөмләләр юк. Ул шигырьләрне оста итеп үрә белә, ритмик сиземләве көчле. Бер генә теләк бар: балалар дөньясына ныграк үтеп керергә иде.

Балалар дөньясы үзе бер континент бит. Алар тимер аякта яки чанада гына шумыйлар, балык кына тотмыйлар...

Безнең халыкта легендар геройлар бар: Алып батыр, Хуҗа Насретдин, Шомбай... Боларын халык уйлап чыгарган, ә бәлки чыннан да булганнардыр. Шуларга өстәп, Ш. Галиев тә үз иҗатында күп кенә популяр геройлар тудырды. Сәйфетдин, Котбетдин мәргән, татар балаларының яраткан герое — Хуҗа Насретдинның оныгы — Шәвәли, Хәлим, Сәлим, Мәсәлим... Шагыйрь бу геройларын бергә җыеп, мөгаен, берәр күңелле шигъри пьеса да язар әле. Узган ел балалар шагыйрьнең яңа герое «Булат хикмәтләре» белән таныштылар. Бу малай белән дә укучылар чын-чынлап дуслашыр дип ышаныйк.

Х. Халиковның Леонид Ханбиков тәрҗемәсендә «Кәнфит агачы» исемле китабы рус телендә чыкты. «Яшь ленинчы»да шигырь белән язылган уеннары, яңа шигырьләре дә дөнья күрде. Авторның кечкенә уеннары җиңел тел белән язылган, һәрберсенә тәрбияви мәгънә салынган була.

Рәшит Әхмәтҗановның тирән эчтәлекле лирик шигырьләре, Ф. Яруллинның оптимизмга, батырлыкка әйдәүче әсәрләре, Н. Мадьяровның туган җиргә мәхәббәт хисләре белән язылган парчалары, И. Юзеевнең «Бакчачы турында баллада»сы укучыларга менә дигән шигъри бүләк булды. Р. Гәрәй, Ф. Сафин һәм М. Әгъләмовларның балалар рухын тоеп, оста язылган шигырьләрен укып та шатланмый мөмкин түгел.

Балалар хәзер русчаны туган телләре кебек үк яхшы беләләр. Шуңа күрә дөнья әдәбияты тудырган шедеврлар алар игътибарыннан читтә кала алмый. Ләкин ничек кенә булмасын, укучыларыбыз (биредә авыл укучылары күздә тотыла) иң элек үзебезнең татар язучылары әсәрләрен укып баралар. Һәм, әйтергә кирәк, рәттән, сайламый-нитми укыйлар. Татар язучылары бу яктан горурлана ала. Ләкин әлеге рәттән укып баруның һәм уңай, һәм тискәре яклары бар. Күрүебезчә, яхшы әсәрләр белән бергә, әле өлгереп җитмәгән, зәвыксыз, татар әдәбиятының дәрәҗәсен, бәясен төшерә торган әйберләр дә укучылар кулына барып керә тора. Ә бит нәни яисә яшүсмер укучы аларның һәр икесен дә еш кына «саф алтын» итеп кабул итә... Без бүген тәрбияләгән балалар — XXI гасырда яшисе кешеләр. Аларның интеллектлары, фантазияләре, күңелләренең сафлыгы ни дәрәҗәдә булыр? Бу кадәресе безнең дә өскә төшкән олы җаваплылык. Балалар өчен язу — ул иртәгәсе көннең өлкән укучыларын әзерләү, аларда эстетик зәвык булдыру, коммунизм төзүчеләр тәрбияләү. Әгәр дә без киләчәк буынны урта кул әйберләр белән генә тәрбияләсәк, аларның якты хыялларын, күңелләрен шул начар әсәрләр белән алдасак, аларның зәвыкларын тупасландырсак, алар безне бервакытта да кичермәсләр. Кичермәсләр!

Энгель Нигъмәтуллин

# ПРОЗАБЫЗ ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР

Бүгенге әдәбият фәнен, язучыларны, беренче нәүбәттә, әсәрләребезнең идея-художество һәм эстетик югарылыгы, коммунистик идеал белән яшәгән замандашыбызның формалашуы мәсьәләләре дулкынландыра. Язучыларыбыз индивидуальлекләре һәм тел-стиль үзенчәлекләре белән төрле-төрле булсалар да, идея-философик асыллар уртак, ул марксистик-ленинчыл философия һәм диалектик материализм. Язучы өчен табигый талант кына җитенкерәми (бу күптәнге хакыйкать, бәхәссез шарт). Безнең көннәрдә язучыларның хәрәкәтчәнлеген мәгълүм бер план буенча оештыру ихтыяҗы көннән-көн арта бара. Күп милләтле совет әдәбияты һәм, гомумән, бүгенге фән казанышларыннан хәбәрдар булу, язучылар арасында үзара тәҗрибә уртаклашу, алдыбызда торган конкрет-тарихи бурычларыбызны ачык күзаллау да бүген гаять зур әһәмияткә ия. Үз «хуҗалыгыбызны» барлап чыгу, таза тенденцияләрне ут яктылыгына китереп карау, аларның кыйммәтләрен билгеләп, үстереп җибәрү ихтыяҗы да кичкенә түгел. Шул уңайдан берничә мәсьәләгә тукталасыбыз килә.

* * *

Беренче карашка бәхәссез күренгән логик бөтенлек мәсьәләсе чынлыкта каты чикләвек тышы булып чыкты. Яңа тип әсәрләргә иске үлчәү белән килеп буламы икән? Менә Ф. Мусин Әхсән Баяновның «Ут һәм Су» романындагы логик төзелеш уңае белән түбәндәге фикергә килә: «...Тормыш турында эзлекле һәм дәлилле фикер йөртү, аны үсештә карау җитми. Бу хәл романның әдәби тукымасына да тәэсир иткән. Анда эчке бөтенлек юк, сюжет-композициясе дә яңа башланган төзелеш мәйданын хәтерләтә («Казан утлары», 1973 ел, 6 сан, 154 бит). Димәк, тәнкыйтьче «эчке бөтенлекне» сюжет-композиция төзелешендә «эзлекле һәм дәлилле фикер йөртү» дип аңлата.

Ә Ф. Хатипов романтик яңгырашы белән «Ут һәм Су»га охшаш булган «Әтил суы ака торур» романында, киресенчә, сюжетның логик эзлеклелектә төзелмәвен аклый. Тотышны, ди рецензент, сөйгәнен Каган тырнагыннан коткаручы итеп тә күрсәтергә булыр иде, ләкин ул чакта образның бөтенлеге җимерелә, ә герой башка монархлардан берничнди ягы белән аерылмый булып чыга. Әсәргә зыян китермәстән, бу сюжет борылышы мәхәббәт көченә ышаныч арттыра, мәхәббәтне үлемнән өстен куя һәм шуның белән тирән философик фикергә ишек ача («Казан утлары», 1974 ел, 1 сан). Шул рәвешчә, ике тәнкыйтьче сюжет-композиция логикасы турында капма-каршы якта торып фикер йөртә. Ф. Хатипов әсәрдә логик юнәлештән ниндидер бер тайпылу, «сюжет борылышы» сиземли. Мондый көтелмәгән «сикерешләр» әсәрнең реалистик тукымасында романтик-субъектив башлангыч барлыгы белән аңлатыла. Н. Жегалов уйлавынча, романтик метод «яшәешнең һәр мизгелендә үтә кабарынкы, үтә контрастлы, мисле күренмәгән элементларны һәм почмакларны тотып алуга» һәвәс була («Новый мир», 1977 ел, № 10, 240 бит).

Аерым язучыларның романтик стильгә тартылуларын Р. Мостафин да күзәтеп бара. Берәүләр (мәсәлән, М. Әмир, Г. Әпсәләмов) вакыйгаларны читтән торып кына, үзләре катнашмыйча гына сурәтләргә яраталар, икенчеләр (Ф. Хөсни кебекләр) хикәяләүгә әледән-әле үзләре катнашып китә, лирик чигенүләр ярдәмендә «геройларга, аларның эш-хәрәкәтләренә аңлатмалар бирә, үзләренең фикерләрен белдерә бара»,— дип яза ул («Совет әдәбияты», 1961 ел, 6 сан, 119 бит).

Шулай итеп, кайбер әсәрләрдә табигый хикәяләү автор фикере логикасы белән бүленә һәм хакыйкатьтә без ике төрле, реалистик һәм романтик, логикага тап булабыз. Г. Ахунов «Ут һәм Су» турында болай дип яза: «Ахсан Баянов все время старается соединить в своем романе эпическое и лирическое и достигнуть этим самым богатства созвучий, полифонии» («Литературная Россия», 1975, 12 декабрь). Шул уңайдан «Ут һәм Су» әсәренә тәфсиллерәк анализ ясап үтик.

Әсәрдәге ике план (объектив һәм субъектив) автор ачыкларга ниятләгән мәсьәләләрдән килеп туа. Объектив хикәяләү планы иң элек җитәкче һәм эшчеләрнең хезмәт сыйфаты өчен көрәшүләре, аларның кеше турында, аның язмышы, уй-хисләре хакында кайгыртуларына барып тоташа. Объектив план логикасы әсәрдә бүленми: төзелеш үсә, ныгый, кызу темп ала: төзелеш дәвамында коллектив белән җитәкчелек арасында тормышчан мөнәсәбәтләр урнаша, ялгыш һәм искереп тузган принциплар, методлар читкә ыргытыла. Төзелеш — социалистик шартларда барлыкка килгән бер бөтен организм, тарихи-объектив зарурият. Аның хәрәкәт логикасы да эзлекле. Ә субъектив хикәяләү планы исә үзәк геройларның тормышка карашлары аркылы ачыла. Шагыйрь буларак, Ә. Баянов характерларны традицион юлдан баручы әдипләргә хас, психологик монолит итеп күрсәтүдән баш тарта, аларны икегә — конкрет шәхескә һәм символик фигурага — тармакландыра. Алдыбызда тормышка һәм производствога мөнәсәбәтләрендә еш кына капма-каршы позицияләрдә торган ике дус — Фәез белән Борис. Алар тормышның символик ягы Кама (Камилә) образына мөнәсәбәтле дә үстереләләр (Кама образын Х. Хәйри, нигәдер, романның артык өлеше дип саный.— «Социалистик Татарстан», 1974 ел, 6 октябрь). Кама — табигать образы, күп функцияле образ. Беренчедән, ул туган-үскән җирнең әйтеп бетермәс матурлыгын, аның гүзәл традицияләрен гәүдәләндерә. Икенчедән, Кама галәмнең биниһая киңлеген һәм кешедәге мәңге сүнмәс иҗади ялкынны чагылдыра. Кыз сынына әйләнгән Камага гашыйк Фәез хыяллары белән әллә кая, космос киңлекләренә очып китә: «Адәм баласы төнге күккә караса, уйлана башлый. Дөньяның башка сыймас хикмәтләре шул ераклыклар белән бәйләнгән бит. Мәңгелек сер — йолдызлар каян килеп чыккан? Газ сыман әйберләрдәнме? Ә газлар үзләре каян?

Җир — безнең бәллүебез. Аннан ары — планеталар, кояш, тагын да арырак — безнең галактика, аннары бүтәннәре...— башка дөньялар, томанлыклар... Ә алар нинди дөньяга барып тоташа? Галәмнең чиге булмаса, шул чиксезлек кая хәтле сузыла һәм аннан ары — тагын да ары нәрсә китә?

Сорауларның чиге юк. Алар кешенең бала чак акылын аеруча нык борчыйлар. Уйлап-уйлап та җавап таба алмагач, соңыннан адәм баласы алардан кул селти һәм чагыштырмача уйсыз гомер кичерә. Ә туктый алмаса — алардан яңа Лобачевский яки Эйнштейн килеп чыга».

Лобачевский да, Эйнштейн да парадокс идеяләр тудыручы иҗатчылар. Шул рәвешчә, автор укучыга субъектив планлы логика ачкычын тоттыра. Өченчедән, Кама образы аша табигать «зәңгәр кош»ка тиңләштерелә, кеше йөрәгендә романтик «җүләрлек», дуамаллык булуы күрсәтелә. Камага мәхәббәт Бористагы рациональ системалылыкны җимереп ташлый. Даһиларча ялкынланып, Борис Камиләнең зәһәр елан чаккан аягыннан яраланган иреннәре белән агуны суырып ала.

Әлеге романтик-символик план ярдәмендә автор геройларның үзгәрү, урыннары белән үзара алмашу логикасын барлыкка китерә. Бу логика — эзлексез. Дөреслек я берсе, я икенчесе ягында. Моңарга тәнкыйть тә игътибарсыз калмады. Р. Мостафин Фәезгә дә, Бориска да өстенлек бирми. Беренчесе энтузиазм канатында очып йөри, вакытын кызганмый, эшкә башы-аягы белән бирелә. Икенчесе салкынча табигатьле, аек карашлы, эшне үлчәп кенә эшли («Казан утлары», 1973 ел, 11 сан).

Нәтиҗәдә автор «тәртипсезлек» моделен планлаштырып, исәпләп чыгара, диалектик көчләр ярдәмендә табигатькә, галәмгә баш булган совет кешесенең хезмәт бәхетенә, ул кешенең шаблонга дошманлыгына мәдхия укый.

Кайчак язучыларыбызда, аеруча яшьләрдә, алогизмнар (логикасызлыклар) язучы ихтыярына буйсынмый башлый, йөгәнсезләнәләр. Марсель Галиевнең «Кар абагалар» повестен генә алыйк («Идел» альманахы, 1976 ел). Әсәрнең төзелеше йомшак, аны укыганда ни турында уйланырга, фикер йөртергә дә кыенсынасың. Автор укучыны үзе өчен дә формалашып өлгермәгән идеяләр чоңгылына ыргыта. Кайбер идеяләр кызыклы да шикелле. Әйтик, «аталар һәм балалар» мәсьәләсе яки яшәеш, вакыт, ирек, чикләнгәнлек турындагы фәлсәфи уйланулар («Җир шары әйләнә. Кайдадыр илләр чәкәләшә. Галәмдә кайсыдыр күк җисеме кояш булып кабына да бөтен тереклеге белән көлгә әйләнә»). Яшьләрнең характер үзенчәлеге, аларның эстетик тою хасиятләре, ниһаять, «исповедь» алымы да кызыклы. Төзү институты студенты Данияр тормышының беренче сукмакларын күңелдән кичерә. Әмма тәүбә итү (исповедь) — бик үзенчәлекле һәм алдаучан юнәлеш. Язучыдан ул зур осталык таләп итә. Язучы геройга хөкем хокукы биреп, аңардан үзенә дә хөкем ясата. Герой алгы урынга бастырыла икән, аның фикерләре, күңел хәзинәсе укучы өчен инде мөһим һәм мавыктыргыч булырга тиеш. Ә «Кар абагалар»дагы геройның әле тормыш тәҗрибәсе җитенкерәми, зәвыклары оешып бетмәгән, «умыртка сөяге» сыеграк. Шуңа күрә хикәяләү чылбырын герой ихтыярына тапшыру дөрес түгел. Герой фикерләрен башка персонажларның монологлары белән аралаштыру яхшырак булыр иде.

Романтизм белән сугарылган «тәртипсезлек», ягъни энтропия, әдәбият өчен гадәти процесс. Сюжет-композиция белән генә чикләнмичә, ул әсәрнең һәр өлешенә кагылып уза. Мәсәлән, А. Расихның «Ике буйдак» романындагы Заһид Сафич. «Нормаль» логикадан чыгып караганда, ул Рәхимнең кыен хәленнән файдаланып, аңарга кискен ут ачарга тиеш иде түгелме? Мәдинәнең дә саф мәхәббәтен аңлап җиткермәде... Әмма эш аларда гына түгел. Заһид Сафичның логикага хилаф йөрешләре, күрер күзгә бигүк ачык булмаган икеләнүләре, ахыр чиктә авторга фәнни дөньябыздагы киеренке, ләкин асылда туры, намуслы мөнәсәбәтләрне күрсәтергә ярдәм итте.

* * *

Безнең тәнкыйтьтә конфликтка ике төрле караш урнашты: беренче төр конфликт — характерлар, принциплар бәрелеше; икенче төр конфликт — диалог.

Бу мәсьәләне аңлатуда тәнкыйтьчеләр, схемачылыктан арына барып, конфликтны әсәрнең тукымасын, форма-эчтәлеген үреп алган конструктив этәргеч итеп аңлый башладылар. «Персонажлар арасындагы бәрелеш,— дип яза А. Әхмәдуллин,— ул конфликтның өстә яткан, күренеп торган, тотып алу өчен ансат ягы. Ә чын конфликтның табигате күп катлаулырак бит» («Казан утлары», 1970 ел, 6 сан). Н. Юзиев та, А. Расихның «Язгы авазлар» романындагы Ифрат белән Халиков арасындагы мөнәсәбәтләргә тукталып, бу ике кешенең бәрелеше дөньяга ике төрле караш, җитәкчелектәге ике стиль көрәше итеп сурәтләнә, ди. Һәм һәр язучыдан да эчке һәм тышкы конфликтларны тыгыз итеп куша белү, төп конфликтны үстерүдә эзлеклелек, образда социаль як белән психологик һәм индивидуаль якның бердәмлегенә ирешү таләп итәлә дигән нәтиҗәгә килә. («Совет әдәбияты», 1964 ел, 4 сан).

Г. Ахунов исә социаль каршылыкларга нигезләнгән элекке роман («Матур туганда», «Язгы җилләр», «Онытылмас еллар») үзенең беренче кыяфәтен югалтып бара, хәзерге заман каршылыклары башкачарак — катлаулырак, нечкәрәк, аларның төбенә төшенер өчен характерларга тирәнрәк керергә кирәк дип саный («Литературная Россия», 1975 ел, 12 декабрь). Ф. Хөсни, шулай ук конфликт мәсьәләсен истә тотып булса кирәк, язучыны Л. Н. Толстойның күңел диалектикасына җитәкләп китерә: «Әгәр дә Лев Толстойда аның хыялының гүзәл чәчәкләре булып Платон Каратаев һәм капитан Тушин образлары туса, шул ук Толстой-художникның җанында Сергей попның кыска аяклы җилбәзәк Мариядан башы әйләнеп гөнаһыга батуын сурәтләү кебек ямьсез картиналар да туа һәм тирәнтен кичерелә алган... Художник күңеленә барлык гөнаһлар да һәм барлык изгелекләр дә сыя ала» («Социалистик Татарстан», 1970 ел, 31 май).

Күргәнебезчә, сүз объектив һәм герой күңелендә туган эчке каршылыклар арасындагы бәйләнеш турында бара. Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» повесте уңаеннан рецензентларның бәхәсләшүе гыйбрәтле. Тәнкыйтьчеләрнең бер өлеше Мирвәлине «кулак» итеп кенә күрә. Икенчеләре исә аның ил белән тыгыз бәйләнештә икәнен ассызыклый (Р. Мостафин, Р. Фәизо-

ва, Л. Лебедева). «Совместимы ли масштабы, сопоставима ли история Мирвали и Шамсегаян с историей, со временем и современностью?» — дигән сорау куя Л. Лебедева һәм: «Гилязов написал свою повесть так, что она убеждает: совместимы»,— дип йомгак ясый. Юк, Мирвәлине алыш-биреш кызыксындырмый, атасында булган сыйнфый сызыклардан ул азат, аның өчен, беренче чиратта, үз сүзен әйтү мөһим. Аһ та итмичә, ул аталар йортын ташлап чыга, байлыкка төкерә, сөйгән кызы өчен янып йөри. Әйе, геройның минминлеге артыгы белән, ташып тора, ләкин Мирвәли буржуаз тип буларак күрсәтелми.

Авторның күңел көзгесендә көндәлек ыгы-зыгы түгел, бәлки кешеләр хәтере һәм изгелек белән явызлык турындагы фәлсәфи уйланулар чагыла. Кеше яманны авызлыклый ала, чөнки аңарда олы көч бар. Табигать тә, кеше күңелен сизгәндәй, сабыйларча назлана, елмая: «Күк зәп-зәңгәр! Анда-санда гына болытлар йөзә, тик алары да сабый бала хәсрәте кебек җиңел, юка иделәр, күләгәләре җиргә дә төшеп җитә алмыйча эрел бетә иде». Менә шул җиңел сулыш Гыйләҗев повестеның аһәңен, фикер нагрузкасын тәшкил итә. Ә тарих, ерак күк күкрәве сыман, әсәрнең арткы фонында яшеренгән. Автор аны алгы планга колагыннан өстерәми; Мирвәли йөрәгендә яңгыраган диссонанс тавышлар аркылы, «кеше — табигать — җәмгыять» дигән ассоциация чылбырын кузгатып, автор укучыны тарихи үсеш юлы белән баетылган яңа чынбарлыкка илтеп җиткерә.

Кайчак аерым язучыларда бу объективреаль сәбәплелек караңгылана, сыеклана төшә. Олы язучыбыз Г. Әпсәләмовның «Яшел яр» романыннан бер мисалга тукталыйк. Әсәрнең үзәгендә — Гәүһәр, аның тормыш одиссеясе. Гәүһәр чын мәхәббәт, дуслык һәм күңеленә яткан эш эзли. Йомшак табигатьлелеге, кешеләргә ягымлылыгы аның субъектив конфликтын бермә-бер йомшарталар. Автор героинясын романның башыннан ук оптимист кеше итеп күрсәтә, аны чиксез киң Идел ярында каршы ала. Димәк, Гәүһәрнең язмышын чәлпәрәмә китерер өчен тирә-якта нинди дә явыз көчләр посып торган булырга кирәк. Авторның игътибары объектив конфликтка юнәлергә тиеш. Әмма ул мондый юлдан бармый, бары тик кеше күңелендәге эволюцион хәрәкәтне генә күреп кала. «Кеше аерым мохит эчендә яши. Аңа аерым нәрсәләр туктаусыз тәэсир итеп торалар. Тик кайбер тәэсирләр шул кадәр кечкенә була, кеше хәтта аларның барлыгын да сизми. Кайсыберләре, киресенчә, үзеңнән көчле күренәләр, кеше алар тәэсиренә бирелеп, байтак вакыт үзен кая куярга белми йөри. Ләкин бу тәэсирләр ике котыптан гына тормый, кеше дигәнең үзе чиксез катлаулы булган шикелле, аның тәэсир чыганаклары да санап бетергесез. Гәүһәрнең уй агышы үзгәргән икән, моның сәбәпләрен кем әйтә алыр?» Дөрес... Ләкин сүз героиняның аңында булган кискен үзгәреш турында бара бит! Ә монда аның яңаруы бик җиңел үтте, нәфрәт чаткыларын чәчрәтеп чыгарырга Җәгъфәрнең көче генә җитмәде. Без аптырашта: ничек инде шундый басынкы, уйлап эшли торган кеше юлыннан язсын, ди. Алай булгач, аны йөгәнсез итеп күрсәтү кирәк иде. Гомумән, автор эчке, лирик конфликт белән мавыгып, чын тормыш драмасын күрсәтергә, мещаннарга ут ачарга өлгерми кала.

Инде характерлар конфликтыннан чыгып диалогка килик. Диалогның хәрәкәт мәйданы конфликтныкына караганда да колачлырак. Диалог, мәсәлән, Әхәт Гаффаровның «Теге гозер...» повестенда үзенчәлекле чагылыш таба. Күрше авылдан сыер сатып алган Җиһангир карт өенә кайтырга чыга. Боларны бүре өере сырып ала. Урман эченнән барганда бүреләр тимиләр әле. Күзләре генә, янган күмердәй, төнге караңгылыкта ялтырап китә. Кырга чыккач инде алар актив хәрәкәткә күчәләр, баш бүре алга узып карт белән сыерның юлын кисә. Үлем афәтеннән куркып котырган сыер картны читкә өстерәп китә. Бер мизгелгә аптырап калган бүреләр ауны дәвам итәләр. Бүреләрнең берсе карт өстены ташлана.

Сугышта булып кайткан Җиһангир карт бу минутларда көрәштәш дусларын хәтергә төшерә. Юк кына нәрсәдән — сыер сатып алу мәшәкатьләреннән башланып, повесть безне җитди проблемаларга китереп чыгара. Җиһангир карт башыннан үткән михнәтләр аркылы язучы, диалог ярдәмендә, укучыга әйтергә теләгән төп фикерен җиткерергә омтыла: дөньяда бәхет көрәшеп алына; намуслы булып кал, ләкин явызлыкка каршы чыкканда уяу бул. «...Явызлык дөньясында шулай инде, көчле көчсез артына поса. Алай иткәндә калҗаның майлырагы тия аларга», дип уйлады карт. Безең командирлар гына алдан йөгерде шул, аларны без атлап үттек. Не-

мецларныкы үлек аша атлап йөрде».

Әдәбиятчы В. Ковский диалог-диспутны дөньяга карашның композицион һәм художество үзенчәлекләренә ия мөһим бер принцибы итеп таный һәм аның характерлы чагылышын С. Залыгинның «Көньяк Америка варианты» романында күрә. Эстетик чынбарлык романда автор белән героиня арасындагы диалогта туа. С. Залыгин сюжет зарурияте кысаларыннан чыгып роман табигатенә хас җанр иреклелеген үз ихтыярына буйсындырган. Әсәр буеннан-буена диспут рәвешендә оештырылган (героиняның автор белән, үз-үзе белән, дуслары, хатын-кыз һәм ирләр «даирәсе» белән һәм, ниһаять, авторның әдәби икейөзлелек белән, хатын-кызның семьядагы роленә стереотип карашлар белән диалогы һ. б.).

Безнең әдәбиятыбызда да диалогка игътибар үскәннән-үсә бара. А. Расихның «Каһарманнар юлы»нда «аталар» белән «балалар» арасында диалог алып барыла, иң көчле диалог — татар бригадасында катнашкан карт ветеран Хәбибрахман абзый белән яшь галим Альфред арасында.

Г. Әпсәләмовның «Күк күкрәр» романында да «аталар» белән «балалар»ның диалогы ачыклана. «Аталар» — «Карышкан кызлары» традицияләрен саклаган һәм, гомумән, революцион көрәш идеяләре белән рухланган олы буын. «Балалар» — яшь буын (Вәли, Мәрхәбә, Владимир Ильич һ. б.).

А. Гыйләҗевнең «Кызлар хатлары»нда Рушанияне бер уй борчый. Аның ахирәте авыр хәлдә, ярдәмгә мохтаҗ. Рушания ярдәм кулын сузарга әзер. Ләкин чигенерлек булмасмы? Һәм ул үз тормышына анализ ясый — ата-анасы, дус кызлары белән диалогка керә.

М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар»ы да диалогтан гыйбарәт. Аны Рушад алып бара. Рушадның оппоненты — үз хәтере, анда күп кенә кадрлар — күренешләр яктырып китә.

* * *

«Заман дигән нәрсәне нәкъ бүгенге көн белән генә чикләү һәм әдәби әсәрнең кыйммәтен бары аның көндәлек хуҗалык мәсьәләләрендә генә күрергә тырышу, бу, минемчә, бик тар караш, бик примитив караш»,— дип язды үз вакытында Ә. Еники («Социалистик Татарстан», 1962 ел, 31 май). Өлкән әдип Шәйхи Маннурны Г. Ахунов «вакыйгаларны киңрәк масштабта алып уйланырга» чакырды («Социалистик Татарстан», 1975 ел, 15 февраль). Әдәбиятыбызда бүгенге белән үткәннең органик төстә үзара кушылуы процессы бара хәзер. Ул процесс ике тармакка аерыла. Беренчедән, тарихи роман һәм повестьлар иҗат ителә. Аларда тарих әр-яңа фәнни методология нигезендә, бүгенге көн югарылыгыннан торып тикшерелә; икенчедән, роман жанры үзе катлаулана бара. Соңгысына мисал итеп Ю. Бондаревның «Яр» исемле «күп этажлы» романын күрсәтергә була. Бу төр әсәрләрнең үрнәге итеп тәнкыйтьче Х. Хәйри татар әдәбиятында Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар» романын саный. «Бу эпопея халыкта революцион аң үсү процессын, революция һәм гражданнар сугышы чорын тарихи дөрес, киң итеп тасвирлавы белән, проблемаларның төрлелеге, күп планлы композицион төзелеше... белән аерылып тора» («Социалистик Татарстан», 1974 ел, 17 май).

Х. Хәйри башлаган исемлекне дәвам итеп, без Э. Касыймовның һәм А. Расихның роман-дилогияләрен, Г. Ахуновның «Идел кызы»н, Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишег»ен искә алыр идек. Аларда конкрет социаль һәм милли җирлектә туып үскән тулы канлы образлар да, әсәрнең үзәк пунктларында калкыган символлар да (мәсәлән, Г. Бәшировта тулпар, Э. Касыймовта Революция тавы, Г. Ахуновта сал), магистраль образ-идея дә (Э. Касыймовта химия заводы, Г. Ахуновта Мулланур Вахитов образы, А. Расихта «Урал» газетасы), тормышның киң панорамасы да, психология, әхлакый, фәлсәфи сыйфатларның үрелеп килүе дә бар.

Ә гомумән алганда, безгә әле тарихи фактлар һәм информациягә бәйлелек житенкерәми. Шуңа бәйле рәвештә язучыларыбыз кайчак узганны легенда яки символик образлар формасында гына күз алдыбызга китереп куялар. Романчыларга әледән-әле тарихчы галим ролен дә үз өсләренә алырга туры килә (бу эш кирәктер дә, ләкин материал җыю процессы артык кыен, катлаулы булу сәбәпле язучының талчыгу һәм иҗат энергиясе киму ихтималы да арта). Казанышларыбыз шактый, әмма бүгенге совет әдәбиятының аеруча җитди уңышларына тигезләшү өчен дә безгә әле байтак кына эшләргә, эзләнергә кирәк. А. Чаковскийның «Блокада»сы, В. Ивановның «Мәңгелек чакыру»ы, С. Залыгинның «Комиссия»се, И. Стаднюкның «Сугыш»ы, Ю. Бондаревның «Яр»ы кебек романнарны укыганда сокланып ук куясың, әйтер-

сең лә аларны автор ялгызы түгел, ә бер төркем әдипләр язган (энциклопедияләр һәм тарих дәреслекләре сыман). Ә без үзебезгә имана җире бүлеп алабыз да, шул җир киңлегеннән генә карап язабыз. Гомумиләштерү һәм фәлсәфи мөмкинлекләр файдаланылмый кала. Әйе, файдаланылмый кала, мөмкинлекләребез зур, юкса.

Энциклопедик белемнең язучы өчен ни дәрәҗәдә зарури булуын мәкаләләрнең берсендә М. Мәһдиев тә ассызыклап язган иде. Анатоль Франсның язуына караганда, ди ул, Теофиль Готье үз гомерендә бик күп сүзлекләр, белешмәләр, сәнгать, һөнәр турында күп кулланмалар укыган, ә сүзлекләрдән файдаланырга яратмаган язучыны язучы исемен йөртергә лаек түгел дип исәпләгән («Социалистик Татарстан», 1974 ел, 3 февраль). Ә бит энциклопедик белем таләп итә торган күпме темалар көтеп тора безнең язучыларны, күпме яңа ачышлар көтә! Гомәр Бәширов әйтеп узганча, күп белү генә дә аз, «кызыксынучан, күзәтүчән булу таләп ителә. Кайда? Нәрсә? Ничек? Нигә алай? Ничек шулай? Нишләп тегеләй түгел? кебек сораулар бервзлексез мазасызлап торса гына тормышны тирәнтен белә аласың.»[1]

Болар өстенә язучы-романист өчен хыял көче, иҗат фантазиясенең дә әһәмияте гаять зур. Шул уңайдан өлкән язучы Г. Әпсәләмов сүзләренә игътибар итик: «Икенче дәфтәр — иҗат лабораториясенең икенче бүлмәсе дидем. Ләкин иҗат лабораториясе ике бүлмәдән генә тормый, аның әле өченче, дүртенче, бишенче... бүлмәләре дә, бихисап подваллары да җитәрлек»,— дип яза ул («Казан утлары», 1974 ел, 4 сан, 140 бит). Аңарга Ф. Хөсни дә кушыла: «Үзе күргән, үзе кичергән материалны оештырып яза белү — әле ул беренче генә этап. Ничек итеп ул менә тормышның тагын да катлаулырак серләрәк икенче, өченче «бүлмәләренә» керә алыр да, анда яшәүче кешеләрне сәнгатьчә ни дәрәҗәдә дөрес күрә һәм сурәтли алыр?» (Социалистик Татарстан», 1970 ел, 31 май). Кайчакларда автор панорамалы әсәр язарга керешә, ә җентеклəбрәк карасаң, ул бер мелодраматик повесть булып чыга. Моңарга Газиз Кашаповның «Сәмум җиле» повесте гыйбрәтле мисал булып тора. Автор киң масштаблы бай материалдан файдалана: Советлар Союзының Венгрия халкына ярдәм кулын сузуы; совет кешеләренең интернациональ бригада составында Испания җирендә фашистларга каршы көрәшүләре; илебездә уздырылган хәрби маневрлар; Ерак Көнчыгыш вакыйгалары; госпиталь тормышы һәм башкалар. Тематика ифрат бай һәм кызыклы... Ә эшләнеше? Иң элек, автор эчтәлеккә тәңгәл форма эзләп таба алмаган. Повесть үзәгендә ике персонаж — рота командиры өлкән лейтенант Рамиз Җәләев һәм аның табылган анасы, медицина полковнигы Ирина Андреевна Геева. Сюжет, нигездә, шушы ике герой тирәсендә әйләнә. Уңышлымы бу форма? Юк! Әгәр автор сугыш елларын тасвирлап, сугыш афәтенә тарган кешеләр турында гына язган булса, нияте акланган да булыр иде. Ә бит повестьта вакыйгалар башкачарак. Ниндидер «сәбәп»ләр аркасында ана улы белән очраша алмый, имеш, «ана булып яшәүне кырыс хәрби хезмәткә алыштырган», ләкин «иң нечкә, иң саф хисләре әллә кайда, йөрәкнең иң тирән түренә яшеренгән иде...» Күренә ки, автор мелодраманы сайлап, тормышчан һәм олы темадан шактый читләшә, киң тарихи панораманы сурәтләүдән баш тарта.

Тематиканы ачыклау, язылачы әсәрнең сюжет сызыкларын билгеләү дә әле чагыштырмача җиңел эш. Әмма әсәрнең структурасын төзү, оештыру җиңеллəрдән түгел. М. Мәһдиевнең тыгыз информацияле «Каз канатлары» романын гына искә төшерик. Анда аерым-аерым язмышлар әйтерсең лә бер җепкә тезеп бирелгәннәр. Ә эчке бәйләнеш, П. Громов әйткән «эчкәре фон»[1] әсәргә җитешми.

Бүгенге көн романы тормышны турыдан-туры чагылдыру белән генә чикләнә алмый (бу — сәнгатьнең төп законы), бәлки тормышның күп этажлы һәм катлаулы моделен күз алдына китерергә тиеш. Һәм ул этажлар берсе өстенә икенчесе гади генә тезеп куелмаган, ә үзара чолганып, художестволы вакыт өлешләрендә төрлечә иерархиягә буйсындырылганнар. Әдәбият белгечләре бүген семиотика, информацион теория һәм башка фәннәр мәгълүматларын файдаланып нәкъ менә шул катлаулы бәйләнешләрне ачыклау юлында күп хезмәт куялар.

Әсәрнең күп баскычлы структурасы нәрсәдән килә? Бу сорауга авторның барлык

---

[1] Гомәр Бәширов. Бүген дә, иртәгә дә. Әдәби тәнкыйть, публицистика, истәлекләр. Тат. китап нәшрияты, Казан, 1974, 192 бит.

[1] П. Громов. О стиле Льва Толстого. «Диалектика души» в «Войне и мире». Л., «Художественная литература», 1977.

кулъязмаларын тикшергәндә генә канәгатьләнерлек җавап табып булыр иде. Мондый тикшерү методы, мәсәлән, Нур Гыйззәтуллин тарафыннан еш кулланыла (аның К. Нәҗми, И. Гази романнарына багышланган рецензия-мәкаләләрен карагыз).

Безнең фикеребезчә, җитлеккән проза әсәре язучы иҗатында реалистик һәм романтик башлангычларның бергә кушылып, үзара органик рәвештә үрелеп баруы нәтиҗәсендә генә туарга мөмкин. Бу башлангычлар, үз чиратында, язучының эстетик идеалына (монда язучының фәлсәфи, социаль, әхлакый карашлары да, аның чынбарлыкны художестволы-психологик сиземләү үзенчәлекләре дә керә) буйсыналар. Реалистик һәм романтик башлангычларның берлеге шулай ук гаять четерекле мәсьәлә. Романтик якка тайпылу композициянең таркалуына, йөрешләр кабатлануына, «реклама»га хас кычкырып торган сурәтләү чаралары белән артык мавыгуга китерергә мөмкин. Әлбәттә, әдәбият дөньясында әле күп кенә фәлсәфи-художество юнәлешләре дә яши: пантеизм, экспрессионизм, экзистенциализм, натурализм һ. б. Социалистик реализм әдәбияты киң колачлы, ачык система буларак, аларның кайсыберләрен үз составына өлеш, элемент рәвешендә кабул да итә ала (бу безнең хәзерге татар совет әдәбиятында үзен әледән-әле сиздереп тора), әмма төп башлангычлар булып барыбер реализм белән романтизм кала.

Әйтик, Ә. Баяновның «Декабрьның үнөченче көне» повестенда, М. Әмир, Г. Әпсәләмов, Г. Ахунов романнарыннан үзгә буларак, эпиклык арткарак чигенә. Герой характерын формалаштырган шартлар да Исәнбәк язмышына гына кагыла (Исәнбәк монологы). Автор аның үсешен сузып-сузып тасвирлый, геройны чуар ситуацияләргә ташлый. Ә Әнис образы башкачарак төзелгән. Ул инде формалашып җиткән булып күз алдыбызга баса (яшь булуга карамастан). Ул таләпчән дә, күзәтүчән дә, хәтта нечкә сизгер дә. Мондый яшьләр тормышта шактый. Аларның рухи халәте сау-сәламәт икән, бу бит үзеннән-үзе генә килмәгән. Димәк, боларны тәҗрибәле педагог, акыллы психолог тәрбияләп килгән. Кем соң ул, Исәнбәкме? Ирле хатын артыннан йөрүче Исәнбәкме (Ч. Айтматовның Җәмиләсе хәтергә килә)?

Димәк, автор геройны әхлакый эзләнүләр, үзгәреш һәм үсеш юлында күрсәтми, монда һәр геройның язмышы башкаларныкыннан аерым, үзенә күрә бер бөтенне тәшкил итә (пантеистик алым). Һәм нәтиҗәдә күп кенә звенолар югала (мәсәлән, психологик анализ, геройлар мохиты киңлеге, характердагы бушлыкны тутырыр өчен яңа җеп-нокталар табу, образларны бер-берсенә тыгызрак бәйләү һ. б.). Әмә «Төлке тоту кыен түгел»дә Ә. Баянов романтик алымны сакланып кына эшкә җигә. Бу әсәрнең үзәгендә — кыяфәте һәм кыланышы белән Кола Брюньонга охшашлы, тормышка гашыйк тулы канлы милли-тарихи характер.

Ф. Хөсни, Ә. Баяновтан аермалы буларак, яңа темалар, яңа күренешләр һәм ракурслар артыннан чапмый, бәлки чагыштырмача таррак күләмле күренешләрне йомшак һәм сихри ут яктысына китерә, һәрчак аларга яңа төс, яңача образлылык, тылсымлы аһәң өсти. Ф. Хөсни шагыйрьләребездән Нури Арсланов, Гамил Афзал, Равил Фәйзуллиннарны хәтерләтә. Әмма прозада, үзебезнең татар прозасында мин аңарга охшаган язучыны таба алмадым. Ләкин романтик башлангыч белән артык мавыгып китү еш кына аңарга да үзенең реалистик фикерләү сәләтен җәеп җибәрергә комачаулык итә. Мәсәлән, «Гыйльменисаада Ф. Хөсни чын мәгънәсендә тормышчан катлаулы образ бирергә исәп иткән. Әлмөхәммәт байның кызы Гыйльмениса Хафиз исемле егет белән йөргән (егет сабан туйларда көрәшеп батыр калган, оста биюче саналган). Шул Гыйльмениса авылның иң фәкыйрь егетенә ябышып чыга. Автор Гыйльмениса психологиясендә көтелмәгән бер «шартлау» булуын таный, ләкин героиня күңелендә булган хисләр-фикерләр көрәшенә күзен йомып китә. Нәрсә кузгатты аның күңелен? Бурычмы... Бурыч бит сыер сабырлыгы түгел. Бәлки мин-минлекне, эгоистик теләкләрне, инстинктларны басудыр... Әлбәттә, бу үз-үзеннән генә хәл ителмәгәндер.

Инде «Урталыкта»га күчик. Аның авторы Аяз Гыйләҗевнең дә дөньяга карашы үзенчәлекле, һәм ул фикерләү спецификасы ягыннан күпмедер дәрәҗәдә Юрий Бондаревны хәтерләтеп куя. Әмма бу охшашлык, кызганычка каршы, иҗат җимешләре белән әлегә ныгытылмаган. Повестьның күп урыннарында автор сәбәпле бәйләнеш арканын кулдан ычкындыра ясә гел югалтып җибәрә. Дөрес, моның белән ул безне беркадәр тирәнрәк ассоциацияләргә күнектерә, иҗади фикерләребезне

уята, шаблоннан арындыра кебек. Ләкин һәр эштә чама булырга тиеш.

Әсәрдә аңлатуы кыен булган каршылыклар да юк түгел. Нигә, әйтик, Шәйхи эчүгә сабыша һәм шуңа да карамастан ни өчен ул әүвәлге эшләгән урынына (инде бер куылгач) яңадан эшкә кабул ителә һәм эксперименталь группага, җитмәсә? Кем ул Гали Кадыйров? Нигә Рузалия үзе күптәннән күрмәгән кешегә ачылып китә? Баязит Гарифуллинның роле дә шактый томанлы. Нигәдер бу геройны Сәгыйть фигурасы арткы планга этәреп куя. Сәгыйть акыллы кеше күренә, аның талант турындагы фикерләре хәтердә кала: «Талант иясенең идеаллары бүгенге көн обывательләренең таләпләре белән тәңгәл килә алмый, һич! Талант алданрак күрергә тиеш, ераграк, тирәнрәк карарга». Ләкин бу фикерләрне герой үзе түгел, автор әйткән кебек тоела. Бит әле Сәгыйть әхлакыйрухи кыйммәтләрне тиешенчә аңына сыйдыра алмаган, ул ничек кенә матур, акыллы сөйләшмәсен, чынлыкта роботны гына хәтерләтә. Сәгыйть тормыш сынавын үтә алмады, үзенә тапшырылган эшне дә ярты юлда калдыра. Эксперименталь эзләнүләр, тикшерүләр күпме дәүләт, акчасын йотты, күпме көч алды, күпме кешеләрнең энергиясен һәм ышанычларын сарыф итте. Сәгыйть иптәшләре арасында түгел, Рузалия тирәсендә генә кайнаша. Мондый геройның кабат эшкә тотынуы бик шөбһәле, әлбәттә. Ә инде Баязит абый бөтенләй башка. Ул сүнеп барган эшкә яңа дәрт, яңа сулыш өрә. Ул иҗат кешесе, парадоксаль фикерләр иясе, тик авторның аны уртә кул геройлар хәлендә калдыруы гына гаҗәп тоела.

Инде зур күләмле проза әсәре иҗат иткән язучы алдында тагын бер нәрсә — ныклы җирлек булу шарты куела. Информация бездә байтак, ул башка милли әдәбиятларда да җитәрлек. Информация дөньяда тау ташкыны тизлегендә үсә бара. Бөтен информация милли әдәбиятның үз җирлегенә туры китерелгән булырга тиеш. Ә әдәбиятның милли үзенчәлеге әле бик аз өйрәнелгән өлкә дисәк тә күп ялгышмабыздыр, шәт. Шуңа күрә бу өлкәгә кул сузмыйча гына, кайбер фикерләр белән уртаклашып узыйк.

Милли дигәч тә традицияләр искә төшә. Ә без аларга шактый бай. Әүвәл заманнардан ук бикләнеп ятмадык, тарихның бер почмагына посмадык. Якташларыбыз Пугачев янында да катнашкан, Беернче Ватан сугышында да... Ә татар крестьяннары, эшчеләре бөтен Россия буйлап эш эзләп йөргәннәр, шахталарда, алтын приискаларында, нефть, балык промыселларында хезмәт иткәннәр. Димәк, традиция, беренче чиратта, халкыбызның үткәндәге тарихи бай тормышында ул. Традицияләр турында газета-журнал битләрендә дә язылмый түгел. Нил Юзиев «Татар әдәбиятындагы гуманистик һәм реалистик традицияләрнең Октябрьдән соңгы яңа дәвердә нинди яңа хасиятләр белән баюы» турында яза («Социалистик Татарстан», 1975 ел, 25 июль). Интернациональлек традицияләренә К. Фасеев туктала («Социалистик Татарстан», 1975 ел, 26 январь). Эстетик традицияләр дә онытылмый, мәсәлән, Г. Кашшаф «Ил белән, халык белән» исемле мәкаләсендә «эстетиканың гүзәл традицияләрен дәвам иттерүче сүз осталары»н искә ала («Социалистик Татарстан», 1975 ел, 18 сентябрь). Гражданлык традицияләре турында 1965—1966 елларда Г. Тукай, М. Җәлил традицияләренә багышланган дискуссиядә шактый кызыклы гына мәкаләләр язылды.

Әмма традицияләр бер генә әдәбият рамкаларында чикләнеп калмый, ул башка халыкларга да дуслык кулын суза, аларның барган юнәлешенә хәер-фатиха бирә. һәм үзе дә алардан ала.

Традицияләрне ничек һәм нинди юнәлештә үстерү кирәклеге турында артык сөйләшеп тору кирәкмидер дә. Сөйләү белән генә күп эш майтарып булмас. Традицияләрне әдәбият эченә чумып, җентекләп, филологларча пөхтәләп һәм фәнни намус белән анализларга кирәк. Башка юлны күрмим. Традицияләр әсәрнең бөтен тукымасына сеңәләр, аларны кисәк-кисәк бүлеп булмый. В. Г. Белинский әйткәнчә, алар язучының дөньяга үзенчәлекле карашын тәшкил итә. һәм бу уңайдан да әле безнең алда җитди эзләнүләр тора...

*
* *

Без өстән генә йөгереп үткән проблемалар диалектик рәвештә бергә бәйләнгән. һәр язучының үз мәктәбе, үз алымнары, үз сүзе һәм фикри дөньясы бар. Ләкин гомуми, уртак мәсьәләләр дә шактый гына. Логик фикерләү дә, конфликтны әсәр рамкасыннан чыгарып гасырлар арасындагы диалогка күчерү дә, әсәрнең катлаулы контексты да — бу проблемалар барлык язучылар өчен мөһим һәм әһәмиятле. Алар фәлсәфи әһәмияткә ия.

**Вахит Хаков,**
*филология фәннәре докторы*

# КАТЛАУЛЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРНЕ ХӘЛ ИТҮ ЮЛЫНДА

Татарстан дәүләт нәшриятында «Татар халык теленең барлыкка килүе» дигән хезмәт басылып чыкты[1]. Бу — татар культурасы һәм тел белемендә генә түгел, гомумән совет тюркологиясендә эз калдырырлык вакыйгаларның берсе.

Тел тарихы һәм халык тарихына багышланган хезмәтләрне язу икеләтә катлаулы, алар автордан киң эрудиция һәм зур җаваплылык таләп итә. Тагы шунысы да бар: монда бер фәнне генә түгел, күп фәннәрне белү, андагы принципларны, методларны өйрәнү дә — бик мөһим шарт. Тел үсеше халык тормышында зур урын тоткан иҗтимагый вакыйгалар белән аерылгысыз мөнәсәбәттә тора. Тел, аралашу коралы буларак, халыкның бөтен тормыш-көнкүреше белән тыгыз бәйләнгән. Шунлыктан тел үсешен өйрәнү халыкның үткәнен, тарихын белергә дә ярдәм итә.

Хәзерге фәнни-техник революция чорында, табигать фәннәре белән беррәттән, гуманитар фәннәр дә зур үсеш кичерәләр. Алар арасында органик бердәмлек яши. Тормыш үзе таләп иткәнчә, бу бердәмлек филология һәм тарих фәннәрендә катлаулы проблемаларның яңа методлар белән тикшерелүенә китерә.

Татар халкы һәм аның тел тарихы мәсьәләләрен тикшергәндә, бер-бер артлы зур тарихи вакыйгалар, дәверләр күз алдына килеп баса: Идел буе бөек Болгар дәүләте, монгол яулары һәм Алтын Урда дәүләте, Казан ханлыгы һәм аның Рус дәүләте составына керүе һ. б. Татар халкы тарихында тирән эз калдырган бу дәверләрне өйрәнмичә, куелган проблеманы тикшерү һәм тәмам ачыклау һич мөмкин түгел.

Соңгы елларда илебездә төрки халыклар һәм аларның телләре тарихын өйрәнүгә игътибар көчәйде. Бу өлкәгә караган күп фәнни хезмәтләр язылды, гыйльми конференцияләр, киңәшмәләр һәм симпозиумнар үткәрелде. Төрки язма истәлекләрне бастырып чыгару юнәлешендә дә эш җанланып китте.

Профессор М. З. Зәкиевнең күрсәтелгән хезмәте татар халкының сөйләм теле барлыкка килү юлларын ачыклауга зур өлеш кертә. Анда моңа кадәр булган хезмәтләр һәм авторның үз тикшеренүләре нигезендә татар халкының сөйләү теле тарихына, болгар-татар теориясенә җентекле анализ бирелгән.

Төрки халыкларның тарихы, телләренең башлангыч формалашу чоры, язуда теркәлә башлавы ерак гасырларга барып тоташа. Автор төрки халыкларның тарихын Үзәк Азия территориясе белән генә чикләмичә, аларның беренче эзләрен үзәк Америкадагы кабиләләр һәм аларның телләре белән дә бәйләп карый. Шул мәсьәләгә караган фикерләргә кушыла.

Автор дөрес кисәтә: халыкның барлыкка килү тарихы белән аның исеме туры килмәгән очраклар бар. Т а т а р дигән этноним белән дә эш шулай тора. Татар дигән төшенчәгә элек төрле халыклар һәм төрле телләр кергән. Бу исем борынгы заманнардан ук килә. Шуңа күрә авторның татар исеме белән элек нинди кабиләләр һәм халыклар яшәгәнлеген тикшерүе аерым әһәмияткә ия.

Идел һәм Урал буйларында төрки халыкларның таралышы, аларның телләре турындагы мәсьәлә күптәннән тикшеренүчеләрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Бу өлкәдә төрле карашлар яши. Идел-Урал буе төркиләре тарихын монда болгарлар килгән чордан башлап караучылар да, Европага һуннар килү һәм аңа кадәрге чор белән бәйле рәвештә тикшерүчеләр дә бар. М. Зәкиев үзенең китабында бу регионның

[1] М. З. З а к и е в. Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1977 ел, 207 бит.

гуннарга хәтле, безнең эрага кадәр үк төркиләшә башлау мөмкинлеген куя, үз фикерен раслау өчен шактый ышанычлы дәлилләр китерә. Беренче төркиләрне скифлар, сарматлар һәм ул чорда яшәгән башка кабиләләргә бәйле итеп күрә. Төрки халыклар тарихын моңа кадәр табылган язмалардан гына башлап китү, һичшиксез, куелган проблеманы чикләү булыр иде. Киләчәктә дә бу юнәлештә нигезле һәм дәлилле тикшеренүләр алып барылырга тиеш.

Әлеге китапта татарларның килеп чыгышы борынгы болгарлар белән бәйле рәвештә карала. Болгар проблемасы ул тикшеренүчеләрне күптәннән борчыган мәсьәлә. Идел буе болгарлары, һичшиксез, хәзерге татар халкы формалашуда төп компонент булган. Моны тарихи-географик, археологик, этнографик, антропологик, лингвистик чыганаклар, фольклор материаллары җирлегендә расларга мөмкин. Болгар-татар теориясенә ябышып яту «безнең татарлык» белән генә бәйләнмәгән: тарихи үсеш үзе шуны күрсәтә. Бу мәкаләнең авторына да болгар-татар теориясе белән шактый шөгыльләнергә, илебезнең төрле шәһәрләрендә үткәрелгән конференцияләрдә катнашырга туры килде. Татарларның болгарлар белән тарихи бәйләнеше турындагы караш күптәннән килә. Үз вакытында бу мәсьәләгә Н. Г. Чернышевский, И. Н. Березин, В. В. Григорьев, Шиһаб Мәрҗани, Каюм Насыйри һәм башка галимнәр игътибар иткәннәр. Латыйф Җәләй болгар-татар теориясен үстерүгә җитди өлеш кертте. Аның «Татар теленең урта диалекты» дигән докторлык диссертациясе, «Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар» китабы бу өлкәдә аеруча әһәмиятле хезмәтләр рәтендә тора.

Сугыштан соң, 1946 елда Мәскәүдә СССР Фәннәр академиясенең тарих һәм философия бүлеге тарафыннан Казан татарларының килеп чыгышына карата фәнни сессия оештырылган иде. Анда галимнәр Казан татарларының килеп чыгышында Идел буена монголлар килгәнче үк, үзләренең дәүләте булган болгарлар һәм төрки телдә сөйләшә торган халыклар хәлиткеч рольне уйнаганнар дигән нәтиҗәгә килделәр. Бу конференциядә болгар-татар теориясен этнограф Н. Воробьев, тарихчылар һәм археологлардан А. П. Смирнов, Н .Ф. Калинин, Х. Гыймади, телчеләрдән Л. Җәләй, антрополог Т. А. Трофимова һәм башкалар яклап чыкты.

Шуны да әйтергә кирәк, сугыштан соңгы елларда саф кыпчак-татар теориясе дә киң җәелә башлады. Мәсәлән, тарихчы М. Г. Сәфәргалиев Казан татарларының борынгы бабалары Алтын Урда составына кергән төрки халыклар һәм кабиләләр булган дигән версияне яклый. «Сессиядә катнашучылар Казан татарлары болгарлардан барлыкка килгән дигән карашка гына нигезләнеп эш иттеләр,— ди ул,— татарларның формалашуында элекке татар исемендә йөртелгән, Кама болгарлары кебек төрки телдә сөйләшә торган Дәште кыпчак кабиләләренең катнашуын бөтенләй исәпкә алмадылар»[1].

М. Н. Тихомиров, Ш. Мөхәммәдьяров һәм башка кайбер галимнәр дә татарларның формалашуын кыпчаклар белән бәйлиләр[2]. Хәтта 1946 елгы конференциядә болгар-татар теориясе ягында торган кайбер галимнәр дә үз фикерләрен үзгәрттеләр.

1968 елның сентябрендә этнография һәм антропология фәннәре буенча Халыкара VIII конгресста Казан татарларының килеп чыгышлары ягыннан өлешчә болгар, ә телләре ягыннан кыпчак булулары турында әйтелә[3].

Үзеннән-үзе аңлашыла ки, болгар-татар теориясенә бүгенге көн таләпләреннән чыгып, соңгы фәнни казанышлар җирлегендә бәя бирү, бәхәсле мәсьәләләргә ачыклык кертү кирәклеге көн тәртибендә тора иде. М. Зәкиев хезмәте шушы катлаулы мәсьәләләрне хәл итүдә ныклы бер баскыч булып тора. Әмма шушы теорияне аңлатканда, татар теле тарихы белән бәйләнешле булганлыктан, кыпчак теленең роленә дә киңрәк тукталып китү кирәк.

Чыннан да, болгарлар һәм кыпчаклар арасындагы мөнәсәбәтне ачыкламыйча, татар халкы һәм аның теле үсешен күз алдына китерү мөмкин түгел.

Идел буе Болгар дәүләте биләмәләрендә элек-электән кыпчак кабиләләре яшәгән. Борынгы заманнарда ук болгарлар белән кыпчаклар арасында тыгыз мөнәсәбәт урнаша. Рус елъязмаларында бу хакта шактый ачык мәгълүматлар сакланып калган. 1183 елда Владимир кнәзе Всеволод Киев кнәзе Святославка кыпчакларның тел һәм

---

[1] М. Г. Сәфәргалиев. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960 ел, 254 бит.
[2] Ш. Мөхәммәдьяров. Основные этапы происхождения и этнической истории татарской народности. Мәскәү, 1968 ел. 6 бит.
[3] Ш. Мөхәммәдьяров. Күрсәтелгән хезмәт, 10 бит.

кардәшлек ягыннан болгарларга бик якын торулары турында әйтә[1]. Моны раслый торган башка фактлар да китерергә мөмкин.

Элекке төрки-татар ядкарьларында кабилә этнонимнарын, халык исемнәрен берберсе белән алмаштырып куллану очраклары да күзәтелә. Киң таралган легенда-риваятьләрдә, башка фольклор әсәрләренең төрле вариантларында бер үк урында болгар яки кыпчак атамалары очрый. Мәсәлән, Туйбикә турындагы легендаларда аның болгар ханы кызы булуы турында әйтелсә, кайбер вариантларында Туйбикәнең әтисе кыпчак ханы дип тә йөртелә. Күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйриның «Фәвакиһел-җөласа» әсәрендә без нәкъ шуны күрәбез.

Күренекле тел галиме Латыйф Җәләй болгар һәм кыпчакларның телләрен татар теленең ике зур җирле сөйләме (Урта диалект һәм Көнбатыш диалект) белән бәйләгән иде[2]. Күренә ки, татар теленең килеп чыгышын тикшергәндә, болгар теориясен һәм кыпчак теориясен берберсенә каршы куярга ярамый, алар икесе дә үзара тыгыз үрелеп бара. Чөнки хәзерге татар милләте составында, кыпчакларның дәвамчысы буларак, мишәр этник компоненты да зур урын тота. Шул ук вакытта мишәр сөйләмендә дә болгар теле үзенчәлекләренең билгеле күләмдә урын алуын истән чыгармаска тиешбез. Тарихи үсеш процессында татарларның борынгы болгар-кыпчак кабилә телләре белән бәйләнештә булуын телчеләр генә түгел, бәлки тарихчылар-археологлар да инкарь итмиләр[3].

Татар халкы этногенезында болгар-кыпчак теориясе дигәндә нәкъ шушы караш күздә тотыла. Әйткәнебезчә, болгар компонентын кире кагып, саф кыпчак теориясе ягында торучылар да бар. Моны шулай ук тулысы белән кабул итү мөмкин түгел. Мәсьәләгә берьяклы гына — саф болгар юнәлешендә генә дә килеп булмый. Тарих әле күп күренешләрне сер итеп яшереп саклавында дәвам итә.

Шунысын да искәртик, кыпчак теле дигәндә күчмә кыпчак кабиләләренең сөйләм теле генә түгел, бәлки Хазар дәүләте чорларыннан ук яшәп килгән Идел буе төрки язма һәм сөйләм теле дә күздә тотыла. Бу мәсьәлә әле аерым тикшеренүне таләп итә.

Тарих үз парадоксларын туктаусыз күрсәтеп тора. Тюркология фәнендә «болгар язма ядкарьлары» дигән атама киң кулланылышта түгел. Бу мәсьәләдә, элекке язма истәлекләрнең сакланып калмавыннан тыш, башка сәбәпләрнең дә булуы мөмкин. Монголлар басып алганнан соң, Болгар дәүләте автономия рәвешендә яшәвен дәвам иттерә. Болгар дәүләте территориясендә яшәгән төп халык Алтын Урда дәүләте төзелгәч тә юкка чыкмаган. Халык бар икән, аның теле дә яши дигән сүз. Әмма шулай да бу дәвердә без кыпчак, кыпчак теле дигән төшенчәләрнең зуррак урын алганлыгын күрәбез. Язма истәлекләр дә шул кыпчак теленә бәйләнешле рәвештә карала башлый. Моны ул чорда кыпчакларның төп урынны алып торулары, иҗтимагый-тарихи мөнәсәбәтләрнең үзгәрүе белән аңлатырга да мөмкин. Ләкин күп нәрсә ачылып җитми. Болгар һәм кыпчак телләре арасындагы якынлыкмы бу? Әллә монда башка сәбәпләр дә бармы? Нәкъ шушы урында халыкның, телнең килеп чыгышына карата төрле карашлар туа. Соңгы елларда чыккан хезмәтләрдә болгар теленең кыпчак теле тарафыннан ассимиляцияләнүе турында да фикерләр әйтелә башлады. Кайбер иптәшләр уйлаганча, моны элекке болгарларның бөтенләй юкка чыгуы, кыпчак булып китүе дип аңламаска кирәк. Болгарларның кыпчаклашу процессы аерым урынчылыклар белән генә бәйле. Бер дәүләт таркалып, аның урынында икенче дәүләт төзелү телнең торышына һәм үзгәрешенә зур йогынты ясый. Алтын Урда төзелгәч, элек дәүләт теле булып хезмәт иткән болгар теле яңа иҗтимагый шартларда структур яктан да һәм функциональ яктан да кайбер үзгәрешләргә тартыла. Гаять киң территориядә дәүләт теле ролен үтәгән кыпчак теле үзенең функциональ сферасын киңәйтә, күп халыкка хезмәт итә башлый. Бу хәл болгар теленә дә тәэсир иткән, урыны-урыны белән аны өлешчә ассимиляцияләүгә китергән. Гасырлар дәвамында болгарлар башка халыклар белән аралашып, кайбер төбәкләрдә алар белән кушылып киткәннәр. Мисалга Пенза өлкәсендә һәм башка җирләрдә утырып калган болгарларны китерергә була. Кушылу нигездә кыпчак-мишәр җирлегендә барган.

---

[1] В. Н. Татищев. История Российская. III том, «Наука» нәшрияты, М.-Л., 1964 ел, 128 бит.

[2] Л. Җәләй. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. Казан, 1954 ел, 31 бит.

[3] А. Х. Халиков. Татар халкының килеп чыгышы. Казан, 1974 ел, 55 бит; Р. Г. Фәхретдинов. Ташлар моңы. Казан, 1978 ел, 157 бит.

Җәмгыятьтәге үзгәрешләр язма телгә генә түгел, сөйләм теленә дә үзенең тәэсирен ясамый калмаган. Сөйләм теле белән язма тел үзенчәлекләре бер-берсе белән элек-электән тыгыз кушылып килгән. Бу процесс төрле төрки кабилә телләре катнашында барган. Хәзерге татар теленең диалекталь төрлелеге дә шуны ачык күрсәтә. Шулай итеп, XIII—XIV йөзләрдә татар теленең үз нормалары тотрыклылана, үсә һәм ныгый. Моны тикшерүдә ул вакытта төзелгән сүзлекләр ярдәмгә килә. Борынгы чорда һәм урта гасырларда сүзлекләр практик максатлардан чыгып төзелгән. Аларда җанлы сөйләм дә һәм язма тел дә чагылган, шул яктан алар кыйммәтле чыганак булып торалар. Шуларның берсе — 1245 елда төзелгән төркичә-гарәпчә сүзлек [1]. Шулай ук башка язма истәлекләрдә дә төрки кабилә телләре җирлегендә үсеп чыккан бай һәм камилләшкән тел чагыла.

Идел-Урал регионында төрки кабиләләрнең бер-берсе белән аралашып яшәве, шул нигездә гомумуртак тел нормаларының барлыкка килүе нәтиҗәсендә, шулай ук борынгы язма төрки тел һәм сөйләм теле йогынтысында, X—XIV йөзләрдә татар теленең лексик, фонетик һәм грамматик нормалары һәм стильләре формалаша.

Китапта болгар-чуваш теориясен анализлауга һәм аны тәнкыйтьләүгә киң урын бирелгән. Революциягә кадәр үк тюркологиядә бер караш таралган була. Тел аерымлыкларыннан чыгып, төрки телләрне нигездә икегә бүлеп карыйлар. Аларның берсенә башка төрки телләрдән аерым торган чуваш теле, икенчесенә исә, гомуми уртак билгеләренә карап, күпчелек төрки телләр (үзбәк, татар, әзербәйҗан, казакъ, төрекмән, кыргыз, балкар, уйгур, комык һ. б.) керә дип саныйлар. Чуваш телен болгар теле белән бер дип санау нәтиҗәсендә болгар-чуваш теориясе барлыкка килә. Бүгенге көндә дә аны яклаучылар бар.

М. Зәкиев протоболгарларның һәм Идел буе болгарларының теле гадәти төрки тел булган дигән нәтиҗәгә килә. Моны исбатлау өчен артык көч сарыф итәргә кирәк түгел, тарихи фактларны объектив тикшерү дә җитә дип күрсәтә. «Әмма болгар-чуваш теориясенең дөрес түгеллеген исбатлау,— ди автор,— бик күп көч сорый. Ул тарих фәнендә очрый торган кайбер башка теорияләр кебек традициягә әверелгән» (144 бит). Бу фикерләр белән килешмичә мөмкин түгел.

Мәгълүм булганча, кайбер рус һәм совет тюркологлары, чит илләрдә төрки телләрне тикшерүчеләр болгарларның хәзерге чувашларга якынлыгын күрсәтергә, анда болгар теле үзенчәлекләре сакланган дип расларга тырышалар. Мәсәлән, Н. И. Ашмарин, В. Ф. Смолин, А. А. Шахматов, А. Н. Самойлович, В. Г. Егоров, В. Ф. Каховский, чит ил тюркологлары О. Прицак, Н. Н. Поппе, З. Гомбоц, Б. Мункачи, Рона-Таш һәм башкалар шушы карашны яклыйлар. Үз тезисларын раслау өчен алар XIII—XIV йөздән калган кабер ташы язмаларын, Дунай болгарлары ханнары турында безнең заманга килеп җиткән язма документны, венгр телендә сакланган төрки сүзләрне дәлил итеп китерәләр. М. Зәкиев әнә шул язма текстлар һәм сүзләрне бүгенге татар теле җирлегенә куеп анализлый, болгар-чуваш теориясенең нигезсез икәнен күрсәтә, борынгы болгарларның хәзерге татарларга якынлыгын, аларның телләре охшаш икәнлеген төрле яклап исбатлый. Карыйк, болар ышандырамы соң?

Әйткәнебезчә, М. З. Зәкиев үзенең хезмәтендә **гадәти төрки тел** дигән атама куллана, бу төшенчә астында угыз-кыпчак телләренә хас үзенчәлекләрне күздә тота һәм болгар телен дә шул төркемдә карый. Дөрес, Болгар истәлекләрендә шушы гадәти төрки телгә туры килми торган кайбер сүзләр дә очрый. Мәгълүм булганча, Болгар дәүләте территориясендә табылган кабер ташы язмаларында ике төрле стиль үзенчәлекләре чагыла. I стиль хәзерге татар сөйләменә якын. Кайбер ташъязмаларда чуваш телен хәтерләткән сүзләр дә очрый. Гадәттә мондый ташларны II стиль эпитафиясе дип йөртәләр. Нәкъ шушы стильне болгар-чуваш теориясен дәлилләү өчен китерәләр. М. Зәкиев әнә шундый сүзләрне җыеп, бер таблица төзи һәм аларны хәзерге татар һәм чуваш телләрендәге сүзләр белән чагыштыра. Нәтиҗәдә, таблицада китерелгән илле сүзнең егерме өчесе (алты, бирү (бер), ике, бакый, фани, һиҗрәт, җол, көн, рәҗәб, рамазан, сәфәр, тарих, тындыйы (тынды иде), вафат, зыярәт һ. б. шундый сүзләр) татар телендә күбрәк сакланганлыгы, бары унөче генә чуваш теленә якын булуын, калганнары исә татар һәм чуваш телләренең икесендә дә очравы ачыклана. Димәк,

[1] Бу хакта кара: «Казан утлары», 1970 ел, 3 сан.

I стиль ташъязмаларындагы тел кебек үк, II стильдә дә гадәти төрки телгә — татар теленә якынрак торган диалект өстенлек ала. Шуны да искә алырга кирәк: аерым сүзләрне татар теленә дә һәм чуваш теленә дә якын итеп укырга мөмкин.

М. Зәкиев болгар чорыннан калган ташъязмаларның ике стильдә язылуын түбәндәгечә аңлата: гадәти төрки телле диалект вәкилләре Кавказның төньягындагы далалардан килгән болгарлар булганнар, ә чуваш теленә якын диалектта сөйләгәннәрне чувашларның борынгы бабалары дип каралырга тиеш. Алар гуннар чорында яисә аларга кадәр үк шунда торганнар дип уйланыла» (132 бит).

XIV йөздән соңгы ташъязмаларда инде чуваш сүзләренең булмавын автор чувашларның болгарлар арасында ассимиляцияләнүе белән аңлата, болгар тәэсирендә булмаган чувашларның гына ассимиляциягә — йотылуга бирелмичә, хәзергәчә сакланып калулары турында сүз алып бара.

Моңа кадәр болгар-чуваш теориясенә дәлил итеп йөртелгән, Дунай болгарларыннан калган документның телен дә чуваш теле җирлегендә генә түгел, бәлки башка төрки телләргә, шул исәптән татар теленә, нисбәтле рәвештә тикшерергә мөмкин. Шундый тәҗрибәне бу мәкаләнең авторы үзе дә эшләп караган иде[1].

Венгр телендәге төрки алынмаларга карап, болгар-чуваш теориясен расларга тырышу да үзен акламый. Китапта бу конкрет мисаллар өстендә раслана. Борынгы чорларда венгрларның төрки халыклар белән аралашып яшәве хәзерге венгр телендә төрки сүзләрнең шактый күп булуына китергән. З. Гомбоц үзенең 1912 елда чыккан хезмәтендә венгр телендә йөзләрчә төрки сүзнең Идел буе болгарларыннан булуын әйтә. Болгар теле дигәндә ул чуваш телен күздә тота. М. Зәкиев бу хезмәтне җентекле рәвештә тикшерү нәтиҗәсендә, венгр телендәге ул сүзләрнең чуваш теленә генә түгел, ә башка төрки телләргә, шул исәптән татар теленә дә хас булуын күрсәтә. Чагыштырма статистик анализдан соң әлеге алынмалар арасында чуваш теле өчен характерлы булган сүзләрнең 6,5 процент кына тәшкил итүе беленә.

Шулай итеп, татар халык сөйләм теленең тарихы Идел буендагы болгар-кыпчак телләре белән бәйле икәнлеге аңлашыла. Бу компонентлар бер-берсе белән бик тыгыз мөнәсәбәттә тора. Иҗтимагый-тарихи һәм географик шартлар әдәби телнең дә шул җирлектә нормалашуына китерә. Бу процесста тирәлек мәсьәләсе аеруча зур роль уйный. Бер территориядә яшәүче кабиләләр тел ягыннан бер-берсенә тәэсир итешәләр. Телләр һәм диалектлар арасында бара торган мондый үзара йогынты кабиләләр союзга берләшкәндә дә, халык һәм милләт барлыкка килгәндә дә дәвам итә.

Төрки телләрнең глоттогоник үсеш процессы бердәм системага корылган. Бөтен төрки телләрне төрки тел иткән уртак гомуми үзенчәлекләр бар. Алар борынгы заманнарда ук барлыкка килгән. Төрки телләр, дөньядагы башка телләр кебек, шул структураны саклаган хәлдә генә үсә алалар. Шулай булгач, хәзерге чорда яшәп килгән төрки телләрдә дә борынгы эчке төзелеш һәм гомуми уртак сыйфатлар яшәүдә дәвам итә. Озак вакытлар бер урында яшәү, төрле халыклар белән аралашу нәтиҗәсендә телдә яңа үзенчәлекләр туа. Шулай итеп, гомуми типологик охшашлык җирлегендә, тарихи дәверләр дәвамында, аерым мөстәкыйль телләр үсеп чыга. Идел буе дәүләтендә дә шушы гомуми төрки сөйләмне чагылдырган тел булган. Тарихи-географик, иҗтимагый-политик шартларга карап, төрки телләрдә тегеяки бу үзенчәлекләр барлыкка килүне инкарь итү мөмкин түгел. Нәкъ шул үзенчәлекләргә карап, төрки телләр төрле төркемнәргә (угыз, кыпчак, карлук h. б.) бүленә.

Чуваш теле төзелеше ягыннан төрки телләргә охшаган булса да, ул алардан нык аерыла. Аңарда гадәти төрки телгә чит булган угро-фин теле үзенчәлекләре зур урын ала. Шуңа күрә чуваш теле Идел буе болгарларында дәүләт теле булып торган болгар теленең турыдан-туры дәвамы булып карала алмый һәм чуваш телен болгар теле итеп күрсәтү тарихи чынбарлыкка туры килми.

М. Зәкиев чуваш телен Идел буена болгарлар килгәнче үк угро-фин теленә төрки тел тәэсире нәтиҗәсендә формалашкан, гадәти төрки һәм угро-фин телләре керешүдән (интерференциясеннән) барлыкка килгән дип саный һәм үзенең китабында шул карашны үткәрә.

Автор антропологик яктан да Идел буе татарларының болгарларга туры килүен күрсәтә. Бу юнәлештә аңа В. П. Алексеев хезмәтләре ышанычлы чыганак булып тора. Татар халкының гореф-гадәтләре, тормышкөнкүреше һәм яшәеше этнографик яктан

[1] В. Хаков. Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. Казан, 1972 ел, 29—31 бит.

да болгарларныкына охшаган. Язу, фән үсеше дә, культура традицияләре дә («Кыйссаи Йосыф», «Нәһҗелфәрадис» әсәрләренең авторлары болгардан чыккан булу һ. б.), фольклор әсәрләрендәге тарихи үзенчәлекләр дә шуны ук раслыйлар. Татар халкының элек-электән яшәгән урыны да аның болгарга якынлыгын раслый торган ышанычлы дәлилләрнең берсе.

Болгар дәүләтендә төп урынны болгарлар алып торса да, IX—XII йөзләрдә шул исем белән күп кабиләләрнең берләшкән, үзәкләшкән булуын да истән чыгармаска кирәк. Китапта бу мәсьәләгә дә урын бирелә, болгарларның төрле халыклар — кыпчаклар, хазарлар, печенеглар, мадьярлар, бортаслар, славяннар, угро-финнар белән аралашып яшәве турында әйтелә. Гарәп тарихчыларының мәгълүматларыннан чыгып караганда, Идел буе болгарларының берничә тармакка бүленүләре билгеле. Язма һәм археологик чыганаклар күрсәткәнчә, Идел буйларына килгәннән соң, алар төрки телдә сөйләшә торган башка кабиләләр белән дә очрашканнар, үзара аралаша башлаганнар. Бу диалектлар бер-берсенә якын торган. Моның шулай икәнлеген борынгы язма чыганаклар ачык күрсәтәләр. Болгар дәүләте югары культуралы һәм экономик яктан алга киткән феодаль дәүләтләрнең берсе була. Бу хәл сөйләм һәм язма тел нормаларының да үсүенә, тотрыклылануына китергән. Бу тирәгә монголлар килгәнче иҗат ителгән, халыкка мәгълүм булган әсәрләрне («Кисекбаш китабы», «Кыйссаи Йосыф»), эпитафика, фольклор материалларын шул чор белән бәйләнештә карарга кирәк. Ләкин ул чор язма истәлекләренең күбесе безнең заманга килеп җитмәгән.

М. Зәкиев төрки телләр тарихына карата моңа кадәр яшәп килгән ялгыш карашларны, каршылыклы теорияләрне бик урынлы тәнкыйтьли. «Бу караш буенча,— ди автор,— Көнчыгыш Европага гуннар килә, берничә йөз ел яши дә бөтенләй юкка чыга, телләре онытыла; алар урынына төркиләр килә, бик күп еллар яши дә кинәт кенә югала, телләре дә югала; алар урынында хазарлар, болгарлар кала, алар да һәм аларның телләре дә юкка чыга. Печенеглар, кыпчаклар белән дә шундый ук хәл кабатлана. Идел болгарлары да тарихта азга гына күренеп алалар, телләрен Идел буе фин кабиләләренә бүләк итәләр дә үзләре югалалар» (144 бит). Галим монда да хаклы. Тел тарихта кинәт кенә үзгәреп китми яки бөтенләй юкка да чыкмый. Алар хәзерге халыкларда саклана.

Хезмәттә этнонимнарның — кабилә, халык атамаларының килеп чыгышына карата әйтелгән фикерләр дә киң күләмдәге эзләнүләргә, тикшеренүләргә нигезләнгән. Без **татар, болгар, суар, биләр, мишәр, мадьяр, башкорт, кыпчак, коман, бортас,** тәмтез кебек исемнәрне күздә тотабыз.

**Казан** сүзенең этимологиясенә килгәндә исә, бу турыда укучылар соңгы вакытта күп төрле аңлатмаларның булуын беләләр. Без **Казан** сүзенең беренче компоненты борынгы ыру-кабилә исеме белән бәйләнешле булырга тиеш дигән карашта торабыз. Бу тарихи чынбарлыкка күбрәк туры килә.

Гомумән, автор катлаулы проблемаларны чишү, үз фикерләрен раслау өчен бу хезмәтенә күп көч салган. Аңа рус, совет һәм чит ил тюркологларының төрле телләрдә язылган хезмәтләре белән танышып чыгарга һәм шулар нигезендә гомумиләштерүләр ясарга туры килгән.

Әле эшлисе эшләр дә күп.

**Болгар теле** дигән төшенчә һаман да катлаулы проблемаларның берсе булып калуында дәвам итә. Аны тиешенчә ачыклыйсы бар. Бу мәсьәләгә карата төрле фикерләр әйтелә, аның тирәсендә каршылыклы теорияләр яшәп килә. Болгар теленең асылын ачу юнәлешендә киң һәм дәвамлы эш алып барылырга тиеш.

Китапта фольклор материалларын, язма әсәрләрне тикшерү максат итеп куелмаса да, сөйләм теленең үсешен күрсәтүдә зур чыганак булганлыктан, аларга мөрәҗәгать иткәндә дә яхшы булыр иде. Моны алдагы басмаларда, һичшиксез, искә алырга кирәк.

Шулай ук З. Гомбоц китабындагы сүзләргә карата да бер фикер әйтәсе килә. Андагы сүзләр китапта саннар белән генә күрсәтелгән (кара: 141—142 бит). Болай эшләү статистик анализ максатына туры килсә дә, Гомбоц китабының сирәк экземпляр, библиографик раритет булып кына калуын искә алганда, ул сүзләрнең үзләрен китерү дәлилләү көчен тагын да арттырыр, китапның эчтәлеген тулыландырыр иде.

«Татар халык теленең барлыкка килүе» дигән хезмәт бүгенге көн таләпләреннән чыгып язылган. М. З. Зәкиев татар халкының этногенезы һәм тел тарихы мәсьәләләрен ачыклау, бәхәсле проблемаларны хәл итү ягыннан совет тюркологиясенә зур өлеш кертте.

# АКТЕР ШӘХЕСЕ. УЛ НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШ?

Төзүче яки авыл механизаторын, укытучы яисә китапханә хезмәткәрен һәм башка күп төрле һөнәр кешеләрен нинди уку йортларында әзерләүләрен, алардагы укыту-тәрбия процессын һәркем дә диярлек шактый ачык күз алдына китерә ала. Шул ук вакытта сәнгать кешесен, әйтик, яшь рәссам һәм композитор, язучы һәм актерны кайда «сугарып үстерәләр», аларны ничек укыталар һәм өйрәтәләр, әлеге иҗади һөнәр ияләрен әзерләүнең үзенчәлекләре нидән гыйбарәт?— бу сорауга бик күпләр ансат кына җавап бирә алмаслар иде. Әлбәттә, иҗади сәләт таләп итмәгән һөнәрләр юк дип әйтергә кирәк. Укытучымы ул, инженер яисә терлекчеме — һәр кешегә төрле шартларда әлегәчә очрамаган яңа мәсьәләләрне хәл итәргә, билгесез сорауларга җавап эзләргә туры килә. һәм ул кыенлыкларны җиңүдә, махсус белемнәр өстенә, һәркемгә дә иҗади рухлану, иҗат дәрте, хыял байлыгы, аң-белем даирәсенең киңлеге, тирән тойгы-хисләр кичерә алу сәләте ярдәмгә килә. Сәнгатьнең теләсә кайсы өлкәсендә эшләүчеләр өчен исә аеруча зарури, гаять кыйммәтле сыйфатлар болар. Чөнки аларның иҗат объекты гомер буе өзлексез үзгәреп тора, яңа тема, яңа әсәр, яңа образны гәүдәләндерү, тасвирлау, сурәтләү, яңгырату һәр чак иҗади шәхестән яңа уй-фикерләр, хисләр, яңача күзаллауны таләп итә. Сәнгатькяр хезмәтенең башка мөһим үзенчәлекләре дә бар, әлбәттә. Театр сәнгатен, актер хезмәтен генә алыйк. Театр сәнгатендә актерның үз шәхесе, шәхси сыйфатлары, хәтта аның буй-сыны да гаять зур әһәмияткә ия. Нәкъ менә актерның үз шәхесе аның хезмәт җимешләренең кыйммәтен билгели дә. Чөнки образ тудыручы да, образ тудырыла торган материал да — ул үзе.

Актер шәхесе — күп кырлы төшенчә. Актерның сәхнә уены оригинальлеген тәэмин итә торган индивидуаль иҗат йөзе булырга тиеш. Профессиональ сәләте өстенә аның югары культурага, интеллектуаль һәм әхлакый сыйфатларга ия булуы таләп ителә. Әмма иң әһәмиятлесе — актерның дөньяга карашы, гражданлык позициясе дип әйтер идек. Нәкъ менә аның дөньяга карашларының нык һәм эзлекле булуы, гражданин буларак өлгереп җиткәнлеге актерга сәхнәдә идея-сәнгать акцентларын дөрес билгеләргә ярдәм итә, аның уенының идея-эмоциональ тәэсир итү куәтен билгели.

Бүгенге заман актеры чорыбызның алдынгы идеяләрен пропагандалаучы ул. Ул материалны чынбарлыктан алырга, тормыш хакыйкатен чагылдырырга, кешеләр арасындагы яңа мөнәсәбәтләрне гәүдәләндерә белергә тиеш. Актерны әнә шундый җитди таләпләргә җавап бирерлек итеп тәрбияләү, рухи үстерү — гаять тә катлаулы бурыч. Социалистик сәнгатьнең иҗтимагый вазифасы шуны таләп итә.

Актерлык сәнгате беркайчан да без яшәгән дәвердәге кебек зур иҗтимагый әһәмияткә ия була алмагандыр. Чөнки бернинди җәмгыять тә элек үзалдына һәр яктан гармонияле кеше тәрбияләүне, аның иҗади көчләрен үяту һәм үстерүне иң мөһим бурыч итеп куймаган.

Художникның үсеп формалашу процессы сәнгать төрләренең иҗтимагый юнәлеше, иҗтимагый асылы белән бәйле. Социалистик сәнгать художестволы образлар

системасының, барлык сәнгать чараларының эмоциональ тәэсир итүе аша тамашачыда актив тормыш позициясе булдыруга ярдәм итә.

КПСС Үзәк Комитетының «Иҗади яшьләр белән эшләү турында»гы карарында уку йортларының яшь художникларны тәрбияләүдәге ролен һәм җаваплылыгын күтәрүгә аерым игътибар бирелә. Сәнгатебезнең яшь көчләрен профессиональ яктан әзерләү һәм идея-политик чыныктыру юлларын билгеләүче киң программа ул.

Илебезнең бүгенге культура һәм сәнгать учакларына талантлы белгечләр генә түгел, ә югары интеллект һәм зур культурага, тирән гражданлылык сыйфатларына ия булган шәхесләр кирәк. Үзеннән-үзе аңлашыла ки, мондый шәхесләрнең өлгереп җитүе өчен иҗат атмосферасы, сак һәм игътибарлы мөнәсәбәт, таләпчәнлек һәм принципиальлек рухы хөкем сөрергә тиеш. Мәгълүм ки, уку йортлары талантлар тудыру белән шөгыльләнми, аларның бурычы — талантларны үстерү һәм тәрбияләү. Бер яктан алганда, театраль уку йортларының эше дә, һәркайдагыча, хисап, план кебек категорияләргә нигезләнә. Икенче яктан исә, биредә иҗади илһам, иҗат газаплары кебек төгәл генә хисапка алу читен булган нәрсәләр белән дә исәпләшергә туры килә.

Яшь белгечләрне үзләренә генә хас индивидуаль иҗат йөзләре булган шәхесләр итеп үстерү бурычының уңышлы хәл ителүе уку йорты җитәкчелеге, укытучылар составы, партия оешмасы һәм җәмәгать оешмаларының укыту-тәрбия эшен ни дәрәҗәдә комплекслы итеп планлаштыра һәм тормышка ашыра алуына бәйләнгән.

Укыту-тәрбияләү процессы уку йортына кабул итү имтиханнарыннан ук башлана. Булачак артист, музыкант яисә рәссамның потенциаль сәләте һәм мөмкинлекләре, иҗади индивидуальлеге нәкъ менә шушында чамалана да инде. Никадәр генә җаваплы булмасын, кабул итү имтиханнары әле шулай да бары тик беренче адымны атлау гына.

Иҗади тәрбия процессы беренче курста ук җитди төс ала. Студентлар заманыбыз югарылыгыннан торып, совет сәнгате казанышларын күңелләренә сеңдерергә, кеше һәм кешелек язмышын үз йөрәкләре аша уздырырга, чорыбыз сулышын, аның сәнгать әсәрләрендә кабатланмас гәүдәләнешләрен тоеп яшәргә өйрәнәләр. Уку процессында профессиональ әзерлек серләрен үзләштерү идея-эстетик һәм этик тәрбия белән тыгыз бәйләнештә генә алып барыла. Социалистик реализм методын тирәнтен үзләштерү, халык тормышы белән аерылгысыз бәйләнеш, чынбарлык күренешләрен туктаусыз өйрәнү, осталыкны даими төстә үстерү юнәлешендә генә актер формалаша, чорыбызга лаек иҗат биеклекләрен яулый ала.

Сәхнә осталарының яшь буыны тормышта үз урынын торган саен ышанычлырак яулый бара. Төрле күргәзмәләрдә яшь рәссамның күркәм әсәрләрен, ә сәхнәдә яшь актер тудырган уңышлы образларны күрү күңелгә шатлык хисе өсти. Яшь сәнгать эшлеклеләренең әсәрләрендәге фикер үткенлеге, хыял байлыгы безне битараф калдырмый. Әмма кайчак сәләтле яшьләребезнең кайберләре мактау сүзләрен берьяклырак кабул итә. Алар чын иҗат эше зур шәһәрләрдә, идеаль шартлар булганда гына мөмкин дип уйлыйлар. Авыл районнарында яшь рәссамнар, музыкантлар һәм башкаларга иҗат эшен җайга салу өчен мөмкинлекләр нык артты. Районнардагы культура учаклары иҗат дәрте кайнап торган яшь белгечләрне көтә. Ләкин махсус уку йортын тәмамлаганнан соң авылга эшкә барудан баш тарту очраклары да булгалый әле. Кайберәүләр театр, музыка институты һәм техникумы дипломын алып чыгу белән Мәскәү яисә Казанны «әсир итү» максатын гына күреп яшиләр. Хәлбуки, олы художникларның иҗат юлын күздән кичерә башласак, аларның үз туган җире, халык тормышыннан нык хәбәрдар булганлыкларын күрербез. Элгәре дә, бүген дә бу шулай. Халыкның рухи дөньясын яхшы белү өчен яшь актер, рәссам һәм музыкантларга да эшне теге яки бу төбәктә башларга, хезмәт кешеләре белән якыннан аралашып, белемнәрең, күңел нурларың белән уртаклашып яшәргә кирәк. Уку йортларында белем алучы яшьләребез арасында көндәлек агымга бирелеп, гамьсез генә уй-хисләр эчендә, артык борчылмый-пошынмый гына яшәүчеләр дә юк түгел. Андыйларга зур, җитди эшләр әле кайдадыр алда һәм турыдан-туры аларга кагылмый кебек тоела. Нәкъ менә шушы рәвешчә гамьсез үткәргән еллар соңыннан үкенечле була да инде. Театраль уку йортларында укучы студентларның кайберләренә театрны зур һәм изге йорт итеп карау җитми. Бу исә яңа кешене тәрбияләүдә

театр сәнгатенең ни дәрәҗәдә куәтле чара булуын, шул олы бурычларны хәл итүдә актер-гражданинның нинди роль уйнавын төшенмәүдән дә килә. Булачак иҗади шәхеснең оеткысы беренче уку елында ук салынырга тиеш, дидек. Бу елда укытучылар һәм группа җитәкчеләре студентларның индивидуаль сыйфатларын, характер үзенчәлекләрен өйрәнәләр һәм шул нигездә укыту-тәрбия процессын җайга салып җибәрәләр. Тәрбия эшен комплекслы алып баруга соңгы елларда аеруча зур игътибар бирелә башлады. Шушы җәһәттән Казан театр училищесында тупланып килгән тәҗрибә дә уңай бәяләнүгә лаек. Тәрбия мәсьәләләре бередә педагоглар советы утырышларында да, методик киңәшмәләрдә дә, ата-аналар белән берлектә даими үткәрелә торган җыелышларда да тикшерелә килә, ирешелгән уңай нәтиҗәләр гомумиләштерелә бара.

Идея-политик һәм укыту-тәрбия эшенең комплекслы планында индивидуаль тәрбия эшенең сыйфатын күтәрә баруга аеруча зур урын бирелә. Сәнгать эшлекләләре әзерли торган уку йорты өчен бу — төп зарурият. Тәрбиячеләрне туып килә торган һәр иҗатчының кабатланмас иҗат йөзе кызыксындырырга тиеш. Булачак белгеч һәм художник үзенең яшеренеп яткан мөмкинлекләрен аңласын, үстерсен өчен аның индивидуаль сыйфатларын күрә һәм ача белергә кирәк. Шуңа күрә һәр педагог үзенең студентлары хакында мөмкин кадәр күбрәк белергә, уку һәм тәрбия процессында аның теге яки бу характер сыйфатларына тәэсир итеп, юнәлеш бирә барырга тиеш.

Театраль педагогиканың нинди генә камил системасы да талантсызга тылсым өрә алмый, әмма кеше шәхес булып өлгереп җиткәндә генә аның табигый таланты меңнәрне рухландырырлык көчкә әверелә, социаль яңгыраш ала. Ә шәхес исә культура мирасын үзләштерү, үзеңне иҗади раслау, социалистик эпоха гражданины итеп тою, олы идеалларның тантана итүе өчен көрәш процессында гына өлгерергә мөмкин. Алдынгы тәҗрибә үрнәкләреннән күренгәнчә, фәнни нигезләнгән һәм тормыш сынавы үткән тәрбия методикасын кулланганда, педагог белән студент арасында җанлы элемтә, үзара аңлашу (ә бу кайчак бик ансат эш түгел) булганда яшь художникның табигый сәләтләрен максималь баету, үстерүдә күп нәрсәгә ирешеп була.

Казан театр училищесында иҗади өлгергән, әзерлекле педагоглар коллективы эшли. Татарстанның халык артисты Е. А. Кузин, Татарстанның атказанган артистлары А. Х. Хәйруллина, А. Ф. Гацулина, Татарстанның атказанган культура работнигы Н. В. Алексеева һәм башкалар яшь талантларны тәрбияләү процессының заманыбыз рухы белән тыгыз бәйләнештә алып барылырга тиешлеген тирән аңлап эшлиләр, күп милләтле совет сәнгате туплаган хәзинәләрне һәр укучы күңеленә үткәрергә тырышалар. Студентлар белән эчкерсез, дустанә әңгәмәләр, үзара тирән рухи элемтә булачак белгечнең күңеленә юлны тизрәк табарга, аларда максатка эзлекле омтылышлылык уятып, укыту һәм тәрбия эшендә тиешле нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә.

Яшь белгечләрне коммунистик төзелештә актив катнаша алырлык кешеләр итеп әзерләү өчен аларны иҗтимагый үсеш законнары белән коралландырырга, аларда коммунистик идеяләргә тирән ышанганлык тәрбияләргә кирәк. Укучыларны идея ягыннан чыныктыру, тормышка төпле карашлар тәрбияләү эшендә иҗтимагый фәннәрне тирәнтен үзләштерү, илебезнең Конституциясен, Дәүләт законнарын ныклап өйрәнү, тәрбия эшенең ленинчыл зачет, иҗтимагый фәннәр буенча үткәрелә торган конкурслар кебек формаларын куллану аеруча зур әһәмияткә ия.

Ватаныбыз тарихы — совет халкының батырлык елъязмасы ул. Данлы традицияләребез эстафетасы буыннан-буынга күчеп бара. һәм шушы дәвамлылык, аталар һәм балалар арасындагы аерылгысыз тыгыз бәйләнеш — җиңелмәс куәт чыганагы, туктаусыз алга баруыбызның шарты. Әйтергә кирәк, Казан театр техникумы коллективының тәҗрибәсе бу яктан да аерым игътибарга лаек. Яшьләрне героик-патриотик, хезмәт һәм революцион традицияләр үрнәгендә тәрбияләү буенча бередә инде озак еллар җитди эш алып барыла. Бөек Ватан сугышы елларында Казанда 146 нчы укчы дивизия төзелә һәм ул Мәскәү тирәсеннән алып Берлинга кадәр данлы сугышчан юл үтә, Суворов ордены белән бүләкләнә. Техникум студентлары шушы дивизия сугышчыларының батырлыклары белән кызыксына башлыйлар. Комсомол оешмасы инициативасы белән 1969 елда Тарас Рымарь исемендәге

эзтабарлар батальоны төзелә. Яшь энтузиастлар батыр якташлары үткән эзләр буенча походларда йөриләр, дивизиянең бүген исән булган сугышчыларын һәм командирларын, политработникларын эзләп табалар, ветераннар белән очрашулар оештыралар. Алар шулай ук Казан мәктәпләрендә хәрби-патриотик эш җәелдереп җибәрәләр. Хәрби-патриотик эшләр училище укучылары тормышының аерылгысыз өлеше булып китә.

Совет Армиясенең сугышчан данлы тарихы аталар батырлыгы хакында истәлек саклау өчен генә өйрәнелми. Ул — буыннар арасында җанлы элемтә булдыру дигән сүз. Училищены тәмамлаганнан соң кичәге студентларның күбесенә хәрби-патриотик темага багышланган спектакльләрдә уйнарга, ил сакчысы образлары тудырырга туры киләчәк. Шуңа күрә көрәш кырларын алар үзләре күрергә, сугыш шартларын үз күңелләре белән тоярга, совет кешеләренең батырлык чыганакларын аңларга тиеш. Булачак художниклар өчен бу бик мөһим. Училищеда тәрбия алып чыккан күп кенә яшь актерларның хәрби тема өлкәсендә уңышлы эшләп килүләре шул хакта сөйли. Мәсәлән, училищены 1970 еллар башында тәмамлаган Александр Демидов Чистай шәһәрендә халык театры режиссеры булып эшләгән дәверендә Анкиловның «Солдат хатыны», Салынскийның «Барабанчы кыз», Макаенокның «Трибунал» әсәрләрен сәхнәгә куйды. Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисты Илдар Хәйруллин да укыган чорда әлеге батальонның актив эзтабарларыннан берсе иде. Бу хәл аның киләчәк иҗатында да чагылмый калмады. Әле шәкертлек елларында ук ул «Моабит дәфтәре» кинофильмында уйнады, ә соңрак академия театрында яшь артистлар белән хәрби темага планнан тыш ике спектакль чыгарды. 1977 елда Илдар Хәйруллин училищега педагог-режиссер итеп чакырылды һәм татар актерлары группасын тәмамлаучы студентлар белән диплом спектакле куйды.

Училищега Әлмәт дәүләт драма театрыннан килгән Дамира Кузаеваның иҗади эшчәнлеге дә шул ук фикерне раслый. Җәмәгать эшләрендә активлыгы, укудагы тырышлыгы аңа училищены уңышлы нәтиҗәләр белән тәмамларга мөмкинлек бирде. Хәзер Дамира Татарстанның атказанган артисткасы дигән мактаулы исемне йөртә. Республика комсомоллары исеменнән ул ВЛКСМның XVIII съездына делегат булып барды.

1977 елда Әлмәт театры Казанда гастрольдә чакта «Барабанчы кыз» спектаклендә Дамира башкарган Снешко роле әле дә хәтердә. Бу образда героизм совет кешесенең үз-үзен тотышындагы норма, табигый гамәле буларак гәүдәләнә. Аның сәхнәдә ни чаклы ихлас, ни дәрәҗәдә табигый яшәвен күргәннән соң реаль тормышта күп нәрсәгә сәләтле кеше генә шулай уйный алырга мөмкин дип уйлыйсың. Мондый мисалларны күпләп китерергә булыр иде.

Шунысы кызыклы, училище эзтабарлары җыйган материаллар актерлык осталыгы һәм башка предметлар буенча дәресләрдә файдаланыла. Яшь иҗатчыларны аларның үзләре эзләп тапкан фактик материалда тәрбияләү, әлбәттә, җитди нәтиҗәләр бирүче тәҗрибә мәктәбе ул. 1976 елның 12 мартында РСФСР Культура министрлыгы коллегиясе Казан театр училищесында алып барылган хәрби-патриотик тәрбия эшен тикшерде һәм хуплады. Шушы тәҗрибәне гомумиләштергән белешмә барлык культура, сәнгать училищеларына һәм техникумнарына таратылды.

Казан театр училищесы комсомоллары әле 1969 елда ук КамАЗ төзүчеләренә даими рәвештә культура-шефлык хезмәте күрсәтергә чакырып, республиканың иҗади оешмаларына мөрәҗәгать иткәннәр иде. Шуннан соң Кама автозаводында студентларның диплом спектакльләрен күрсәтү, концертлар кую гадәткә керде. Техникум яшьләре Чаллы шәһәренең үзешчән сәнгать коллективларына да практик һәм методик ярдәм күрсәтеп киләләр.

Профессиональ әзерлек бирү процессы шәхесне формалаштыруның аерылгысыз бер өлеше итеп карала. Югары профессиональ әзерлек шәхесне баета, шул ук вакытта актер шәхесенең нык өлгергән булуы профессиональ осталыкның чәчәк атуына китерә. Укыту процессының диалектикасы әнә шундый.

Яшь актерларны тәрбияләү процессында Казан театрларының танылган режиссерлары һәм актерлары да зур урын тота. Алар студент аудиторияләренә бүгенге сәхнә сулышын алып керәләр, уку-укыту процессын үз иҗат тәҗрибәләре белән

баеталар, татар совет театрының традицион уен мәктәбе алымнарын үзләштерүгә ярдәм итәләр. Һәм бу осталарның училищены тәмамлаган яшь актерлар арасыннан иң сәләтлеләрен үзләре эшләгән театрларга эшкә чакыруларында зур әчке мәгънә бар. Мәсәлән, Г. Камал исемендәге академия театры баш режиссеры Марсель Сәлимҗановның унике шәкерте шул театрда эшли. В. И. Качалов исемендәге Зур драма театрында да андый яшьләр аз түгел. Уку, өйрәнү процессы театрларда дәвам итә. Остазлар үз шәкертләренең иҗади шәхес буларак үсүләрен игътибар белән күзәтеп баралар.

Иң өлгер һәм сәләтле студентларны, училище курсын тәмамлаганнан соң, Мәскәү һәм Ленинградның театр институтларына укырга җибәрү дә — урнашып килгән традицияләрнең берсе.

Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең концерт программаларын алып баручы конферансьеларга мохтаҗлык күрүен истә тотып, училищеда әле беренче ел гына махсус группа оештырылды. Ул группа белән РСФСРның халык артисты Абдулла Шамуков кебек тәҗрибәле актерлар эшли. Бернича ел үтүгә, татар дәүләт филармониясенә махсус әзерлекле нәфис сүз осталары килә башлаячак.

Безнең илдә милли театрлар өчен кадрлар әзерләүгә гаять зур игътибар бирелә. Махсус югары уку йортлары булмаган республикаларга актерлар А. В. Луначарский исемендәге дәүләт театр сәнгате институты (ГИТИС), Ленинград дәүләт театр, музыка, кино институты һәм башка югары уку йортларының милли студияләрендә әзерләнә. Бу студияләрдә уку-укыту процессы СССР халыклары сәнгать традицияләрен исәпкә алып оештырыла. Совет власте елларында А. В. Луначарский исемендәге дәүләт театр сәнгате институты студияләрендә генә дә иллеләп группа чыгарылды.

Актер уенының ышандыру көче аның темпераменты һәм осталыгы белән генә түгел, әмма образларның тирәндә ята торган идея асылына фәлсәфи яктан якын килә белү белән дә билгеләнә. Дөньяга карашындагы концепциясезлек актерны натурализмга алып килергә мөмкин. Театрдамы, кино яисә телевидениедәме,— совет актерының гражданлык позициясе иң төп принцип булып кала. Һәм ул чын художникның һәрбер иҗади эшендә чагыла.

Әгәр дә рольдәге актерның киеме, гримы шәп булып та, йөз-кыяфәте сүлпән, карашы битараф кала икән, тамаша залы каршында ул бик тиз «сүтелеп» төшәчәк — тавышының матур һәм яңгыравык булуы да, сөйләгән сүзләренең бик хак сүзләр булуы да ярдәм итмәячәк.

Миллионнар күңелен җилкетер, дәртләндерер, ярсытыр һәм шатландырыр өчен бүгенге актерга коры осталык, чынбарлыкны образлар аша күрә белү сәләте, сәнгатьнең технологиясенә ия булу гына җитми. Заман актердан чагыштыргысыз дәрәҗәдә зуррак нәрсәне — үз чорың тормышын төптән, фәлсәфи тирәнлектә аңлауны, дөньяга карашларында өлгереп җиткән, партиячел ихлас инанган шәхес булуыңны, гражданлык позицияңнең калку гәүдәләнүен таләп итә.

Социалистик җәмгыять художнигы, М. Горький сүзләре белән әйткәндә, үз иленең, үз сыйныфының сизгер җаны, аның йөрәге, күзе һәм колагы ул. Үз эпохасының җанлы авазы булган әнә шундый художник-гражданинны үстерү — иҗат яшьләрен коммунистик тәрбияләү эшендә иң югары бурыч.

**ЛЮДМИЛА ДОМРАЧЕВА,**
сәнгать фәннәре кандидаты.

Зәки Нури

# НӘНИЛӘР ҺӘМ ЗУРЛАР

*Купбелмеш китабыннан*

## «БАРАБАН АЛЫЙК!»

— Юк, юк, алмыйм! Эштә тавыштан да
Тубал була башым көн дә менә!
— Алыйк инде! Әти, мин кагармын
Син йоклагач аны... Төнлә генә!

## КУАНДЫ ГЫНА

— Сөт юк бүген, кызым. Сыер савылмады...
Бик соң кайттым...— диде ана җайлап кына.
— Әнекәем,— дип кул чапты кызый,— димәк,
Иртәгә син савасың гел каймак кына!

## ЯШЬТӘШЛӘР

— Әйтмә миңа: «Оныгым, син бәләкәч» дип,
Яшьтәш итеп сана, әби, үзеңә! —
«Әби дә бер, сабый да бер!» диде әти,
Мин ышанам аның һәрбер сүзенә.

## БАЛЕРИНА БУЛАСЫ КИЛӘ

— Үскәч мин, әни, балетта биим!
— Нәрсә беләсең син соң бу хакта?
— Чөнки аларны кулга күтәреп
Йөртәләр әнә сәхнәдә хәтта!

## ЧЕРКИ БИТЛЕГЕ

— Бу битлек безне черкидән саклый,—
Ди ата улы аңласын өчен.
— Черки битенә кидерәләрме
Ул безне тешли алмасын өчен?

## ТЫНЛЫ ОРКЕСТР КҮРГӘЧ

Ул беренче күрә әле моны!
Ә фикере инде ап-ачык:
— Әни, нигә кагып йөри болар
Безнең кастрюльләр капкачын?

## ТИРЛӘТМИ ТОРГАН ИТӘ

Өр-яңа тун. Мех тыш. Шуның йонын
Кырка малай... Әнисе эштә.
— Бик тирләтә! — диде.— Мин тирләтмәс
Итәм аны әни кайткан төшкә.

## КУНАК КҮРГӘЧ

— Әнә безгә килә, әни, кунаклар!
Елмаеп һәм кочак җәеп каршыла!
Берсе әнә алдан атлый торт тотып...
Үзем, әни, кул бирермен ансына.

## УРМАНДА ЙӨРГӘН ЧАКТА

— Теге матур кош ничек атала?
— Исемен белмим. Әмма ул тәти!
— Кечкенә чакта кемнән дә булса
Ник шуны сорап белмәдең, әти?

## ИКЕ УРАМ ЧАТЫНДА

— Ник елыйсың?
— Машиналар узмый...
— Нигә кирәк алар сиңа, нәни?
— Чөнки машиналар узмый торып
Урам аша чыкма,— диде әни.

## АТАҢ НИ ДИЯР?

— Йокыңны тизрәк күзгә керт!
Соң бит инде... Атаң кайтыр...
Күрсә ни дияр?
— Беләм лә,
«Җыелыш булды!..» диеп әйтер.

## КАТЫ КУЛ ҺӘМ ЙОМШАК СҮЗ

— Түшәктә болай күп аунар булсаң,
Каешлармын да! Мин — каты кул бит...
— Үзең бит, әти, бер әйткән идең:
«Ятканны кыйнау ярамый ул!» дип.

## АДАША ЯЗГАЧ

— Бик биек морҗа. Кап-кара төтен.
Күпере былтыр ишелгән урам,—
Аңлата сабый бер постовойга.—
Шунда илтегез! Шул якта торам!.

## БИЛГЕЛЕ СӘБӘП

— Әни, безнең рюмкалар кайда?
— Күршеләр алдылар иртән.
— Гәрәй абый әллә тагын
Получка алдымы икән?

## Ә ЧЫНЫ КАЙДА?

— Еракларда йөреп кайтты бабаң.
Бүләгем бар! Менә тот шуны!
— Бу бит... бу бит тик уенчык «Волга»...
Ә әнигә кирәк чып-чыны...

## ӘЙТТЕ, ИМЕШ...

— Әни, әйтче, нигә җиргә
Куп-куе чык төшә икән?
— Чөнки җир кызу әйләнә —
Шуңа тирләп-пешә икән.

## ӨЕ ЯНЫННАН УЗГАНДА

«Ник күренми? Безнең Әхтәм кайда?» —
Тәрбияче шуны белмәк итте.
— Ул «аягым минем сынды» диеп,
Чаба-чаба өенә кереп китте.

## ЗООПАРКТАН КАЙТКАЧ

— Яле, кызым, сөйлә, ниләр күрдең анда?
Сөйлә, тыңлыйм! Эштән инде бушадым!
— Маймылларны тел күрсәтеп, йодрык янап
Үртәгән бер исерек абзый ошады.

## ӨЙРӘТКӘНЧӘ ӘЙТӘ АЛМАДЫ

Әйтә ана: «Билет алмас өчен юлда,
Мин бит әле биш яшемдә түгел!» диген.
«Билетым юк! Мин алтыда инде!» диеп,
Дөп-дөресен әйтеп салды бала бүген.

## ЗООПАРКТА БӘЙРӘМ

Бегемотка чәчәк ашаталар...
Бүген аның туган көне икән.
Уйлый бала: «Бу бегемот кайдан?
Һәм директор аның кеме икән?»

## УРАМДА КЫЗЛАР КҮРГӘЧ

Сорый нәни: «Кем дә булса боларны
Әллә шулай кыйнаганмы, әтием?
Күз күгәргән, ә иреннәр канаган...»
— Алар шулай буялганнар, тәтием.

## КҮРШЕЛӘР БАКЧАСЫНДА

— Күршеләрнең алмаларын өзеп
Синме әллә җиргә ташладың?
— Мин өзмәдем! Алар әче иде.
Җиләк кенә анда ашадым...

## Әбрар Шәмин

# ЭХ, ГАТА, ГАТА!

*Парча*



Мин үземнең ерак туганым Мәгъсумов Гата квартирында утыра идем. Квартир әйбәт, мебель дә шәп: кайчандыр Ригадан китерелгән. Гатаның эш урыны да гүзәл: ни дисәң дә зур бүлек башлыгының икенче ярдәмчесе.

Кунакта булгач, кунак буласың инде: өстәлдә әрмән коньягы, башкорт балы. Моңа өстәмә — грузин чәе. Шулай итеп утыра торгач, сүз Гатаның башлыгы, дәресрәге, аның идарә җитәкчесе Фәттахов Иркен турында башланып китте.

— Туганым! — диде Гата, гадәттәгечә бер күзен кыса төшеп.— Беләсеңме, туганым? Фәттахов алтын кеше ул. Менә мине генә ал: Фәттахов өчен үләргә дә риза мин. Риза, билләһи, риза! Әй кеше дә инде безнең Фәттахов. Мактанып әйтмим: мин аның туган көнендә өендә булганым бар. Сый, сый! Тик карының гына чыдасын: кара икра... симез күркә... тутырма тавык... Кыскасы: җаның ни тели — өстәл шыгрым тулы. Ә балык, балык дигәнең? Стерля... Осетра... теләсәң, тот та буа бу! Әмма эш башлыкта гынамени? «Иләгенә күрә чиләге, өенә күрә өйрәсе»,— дигәннәр картлар. Фәттахов үзе акыл иясе, абруйлы кеше. Талант Фәттахов, талант инде. Җитмәсә — гади. Әй гади дә инде! Әйтерсең якын туганың. Фәттаховның дуслары да бик гади. Алар белән бергә утыру үзе зур бәхет. Менә күрерсең: Фәттахов тагын күтәреләчәк. Обязательно! Чөнки ул талант һәм әйбәт кеше. Туктале, мин аңа хәзер үк шалтыратыймчы. Бүген ял итәбез ич: әгәр дачага китмәгән булса, өйдәдер, бәлки.

Мәгъсумов урыныннан торды да Фәттаховның квартирына шалтыратты:

— Иркен абый? Хәерле көн, Иркен абый! Мәгъсумов Гата әле бу... Рәхмәт, зур рәхмәт, Иркен абый! Сезгә дә шундый теләкләр, Иркен абый... Булды, эшләдек, Иркен абый... Иркен абый! Тагын да берәр поручение юкмы? Ярый, ярый, рәхмәт, Иркен абый... Ярый хуш, хуш, Иркен абый...

Сүз бетте, Гата рәхәтләнеп авызын ерды һәм учларын уа-уа, янә өстәл каршына килеп утырды.

— Беләсеңме син? — диде ул, кинәт җитди төс алып.— Беләсеңме син? Фәттаховны кайсыбер бәндәләр эштә яратмыйлар бит. Әйе, яратмыйлар! Һаман бер балык башы: «Борын күтәрә, хезмәткәрләр гозеренә колак салырга теләми»,— янәсе...

Вакыт тик тормый. Тизлек заманы бит. Минут-секундлар гына түгел, атналар үтеп киткәне дә тоелмый кайчак. Менә соңгы көннәрдә минем өчен дә нәкъ шулай булды. Нәтиҗәдә мин үземнең ерак туганым Мәгъсумов белән янә бер тапкыр дүрт айдан соң гына күрешә алдым. Очрашу Мәгъсумовның эшендә булды.

— Я, хәлләрең ничек, Гата? — дип сорадым мин.— Эшеңдә тынычлыкмы? Башлыгың Фәттахов белән еш очрашасыңмы?

— Юк! — диде Гата, чыраен сытып.— Бездән кудылар аны. Юньсез адәм булып чыкты ул. Әйе, мәгънәсез. Мине берәр яхшырак эшкә күчерергә дә кулыннан килмәде аның. Надан иде ул. Түрә!.. Эш урыныннан файдаланырга ярата иде, төлке. Хәзер берәүгә дә кирәкми инде. Йөрсен инде менә, акылсыз шәхес булып!

Гата өстәл тартмасын ачып, папирос алды һәм, бераз дәшми утыргач, үзенең яңа башлыгын мактый башлады:

— Вәт кеше ичмаса! Кара син аны, ә? Килгән көнне үк коллектив белән танышып чыкты. Үзе яшь, шулай да кешенең йөрәген аңлый белә торган җитәкче. Элек тә шәп урында эшләгән икән. Бер көнне миңа, совещаниедә утырган чакта, елмаеп-елмаеп карап куйды. Әйбәт, бик әйбәт, бик шәп кеше!..

Гата тынды. Мин уйга калдым: «Эх... Гата, Гата!»

## Григорий Луч

# АВЫЛ СКЛЕРОЗЫ

*Юмореска*



Врачлар склерозны чир диләр. Бу чыннан да шулай булырга тиеш. Чирне, кем әйтмешли, берәү дә уйлап чыгармый, кешегә ул үзе килеп ябыша. Ә менә безнең авыл аксакалларыннан сорасагыз, алар сезгә бу чир уйлап чыгарылган диярләр иде. Әйе-әйе, нәкъ менә уйлап чыгарылган һәм аны хәзерге аксакаллы картлар түгел, ә борын замандагы бабаларыбызның бабалары уйлап чыгарган. Һәм ирләр арасында ул бигрәк тә нык таралган икән. Хатын-кыз аның белән бик сирәк изалана, ди.

Мин бу зәхмәткә үзем дә шушы арада гына тап булдым әле. Гонконг гриппыннан да яман булып чыкты үзе.

Күптән түгел хатыным Мария белән бәхетебез артты — улыбыз туды. Гадәт буенча бәби туе үткәрергә уйладык. Туйга колхоз председателе Иван Ивановичны да чакырырга булдык. Улыбыз хөрмәтенә шау-гөр килеп күңел ачасы килде. Ә безнең Иван Иванович тамчы да капмый. Алай гына булса бер хәл иде — хәмерле табында өч минуттан артык утыра ук алмый ул. Менә шулай...

Хатын белән уйга калдык. Беренчедән, бөтен туган-тумачаны, дус-ишне җыясы килә. Чакыргач, коры чәй белән генә булмый, әлбәттә. Күңелләрен күрәсе, хөрмәт итәсе килә. Югыйсә, саран атың чыгуы да бар. Икенчедән, өстәлдә хәмер-фәлән күренү белән безнең Иван Иванович өч минуттан тора да китә инде — анысы көн кебек ачык. Инде нишләргә?..

Без Мария белән болай итәргә булдык. Бүген, мәсәлән, туган-тумачаны, дус-ишне чакырып, булганы белән сыйлыйбыз, бәйрәм итәбез. Ә иртәгә карчыгы белән Иван Иванович килер, самавар куеп чөкердәшеп утырырбыз.

Һәм шулай эшләдек тә. Әй, кызык та булды соң беренче кичне! Җыр-бию, уен-көлке, гармуны да сайрап торды. Аның каравы икенче кичне өстәлгә самавардан бүтән нәрсә куймадык. Утырабыз шулай Иван Иванович белән хәл-әхвәлләр, колхоз эшләре турында җай гына гәпләшеп.

Кинәт ишек кактылар. Хатын барып ачарга да өлгермәде, абыйсы Костя атылып керде.

— Бәхетле гаиләгә сәлам! — ди бу бусагадан ук.— Ну кичә бирдек кирәген, азындык, ә!.. Тукта, мин нигә килдем соң әле?.. Ә... әйе, перчаткам калган. Склероз, мин сиңа әйтим! Менә үзе дә, мич кырыенда... Кхм... Чәйләп утырасыз алайса? Ә минем кесәдә бер чүлти онытылып йөри. Ярый әле искә төште. Склероз, мин сиңа әйтим... Мария, кая рюмкалар китер әле.

Инде өстәл янына утыртмый нишлисең. Костя шешәнең бөкесен дә ачарга өлгермәде, тагын ишек шакыдылар. Монысы минем абый Миша иде.

— Мин бер генә минутка,— ди бу.— Киез итекнең галошы калган. Мария, күзеңә чалынмадымы?.. Сәер... Кайда гына ята икән соң? Хәтер диген инде шуны... Карале, сезнең теге нәрсә калган икән. Болай булгач яшибез аны, яшибез... Ярар, галошы табылыр.— Һәм ул да өстәл янына килеп утырды.

Иван Иванович баштa мескен генә итеп миңа карап куйды, аннан Мариягә, аннан үз хатынына. Шул мизгелдә тагын ишек ачылды һәм бүлмәгә айкала-чайкала күрше Макар килеп керде. Кулында гармун.

— Бәйрәм белән күрше! — ди бу.— Гармунның футляры калган, пнимаеш, барып алыйм әле, мәйтәм. Уйнап утырган хәтердә, биегән, җырлаган хәтердә. Футлярны югалту — башка күсәк белән тамызсаң да искә төшмәс... Кичә менә моны җырлаган идек,— дип, Макар килеп утыруга гармунны тартып җибәрде.

Музыка тавышына, утка омтылган күбәләкләр кебек, кичәге халык җыела башлады. Иван Иванович түзмәде, бүреген киде дә, хатынын култыклап ишеккә юнәлде.

— Петр, бер дә яраган эш түгел инде бу,— ди ишек төбендә.— Чәйгә чакырасың тагын... Минем ул нәрсәне сөймәгәнне беләсең бит...

Кыскасы, Иван Иванович үпкәләп китте. Шулай да мин өметне өзмим — бергәләп чәйләрбез әле дим. Чөнки ул да бияләен онытып калдырган. Алырга килеп чыкмый калмас.

Ни дисәң дә склероз безнең авылда күпләр өчен уйлап чыгарылган чир. Монда врач кына ярдәм итәрлек түгел. Әйдәгез, үз көчебез белән дәваланыйк!..

## М. Әпкәли

# БАЛЫК ТОТКАНДА

*Г. Рыклин буенча*



Әфләтунов елга буена төште. Кармак салды. Бәхете бар икән юньсезнең — алтын балык капты.

Әфләтунов алтын балыкка сокланып карап-карап торды да аны кире елгага җибәрде:

— Рәхмәт инде, — диде аңа алтын балык, — әйт, нәрсә телисең? Күз ачып йомганчы әзер булыр.

— Миңа бернәрсә дә кирәкми, — диде Әфләтунов, битараф тавыш белән.

— Акча кирәктер бәлки?

— Акча бездә бер букча.

— Ә машина?

— Машина да бар.

— Фатир ягы ничегрәк?

— Фатирым әйбәт.

— Дача кирәкмиме?

— Алдым инде.

— Премия бирдеримме?

— Рәхмәт, премияне дуслар аша оештырам.

— Дан кирәкме?

— Даным бар, шөкер. Җыелыш саен президиумга сайлыйлар. Язган әйберләремне дә мактаучылар буа буарлык.

Алтын балык йөзеп киткәч, Әфләтунов, өенә кайтып, күргәннәрен хатынына сөйләде.

— Ә син алтын балыктан нәрсә сорадың? — диде хатыны, Әфләтуновны ашарга җитешеп.

— Берни дә сорамадым.

— Тәпәч син алай булгач...

— Нәрсә сорарга тиеш идем соң мин?

— Талант сорарга кирәк иде, җанашым, талант!..

# ПЛАГИАТЛАР ҖЫЕЛЫШЫ

Трибунага өлкән плагиат күтәрелгәч, көчле кул чабулардан зал тетрәнеп китте.

— Без, плагиатлар, кайчагында үзебезнең миссиябезгә хыянәт итәбез, — дип, илаһи уптым башлады үзенең сүзен өлкән плагиат, — мисалга Кәбир Кыдырачның яңа романын гына алып карыйк. Ишбулдин романының сүзен-сүзгә күчерә алмаган Кыдырач. Кайбер бүлекләрдә аның үз сүзләре дә очрый. Мәсәлән: 987 биттә «һәм»

бәйлеге урынына «вә» кулланылган. Ә 862 биттә нокталы өтер урынына өтер генә куелган. Шуңа күрә мин Кәбир Кыдырачны халтурщик дип тамгалап үтәргә җөрьәт итәм.

Кәбир Кыдырач бу мәсхәрәгә түзеп тора алмады. Чәчләрен үрә торгызып, сәхнәгә каты-каты сүзләр ыргытты:

— Мин халтурщик булсам, син язучы, белдеңме, кем син! Язучы, язучы! Үзеңнең «Кәккүк кычкыра микән?» дигән хикәяңне укып кара. Егерменче биткә кадәр Зәйнуллинга матур гына ияреп килгәнсең-килгәнсең дә, 21 биттә «Кояш кызарып баеды» дип язып куйгансың. Ә Зәйнуллин, беләсегез килсә, «Кояш кызарып батты» дип яза. Шулай булгач, язучы булмыйча, кем буласың инде син. Плагиатның «п» хәрефе дә юк синдә, хөрмәтле иптәш!

Зал өстеннән көлү дулкыны шаулап узды. Плагиатлар эчләрен тотып урындык артларына аудылар. Чөнки плагиатлар арасында «язучы» дигән сүз «шагыйрь», «драматург» дигән сүзләр кебек үк хурлыклы сүз булып санала иде.

Өлкән плагиат иңбашларын җыерып, башын галстук төененә яшереп, урынына барып утырды.

Трибунага плагиат тәнкыйтьче Гөрзиле чыкты. Башта ул залдагыларга кушылып көлде, аннары югары пафос белән шигырь куплеты укыды:

Ал да булырбыз әле,
Гөл дә булырбыз әле...

— Кем шигыре?

— Аллыныкы, — дип гөрләде зал.

— Инде менә хәзер яшь плагиат Гөлле шигырен тыңлап карагыз.

Гөл дә булырбыз әле,
Ал да булырбыз әле.

Зал өстендә ачулы, нәфрәтле сүзләр яңгырады:

— Долой, Гөллене әдәбияттан куарга! Оригинальничит итмәсен!! Монда инде шагыйрьлеккә бер генә адым калган...

Шау-шу тынгач, Гөрзиле драматургиягә күчте.

— «Доктор керә, унтер чыга»... Кем әсәреннән?

— Хәсбиев триптихыннан.

— Дөрес. Ә менә плагиат Алмашлы «унтер керә, доктор чыга» дип яза. Япь-яшь башыннан драматурглар базына тәгәрәгән кеше. Нәрсә соң бу, иптәшләр? Кая бара безнең плагиат халкы?!

Гөрзиледән соң плагиат Гелмактар йомгаклау сүзе белән чыкты:

— Без күбрәк мәсьәләнең кара ягына туктадык, иптәшләр, — диде ул җитди тавыш белән. — Кимчелекләребез белән беррәттән күкрәк сугып сөйләрлек уңышларыбыз да бар бит безнең. Мисалга бер генә куплет шигырь укып китәргә рөхсәт итегез.

Мич алында капкач,
Җылы чыкмый япкач.

Бусы Ибәт шигыре. Ә менә безнең яшь плагиат Гыйбат болай иҗат итә:

Мич алдында капкач,
Җылы чыкмый япкач.

Аерма бары тик «алында» һәм «алдында» сүзләрендә генә. Мондый гына гаеп мулла кызында да була, җәмәгать. Миндә Гыйбатны Плагиатлар премиясенә тәкъдим итәргә дигән фикер бар.

Залда шау-шу. Гыйбатка дан! Гыйбат хөрмәтенә зур банкет, ура! дигән сүзләр яңгырый.

Җыелыш ябыла.

# ТЫНГЫСЫЗ ӘДӘБИЯТЧЫ



Филология фәннәре кандидаты Исхак Зәбиров исемен журнал укучылар да, гомумән, әдәбият белән кызыксынучылар да яхшы белә. Без аны иң элек патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең һәм аның көрәштәшләренең тормышын өйрәнүче тынгысыз һәм эзләнүчән әдәбият галиме дип беләбез.

Исхак Хөсәен улы Зәбиров соклангыч язмышлы, тынгысыз җанлы, көчле рухлы кешеләрнең берсе. Аның романтика белән тулы тормышы илебезнең хезмәт энтузиазмы кайнап торган иң мөһим урыннары белән бәйле. Ул илебездә барган социалистик төзелешнең иң кайнап торган ноктааларында катнаша һәм алгы сафларның берсендә бара. 1928 елда Пенза өлкәсенең Синар авылында туган егет сугыш афәтләрен күреп үсә, үзе дә сугыш алып килгән җимерекләрне торгызуда актив катнаша, гомерен төзелешкә багышларга уйлый. Шул ният белән ул төзелеш техникумын тәмамлый. Пенза, Калининград, Славск шәһәрләрендә барган төзелешләрдә төзүче-техник, төзүче-инженер вазифаларын башкара, яшьләр арасында комсомол вожагы була. Җаны-тәне белән туган илгә хезмәт итәргә омтылучы яшь комсомолец Исхак Зәбиров комсомол путевкасы белән Урта Азиягә удар төзелешкә китеп бара. Ул анда төзүче-инженер, төзелеш идарәсе начальнигы урынбасары, комсомолның, аннары партиянең Ташкент шәһәр комитеты инструкторы, төзелеш эшчеләре профсоюзының Ташкент өлкә комитеты председателе кебек җаваплы эшләр башкара. Ул партия кушкан һәрбер эшне җиренә җиткереп эшли. Удар төзелешләрдә актив катнашканы өчен Исхак Зәбиров 1957 елда Мәскәүгә яшьләр һәм студентларның VI бөтендөнья фестивалена кунак булып та бара.

И. Зәбиров кайда гына эшләсә дә, әдәбият белән, культура тарихы белән кызыксынуын бер дә туктатмый. Үзе дә каләмен сынап карый. Үзен кызыксындырган, борчыган мәсьәләләр турында газета-журналларга мәкаләләр язып тора. 1957—1958 елларда «Строительная газета"ның Үзбәкстан буенча үз хәбәрчесе булып эшли. Соңрак И. Зәбиров Ташкент дәүләт университетын, аннары шунда ук рус һәм чит ил әдәбиятлары буенча аспирантура тәмамлый. 1972 елда исә Мәскәүдә «Муса Җәлил һәм татар шагыйрьләренең Моабит группасы» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Яклауда катнашкан күренекле галим-җәлилче Гази Кашшаф, СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты В. Р. Щербина кебек танылган әдәбиятчылар әлеге фәнни хәзмәткә югары бәя бирәләр.

И. Зәбировның әлеге хезмәте — Муса Җәлилнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә керткән зур хезмәт. Анда Муса Җәлилнең соңыннан табылган шигырьлә-

ренә анализ ясалган, җәлилчеләрнең батырлыгын исбатлаучы әр-яңа фактлар, документлар тупланган. Галим Җәлил тормышын өйрәнү өчен вакытын да, көчен дә кызганмый: илебезнең төрле шәһәрләрендә, авылларында була, Җәлилнең көрәштәшләре белән очраша, алардан яңа мәгълүматлар ала, җәлилчеләрнең туганнарын табып сөйләшә. ГДРда яшәүче немец язучылары Леон Небенцаль һәм Эрих Мюллер белән элемтәгә керә. Э. Мюллер — Җәлилгә багышланган «Кызыл ромашка» исемле телевизион фильмның авторы, Җәлил шигырьләрен немец теленә тәрҗемә итүче. Бер хатында ул болай дип яза: «Йолдызларга геройлар исемен бирәсе иде. Әйдәгез, без дә Денеб йолдызын Җәлил йолдызы дип атыйк».

И. Зәбировның «Җәлил белән янәшә» исемле китабы үзенең пафосы белән интернационализм һәм патриотизм, социалистик Ватанга бирелгәнлек һәм җәлилчеләрнең легендар батырлыгы турында. Автор Муса Җәлилнең тормышына һәм иҗатына табынучы гына түгел, ә аның ялкынлы шигърияте пропагандалаучы да, Җәлил һәм аның көрәштәшләре турындагы яңа материалларны җыйнаучы һәм барлаучы да.

И. Зәбиров бүген дә иҗат дәрте белән янып яши. Аның публицистик язмаларына һәм очеркларына тирән психологизм, патриотизм хас, бүгенге көн турында уйланулар һәм бүгенге көн кешесенең эчке дөньясына үтеп керергә омтылу хас. Ул матбугатта М. Ю. Лермонтов, А. Н. Радищев, А. П. Чехов иҗатына, СССР халыклары әдәбиятына багышланган мәкаләләр белән дә катнаша. Үзбәк-татар әдәбиятлары бәйләнеше, Җәлил һәм аның көрәштәшләре темасына багышланган мәкаләләре һәм публицистик чыгышлары «Казан утлары» журналында да ел саен диярлек басылып тора. Ул илебезнең төрле шәһәрләре һәм авылларында, эшчеләр һәм колхозчылар, студентлар һәм укучылар алдында Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында лекцияләр укый, Җәлил тормышын өйрәнүне дәвам итә.

Каләмдәш дустыбызның тынгысыз иҗаты өчен без дә шатланабыз һәм аңа яңа иҗат уңышлары телибез.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ИҖАДИ ДУСЛЫК

Татарстан китап нәшрияты белән КамАЗ арасындагы иҗади дуслык күптәннән яшәп килә. КамАЗ төзелә башлагач ук нәшрият-та Кама буендагы бөек төзелешкә багыш-ланган очерклар, мәкаләләр, репортажлар тупланган җыентыклар дөнья күрде. Китап чыгаручылар хәзер дә КамАЗга игътибарны киметмиләр. «КамАЗ китапханәсе» сериясендә алдынгылар тәҗрибәсе, камазлыларның данлы хезмәт традицияләре турында ел саен китаплар чыгарыла.

Нәшрият белән КамАЗ арасында урнашкан иҗади дуслыкны тагын да ныгыту максатыннан, июль аенда нәшрият директоры Г. Шәрәфетдинов җитәкчелегендәге делегация Чаллы шәһәре, Түбән Кама ГЭСы төзелеше объектларында һәм КамАЗ берләшмәсе заводларында булды. Нәшриятның баш редактор урынбасары, РСФСРның атказанган культура работнигы Н. Габитов, масса-политик әдәбият редакциясе мөдире И. Низамов, матур әдәбият редакциясе мөдире, Тукай премиясе лауреаты шагыйрь Ш. Галиев, «Казан утлары» журналының баш редактор урынбасары, язучы һәм шагыйрь Ә. Баянов, нәшрият редакторлары С. Сибгатуллина, В. Белокопытов, М. Зарецкий, шагыйрьләр Г. Зәйнашева, Н. Беляев, җырчы М. Галиев, гармунчы К. Нигъмәтҗанов иптәшләр ике группага бүленеп, КамАЗ берләшмәсе заводларында, тулай торакларда, китапханәләрдә эшчеләр, китап сөючеләр белән очраштылар, үзләренең иҗат планнары белән уртаклаштылар, әсәрләрен укыдылар.

Аннары КамАЗ производство берләшмәсе белән нәшрият иҗади хезмәттәшлеккә договор төзеделәр. КПССның Чаллы шәһәр комитетының беренче секретаре Р. К. Беляев КамАЗ белән Татарстан китап нәшрияты арасында туган иҗади хезмәттәшлеккә олы бәя бирде, аның яңа уңышлар китерәчәген әйтте.

## РЕСПУБЛИКА КУНАКЛАРЫ

Казанга француз публицисты, Гомуми хезмәт конфедерациясенең «Ви увриер» атналыгының культура һәм иллюстрацияле яңалыклар бүлеге редакторы Серж Зейон һәм «Юманите-Диманш» атналыгы журналисты Мишель Серрьер килде. Алар республикабызның экономик һәм культура тормышы белән таныштылар.

Франциядән килгән кунакларны Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев кабул итте.

## ЯЗУЧЫ МАРИЯ ЕЛИЗАРОВАГА 70 ЯШЬ

20 июньдә Татарстан язучыларының Габдулла Тукай исемендәге клубында күренекле язучы, РСФСРның атказанган культура работнигы, А. М. Горький музее директоры Мария Николаевна Елизаровага 70 яшь тулуга багышланган кичә булып узды. Әдипнең тормышы һәм иҗат юлы турындагы докладны әдәбият галиме Л. Юдкевич сөйләде. Аннары юбилярга КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Почет грамотасы тапшырылды. Шәһәребез музейларыннан, илебездәге төрле музейлардан килгән хезмәттәшләре, югары уку йортлары, партия һәм җәмәгать оешмалары, иҗат союзлары, М. Горький исемендәге колхоз һәм башка оешмаларның вәкилләре М. Н. Елизарованың пролетар язучысы М. Горький иҗатын һәм тормышын өйрәнүдәге, пропагандалаудагы зур хезмәтенә югары бәя бирделәр, кайнар котлау сүзләрен әйтеп, яңа иҗат уңышлары теләделәр.

## ФӘННИ ЭЛЕМТӘЛӘР НЫГЫЙ

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре Хельсинки университеты белән якын фәнни элемтәдә торалар. Соңгы елларда профессор А. Халиков бу университетта берничә мәртәбә лекцияләр белән чыгыш ясады. Күптән түгел институтның халык иҗаты секторы мөдире, филология фәннәре кандидаты И. Надиров та Хельсинки университетында фәнни командировкада булып кайтты. Ул анда фин әдәбияты һәм фольклоры җәмгыятенең эшчәнлеге белән танышты, халык иҗатын җыю-өйрәнү өлкәсендәге яңалыклар буенча тәҗрибә уртаклашты, татар фольклоры турында лекция укыды. Лекция ике мәсьәләгә — Урта Идел буендагы татарлар белән угро-фин халыклары фольклорын тарихи чагыштырма өйрәнүгә һәм татар совет фольклористикасының хәзерге торышын яктыртуга багышланган иде.

И. Надиров университетка «Татар халык иҗаты» исеме астында чыга торган унике томлык фольклор җыйналмасының инде дөнья күргән өч томын бүләк итте.

Казан галименең командировкасы вакытында Финляндиядәге Тукай җәмгыяте җитәкчесе Гомәр Таһир Хельсинки һәм Тампере шәһәрләрендә әлеге җәмгыятьнең ике кичәсен оештырды. Кичәнең беренче өлешендә тамашачылар И. Надировның Г. Тукай иҗатында фольклор чыганакларын яктыртуга багышланган чыгышын тыңладылар, аннан соң «Кырлай» фильмын карадылар. Фильм кичәдә катнашучыларда тирән кызыксыну уятты. Г. Таһир бу фильмны әзерләгән һәм аны Хельсинкига җибәргән культура оешмаларына зур рәхмәт әйтте.

## КАРАБИХАДА ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Ярославль шәһәре янындагы Карабиха усадьба-музеенда Некрасовка багышланган Бөтенсоюз шигырь бәйрәме булды. Шигырь бәйрәмендә СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Алексей Сурков житәкчелегендәге язучылар делегациясе катнашты. Алар арасында Ю. Друнина, В. Жуков, М. Лисянский, Ю. Кузнецов, П. Осадчук, Р. Бородулин, А. Атабаев кебек танылган шагыйрьләр бар иде. Шигырь бәйрәмендә Татарстан шагыйрьләре исеменнән шагыйрь Равил Фәйзуллин чыгыш ясады.

## ГАЛИМНЕҢ УҢЫШЫ

В. И. Ленин исемендәге СССР Дәүләт китапханәсе каршындагы махсус гыйльми советта СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре, күренекле галим Әбрар Кәримуллин «XX йөз башы татар китабы» дигән темага докторлык диссертациясе яклады. Рәсми оппонентлар һәм диссертацияне яклауда катнашучы күренекле совет галимнәре Ә. Кәримуллин алып барган эзләнүләргә югары бәя бирделәр.

## КамАЗ КЕШЕЛӘРЕ ТУРЫНДА

«Бетми торган очрашу» («Встреча, которая не кончается») — рус язучысы Анатолий Злобинның «Советская писатель» нәшриятында чыккан китабы шулай дип атала. Анда язучының Чаллыга берничә мәртәбә бару нәтиҗәсендә туган очерклары тупланган. А. Злобин КамАЗның, аның төзүчеләрен яхшы белә. Шуңа күрә дә очерклардагы геройларның язмышлары укучыларны дулкынландырырлык, уйландырырлык итеп бирелгән.

## 1979 ЕЛ КИТАПЛАРЫ

Татарстан китап нәшрияты 1979 елга тематик план бастырып чыгарды. Әдәбият сөючеләр киләсе елда татар әдипләренең бик күп яңа әсәрләре белән таныша алачаклар. Проза буенча түбәндәге китаплар дөнья күрәчәк:

**Әмирхан Еники.** «Юлчы». Хикәяләр, **Мирсәй Әмир.** «Без бәләкәй чакларда». Автобиографик повестьның беренче китабы; **Гариф Ахунов.** «Без бит Арча яклары». Документаль повесть; **Фатих Хөсни.** «Очрашулар». Хикәяләр; **Әхсән Баянов.** «Тау ягы повесте». Повестьлар; **Шәүкәт Галиев.** «Әзмәз мәзәк». Мәзәкләр; **Мөхәммәт Мәһдиев.** «Наратлар шаулый». Повестьлар, хикәяләр; **Вакыйф Нуруллин.** «Аккан су юлын табар». Повестьлар; **Гәрәй Рәхим.** «Көннәр язга авышкач». Повестьлар; **Хәсән Сарьян.** «Бер ананың биш улы». Повесть; **Фаил Шәфигуллин.** «Күзгә карап». Юмористик хикәяләр; **Миргазиян Юныс.** «Энже эзләүчеләр». Повесть, хикәяләр; **Ибраһим Нуруллин.** «Тукай». ЖЗЛ сериясеннән; **Кояш Тимбикова.** «Агым уртасында». Повесть; **Лирон Хәмидуллин.** «Онытылмас сукмаклар». Повесть; **Фәнис Яруллин.** «Язмышлар язылганда». Повесть; **Барлас Камалов.** «Канатлы кырмыска». Повесть.

Шигърият сөючеләр татар шагыйрьләреннән Гамил Афзал, Сажидә Сөләйманова, Рәшит Гәрәй, Мәхмүт Хөсәен, Роза Хәлиуллина, Салисә Гәрәева, Роберт Миңнуллин, Марсель Галиев, Нәҗип Мадьяров, Эдуард Мостафин, Зиннур Мансуров әсәрләре белән таныша алачак. Шулай ук Дәрдмәндең, Ә. Давыдовның, А. Шамуковның сайланма әсәрләре укучылар кулына барып ирешәчәк.

1979 елда драма жанры белән кызыксынучыларга Аяз Гыйләҗев «Кар астында кайнар чишмә», Шәриф Хөсәенов «Пьесалар», Габделхәй Сабитов «Чулпан таңны уята», Ш. Зәйни «Гөмбәз асты серләре» исемле яңа китапларын тәкъдим итәләр.

Тәнкыйть өлкәсендә Сибгат Хәкимнең «Халык язмышы — шагыйрь язмышы», Хәсән Хәйринең «Язучы һәм тормыш», Рафаэль Мостафинның «Җаваплылык хисе», Шәрәф Әхмәдуллинның «Киләчәкне уйлап» дигән китаплары басылып чыгачак.

## БЕРЛӘШМӘНЕҢ ЮБИЛЕЕ

Лениногорск шәһәрендә чыга торган «Ильич васыятьләре» газетасы редакциясе каршында эшләп килүче «Чишмә» әдәбиятсәнгать берләшмәсенең яши башлавына сентябрь аенда 20 ел тулды. Шул гомер эчендә әдәби берләшмә үсте, ныгыды. Заманында яңа гына чыга башлаган «Ильич васыятьләре» газетасы редакциясе каршындагы берничә генә кешедән торган кечкенә бер оешма иде ул: Кыям Галләмов, Сәгадәт Ибраһимов, Шамил Бикчурин, Әнвәр Мусиннар... Аннары аларга Фуат Насыйбуллин, Фәйзи Сәйфетдинов, Әнвәр Шәрипов кебек эшче һәм укучы яшьләр килеп кушылды. Ул гына да түгел, яңа берләшмәгә язучы яшьләр күпләп килә башлады. Җәмит Рәхимов, Гәрәй Рәхим, Җәүдәт Дәрзаманов, Әсрар Галиев, Мәхмүт Газизов, Альберт Хәсәновлар сафны тулыландырды. Шул елларда берләшмәдә чыныгу алган иптәшләр: Шамил Бикчурин, Гәрәй Рәхим, Җәмит Рәхимов һәм Мәхмүт Газизов СССР Язучылар союзына кабул ителде. Сәгадәт Ибраһимов белән Әнвәр Шәрипов — филология фәннәре кандидатлары. Инде берләшмәдә чыныгу алган яшьләрдән Рәшит Бәшәров белән Җәүдәт Дәрзамановларның да икешәр китабы дөнья күрде.

«Чишмә» берләшмәсе район һәм шәһәрдәге барлык язучыларны һәм башлап язучыларны гына түгел, үзешчән композиторлар, һәвәскәр җырчылар, музыкантлар, рәссамнарны да берләштерә. Берләшмә членнары ел саен авыл һәм шәһәр клубларында уннарча чыгышлар ясыйлар. Җирле радио аша тапшырулар алып баралар. Район газетасы битләрендә даими рәвештә әдәби сәхифәләр чыгып килә. Бүгенге көндә Разим Вәлиуллин, Наил Гыйләҗев, Таһир Шәмсуаров, Илгиз Зәйнетдинов, Әсрар Галиев, Гөлисә Кәримова кебек яшьләр берләшмә эшендә актив катнашалар, яңа әсәрләр иҗат итү теләге белән янып яшиләр.

## КОЛХОЗДАГЫ ӘДӘБИ ТҮГӘРӘК

Әгерҗе районының Карл Маркс исемендәге колхозында оешкан «Чулпан» әдәби түгәрәгенә йөрүче яшьләр Тукай-Кырлайда һәм Казанда булдылар. Язучылар союзында уздырылган очрашуда алар язучылардан Фатих Хөсни, Шамил Рәкыйпов, Саҗидә Сөләйманова, Рәдиф Гатауллин, Зөлфәт, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Әхмәт Рәшитов һәм Әхмәт Гаделнең әдәбиятыбыз турындагы фикерләрен, яңа шигырьләрен тыңладылар. Түгәрәк әше турында сөйләделәр, үзләре иҗат иткән шигырьләрне һәм җырларны башкардылар.

## КҮРШЕЛӘРДӘ КУНАКТА

Киров өлкәсе язучылары чакыруы буенча, язучы Ләбибә Ихсанова үзенең туган ягы, Вятская Поляна районында үткәргән әдәбият һәм сәнгать атналыгында катнашты. Ленин комсомолының 60 еллыгына багышланган бу бәйрәмгә килгән язучылар, артистлар, рәссамнар промышленность предприятиеләрендә, колхозларда, китапханәләрдә һәм район газетасы редакциясендә күп санлы әдәбият сөючеләр белән очраштылар.

## ҮЗӘК НӘШРИЯТТА

Мәскәүнең «Современник» нәшрияты соңгы елларда татар әдипләренең күп кенә яңа китапларын бастырып чыгара башлады. Шундый китапларның тагын берсе дөнья күрде. Ул — Казан шагыйре Илгиз Кәлимуллинның «Дорога к людям» исемле шигырьләр җыентыгы. Кереш сүзне шагыйрь Рөстәм Кутуй язган.

## ТОЛСТОЙ МУЗЕЕ

Казанның планетарие бинасында «Толстой — Ясная Поляна» исемле күчмә күргәзмә күрсәтелде. Бөек рус язучысының Казан чоры белән бәйләнешле тормышы турында, Ясная Поляна тарихы турында сөйләүче бу күргәзмәдә меңләгән казанлылар булды.

## СӘХНӘ ОСТАЛАРЫ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Матбугат йортында журналистларның Казанга гастрольгә килгән Липецк өлкә драма театры артистлары белән очрашуы булды. Очрашуны театр директоры С. Кончевский, режиссерлар В. Пахомов һәм Б. Голубницкий, әдәби бүлек мөдире О. Нестерова алып бардылар. Алар театрның иҗади эшчәнлеге турында сөйләделәр.

Артистлар «Минем өметләрем», «Иртән алар уяндылар», «Соңгы срок», «Тормыш вак-төякләре» һәм «Иосиф Швейк Франц Иосифка каршы» дигән спектакльләрдән өзекләр күрсәттеләр.

## ЧИТ ИЛЛӘР ДӘ АЛКЫШЛЫЙЛАР

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле соңгы елларда зур иҗади биеклекләр яулый. Ансамбльне хәзер чит ил тамашачылары да яхшы белә. Июль аенда Татарстан артистлары Италия һәм Мальтада булып кайттылар. Гастрольләр вакытында алар Италия коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты органы булган «Унита» газетасы бәйрәмендә катнаштылар.

## «ӨЧ КӨН БӘЙРӘМ»

«Мосфильм» киностудиясенең иҗат группасы Казан тирәсендәге авылларда һәм Аккош күле буенда ике айдан артыграк «Өч көн бәйрәм» исемле төсле нәфис фильм төшерү белән шөгыльләнде. Мәскәүдә яшәүче кинодраматург Роза Хөснетдинова сценариясе буенча төшерелә торган бу фильмдагы вакыйгалар бүгенге татар авылында бара, бөтен персонажлар да — татарлар, бәйрәме дә — татар сабан туе. Шуңа күрә фильмның режиссеры Марк Осепьян фильмны төшерү өчен хәзерге заман татар авылларын, Татарстанның кабатланмас пейзажын сайлап алган.

Тамашачылар ирле-хатынлы Әлфия һәм Раил, Нәзирә һәм Рим белән, Хәнифә карчык белән, Хәмзә һәм Бакый кебек авыл кешеләре белән танышачаклар. Фильм туган җиргә, халыкның изге гореф-гадәтләренә турылыклы булырга чакыра, кеше күңеленең иң тирән катламнарын ачып сала.

## ЭКРАНДА — «САЗ» АНСАМБЛЕ

Күптән түгел Ленинград кино документалистлары киң экранлы, төсле музыкаль фильм төшерделәр. Бу фильм Россия Федерациясенең 30 га якын иң яхшы үзешчән сәнгать коллективлары турында сөйли. Алар арасында Казаннан «Саз» халык ансамбле (художество җитәкчесе — Татарстанның атказанган культура работнигы Рәфкать Гомәров) дә бар.

Бөек Октябрьның 60 еллыгы алдыннан Ленинград кинематографистларының иҗат группасы Казанның В. В. Куйбышев исемендәге химия заводында булды. Чөнки «Саз» ансамбле членнарының күбесе шул заводтан. Бирегә фильмның режиссеры һәм сценарий авторы В. Гранин һәм операторлар ансамбль членнарының эш урыннары белән таныштылар, кино тасмага төрле эпизодларны төшереп алдылар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Совет сынлы сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен РСФСР художество фондының Татарстан бүлекчәсе рәссамы Андрей Лаврентьевич Прокопьевка Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде.

## ХЕЗМӘТКӘ ХӨРМӘТ

Озак еллар күрсәткән фәнни-практик һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен һәм 60 яшь тулу уңаеннан СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының сәнгать секторы мөдире **Фәтхелбаян Нурлыгаянович Гыйззәтуллин (Бәян Гыйззәт) Татарстан өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының** Почет грамотасы белән бүләкләнде.

# ХӘСӘН САРЬЯН



Шушы елның 21 сентябрендә татар совет язучысы Хәсән Сарьян кинәт вафат булды.

Сарьян Салихҗан улы Хәсәнов 1930 елның 24 мартында Башкортстанның Илеш районы, Иске Аю авылында туа. Ул егет чакта ук туган авылында колхозчы, клуб мөдире булып эшли. 1951 елда Бөре педагогия училищесын тәмамлап, Башкорт педагогия институтына укырга керә. Аны уңышлы тәмамлаганнан соң шунда ук тел һәм әдәбият укыта. Хәсән Сарьян «Кызыл таң», «Совет Башкортстаны» газеталарында, «Һәнәк», «Азат хатын» журналларында әдәби бүлекләрне алып бара. 1964 елда ул — СССР Литфондының Татарстан бүлеге директоры. Ул озак еллар Татарстан Язучылар союзы каршындагы проза секциясен җитәкләде. Хәсән Сарьян яшь язучылар өчен оста киңәшче, әйбәт дус иде.

1962 елдан башлап аның берничә хикәяләр җыентыгы басылып чыга. 1967 елда ул СССР Язучылар союзы члены. Аның беренче чор иҗатында балалар өчен язылган әсәрләр күп урын алып тора. Үз сәләтенә иҗат мәйданын ул хикәяче булып таба. Әмма Хәсән Сарьянга аеруча уңыш китергән әсәрләре — «Эткәм һөнәре», «Бер ананың биш улы» повестьлары. Алар татар совет әдәбиятына лаеклы өлеш булып керделәр.

Шул ук вакытта ул тел галиме дә иде, бу өлкәдә күп кенә гыйльми эшләр башкарды. Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзүдә катнашты, тел һәм стиль мәсьәләләренә кагылган китаплар бастырды, радиодан тел мәсьәләләренә багышланган күп санлы әңгәмәләр алып барды.

Хәсән Сарьянның повесть, хикәяләрендәге лиризм, җылылык укучыларга күчә. Аның әсәрләрендәге геройлар изге ният, якты омтылыш, югары идеаллар белән янып яшиләр.

Хәсән Сарьянның әсәрләре рус, мари, удмурт, башкорт телләренә тәрҗемә ителде. Ул кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» повестен татарчага тәрҗемә итте.

Хәсән Сарьянның исеме татар совет әдәбияты тарихында якты сәхифә булып сакланыр.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Сезне елның соңгы ае — 12 нче сан белән таныштырабыз.

Журналыбызның бу саны Кояш Тимбикованың «Агым уртасында» дигән повесте белән ачылачак. Повесть КамАЗ төзүче яшьләр тормышыннан язылган. Мөсәгыйть Хәбибуллинның «Туй балдагы» дигән озын хикәясе дә шушы ук санда чыгачак. «Замандаш» конкурсына Шамил Бикчурин «Рекомендация» дигән хикәя белән катнаша.

Татарстан Язучылар союзы апрель аенда яшь язучыларның Арча конференциясен үткәргән иде. Журналыбыз шунда катнашкан Ш. Маннапов, Р. Хәлиуллина, Н. Габбасов һәм Ф. Мәүлетовның шигырьләрен тәкъдим итә. Шагыйрь Рөстәм Мингалимов шигырьләре дә поэзия сөючеләрнең игътибарын җәлеп итәр.

Илебезнең күренекле язучысы Чыңгыз Айтматовка декабрьда 50 яшь тула. Шул уңай белән аның «Әйләнеп кошлар кайтканчы» дигән повесте тәрҗемә ителеп басыла. Повестьны язучы, галим Миркасыйм Госманов тәрҗемә итте. Өлкән шагыйребез Нури Арсланов тәрҗемәсендә А. С. Пушкин шигырьләре бирелә.

Очерклар бүлеге егерме алты Баку комиссарының берсе — якташыбыз Иван Габишев турында сөйли. И. Хәбибнең Муса Җәлил турындагы истәлеге дә шушы ук санда басыла.

Декабрь аенда Шамил Усмановның тууына 80 ел тула. Бу датаны журналыбыз А. Яхин, М. Маннурова мәкаләләре һәм Ш. Усмановның «Беренче адым» дигән материалы белән билгеләп үтә.

Күренекле галим Г. Алпаровның тууына 90 ел тулу уңае белән М. Мөхәммәдиевнең «Фәнни кыюлык» дигән мәкаләсе басыла.

Күренекле драматург Хәй Вахитның тууына 60 ел тулган көнгә карата «Хәй Вахит һәм аның геройлары» дигән мәкалә бирелә. Авторы — театр тәнкыйтьчесе Баян Гыйззәт.

Моннан тыш бүгенге поэзия турында сөйләшүгә караган мәкаләләр, яңа китапларга рецензияләр, халык иҗаты, укучылардан килгән хатлар, юмор-сатира әсәрләре һәм әдәбият-сәнгать яңалыклары бирелә.

Хөрмәтле укучыбыз!

1979 елга газета-журналларга язылу тәмамланып килә. Журналыбызның даими укучысы буларак Сез алдагы елга да «Казан утлары» журналына язылгансыздыр дип өметләнәбез.

Әлегә кадәр өлгермәгән булсагыз, исегезгә төшерәбез: «Почет билгесе» орденлы «Казан утлары» журналы Бөтенсоюз каталогына кертелгән. Димәк, аңа Советлар иленең барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин.

Журналның индексы 73210.

Язылу бәясе — елга 6 сум.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210